

# Казан утлары

12.1985



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922- ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

12

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

И. САЛАХОВ. **Иманнар тамыр җәйгәндә.** Тарихи роман . . . 3

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Җ. МУЛДАГАЛИЕВ. Күңел ташы. Шигырьләр . . . 89
С. МӘУЛЕНОВ. **Уйлану.** *Шигырь* . . . 90
Г. КАИРБӘКОВ. **Бодай бөртеге.** *Шигырьләр* . . . 90
У. БҮКИЕВ. **Ялгыз аучы.** *Повесть* . . . 91
Ш. МУРТАЗАЕВ. **Чикерткә җыры.** *Хикәя* . . . 112

М. АКЧУРИН. **Тын йокыга чумган йолдызлыклар...** *Шигырьләр* . . . 116
З. МАНСУРОВ. **Кылдан нечкә, кылычтан үткен.** *Поэма* . . . 119
М. ХӨСӘЕН. **Җинүче каһарманга.** *Шигырьләр* . . . 135
Р. РӘКЫЙПОВ. **Минем Ватан...** *Шигырьләр* . . . 136
Н. ӘХМӘДИЕВ. **Кышкы учак.** *Шигырьләр* . . . 137
Х. ХӨСНУЛЛИН. **Алтынчы автобус бара.** *Шигырьләр* . . . 138
Г. МӨХӘММӘТШИН. **Офыкларым.** *Шигырьләр* . . . 139
С. МУЛЛАГАЛИЕВ. **Ничек дөнья суынсын.** *Шигырь* . . . 139

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. **Уральскида Тукай урыннары** . . . 140
С. АКБИЕВ. **Габдулла Тукай һәм Дагстан халыклары әдәбияты** . . . 141

ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Ф. ӘМИРХАНОВ. **Минем тормыш юлым** . . . 145
А. ХИСАМОВ. **Хакыйкатькә юл ярганда** . . . 147
Э. ГОБӘЙДУЛЛИНА. **Уртак уйлар** . . . 151
Р. ӘМИРХАНОВ. **Фатих Әмирхан ядкаре** . . . 153
Р. ГАИСИН. **Бер сюжетның сере** . . . 154

В. ХЛЕБНИКОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

М. ШАБАЕВ. **Шигъри материклар Колумбы** . . . 157

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63

ЯЗУЧЫ СӘЯХӘТТӘН КАЙТТЫ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Чаңны кем дип кагалар . . . 159

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Н. Ф. ВӘЛИЕВ. Җырлы як . . . . . . . . 169

Тат АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

К. ТИМБИКОВА. Ут кирәк, ут! . . . . . . . . 171

БИБЛИОГРАФИЯ

М. НАДЖАФОВ. Традицияләр яңарганда . . . 175
Н. ЮЗИЕВ. Тынгысыз рухлы китап . . . . . 176

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

Д. ГЫЙСМЕТДИНОВ. Оят түгелме? *Хикәяләр* . 180
Җ. ТОКУМАЕВ. Кем алдакчы. *Хикәя* . . . . . 182

Кызыклы хәлләр . . . . . . . . . . . 183

«Казан утлары»нда 1985 елда басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . . . . . . . . 184

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

В рубрике «Дружба литератур — дружба народов» произведения казахских писателей: повесть У. БОКИЕВА «Одинокий охотник», рассказ Ш. МУРТАЗАЕВА, стихи Ж. МУЛДАГАЛИЕВА, С. МАУЛЕНОВА, Г. КАИРБЕКОВА.
Исторический роман И. САЛАХОВА «Когда дубы распускают корни» (окончание). Поэма З. МАНСУРОВА. Стихи М. АКЧУРИНА, М. ХУСАИНА, Р. РАКИПОВА, Н. АХМАДИЕВА, Х. ХУСНУЛЛИНА, Г. МУХАМЕТШИНА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА.
К 100-летию Г. Тукая: статья С. АКБИЕВА «Габдулла Тукай и литература народов Дагестана», рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске».
К 100-летию Фатыха Амирхана: статьи А. ХИСАМОВА, Э. ГУБАЙДУЛЛИНОЙ, Р. ГАИСИНА, новые публикации.
К 100-летию русского поэта В. Хлебникова: статья М. ШАБАЕВА.
Статья-эссе Р. МУХАМАДЕЕВА о личности и творчестве Э. Хемингуэя.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Сармановского райкома КПСС Н. Ф. ВАЛЕЕВА.
«Литературный пост — Тат.АЭС»: очерк К. ТИМБИКОВОЙ.
В рубрике «Библиография» рецензируются книга Г. Валеевой-Сулеймановой «Монументально-декоративное искусство советского Татарстана» и сборник литературно-критических статей Ф. Миннуллина.
В рубрике «За трезвый образ жизни»: юморески Д. ГИСМЕТДИНОВА и Ж. ТОКУМАЕВА.
На нашей обложке — творчество художника Р. НУРМУХАМЕДОВА.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар А. Садыйкова. Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 09.10.1985 ел. Басарга кул куелды 27.11.1985 ел. ПФ 05361. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8)
Тираж 64049. Заказ Ф-435. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

# Ибраһим Салахов

# ИМӘННӘР ТАМЫР ҖӘЙГӘНДӘ

ТАРИХИ РОМАН

18



Өч көн, өч төн Имәнтау станицасы керфек какмады. Урамнарда җыр чайкалды. Гармун иңрәде. Капка алларында, инеш буйларында, урам урталарында казаклар, казачкалар бер-берсен кочаклап, үбеп, ялап, елап, сүгенеп, бер-берсен каядыр чакырып тартыштылар, аудылар һәм шунда ук йоклап киттеләр — төш күрделәр, суганлап-борычлап «япошка»ларны сүктеләр, атакага ташланырга чакырып акырдылар.

Әле үткән кыш кына станицадан беренче разряд казаклар алынып, эшелон озатылгач, станица бушап-тоныкланып калган кебек иде. Инде менә калганнарны, икенче разрядларны, яшьләрне кырып-себереп, икенче эшелонга озатырга боерык килде. Станицада ир затыннан кем генә кала соң?..

Өр-яңа формалар кигән, көяз чәч бөдрәләрен фуражкага сыйдырып бетерә алмаган, итекләрен көзге кебек ялтыраткан мыеклы-мыексыз, сакаллы-сакалсыз казаклар, аллы-гөлле күлмәкләргә, яулык-шәлләргә төренгән казачкалар, бүген барысы да тигез булып, бар тавышларына кычкырып җырладылар.

Ой да, возвеселитесь храбрые казаки,
Ой да, честью-славою... Славою своей.
Ой да, покажите всем друзьям примеры,
Ой да, как из ружья ты бил своих врагов.

Бу җыр инеш аръягында яңгырый.

Урман буеннан бер төркем татар егетләре төшеп киләләр, алар да җырлый.

Ком бураны, ком бураны,
Имәнтауның урамы.
Үсеп буйга җиткәч кенә
Без күрәбез нужаны.

Бу җыр сүнеп бетми, Баһау белән Госман, ике дус, әле генә Порт-Артурдан Җәфрәтил бабайның улы Халюктан килгән хат эчендәге күчтәнәч җырны кушып җибәрәләр.

Пыртартур таш кала,
Күп калага баш кала.
Пыртартурның сопкасында
Безнең газиз баш кала.

---

Ахыры. Башы 11 нче санда.

Жыр очланып бетәр-бетмәстә арттагы рәттәге егетләр кумәкләп кушымта өстиләр:

Пыртартур ут яна!
Казак үлемгә бара!

Казантау артыннан акрын гына тонык ай күтәрелә. Ерак офыктагы алсу учаклар сүнә. Күктә — тау өстендә, бер-бер артлы шәмдәлләр кабына. Төн килә. Йомшак, жылы көмеш нурларга төренгән серле һәм тантаналы төн. Таулар, кара күләгә булып, даладагы ялгыз курган өстенә кунып, кара-кучкыл канатларын киң җәйгән мәһабәт бөркет булып йокымсырый. Гүя, бөтен җиһанда менә шундый изге тынлык. Әйтерсең лә, җирдә хәзер ут-снаряд яңгыры астында калып, дөрләп янган, иңрәгән канлы Порт-Артур да, кургашын суларга билдән батып авыр, дәһшәтле муеннарын рус җиренә сузган, ут-үлем яудырган япон крейсерлары, дредноутлары, эсминецлары да юк. Маньчжурия сопкаларында атакага ташланучы себер казак эшелоннары да юк. Кан. Үлем. Каргыш. Ләгънәтләр. Ялвару. Дога. Өмет. Иң әшәке сүзләр белән сүгенү. Берсе дә, берсе дә юк кебек...

Әмма...

Станицаның ике очында да жыр, гармунга кушылып балалайка елый.

Ә ызбаларда? Ызбаларда мәхшәр! Кайда чыра, кайда шәм, кайда майшәм, кайда өчле-җиделе лампа яна. Елау, сыктау һәм ашыгу — юу, ямау, тегү, мичкә күмәч салу, мич башында сохари киптерү. Ә абзарларда? Йөзләренә үлек төсе кергән, көрәк сакаллы станичниклар абзарлардан күшәп торган соңгы сыерны, соңгы тананы, соңгы үгезне алып чыга. Буралардагы соңгы ашлыкны кырып-себереп капчыкларга тутыра. Куллар дерелди, күзләр томанлы. Арбаларга капчык төяләр, арбаларга мал бәйлиләр. Чөнки — сугыш! Сугышка казак кирәк! Казакка ат кирәк, ияр-тукым, кием-салым кирәк![1] Һәм олаулар күпер башындагы таш кибеткә юнәләләр. Анда Кәлимулла, улы Галимулла белән, малны санап, ашлыкны үлчәп өлгерә алмыйлар.

Менә нинди бит ул фани дөнья!

Әле кайчан гына үр итәгендәге карт драбандның җиргә сеңеп барган өе яктырып киткән иде. Җәфрәтил картның да, кызы Әминәнең дә йөзләре ачылып, сүзе күбәеп, күңелләре эреп, сөенечләре култыкларына сыймый башлаган иде... Басудагы өч дисәтинә яшел хәтфә булып шыткан. Ул көннән-көн күтәрелә, кыяк җибәрә. Димәк, кышка азык мул буласы. Бәлки әле бер тана яки үгез алырга арттырып та булыр. Инде аларның ышанычлары, таянычлары — Госман бар. Ул инде ир-егет. Бәлки аны башлы-күзле итәргә дә җай булыр?! (Бу урында Әминә эчтән генә уйлап сөенеп куя). Ана инде станицаның барлык җиткән кызларын күңеле аша уздырып улына кәләш сайлый!

Һич уйламаганда бөтен өметләр чәлпәрәмә килде — әле өлгермәгән, яшелләнеп кенә утырган ашлыкның яртысы Кәлимуллага закладка салынды. Госманга обмундирование кирәк. Кирәген кирәк, ә үзләренә ни кала?

Әминә чыра яктысында улының күлмәк-ыштаннарын ямый, ә бармак очлары кан...

— Я раббым, я раббым! Үзең сакла. Рәхим-шәфкатеңнән ташлама. Улым Госманның газиз башын чит-ят җирләрдә калдырма, тәңрем!

Чыра янып бетеп сүнә.
Ызба эчендә дөм караңгы.
Ә ана күңелендә — ут.

Абзарда майшәм яктысында карт драбанд оныгының ияр-тукымын тикшерә, тегә, бәйли, майлый. Казакның ияр-тукымы аты кебек үк нык, ышанычлы булырга тиеш. Чөнки аның язмышы, выты, шушы бил, өзәңге

[1] Службага барганда казак үз хисабына түбәндәгеләрне алырга тиеш була: ат, ияр, шашка, ике пар итек, өч пар күлмәк-ыштан, ике шинель, ике фуражка, папаха, өч пар пирчаткә һәм башка поход кирәк-яраклары. (Биредә һәм алга таба да — автор искәртмәләре)

каешларында. Тырыша Җәфрәтил, һәрбер җөйне, бәйләүне күзеннән үткәрә...

Ә Госман үзе кайда соң? Алар егетләр белән тау өстендә утыралар. Берәүләр басып тора, берәүләр сузылып яткан, күпчелек утырган. Күзләр күгелҗем сөремгә төрелгән туган җиргә төбәлгән. Гармунчы Хабуш, озын буйлы арык егет, станицага карап басып торды да кинәт, берәү чалгы белән чалып калгандай, авып китте, җиргә капланып үксеп елый башлады. Госман, егет кешенең елау тавышын ишетеп, шомланып, тетрәнеп китте.

Талгын гына җил исте, кайдадыр еракта иренеп кенә эт өрде, атлар кешнәде.

Карый торгач, төн эчендәге күләгәләр төсмерләнә башлады. Әнә, инеш яры өстендә такта канатларын тырпайткан тегермән. Түбәнрәк озыннан-озынга сузылган правление амбарлары. Аларга каршы бирге очта ялгыз ызба. Ызбаның тегермән якка караган бердәнбер карындык тәрәзәсендә тычкан күзе хәтле генә ут җемелди.

Димәк, йокламый.

Димәк, утыра. Улының сугышка киеп китәсе киемнәрен хәстәрли. Нәкъ шушы минутта Госманның артыннан кемдер төртеп җибәргән кебек булды. Борылып караса, беркем дә юк. Алай да аны кузгалырга әмер итеп аңлады, кайтырга вакыт җиткәнен чамалады. Иптәшләре белән хушлашты да үр итәгендәге ялгыз ызбага, уты җемелдәгән ялгыз тәрәзәгә ашыкты ул.

Сукмак тегермән яныннан уза, шул чагында каршыга килүче бер шәүлә шәйләнде.

— Усманка!

Күләгә якынлашты. Туктады, пышылдады. Инде бераздан килүче йөгереп килеп Госманны кочаклап алды.

— Усманка!

Тегермән канатлары әйләнде. Йолдызлар чәчелде. Госманның иреннәре янып-көеп китте...

Әллә инде бала чактан ук станицадан җәһәннәмгә олагып китеп йөрүләр юаш иттеме аны? Әллә инде күтәрелер-күтәрелмәстә башка гел төшеп торган нужа тукмагы иләс-миләс иттеме, әллә инде?.. Кем белсен! Ни булса да булды, Госман үз кордашлары кебек кызлар кочагына юл тапмады — кич утырулар, кунак кызлар күзләү, куна керүләр берсе дә аңа насыйп булмады. Шуның өчен ул әле бүгенгә кадәр мәхәббәт дигән изге утта янмады да, көймәде дә...

Ә шулай да йөрәкнең әллә кайсы бер төшендә нәни генә нур җемелди иде. Сагышлар басканда ул нур башын калкыта, ыграк яктырта. Сыгыла башлаган гәүдә кинәт тураеп китә, күңел ярсып алга омтыла... Ерак Төрек чүлләрендә, Кара диңгез штормнарында, Кытай җирләрендә хәлдән тайганда бу нур аны җитәкләде, хәл кертте һәм өметләндерде. Чакырды! Госман гомере буе шул тавышка ашыкты, әмма станицага кайткач үзен-үзе тыйды, күңел серен беркемгә дә белдермәде, ул турыда һич кайчан да сөйләшмәде. Чөнки ара бик ерак, аерма бик зур иде. Күңел ни теләмәс, шуның өчен «нәфес — шайтан!» диләр бит. Кая үреләсең син, имансыз! Атаман кызы, чибәр-сылу Маша сиңа тиңмени?! Нигә үз буеңа карап үрелмисең, йолкыш?!

Һәм менә бүләккә кайнар, саф иреннәр. Көйдерәләр һәм рәхәт исертәләр. Егет бу могҗизалы уттан эреп киткәндәй булды...

Бераздан алар, бер-берсенең кочагына кереп-сеңеп, тегермән артындагы куаклыкта утырдылар. Алар бер тән, бер җан булып, сүзсез-өнсез дә бер-берсен бик яхшы аңлап, бер-берсенең йөрәк тавышын тыңладылар...

Дөнья — син нинди гүзәл!
Төн — син нинди серле!
Яшьлек — син нинди татлы!

Бәлки, болар барысы да бер әкият кенәдер? Әгәр шулай икән, бу татлы минутлар мәңгелек әкият булып калсыннар иде!

— Усманка...— Маша кофта якасына кулын төшереп, күкрәк өстендә яшереп, саклап алып килгән бүләген алды һәм Госманга бирде.— Истәлегем. Онытма. Онытмаска...

Тагын кайнар иреннәр һәм дөньяның барлыгын оныттыра торган кайнар кочак. Ярты ай югарырак күтәрелде һәм егет кулындагы хушбуй исе килеп торган чигүле яулыкны яктыртты...

Степной край наказлы атаманның мобилизация турындагы приказы буенча, Горькая линиядәге барлык тугыз казачий полк, приказга кул куелуның өченче тәүлегендә, тулы хәрби снаряжениедә Акмула губернасының өяз шәһәре Күкчәтау җәйге өйрәнү лагерь мәйданына җыелырга һәм шуннан поход эшелоны белән Кызылъяр (Петропавловск) тимер юл станциясеннән фронтка кузгалырга тиешләр иде.

Ниһаять, приказда күрсәтелгән шомлы сәгатьләр якынлашты.

Чыклы, томанлы таңнан ук станица чиркәвенең барлык кыңгыраулары суга башлады. Станица дәррәү кузгалып, ыгы-зыгы килде. Сәгать унберләр тирәсендә мәйданда фронтка китүче казакларны озату мәрасиме башланды. Буш чагында бик киң күренә торган мәйдан бүген тап-тар, кысынкы булып калган. Китүчеләр сотня-сотня булып тигез рәтләргә тезелделәр. Атлар авызлыкларын чәйниләр, дагалы тояклары белән җир казып, баскан урыннарында тора алмыйлар. Казаклар исә тезгеннәрен нык тартып, башны югары чөеп, таш сыман хәрәкәтсез утыралар. Йөзләр чытык, каш-кабаклар салынган, күзләрдә ачу катыш сагыш. Рәтләрнең бирге ягында ашык-пошык кына, чи тактадан кагып-сугып эшләнгән киң һәм биек мөнбәр. Анда яшел бикасап чапан ябынган, башына кардай ак чалма ураган Сираҗетдин мулла басып тора. Аның янында кулларын кушырып, башларын түбән иеп ике карт баскан. Берсе яңа азанчы...

Кинәт, бөтен мәйданны сискәндереп, чиркәү чаңнары даң-доң килделәр. Шуны гына көтеп торгандай, стройның уң флангысында ут янып торган җиз быргылар кычкыра башлады. Поход сигналы яңгырагач, атлар баскан урыннарында тыпыр-тыпыр биеп, кузгалып очып китәргә омтылдылар. Чиркәүнең калын тимер ишеге ачылып китте. Шау-шу басылды. Мәйдандагы бар халык куркып һәм кызыксынып, аз гына үреләтөшеп, шул ачылган ишеккә төбәлде. Аннан эреле-ваклы иконалар тотып, калын бас белән дога укый-укый бер төркем руханилар чыкты. Алдан муенына калын чылбыр белән көмеш тәре аскан тек гәүдәле, һавалы архирей Мефодий ата килә. Аны бу гадәттән тыш вакыйга уңае белән ашыгыч рәвештә Күкчәтаудан барып алганнар. Аның артыннан хәл кадәренчә тантаналы киенгән, кайсы озын, кайсы тәбәнәк Имәнтау, Сандыктау, Аертау, Арык Балык станицаларыннан килгән поплар атлыйлар. Архирей, поход рәтләре алдында туктап, кулларын күккә күтәрде, поплар кадилоларын пыскытып аны урап алдылар. Ул арада шушы төркемгә зәңгәр укалы киемнәргә төренгән ике яшүсмер бала — оҗмах гыйлманнары түгәрәк көмеш савытларда мөлдерәмә тулы изге су күтәреп килеп бастылар. Тантаналы гыйбадәт — гөнаһлардан арындыру башланды. Эшкә беренче нәүбәттә атаман Роман Михайлович кереште, ул бөтен күкрәгенә киң итеп өч бармагы белән чукынды да, иелеп, архирей кулындагы көмеш тәрене һәм аның кулын үпте, шуның бәрабәренә туйганчы тотен исләде һәм изге суга чыланды. Аннан мәшәкать рәтләр буйлап китте. Архирей атларның ярсыганын, казакларның сабырсызлыгын күрмәгән сыман, бер дә ашыкмыйча рәтләр буйлап китте һәм сугышка

китәргә әзерләнгән гаскәрне изге су белән чылатып, изге төтен белән төсләп, аны «дошман пулясы тишмәс, дошман кылычы кисмәс» итте, ярдәмгә Гайсә пәйгамбәрне һәм күп санлы изгеләрне чакырды. Поплар исә бар тавышларына Инҗилдән сүрә укыдылар, остазларыннан калышмаска тырыштылар.

Кояш югары күтәрелде, җил бераздан тынды, мәйданда тымызык тынчу — тир исе, күн исе, деготь исе, өстәвенә изге ладан исе тынны кысты. Атлар да, кешеләр дә бу саваплы мәшәкатьтән шактый ялыктылар. Ниһаять, тантаналы гыйбадәт очланды. Ладаннарын яндырып, суларын түгеп бетереп, нәкъ чыккандагы рәвештә, сафка тезелеп поплар кире чиркәүгә кереп югалдылар. Чаң тагын даң-доң килеп алды.

Инде чират Сиражетдин муллага җитте, ул мөнбәр алдынарак килеп тамагын кырды да: кычкырып «Ясин» сүрәсен укырга кереште. Башта бераз каушаган иде, ни дисәң мәчеттә түгел, мәйданда, күп санлы руслар алдында укый аятен, бераздан ул үзен тынычландырды, көр, моңлы тавыш белән, иҗекләрен дөресләп, җиренә җиткереп укыды. Мәзин белән теге карт пышылдап аңа ярдәм итеп тордылар.

Мөнбәрнең сул ягында татар казаклары сотнясы тора иде. Стройның уң ягында җирән кашка атта сотня командиры кара сакаллы, кара мыеклы, тап-таза гәүдәле Мөхәммәтша — Госманның ахирәт дусты Баһауның атасы утыра. Ул бар ихласы белән бирелеп мулланы тыңлый, сотнядагы башка татарлар да, әллә инде командирларына ияреп, әллә инде чыннан да, коръән сүзләренең могҗизалы көченә ышанып, муллага мөкиббән бирелгәннәр, кайберәүләр хәтта иреннәрен кыймылдаталар, мулла әйткән кәләм шәрифне кабатлыйлар. Сотняның арткы сафында Госман белән Баһау янәшә торалар. Алар йөзендә дә сагыш сөреме, җитдилек. Бу китүдән әйләнеп кайта алырлармы алар?..

Мәйданның күпчелеге руслар булса да, мулла аять укыганда, көлү, үзара сөйләшү, шау-шу ишетелмәде. Руслар да, татарлар кебек үк, дога укылганда тирән тынлык сакладылар. Чөнки алар да, татарларның үзләре кебек үк, гарәп сүзләренең мәгънәсенә төшенмәсәләр дә, мулланың ходадан рус патшасына җиңү теләвен, казакларның сугыштан сау-сәламәт, дан белән станицага әйләнеп кайтуларын теләвен күңелләре белән сизәләр һәм нәкъ менә шуның өчен «дөнья сүзләрен» онытып, өмет белән тын гына иярләрендә оеп утыралар иде.

— Я тәңрем!..

Команда тавышы яңгырады. Кузгалдылар. Мәйданда бары тик карт-корылар, өч көн, өч төн елаудан хәлсезләнгән аналар, апа-сеңелләр генә калды. Хатыннар, кызлар, бала-чагалар җылап, кычкырып-чакырып солдатлар артыннан иярделәр. Җыр яңгырады:

Ай, казак по Иртышу гуляет, казак бравый, молодой,
Ай, он конем своим разъезжает по-над быстрою рекой...

Эшелон һаман ераклашты.
Җыр да тоныкланды, сүзләре аңлашылмас булды...

— Уф, алла!— Әминә башындагы яулыгын йолкып алып битенә каплады да тыенкы гына үксергә тотынды.

— Сабыр ит, кызым, сабыр!— Җәфрәтил карт кызын юатырга теләсә дә, үзенең дә ияге калтырый иде.— Выты, ялгыз без генә түгел. Мир белән. Мин дә төрекләргә каршы Госман кебек чагымда киттем. Аллага шөкер, кайттым. Ничек кенә әле, выты, Георгийлар белән, почет белән...

Госман артына борылып карады — үр өстендә хәлсезләнгән анасы, ә үр астында юлда Маша яулык болгый... Иң нык хәтердә калганы бүгенгә шул булды...

— Әйдә, кызым, укып җибәр әле братыңның бәетен, станишниклар тыңласын...

Мал-туар йөрмәгәнгә, Җәфрәтил картның киң ишегалды ямь-яшел чирәм. Бүген ул станичниклар белән тып-тулы. Мал көтүдән кайтып, сыер-кәҗәләр савылгач, станицаның татар очы — яше-карты монда җыелган. Чакырмыйча. Әйтмичә. «Җәфрәтил драбандка улы Халюк Пыртартурдан мөнәҗәт җибәргән, сугыш хәлләрен бәйнә-бәйнә язган»,— дигән хәбәр ызбадан-ызбага сугылды.

Менә бүген алар шул бәетне тыңларга җыелганнар. Үткән төндә яңгыр явып үткән иде, һава әле дә дымлы. Агачлар тузаннан арынып, үләннәр яшәреп калды. Хатын-кыз, бала-чага бер якка чәчелгән, икенче якка карт станичниклар тезелеп утырганнар да сөякчел бармаклары белән сакалларын «савалар». Барысының да йөзләре суык, карашлары чытык. Кашлар җыерылган.

— Алайса, башлыйм инде,— диде Әминә зәгыйфь тавыш белән. Ул түгәрәкләнеп килгән табынның уртасында зур бүкән өстендә утыра иде. Урынны көндез үк, «бәет тыңларга киләбез!» дигәнне ишетеп, Җәфрәтил карт әзерләп куйган иде.

Халык тынды, картларның куллары колак тирәсеннән урын алды: тыңларга әзерләнделәр. Башта тавыш бик көчсез, курка-каушый гына чыкты, аннан, укый торгач бераз ныгыды. Әминә бәетне «Бәдәвам» көе җаена укый иде.

Тугыз йөз дә дүртенчедә сугышырга башладык,
Сугышка дип хәбәр алгач, вольный кием ташладык.

Бу бәетне язамын, искә алсын туганнар,
Хәзерендә безләрне сугышларга куалар.

Уйлый-уйлый язамын, ниләр булды башыма?
Бар туганнар истән чыкмый, гел торалар каршымда.

Бу бәетне яздык без, нича казак җыелып,
Көне-төне җылаганга, бетте яшем коелып.

Кайсы ябышкан вагонга, кайсы егылып калган,
Япон дигән йөзе кара диңгезгә мина салган.

Февральнең дүртендә машинага утырдык,
Урыс гаскәрләре белән Кореяны тутырдык.

Кореяга барып кергәч, кытайларга катыштык,
Япошкалар каршы килгәч, көне-төне атыштык.

Бик солтанат, гаярь адәм,— Куропаткин генерал,
«Оружия, һоп!»— дип әйтеп, йөрәгемне яралар!

Барып кердек төнлә илә Сеул дигән калага,
Шәһәр эченә сыймагач, гаскәр чыкты далага.

Утыз алты көн булганда Порт-Артурга җиттек без,
Ашамыйча-эчмичә сугышырга киттек без.

Порт-Артурдан чыгып киттек апрельнең өчендә,
Биш йөз чакрым бардык без тугыз көннең эчендә.

Ялу суы буенда унсигез көн тордык без,
Йөзе кара японнарга мылтыкларны кордык без.

Ялу дигән су башына урыс чатыры корды,
Куроки, Ялуны чыгып, меңләп кешене кырды.

Ялу бозы өстендә түшләр белән шудык без,
Ялу суын чыгып киткәч, японнарны кудык без.

— Бәрәкалла, бәрәкалла! — диештеләр картлар. — Әйтәм бит, куалар дип! Укы-укы, кызым!

Маньчжурия җирендә аршын ярым кар булды,
Без атарга керешкәч, японнарга тар булды.

Кара төтен арасында, ут явадыр өсләргә,
Бу хәлләрне күрәсем кермәде бит төшләргә.

Ялу суын чыккан чакта суык алды тезләрне,
Япон дигән йөзе кара харап итте безләрне.

Мылтык төзәп торганда, килеп төште туп өскә,
Японнар туп атадыр безнең гаскәр күп төшкә.

Караңгы төн, ачы буран, ачып булмый күземне,
Эфисәрләр килеп суга «смирно!» дип үземне.

Биек-биек тауларга газап чигеп мендек без,
Ляоян дигән сугышка ничә кәррә кердек без.

Күлмәк-ыштан калмады тәннәремә ябырлык,
Монда йөргән адәмгә ходай бирсен сабырлык.

— Я алла, амин! Көлле мөэмин-мөселманнарга сабырлык бир, мәүләм...— дип Сираҗетдин мулла дога кылды. (Ул бераз соңгарак калып килгән иде). Аннары сәҗдәгә ятты. Халык упыр-тупыр килеп җиргә йөз орды. Берничә хатын кычкырып елап җибәрде. Халык сәҗдәдән торгач, Әминә укуын дәвам итте:

Башымдагы картузым иләк кебек тишелде,
Безнең туплар атканда биек таулар ишелде.

Японнар туп аталар, кирпечне ваталар,
Куропаткин гаскәрләре зекер әйтеп яталар.

Японнарның ашаганы үрдәк белән каз гына,
Моннан барган солдатларга сохари да аз гына.

Порт-Артурның арт ягыннан японнар туп аталар,
Бомбалары бигрәк көчле, Порт-Артурны ваталар.

Су эчәсем килгәчтин ятып эчтем улактан,
Очып-очып пуля китә, выж-выж итеп колактан.

Кара төтен арасында ничә көннәр орыштык:
Японнарның меңләбенә йөзләребез тырыштык.

Төрле кеше уйлаганча, төрле сүзләр куелды,
Бу хәлләрне күрүе безгә авыр тоелды.

Һәркаюмыз яздык без баштан үткән эшләрне,
Сүзләремне тикшермәгез, пуля алды тешләрне,
Туп тавышы яман икән, шакырдатты тешләрне...

Җәфрәтил драбандның ишек алдыннан халык таралганда инде күктә ай күтәрелгән иде. Карчык-корчыклар сугыш хәлләрен тыңлаганнан соң мышык-мышык елашалар иде...

## 20

Ниһаять, чатлама суыклар, күз ачкысыз бураннар, ат-чана күмелеп китәрлек көртләр белән, елап җуелмас кара кайгылар, акланмас өметләр белән, канга һәм күз яшьләренә манылган Яңа ел — 1905 нче ел башланды.

Бу ел табигатьтә, һава торышында гына түгел, Бөек рус империясенең җәмгыять төзелешендә дә, язмышында да аеруча фаҗигалы, куркы-

нычлы һәм шул ук вакытта моңа кадәр һич көтелмәгән, уйланылмаган искиткеч тетрәнүләр, чайкалулар да тудырды. Империя океан киңлегендә тайфунга очраган кораб төсле җилкәннәрен киереп чайкалды, асты өстенә килде.

Икенче январьда Порт-Артур крепостеның гарнизон командиры генерал Стессель (гарнизонның героик оборонасын инкарь итеп, аның теләгенә каршы төшеп!) япон командованиесе алдында тез чүкте, хурлыклы рәвештә, сугышсыз-нисез крепостьны японнарга тапшырды.

Тугызынчы январьда, якшәмбе көнне, йөз илле меңнән артык Санкт-Петербург эшчеләре, тәреләр, иконалар, падишаһ Николай II нең портретларын күтәреп, авыр язмышларыннан, түзә алмаслык хәлләрен аз гына булса да җиңеләйтүне сорап, император галиҗанәбләре исеменә язылган петицияне тапшыру өчен, поп Гапон җитәкчелегендә, дога-мөнәҗәтләр укып, ышанып Кышкы сарайга таба юнәләләр. Әмма барып җитә алмыйлар, Сарай мәйданында, коты очкан патша боерыгын үтәп, халыкны көтеп әзерләнеп торган гвардеецлар, коралсыз тыныч демонстрантларга ут ачалар. Меңнән артык кеше үлә, бернича мең кеше яралана. Күпме кешенең күңел ярасы алуын санап бетереп буламыни?!

Март аенда Мукден (Шаньянь) каласы янында рус-япон җир гаскәрләренең соңгы каты бәрелеше була. Рус гаскәрләренең японнарга каршы торырлык, өстенлек алырлык мөмкинлеге булуга карамастан, генерал Куропаткин үз армиясенә чигенергә приказ бирә.

Апрель аенда Лондонда РСДРПның III съезды ачыла.

27—28 нче майда Цусима бугазында японнар Россиянең адмирал Рождественский командасындагы II эскадрасын тулаем тар-мар итәләр. 14 июньдә Кара диңгездә «Князь Потемкин-Таврический» броненосецы матрослары баш күтәреп, теңкәләренә тиеп җәфалаган явыз офицерларны үтереп борт аркылы ташлап, корабта кызыл байрак күтәрәләр.

5 сентябрьдә Портсмут шәһәрендә Россия белән Япония арасында сугышны туктату турында солых договорына кул куела. Бу договор шартлары буенча: Квантун аренда өлкәсе, Порт-Артур, Дальний портлары, Кытай-Көнчыгыш тимер юлының көньяк тармагы, Сахалин утравының яртысы — көньягы — японнар кулына күчә. Әсир төшкән рус солдатларын асраган японнарга Россия контрибуция түли һәм Япония моннан соң рус территориаль суларында тоткарлыксыз балык тоту хокукын ала! Япония Кореяны үзенең протектораты дип игълан итә!

Октябрь аенда Мәскәү, Петербург һәм Россиянең башка промышленность үзәкләрендә бер миллион җиде йөз илле меңнән артык эшче политик хокуклар, экономик шартларны яхшырту, сигез сәгатьлек эш көненә күчү турында катгый таләпләр куеп эш ташлыйлар.

17 октябрьдә падишаһ Николай II халыкка политик хокуклар бирү һәм законнар чыгару-тәкъдим итү өчен Дәүләт думасын чакыру турындагы манифестка кул куя.

Ноябрь аенда Россиядә беренче легаль большевиклар газетасы «Новая жизнь» басылып чыга башлый.

Ноябрь аенда Владимир Ильич Ленин эмиграциядән кайтып, Россиядәге большевиклар оешмасы белән җитәкчелек эшенә керешә.

Бу елда эшчеләрнең стачка, забастовкалары белән беррәттән, алпавытлар, боярлар, дворяннарның кансыз-комсыз җәберләүләренә түземнәре беткән ярлы крестьяннар, батраклар көрәшкә кузгалалар, боярларның йорт-җирләрен яндыралар, кулга төшкәннәрен үтерәләр, җирләрен тартып алып үзләре иген чәчә башлыйлар. Бу хәрәкәт бигрәк тә Урта Россиядә, Идел буенда, Украина, Кавказ якларында киң колач җәя.

Октябрь-ноябрь айларында Россиядә милли азатлык өчен көрәш көчәя, бигрәк тә Польшада, Финляндиядә көрәш кискен төс ала. 4 ноябрьдә Николай II Финляндиягә политик автономия бирү турындагы манифестка кул куя.

Бу елда Россиядәге төрле милләтләр телендә (шул уңайдан татар телендә!) күп санлы газета-журналлар басылып тарала башлый. Һәвәскәр театрлар оеша, җәдиди мәктәпләр ачыла. Әдәби кичәләр, спектакльләр күрсәтелә һәм беренче «яшерен язмалар уку» түгәрәкләре барлыкка килә.

Россия уяна! Халыклар төрмәсендәге милләтләр уяна! Россия яраланган юлбарыс сыман ачу һәм гайрәт белән күтәрелә.

## 21

1905 нче ел!

Ил кайнады, тулып ташыды, янды, бугазга-бугаз килде, богаулар белән чыңлады, көрәшкә күтәрелде, егылды, җиңде, җиңелде. Дәһшәтле һәм тантаналы Бишенче ел! Ә менә бик еракта, казак даласында каңгырып калган Имәнтау станицасында әллә ни үзгәреш сизелмәде, шаушуларның шаукымы соңарып, анда да бик йомшап, зәгыйфьләнеп кенә барып җитте.

Бүген тагын кар ява. Иртәдән бирле, ашыкмыйча гына ява да ява. Ябалак кар. Алар берсе артыннан берсе чайкалып, ак канатларын салмак кына җилпеп төшәләр дә ак күбек булып һаман куперәләр, һаман калка баралар. Урамнар, тыкрыклар, ызбалар, каралты түбәләре, кыеклар, хәтта кое колгалары, кара-кучкыл таҗлы карагайлар һәм мәһабәт Казантау агарды, мамыкланды — куян тиресе ябынды.

Урамда бер кеше, бер хайван заты, йөгереп үткән бер бала-чага күренми, әллә посканнар, әллә инде бөтенләй юклар. Хәер, инде бу станицаның татар казаклары тора торган очында күп кенә ызбалар үткән көздән үк буш. Моржалардан төтен күтәрелми, ишек-тәрәзәләр аркылыторкылы такталар белән кадакланган, җил капкалар төбенә чаклы каерылган. Бары тик хуҗасыз калган эт-мәчеләр генә, ара-тирә, тавыш биреп куялар, мияулыйлар, мыраулыйлар, шыңшыйлар. Беренче, икенче эшелон белән сугышка киткән казакларның күбесе кайтмады, алар тагын да еракта, Маньчжурия җирләрендә үзләренә соңгы салкын ятак таптылар... Монда калган карт-коры, хатын-кыз, бала-чага, игеннәрне боз сугып тәмам өметләрне өзгәч, җан саклар өчен, төрлесе-төрле якка таралдылар. Бераз эшкә яраганнар Күкчәтау байларына, казак-урыс офицерларына малайлыкка, ялчылыкка яллandылар. Ә калганнар: «Яндык... Пужарда харап булдык... Барча дөньябыз янды!»— дип, шаһитлыкка кисәү тәртәле куларбалар тартып, казак авылларында, баерак кышлауларда хәер сорашалар.

Йокымсыраган ак чаршау кинәт чайкалып киткәндәй булды. Һава дерелдәде! Кыңгырау тавышы! Ул якынлашканнан-якынлаша бара һәм станицаның һәрбер йортына рөхсәтсез орына. Пар кыңгырау, җиз кыңгырау тавышы. Ул Күкчәтау үре ягыннан ярсып чәчри. Озакламый ак тузан туздырып, станица урамына пар җирән килеп керде. Ишекләр ачылды, капкалар шыгырдады, правление йортына җитәрәк, атлар туктартуктамаста гөмбәзле өсле кашевкадан башлык кигән шинельле кеше очып сикереп төште. Ишек ялт кына ачылды, һәм эчтән атаманның гөбедән чыккандай калын тавышы яңгырады.

— Господин есаул! Ба-а, кемне күрәм!

Есаул, шпорларын чыңлатып, атаманның кочагына ташланды.

Сотник Мөхәммәтшаның улы Баһау иде бу көяз есаул. Баш югары күтәрелгән, күкрәк киерелгән, аз гына камыт аяклар өзеп-өзеп атлый. Ә түштә... Түштә ике Георгий кресты!..

Менә шулай кайтып төште Госманның дусты Баһаветдин. Кайтуы белән бер шаккатырды станицаны, тагын бер эше белән бөтен тирә-якны шаулатты. Башта моңа берәү дә ышанмады. «Куык очырасың!»— дип,

сөйләүчеләрнең авызын ябарга маташтылар. «Шартлаталар, беравык борчагы кибеп җитмәгәнрәк күренә»,— дип ха-халап көлештеләр. Чыннан да, ышанырлык хәбәр түгел иде бу!..

Имеш, кыраубаш Мөхәммәтшаның улы Баһаветдин (Госманның яшьлек дусты, хәтерегездәме?!), станицаның беренче бае дөкәнче Кәлимулланың бердәнбер кызы — йөзек кашы төсле нәфис Хупҗамалны көпәкөндез, артык шау-шусыз гына кәләшлеккә алсын, ди! Әле алганда да ничек, чистый әкәмәт, имәнтаулылар мондый буш куык өрдерүгә һич тә ышанмадылар, ышана алмадылар, билгеле...

Әмма туй, станица ярлы-ябагаларының төшенә дә керә алмаслык туй — соңга кадәр шикләнгән, «булмас!» дип кызып-кызып бәхәсләшкәннәрнең дә сүзенә чик куйды. Туй гаҗәп иде. Тирә-юньдәге бәхетсезлекләр, ачлык-ялангачлык бөтенләй юк кебек иде ул көнне Имәнтауда!

Пар аргамаклар иртәдән алып тирә-юнь станицалардан байларны, хаҗиларны, кибет хуҗаларын, хәзрәтләрне ташыдылар. Кәлимулла эшне тиз тотты, шаһитләр кызның ризалыгын игълан итеп бетерүгә, хәзрәт аңа карап соңгы мөһим сорауны бирде:

— Мөхтәрәм мулла Кәлимулла, газиз фәрзәнтегез Хәйрел Хупҗамалны Мөхәммәтшаһ угылы Баһаветдингә хәлал җефетлеккә үзеннең ризалык илә бирәсеңме?..

Бу сорауга Кәлимулла башын да күтәрмичә, төксе генә, ашыгаашыга:

— Бирәм, бирәм,— диде.

Дәстәрхан әйләнәсендә гыгызланган кунаклар бер-берсенә карашып, нигәдер башларын чайкап алдылар. Хәзрәт аларны күрмәмешкә салышып, ике кулын канатландырып дога укырга кереште.

Бераздан хәзрәт яңгыравыклы тавыш белән никах догасын укый башлады...

Мәҗлескә күзләрне нурландырып, нәфесне котыртып әнваг-әнваг нигъмәтләр килде.

Бәхет ташыды...

Бәхет түгелде...

Гармун, скрипка, җыр-бию Кәлимулланың өен асты-өстенә китерде. Бу гаҗәеп туйның икенче көнендә (туйның нәкъ өстенә туры килә язды!) бәхетле кияү Баһаветдиннең ахирәт дусты Госман да кайтып төште. Ике култык астында шомарырга да өлгермәгән ике култык таяк... Күкрәктә ике көмеш тәре... Өс-баш шактый кыршылган... Әминә елап, сөенеп, улының кочагына ташланды. Карт драбанйның тагын да ныграк җиргә иңгән караңгы ызбасы яктырып китте, ул Госманның бүләк тәреләрен тәрәзә яктысына алып килеп, бик озаклап карап утырды. Өйгә сөенеч керде. Әмма, ни үгетләсәләр дә, Госман дустының туена барырга ашыкмады. Баһаветдиннең атаклы карун бай кызына өйләнәлуы һич тә аның башына сыймады. Җәфрәтил өенә кергән куаныч озакка булмаган икән, икенче көнне үк ул тагын ләхеткә охшап калды... Почта бу ызбага полк мөһере белән беркетелгән ләгънәтле кара кәгазь китерде. Анда:

«...Георгий кресты кавалеры, рядовой казак Җәләлетдин улы Халиулла, падишаһ галиҗанәбләре һәм Ватаныбыз өчен япон баскыннары белән сугышта Порт-Артур янында каһарманнарча һәлак булды... Җаны җәннәттә булсын...» диелгән иде.

Кояш баеды...

Өйгә зур өметләр белән кайтып кергән иде Госман. Кесәсендә жалованиедән, наградалардан җыелган бераз акчасы бар иде. «Бәлки әле язгы чәчүгә орлык олырга да калыр!»— дип планлаштырган иде. Бу уйлары Халюкның үлеме белән бер минутта тәмам челпәрәмә килде. Мәрхүм еракта ятса да, аның җаны үз өеннән дога көтә иде. Мулланы, тирә-як күршеләрне, картларны чакырып коръән хәтем әйттереп, әүвәле

җидесен, аннан кырыгын уздырдылар. Сәдакага акча, аш-суга акча... Бер тиенен җәлләмәделәр, Халюкның җаны гына ризасызланып ятмасын!..
Догага килүчеләр, үзләре сорап, Әминәдән Халюкның Порт-Артурдан җибәргән соңгы бәетен дә укыттылар. Тыңлаучыларның берсе дә күз яшьләрен тыя алмады. Бигрәк тә Җәфрәтил картка авыр булды, кичкә кырын хәлдән таеп егылды...
Нишләргә? Кая барып, кем алдына егылырга? Госман тәмам аптырашта калды. Икенче көнне дөбер-шатыр атлап, камыт аякларын ерып аларның тәбәнәк ызбасын куе дегет исе, яңа каеш исе, тагы әллә нинди исләр белән тутырып, Баһаветдин килеп керде. Кочаклашып күрешсәләр дә, бер-берсеннән шактый читтә басып калдылар. Ары-бире хәл алыштылар, бер-ике сүз белән генә әңгәмәгә сугыш хәлләрен кыстырып куйдылар. Госман ни сораша башласа да, Баһаветдин сүзне үз ягына каера, аның тизрәк-тизрәк үзенең өйләнүен, атаклы туй маҗараларын сөйләргә ашкынуы беленеп үк тора иде. Ниһаять, кияү егетенә рәхәтләнеп, җәелеп мактанырга чират житте. Баһаветдиннең өйләнүе чыннан да, маҗаралы һәм истә калырлык булган икән.
Билгеле инде, Кәлимулла бай үзенең йөрәк парәсен — бердәнбер кызын надан калдырырга теләми, шул ният белән Хупжамалны Кукчәтаудагы Фәхретдин хәлфәнең олы кызы Бәдрижамал абыстайга кадимчә укырга бирә. Анда коръән хәтем кылгач, абыстайның ризалыгы һәм фатыйхасы белән кызын гимназиягә күчерә.
Хупжамал чибәр булу өстенә укырга да хирыс була, тырышып укый, бер җәһәттән дә рус кызларыннан калышмый. Кәлимулла серен чәчеп ташламаса да, эченнән генә: «Болай ижтиһат белән укыган кызны өйдә калдырып булмас, тәвәккәлләп Казан шәрифкә, кодаларга җибәреп табиплыкка укытмый булмас!»— дип куанычлы план да корып йөри.
Кышын укыганда Хупжамал Шаһимәрдән хаҗиләрдә тора. Хаҗиның да Һәмаюн исемле сылу гына кызы бар. Хупжамал җәй айларында, җиләк-җимеш вакытында Имәнтауга кайтып күренә дә, тирә-юньдәге яшь казакларның исләрен җибәреп, китеп тә бара. Кәлимулла кызы үз дәрәҗәсен белә, аллага шөкер, берәүгә дә күз күтәреп карамый, түш калкып тора, сүзләр бөердән генә чыга!.. Тик «бәндә теләр, тәкъдир көләр!» дип тиккә генә чыгармаганнар ич! Хәлфәгә сәдака бирергә килгән җирдә Хупжамал сугыштан кайтып килүче Баһаветдинне очрата! Яшь, чибәр казак, житмәсә көяз офицер, күкрәгендә көмеш тәреләр... Бер карап алганда ук кызның тез буыннарының егәре китә. Күңеленә вәсвәсә иңә... Сәдәкасын аннан-моннан гына тапшыра да ашыгып чыгып китә. Тик күңелгә иңгән вәсвәсә тиз генә онытыламы соң?! Баһаветдин, әнисе янына ни ашыкса да, Кукчәтауда өч көнгә торып кала, кыз белән очрашу юлларын эзли... Яшьлек, ни теләсә, шуны ирешә...

Кайтып житеп, Имәнтаудагы кардәш-ыруларын йөреп чыккач, ул беренче сүзе белән үк әнисе Бибигайшәне шаккаттыра. Бибигайшә кулын чәбәкләп телсез кала, беравыктан улының кайнар маңгаен тотып карый.

— Ай алла, улым, әллә инде акылыннан язган?! Хупжамалны сорап яучы җибәрик дисеңме? Кәлимулла булып Кәлимулла бердәнбер кызын безнең кебек хәерчегә ник бирсен? Өйләнәсең килсә, әнә үз тиңеңне кара.
Яучы карчык Маһижиһан да егетнең үтенеченнән баш тарта, «Булмас юлга чыкмыйм, олы башым белән кеше көлдерәсем юк!»— дип ниятне кире кага. Фронттан алып кайткан алтын тәңкә (егетнең бердәнбер байлыгы!) үз эшен эшли, яучы, йөгереп-чабып, Кәлимуллага барып керә. Бай, әлбәттә, аны болдырыннаң ук өреп төшерә. «Хәерчегә дип үстергән кыз юк, тай моннан, убырлы карчык!»— дип, әшәке сүзләр белән сүгә...
Шуннан Баһаветдин үзе яучыларга бара...
— Шәпләп киендем-ясандым да Кәлимулланың өенә барып кердем. Бай янарак кына намазын бетереп, намазлыгын карават башына элеп ма-

таша иде. Кычкырып сәлам бирдем. Сәламемне алмады. Бик төксе генә, даже борылып та карамыйча, сорау ташлады:

— Ник килдең?

Туп-туры ярдым да салдым:

— Ник булсын, кызың Хупҗамалны кәләшлеккә алырга!

Кәлимулла акырып ук җибәрде:

— Кит, кит, йолкыш!

Ачуыннан намазлыгын тартып алды да учында бөтереп-изеп аны идәнгә тондырды, кулларын йодрыклап өстемә үк килә башлады. Күзләре яман акайган, авызыннан төкрекләре чәчелә, сары сакал бер аска, бер өскә сикереп бии. Ә мин торам авыз ерып.

— Стоп, кайнатай!— мин әйтәм.— Алай килешмәс.— Үзем юри шпорларны зыңлатып, кылычны кузгатып куям.— Кеше көлдермик, кайнатай, акыл белән сөйләшик!

— Молокосос!— диде дә Кәлимулла бай туктап көлеп җибәрде. Шүрләп калдым: акылдан яздымы, мин әйтәм... Карыйм, багам, мыскыллап көлә икән!

— Кәлимулла синнән әҗәткә акыл алып торыр дип белдеңме, йолкыш! Күземнән югал!— дип тагын җикеренә. «Кайнатай» дигәнем әле генә акылына барып җитте тегенең!— Нинди кайнатай булыйм ди мин сиңа!— дип акыра.

— Кайнатай булгач, кайнатай инде,— дим, сул күзне кыса төшеп. Чүт кенә аңласын, мәйтәм, аңгыра баш булмаса! Юри каныма тоз салам тегенең, учлап-учлап җибәрәм! Кабатлыйм да торам «кайнатай»ны! Үзем строевой белән шпорларны зыңлатып залның уртасына — хәтфә келәм өстенә үк узам. «Смирно» басам. Күкрәктәге наградалар ялтырап китә. Именной кылыч арлы-бирле чайкала. Башны чак кына өскәрәк күтәрәм. Фуражка селкенеп куя. Үзем тышта суыкта кызарганмын. Колаклар ут яна.— Бак, кайнатай! Мин кемнән ким? Буй-сын аллага шөкер. Наград патшадан, выты бак, звание офицерский. Багам. Кәлимулла бераз йомшады, икеләнде. «Кайнатай!» сүзе белән сыттым үзен, кәбәм. Ә миңа шул гына кирәк. Атакадагы сыман өзеп салам: «Выты, кайнатай, уйла. Бирсәң, Хупҗамалны миңа кәләшлеккә бирәсең яхшылык белән! Булмаса, урлыйм да алып китәм!

— Ничек?!— Кәлимулла хәлсезләнеп, чигенеп сандык өстенә утырып калды, күзләре аларды.— Ни дидең, гуляван?

— Хупҗамал миңа барырга риза. И белеп тор, яхшылык белән бирмәсәң, урлап китәм.

— Бандит!

— Вәт, атакай,— үзем юри тагын да якынрак килдем. Мескен картның иреннәре дерелди, үзе мыш-мыш килә, күзләреннән яшь коела.— Әйткәнем әйткән, я ризалык белән бир, яки валлаһи дип әйтәм, җәһәннәм тишегенә алып китәм! Тап аннары шайтан белән эзләп мине!

— Ләгънәт төшкере! Кан йоткыры!— дип каргана карт.

— Ярый, мин әйтәм, атакай, уйлап тор, Хупҗамал Күкчәтаудан кайткач, тагын килермен,— дидем дә, шарт-шорт басып, бер дә ис китмәгән кыяфәт белән чыгып киттем. Мажара шулай башланды.

Госманның Баһаветдин сөйләгәннәргә һич исе китмәде, булыр, яшьтән үк әрсезлеге бар иде егетнең! Госманның һушын Кәлимулла бай алды! Имәнтауны гына түгел, аның тирәсендәге барлык станицаларны, станичникларны дер селкетеп, авызлыклап үз кулында тоткан атаклы бай, дөканчә, бер яшь казак алдында эри дә төшә, балавыз шәммени!

Гаҗәп! Булса да була икән мондый могҗиза, ә? Тамаша, хәйран тамаша!

Егетнең килеш-килбәте, кыюлыгы, әрсезлеге, шуның өстенә наградалары ошап калдымы байга?! («Бу казак төшеп калмас, кеше булыр!»— дип уйландымы Кәлимулла алга китеп?) Әллә инде чыннан да, кызын

урлап, китеп, халык алдында рисвай калуыннан шүрләдеме? («Күзләре яман, яхшылык көтмә!»)

Кем белгән инде...

Ни булса булган, узасы түй узган, егет кыз кочагына, үзе әйтмешли, «оҗмахка» кереп чумган... Хәзер килүе дә юкка гына түгел, Госманга киңәше бар икән, драбанд алдында бөтенләй үк чишелеп китмәсә дә, яшь кияү яшьлек дусты Госманның атаман кызы белән якынлыгына ишарә итеп маташты. «Рәхәт чигәсең килсә, нужадан ычкынасың килсә, әйдә, йоклап ятма! Менә минем кебек бул!»— дип кат-кат үгетләде.

Карт драбанд яшь казакның тел төбен генә түгел, нигә килүен аяк атлавыннан ук белеп алган иде. Ул еш кына Госманны өйләнергә өнди башлады. Баһаветдин сөйләгәннәрдән көнләшеп калган Әминә дә көненә бер-ике тапкыр аның кылын тарта торган булды:

— Улым, кәбәм, башлы-күзле итикме әллә үзеңне, дим. Выты, ахирәтең Баһаветдин өйләнде дә, оҗмахка керде. Үзеңә дим, күз күзләгән кызларым да юк түгел. Әллә тәвәккәл итәсеңме, аллага мең шөкер, ут эченнән сау-сәламәт кайттың. Бәлки дөнья көтүе җиңелрәк булыр иде, дигәнем. Выты, бабаң ята, үзем дә авырулы-сырхаулы...

Госман өнсез.

Ул сәке астыннан култык таякларын ала да ишегалдына чыгып, карт карагай астындагы бүкәнгә утыра. Драбанд та аның янына чыгып урнаша. Бераздан егетнең уйларын үзе теләгән якка кертеп җибәрергә теләгәндәй әйтеп ала: «Ни әйтәсең, Баһаветдинга бәхет үзе килеп керде. Выты, кругта станишниклар үзен староста итеп сайларга диләр. Ахирәтеңә бәхет күктән төште».

Бәхетме бу? Госман өзеп кенә әнисенә дә, бабасына да җавап бирә алмый әле. Әйе, ансат, таныш юл буйлап китеп тә барып булыр иде... Тик ул да җан иясе, әнисенә ачылып китмәсә дә, аның да өмете бар! Тик артык биектә, артык еракта шул аның йолдызы. Баһаветдин Кәлимуллага барган сыман, атаман каршына кукраеп барып: «Бирсәң бирәсең, бирмәсәң кызыңны алып качам!»— дип әйтә алмассың! Атаман замат арасында каталажкада урын табар!

Ә шулай да күңел — иблис.

Госман, Маньчжурия кырларында атакага ташланганда иң хасиятле коткаручысы итеп Машаның бердәнбер бүләген — чиккән яулыкны саклады. Әнкәсе биргән бөти белән бергә асрады ул аларны. Шул яулык аны пуля-кылычлардан саклый кебек тоелды...

Атакаларның берсендә ул аттан егылып һуштан язган иде. Ярый әле, үзенең сотниклары аны күреп, күтәреп алып, күчмә госпитальгә китергәннәр. Шунда кайналышта, мөгаен бәйләргә бинт эзләгәндә, яулык юкка чыкты... Госман аңына килеп, яулыкның югалуын белгәч, һәммәсен яманга юрады, йөрәге «жу» итеп китте.

Әйе, сизгән икән күңел, сизенгән. Госман кайтканга күпме булды, ә Машаның күренгәне дә юк. Атасы аны Омскига укырга җибәргән. Омск — зур шәһәр, анда кадетлар корпусы. Яп-яшь чибәр егетләр кайнап тора. Мөгаен, Маша хәзер берәр кадет кочагындадыр!.. Атаман кызына рядовой казак тиң буламы?

«Выты, кругом юл ябык миңа!»

## 22

Госман икенче көнне үк, ямчыга утырып, Атбасарга китте. Сергей Ивановичны эзләп тапты, кемлеген белдерде. Сергей Иванович Миңлебай абзасы әйткәнгә караганда да яхшырак, ярдәмчел кеше булып чыкты. Госман «эшли алырмынмы?» дип, шиген белдергән иде, ул аңа «өйрәнерсең!» дип кенә куйды. «Страховое-транспортное общество» дип атал-

са да ул урнашкан урын, төп эш монда почта икән. Күкчәтаудан ямчы белән килгән почтаны ничек кабул итеп алырга, хатларны, газеталарны, посылкаларны кайсы кенәгәгә ничек итеп теркәргә, адресатларга ничек-ничек тапшырырга, страховой кәгазьләрне, таныклыкларны ничек тутырырга һәм башка вак-төяк кәнсә хезмәтләрен Сергей Иванович бер дә иренмичә, ялыкмыйча, шул ук вакытта Госманны да ялыктырмаска тырышып, ара-тирә уен-көлке дә катыштырып төннәр буена аның янында утырып үзе күрсәтте, өйрәтте.

— Вот нәрсә, Усман Умарович,— диде ул беренче көнне үк аны исеме, атасының исеме белән атап-олылап.— Син, булмаса, безнең өйдә генә тор. Без Мария Петровна белән икәү генә, балалар таралдылар.

Юмарт хуҗа фатир акчасы алудан да баш тартты.

Билгеле инде, хезмәт хакы әллә ни зурдан түгел, аена утыз сум. Госман егерме сумны ай саен өенә җибәреп торырга карар кылды, үзенә ашау-эчүгә, башка кирәк-яракка ун сумы җитәр, дип уйлады. (Аракы эчмәгәч, тәмәке тартмагач, «юрганыңа карап аяк сузасың!»)

Шулай яз җитте. Кар эри. Тиздән кырлар ачылыр. Чәчү җитәр. «Иртәгә үк Сергей Ивановичка гариза язып, алдагы хезмәт хакы исәбенә аванс сорап алып өйгә кайтырга да и правлениедән чәчүлек орлык сатып алырга, сукачылар яллларга кирәк булыр».

Госманның алдагы өметләре җиргә бәйләнгән. Башкача уйлый да алмый. Мөмкинлеге дә юк. Имәнтауда әнисе. Бабасы... Аларны саклап, коткарып калырга кирәк.

Койма буенда кар катырак, батмый, шатыр-шотыр килеп ваклана гына. Госман тизрәк атлап китте, инде Ишим елгасына да ерак түгел, мәчет урамын узарга да... Күз дә ияләнә төште ахрысы, ул чокыр-чакырларны урап, әйләнеп уза, батмый. Алдарак бер гәүдә пәйда булды, алпан-тилпән бара, әллә кабактан чыккан исерек инде? Госман таягын сул кулыннан уңга күчерде, белмәссең... Ул арада йортлар арасыннан әфлисун сары ай да калыкты, тирә-як чак кына яктырып китте. Госман кыюланып исереккә якынлашты, күтәрелеп йөзенә карады. Башында иңнәрен каплап төшкән өч колаклы төлке томак, өстендә бөрмә билле озын кара тун. Аякларында Госманныкы төсле пайпаклы итекләр. Жылы киенгән! Ул чайкала-чайкала барды да борылып бер капкага килеп ябышты. Шунда тора микән? Юк, кермәде, коймага авышты, тирәлде һәм буылып-буылып йөткерә башлады. Газапланып, чәчәп йөткерә.

— Эһе... Эһе...

Госман уратып узып китмәкче иде, буылып йөткереп торган кеше янына аяклары тартылды, ул аңа казахча эндәште:

— Җулдас, ә жулдас! Сырхаттап торасызмы? Өеңез кайда, алып бараен?!

— Эһе, эһе...

Томаклы кеше тагын да иелә төшеп, соңгы көченә йөткерде дә косып җибәрде. Госман куркынып артка чигенде, тәне чымырдады, кар өсте кып-кызыл кан иде. Читтәрәк көмеш кысалы күзлек ялтырап ята.

— Уф, алла!— Томаклы кеше авыр сулады. «Татар!» Кесәсеннән яулык чыгарып, бит-авызын сөртте. Кара сакаллы, кара мыеклы түгәрәк йөзле кеше икән.— Гафу итегез...

Ул, иелеп, күзлеген эзли башлады.

Госман күзлекне эләктереп тиз-тиз аңа сузды.

— Менә ул. Киегез.

— Рәхмәт.— Томаклы күзлеген киде, Госманга карады.— Гафу итегез. Авырып киттем. Мин, әнә, мәчет каршындагы яшел капкалы өйдә торам.

Капкага якынлашыр-якынлашмас, кура эчендә ләңгелдәп эт өрә башлады, бераздан чылбыр чылтырады. Шыгырдап өй ишеге ачылды. Эт шунда ук өрүдән туктады. Госман томаклыны җитәкләп капка баганасы төбенә үк китереп бастырды.

Капка ачылды, әрвах төсле ук ап-ак киемле кеше күренде.

— Ой-бай, колыным! — Баштан-аяк ак кимәчәккә төренгән кәмпер жыламсырап урамга чыкты.— Ой-бай, балам! Тагын сырхаттап калдыңмы? Әйдә, өйгә керегдәр. Шәм жагаен.

Ал өйнең киез җәелгән сәкесе өстендәге тәбәнәк аяклы, түгәрәк өстәлгә кәмпер агач савытка салынган сары май һәм әле генә көлдән алынган, буланып торган түгәрәк көлчәләр китереп куйды. Көлчәне ваклап сындырды. Бүлмәгә хуш ис — икмәк исе таралды. Аннан соң ул ике касә сөтле чәй алып килде.

— Хуш килдегез, мөсафир, безнең өйдән дәм татыгыз. Ал, Сабир улым.— Ул шунда чишенеп мендәргә кыйшайган күзлекле фатирчысына аналар борчылуы белән карады.— Син дә чәй эчеп җибәр. Тамагың йомшар, чәеңә май сал. Ул күкҗүтәлгә [1] тәвер булады. Мөсафир, син оялма, көлчә белән тамагыңны туйдырып ал. Сабирны алып килүеңә рәхмәт.

Кәмпер кимәчәгенең чабуына бутала-абына комган күтәреп ишегалдына чыгып китте.

Кечкенә генә калай савытка куй мае салынып, өсте капланып, уртасы тишелгән, шул тишектә урелгән мамык. Аңа ут кабызылган. Менә шушы шәм-май бөтен өй эчен сүрән генә яктырта. Шушы куркак шәм яктысында мендәргә кыйшаеп яткан авыруның йөзе бигрәк тә ябык һәм зәгъфран төсле сары күренә. Үзе болай йөзгә ягымлы, күркәм кеше икән.

— Рәхмәт.— Сабир, кәмпернең киңәшен тотып, сөтле чәйгә бер-ике шакмак сары май салды да бер-ике йоткач, калкынып Госманга эндәште.— Яз житте исә, шулай кысылып калам. Бая, гафу итегез, хәлем бик киткән иде. Кайтып житәрлек чама калмады. Бәхеткә сез очрадыгыз. Гафу итегез, сорарга да онытканмын, кем дип белим сезне. Танымыйм. Атбасарныкы түгел шикелле. Әйдәгез, ашап-эчеп кенә утырыгыз әле, көлчәсеннән авыз итегез. Хуҗаларым бик яхшы кешеләр, тәгамны тәмле әзерлиләр.

— Рәхмәт, ашап утырам. Көлчә бик тәмле, кетердәп тора.— Госман касәне күтәреп чәй йотты.— Мин мондагы кеше түгел. Күптән түгел генә килдем. Агентствода эшлим. Фамилиям Әбдрәшитов.

— Тукта, тукта!— Авыру кинәт җанланып, күзлеген бер салып, бер киеп төбәлеп карап торды да кычкырып җибәрде.— Исемегез Госман түгелме?

— Әйе, Госман.— Госман гаҗәпләнеп, эчәргә дип күтәргән касәсен кире куйганда, чайпалдырып, чәй түкте.— Ничек, минем исемне сез каян беләсез?

— Әсез Куянды ярминкәсенә Шаһимәрдән хаҗиның куйларын әйдәдегезме?— Бу юлы авыруның йөзе яктырып, матурланып китте.— Менә син нинди дәү булгансың, Госман! Таяклы, димәк фронттан, яралы?!

— Вәт очрашу!— Госман сикереп торып күзлекле кешенең кочагына ташланды, аның ябык кулларын кысып, бик озак җибәрмичә ярсып кычкырды.— Сабир! Шәрипов! Әйе! Бу син бит! Вәт очрашу! Ничә еллардан соң?! Кайда! Төнлә!

Сабирның күзләренә яшь тулды, күзлеген сөрткән булып, күз төпләрен дә кат-кат корытып өлгерде, шактыйдан соң гына тынычланды һәм бераздан акрын, тигез тавыш белән сүз башлады:

— Үзем дә быелтыр гына, Урал ягыннан кымыз эчәргә дип килдем. Миндәйләргә кымыз файдалы диләр бит. Хәзер пар тегерменендә столяр булып эшлим... Беләсезме?— Әллә сары майлы кайнар чәй эчкәнгә, әллә күптәнге дусты белән очрашканга Сабирның тавышы җанланып, көрәеп китте.— Беләсезме, Госман әфәнде, монда безнең уртак дуслар да бар бит.

— Кемнәр алар? Кызык!

[1] Күкҗүтәл — туберкулез чире.

— Хәтерлисезме, алар безгә Куяндыга якынлашканда килеп кушылдылар.

— Кемнәр?— Госман башкаларны томанлы гына хәтерләде, ул чактан бирле кайларда булынмаган да, кемнәр белән көрешелмәгән?

— Кәрим белән Хәмит Сутюшевлар.

— Хәтерләдем!Җор һәм әйбәт малайлар иде.

— Алайса сезнең хәтерегез әйбәт икән, Госман әфәнде.

— Юлы онытырлык түгел иде ич... Бөтен бәла-казаларым шуннан башланды дисәм дә ялган булмас... Ә сезнең сеңелләр?.. Исән-саулармы?

— Аларны да онытмадыгызмы?

— Ялгышмасам, зурысы Зифа иде шикелле.

— Әйе, әйе,— диде Сабир кинәт моңсуланып.— Зурысы Зифа, ә кечесе Миңсылу... Исән-саулар... Миңсылуның хәле әлегә ару. Кияү үзебезнең күрше егет. Җаен, әткәй мәрхүм кебек, сал агыза. Кышын Урал якларында сунарчылык белән шөгыльләнә. Тату торалар. Тик менә Зифаның бәхете булмады.

— Ни, әллә авырдымы?

— Юк, мин бит аларны, әти-әни вафат булгач Җәләлетдин муллада калдырып киткән идем. «Ким-хур итмәм!»— дип вәгъдә биреп калган иде кара йөз... Ул көчләп диярлек Зифаны үзенең ахмак бер улына никахлаган... Көне-төне эшләткәннәр бичараны... Җитмәсә, бераз торгач, улы «хәерче кызы миңа кирәкми!» дип, баласы белән Зифаны куып чыгарган. Ярый инде, сабый озакламый үлгән... Менә ни өчен мин аны үз яныма алып килдем... Монда яши.

— Хода аңа озын гомер-бәхет һибә итсен,— диде Госман.

— Сутюшевлар хәзер әфәнделәр!— диде Сабир кинәт кенә сүзне башка якка борып.— Алар хәзер монда Петропавел бае Шәмсетдинов кибетендә приказчиклар. Агалары доверенный...

— Алай!— дип сузды Госман.— Алай булгач алар мине танымаслар да инде.

— Әйтмәгез, Госман әфәнде. Алар икесе дә бик садә һәм нәзакәтле егетләр. Сезне күрсәләр, бик шат булырлар.

— Мин простой казак булып калдым. Ә алар...— Госман шунда нигәдер үзенең ахирәте Баһаветдинне хәтерләде...

— Атбасарда татар әһеле күп,— дип дәвам итте Сабир.— Без әле үткән ел үзара иганә җыеп бер йортны арендага алдык та кыйраәтханә ачтык. Җомга көннәрендә яшьләр шунда җыела. Әдәби кичәләр уздырабыз. Бүген менә мин шул кыйраәтханәдән репетициядән кайтып килә идем.

— Ул кыйраәтханә кайда соң?

— Мәчет урамында ике катлы йорт бар бит, асты таш, өсте агач, менә шул йортның өске катында. Иртәгә җомга. Безнең нәүбәттәге әдәби кичә. Килегез. Сутюшевларны да күрерсез. Бергәләп узганнарны искә алырбыз.

Чәй янарттылар, көлчә белән аны тәмләп эчтеләр. Майшәм пылт-пылт итә башлады, мае бетте бугай. Госман, Сабир белән хушлашып, бу һич көтелмәгән очрашуга куанып, иртәгә әдәби кичәгә килергә вәгъдә биреп чыгып китте. Берьюлы күңеле күтәрелде егетнең. Әле ят бер шәһәрдә иске танышларының булуы ничектер аның офыгын киңәйтеп җибәрде, аның адымы җиңеләйде, кулындагы таягын өстә уйнатып, урам бозларын шатырдатып вата-вата, марш көйләренә сызгырып фатирына кайтып китте.

Капка бигенә үрелгәндә, ул нигәдер Зифа турында уйлады. Аның язмышын үз сеңлесе Мәрфук язмышы белән чагыштырып карады. Икесе дә бәхетсез, икесе дә кимсетелгән. Тик Сабир кыюрак шул, ул сеңлесен үз янына алдырган... Үз янына...

Элек тә житез иде, бүген кулы-кулга йокмый егетнең, посылкаларны, бандерольләрне теркәде, хатларны һәммәсен авылы-авылы белән аерым өемнәргә бүлеп чыкты... Тиргә-суга батып эшен тәмамлады да, ишеккә зур йозак элеп, мәчет ягына йөгерде. Кыйраатханә шул якта булырга тиеш.

Йортны тиз эзләп тапты Госман, өске катка күтәрелгәндә, халык барлыгын сизеп, чак кына тынын җыеп торды. Чыннан да, ул барып кергәндә, зал халык белән шыгрым тулы иде. Башта килгәннәр, өс киемнәрен салып, урындыкларга утырганнар, Госман кебек соңлаганнар исә, туннан, бишмәттән стена буена тезелеп басканнар. Залның нәкъ уртасында, түшәмдә, утызлы лампа яна. Күз күнегә төшкәч, Госман залдагыларның күбесенчә ир-ат булуын абайлап алды. Алай да ара-тирә башларына калфак кигән, дебет шәл ябынган хатын-кызлар да шәйләнә. Татарлар гына түгел, казахлар да бар. Госман кысыла торгач стена буеннан үзенә урын яулап алды. Ярый әле буй озын, бүтәннәрнең башы аша бөтен почмакларны күрергә мөмкин! Сугышта чакта озын буеннан гел зарланган Госман бүген үзенә күрә рәхәтлек кичерде! Яңа дөнья, ят дөнья — ә ул һәммәсен күреп, күзәтеп тора ала!

Госман залга кергәндә үк алда, өстәл янында берәү шигырь укый иде. Стена буена урнашкач, ул укучыны ап-ачык күрде. Кара чәчен артка тарап, кара бәрхет такыя белән бастырып куйган, өстендә кара постау пиджак, чибәр генә егет. Госман кызыксынып аның авызына йотылды. Сүзләре дә ят, яңа иде аның өчен!

Уян, татар, уйлан, татар!
Тарихларыңны ач, актар!
Ирек килде! Иркен чаклар:
Уйлан, татар! Уян, татар!

Кем кистерде башларыңны?
Кем агызды яшьләреңне?
Кемнәр алды авызыңнан
Капкан ризык-ашларыңны?

Синең хәләл малың белән
Туй иттеләр дә туйдылар.
Уйнап тәнең-җаның белән,
Куй иттеләр дә суйдылар.

Илләреңне көл иттеләр,
Ирләреңне кол иттеләр.
Яланнарыңны кисәкләп,
Җирләреңне юк иттеләр.

Хак сүз әйтсәң, Себер киттең,
Җир сорап син кан-яшь түктең,
Илдән-илгә куды патша,
Җир-зинданда гомер иттең.

Сөйләүче шушы урында туктап тын алды, кемдер ашыгып кына аңа өстәлдәге графиннан су коеп стакан сузды, бер-ике йотым су эчкәч сөйләүченең тавышы ачылып, ныгып китте.

Күпме еллар изелдең син,
Таландың син, өзелдең син.
Тапталдың син, тапландың син —
Инде аны сизендең син!
Кулга гайрәт шәмен алып,
Күзең ак юлларга салып,
Омтыл алга! Томырыл алга!
Өмет кояшын уңга алып!
Уян, татар, уйлан, татар!
Тарихларыңны ач, актар!
Ирек килде, иркен чаклар:
Уйлан, татар, уян, татар!

Шигырь укылып бетүгә, залдагы халык башта аптырап, уиланган кебек тып-тын торды да, аннан, кинәт, чайкалып, кабынып кул чаба башлады. Арттагы рәтләрдәгеләр сикерешеп тә тордылар:

— Афәрин!

— Рәхмәт, Кәрим әфәнде, яхшы сүзләреңә!

«Кәрим?! Ул микәнни? Бак, аристократ! Инде мине танымас та!»

Шигырь укучының урынын билен көмеш кәмәр белән буган озын, какча егет алды, ул нәзек тавыш белән сөйләп китте:

— Хөрмәтле әфәнделәр, ханымнар вә туташлар! Бүген без сезгә Кызылъяр каласыннан килгән кунагыбызны — хөрмәтле Мәдинә туташны тәкъдим итәбез. Ишетүебезчә, Мәдинә туташ матур гына җырлый. Әйдәгез, Мәдинә туташның җырлавын үтеник.

— Рәхим итсен!

— Әйдәгенәм, җырласын!

Халык шигырь тәэсиреннән айнып та житмәгән иде, яна тәкъдимне хуплап дәррәү кул чапты.

Шуны гына көтеп торган егет, тальян гармун күтәреп, житез атлап урындыкка килеп утырды да, әйткәнне дә көтмичә, гармунын сузып-сызып җибәрде. Өстәл янына, бая Кәримгә су коеп биргән мөлаем туташ чыгып басты. Энҗе калфак, каерма якалы, озын җиңле, өч бәбәй итәкле канәфер төсле күлмәк. Кызыл ефәк тасма белән ыспайлап үрелгән толымнар чайкалды. Каушаудан йөзе тагын да алсуланып, серләнеп китте.

Беренче башлауда ул гармунга кушылырга өлгермәде, башын түбән иеп, тирән уйга калган сыман тып-тын гына басып торды. Егет көйне бер урап икенче тапкыр башлады, Мәдинә чак кына башын калкытты һәм каядыр еракка, күз күрмәгән якларга төбәлеп, моңлы, сагышлы татар җырын башлады:

Каз канатлары, ай, ак була,
Ир канатлары ат була.
Сабыйларның канатланыр вакыты,
Мәктәпләрдә укыр чак була...

Тавыш көчәйде, гармун белән бер булып моңайды, зарланды, сөенде. Ул акрынлап үсте,күкрәгенә барды һәм бөтен залны ниндидер бик еракта калган, әмма һәрбер күңел өчен үтә кадерле, изге булган тылсымлы моң-сагыш белән тутырды. Әйтерсең лә, һәркемнең күңеленә канат очы белән кагылып кыр казлары очты!

Җыр тынды. Моң калды.

Халык — сихерләнгәндәй — өнсез. Мондый кичәне беренче тапкыр күргән Госманның күкрәгенә нидер килеп тыгылды. Ул бер минутта, шушы кайнар мизгелдә Маньчжурия кырларында ятып калган бик күп иптәшләрен... сызгырып килгән бомба тавышларын... яралыларның акырып-үксеп кычкыруларын... канлы чүпрәкләрне... яшь тулган хәсрәтле күзләрне хәтере аша йөгертеп уздырды...

Зал, чайкалып, озак кына кул чапты. Мәдинә туташ берничә тапкыр рәхмәт әйтеп, урынына утырды, зал һаман тынмады.

Конферансье егет тамагын кырган булып, мул итеп елмаеп, алдагы рәтләргә якынрак килде:

— Инде кунак туташ безгә Кызылъяр халкының үз көе «Биш күл»не җырлап бирсен иде!

— Сорыйбыз! Сорыйбыз!

Мәдинә туташ артык назландырмады, гармунчының колагына иелеп нидер әйтте дә толымнарының берсен иңбашы аша алдан артка ташлады. Аккорд. Тынлык. Гармун күреге сызылу белән аңа җыр ялганды.

«Биш күл» көе, «Биш күл» көе,
«Биш күл» көен яратам.

«Биш күл» көенә җырласам.
Бар хәсрәтем таратам...

Халык тагын калкынып кул чапты, тагын залда дулкын уйнады, йөрәкләр бер булып типте, җыелганнар бер булып иркен суладылар... Мәдинәдән соң тагын кемдер шигырь укыды, аны да хөрмәтләп, «афәрин!» дип озаттылар.

— Кадерле кунаклар,— диде конферансье егет.— Безнең атаклы җырчыбыз Сабир әфәнде Шәрипов бүген сырхаулап тора, сезне җыры белән бүләкләүдән гаҗиз. Әмма, аның бәрабәренә Сабир әфәнде безгә тавышына тиң коралы — скрипкада милли көйләребезне башкарачак!

Залдагы көтү киеренкелеге өзелде, алкыш башланды. «Сабирны беләләр икән монда!» — дип уйлады Госман һәм бөтен кешедән дә ныграк кул чапты.

Сабир музыкантларга хас нәзакәтлелек һәм хөрмәт белән скрипкасын ияк астына җайлап кына куйды да уң кулындагы смычогын күтәрде... Тидеме, юкмы, билгесез, кыллар кинәт тетрәнеп киттеләр. Аннан смычок ашыгып-ашыгып сыкрап, нидер эзләнде, залны тутырып сихри моң түкте. Ул күңелләрне еракка-еракка, бәхет, сәгадәт дөньясенә алып китеп тибрәтте, һәрбер җан шушы тылсымлы моң агымына бирелеп сихерләнде һәм иserde.

Сабирны үз алларыннан бик озакка кадәр җибәрмәделәр. Алкыш, алкышлар, мактау һәм рәхмәт сүзләре.

«Тәфтиләү», «Гөлҗамал», «Энчы Фәхри», «Кара урман» һәм башка көйләр уйналды. Сабирдан соң югары сыйныф укучыларыннан оештырылган хор татар халкының борынгы җырларын башкарды...

***

— Госман дус, сине дә күрер көн бар икән! — Кәрим, залда халык сыеклана башлау белән, стена янында ялгыз калган Госман янына атылып барып җитте һәм кочаклап алды.— Әйдә, безнең белән барып, чәй эчеп, сохбәтләшеп утырыйк әле. Кардәшләрем, дус-ишләрем белән дә танышырсың. Сабир, Гаделбәк әфәнделәр, әйдәгез, сез дә безгә рәхим итегез! Күрәсез, бездә бүген нинди мөбарәк кунак!

Госман үзенә карата булган көтелмәгән игътибардан тәмам аптырап, югалып калса да, егетләр аңа ай-вай итәргә ирек бирмәделәр, бергәләп, култыклашып кыйраәтханәдән чыктылар. Сабир утны сүндереп, ишекләрне бикләде.

Ай калыккан. Аз гына кар — энҗе сибелгән. Хуш ис, яшь кар исе аңкый. Менә алар — чордашлар, бер төркем татар егетләре Атбасарның төнге урамын тутырып кайтып баралар. Бөтенесеннән дә бигрәк калку Госман үз юлдашларына сәерсенеп һәм кызыксынып карап бара. Аның уйлары артык дәрәҗәдә чуалган, колак төбендә әле генә залны биләгән милли моңнар яңгырый...

## 23

— Җиңги, ун елга якын күрешмәгән дустымны очраттым. Менә, таныш: Госман әфәнде! — дип Кәрим, ишектән керә-керешкә Госманны күрсәтеп, җиңгәсеннән сөенеч алды.— Госман, бу минем әнием урынындагы җиңгәм.

Күрешүләр, танышулар. Госманга карата арта барган игътибар егетне һаман кыен хәлгә куйса да, ул кыю гына, иптәшләренә ияреп, алгы өйдән түр якка узды. Җиһазлар артык мул булмаса да, өй эче чип-

чиста итеп җыештырылган, һәммә җирдә күзне рәхәтләндерерлек тәртип, пөхтәлек сизелә иде. Бүлмә түренә күз салу белән, Госман хәйран калды: китаплар! Китаплар белән шкаф тул-тулы, тәрәзә төпләренә дә китаплар өелгән, эресе бар, калыны, юкалары, шкаф өстендә тау булып газета-журналлар өелеп тора... (Белем, гыйлем эзләп кайларга барып чыкмады яшь чагында Госман! Әмма бер җирдә дә шушы кадәр китап-журнал күргәне юк иде!) Каян шулкадәр җыеп бетергәннәр? Нигә шушы кадәр китап?

Кәрим кыска-кыска гына бер-ике сүз алышканнан соң, кунаклардан гафу үтенеп, аш өенә чыгып китте, керүчеләр өстәл янына утырышып, алларында яткан газеталарны кулларына алдылар. Госман шкаф янына басып өстән-өстән генә китапларны карый башлады. Күбесе татарча — Казанда, Уфада, Оренбургта басылган. (Бак, татарча китаплар да шушы кадәр булыр икән!) Госманны аеруча таң калдырганы — татарча газеталар булды. Үзе почтада эшләп, моңарчы газеталарга алай игътибар иткәне юк иде. Менә йомылып яшәсәң! Күгәргән калайга әйләнүеңне көт тә тор! Абайлабрак караса... «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Азат», «Баянелхак», «Фикер» һәм башкалар.

Кай арада кереп җиткәндер, Кәрим җыелганнарны ягымлы тавышы белән чәй янына дәште:

— Ягез, туганнар. Бүгенгә агарту эшен куеп торсак та ярыйдыр. Аз-маз тамак ялгап алыйк,— дип һәммәсенә сүз катарга өлгерде.— Сандугачны җыр белән сыйламыйлар, рус туганнарыбыз шулай әйтә!

— Уй-бай, арамызда сандугач бераү генә гуй! — диде Гаделбәк, аерата бер игътибар белән газета укып утырган Сабирга ишарәләп.

— Сез дә илнең бер былбылы, Гаделбәк,— диде Кәрим, аш өеннән алып кергән аш-суын өстәлгә урнаштыра-урнаштыра.

— Үләңегез дә, думбыра чиртүегез дә миңа бик ошады,— диде Госман бераз кыюланып.

— Кунаклар, гаепләмәгез,— дип, Маһикамал гөжләп торган ак самоварны өстәл уртасына күтәреп утыртты.— Хәзинәдә бары белән. Ашагыз, эчегез, мин балаларны яткырыйм.

Җыелганнар, бер дә кыстатмыйча, ризыкларга үрелделәр, бер-ике чынаяк эчүгә, күңелле әңгәмә башланды. Госман табын тирәсендәге кешеләрнең бер-берсе белән шактый якыннан таныш булуларын һәм аларны нииндидер уртак уйлар, уртак теләкләр берләштерүен сизенеп калды. Алар ярты сүздән я дәррәү көлеп җибәрәләр, сүз арасына Тукай шигырьләрен кыстыралар, дөнья-тормыш хәлләреннән үзләре аңлаганча итеп ниләрдер сөйләшеп, хәбәрләшеп алырга да өлгерәләр иде. Билгеле инде, хуҗа иң әүвәле, яңа кунакны «камап» алды. Куяндыда бүре тырнагыннан котылганнан соң кайларда булуын, ничек дәвалануын, бу якка кайчан һәм ничек килеп чыгуын, кайда эшләвен, барысын да энәсеннән җебенә хәтле дигәндәй, төпченеп сорашты. Госман үзе үткән юллар турында сөйләргә яратмый иде, кирәк тә санамады, бүген исә, һич көтмәгәнчә, үзе дә сизмәстән бар күргәннәрен кыска-кыскарак кына булса да чишеп ташлады. Колҗада булуын, Кытай табибларыннан дәвалануын, аннан кайткач япон сугышына китүен, яраланып, узган кыш кына кайтуын, хәзер монда страховое агентствода эшләвен әйтте.

Сабир Госманның җилкәсеннән кагып куйды:

— Күргәннәрең житәрлек булган, туган,— диде.

— Дөньяны таныгансың икән, моннан соң да югалып калмассың,— дип кушылды аңа Кәрим һәм мәгънәле генә җыелганнарга карап алды.— Ә без монда өчебез дә ак билетлар. Гаделбәк казах, падишаһ хәзрәтләре аңа корал бирүдән курка!

— Үзем дә атылып тормыйм,— диде Гаделбәк.

— Тазалык югалды,— диде Сабир үзалдына гына әйткәндәй итеп.

— Уй-бай, яз гына җитсен, мин Сабир дусны авылга алып барып, кымыз белән казының уртасына куям.

— Батып китсәм? — Сабир күзлек астыннан Гаделбәккә карады да үзе үк көлеп җибәрде.

— Сиңа дәваланырга кирәк, Сабир дус,— диде Кәрим җитди генә.— Саулык барыбызга да кирәк әле. Бик кирәк!

— Саулыксыз ерак барып булмас! — диде Сабир.

— Синең еракка барыргамы исәп? — дип сүз кушты Гаделбәк.

Алар бик гади сүзләр сөйләшсәләр дә, Госман уртада нindidер ул аңламаган сер ятуын сизенә, табындашларының бер-берсенә булган игътибарларына чын күңеленнән сокланып утыра иде. «Бак, нинди дус компания!»

Кәрим кунакларның чәен яңартып чыкты да, тагын Госманга сүз белән төбәлде.

— Госман әфәнде, сезнең Атбасарга килеп чыгып, арабызда булуыгызга барыбыз да ихлас шатбыз. Чөнки без заманында авыр юлны үткән, бер-беребезгә сер сыя торган дуслар. Бу авыр заманда андый дуслар бик кирәк! Сездән аерылгач, без дә шактыйны күрдек, шактыйны кичердек. Гаделбәк әфәнде дә — дөнья таный белә торган казах баласы. Милләтебез өчен синдәй егетләр бик кадерле. Замана авыр! Халкыбыз караңгылык эчендә. Мәдәният, мәгърифәтнең ни икәнен белми белергә әмәле де юк. Татар вә казах халкы балаларының иң ашып киткәне кайда укый? — Мәдрәсәдә. Ә мәдрәсәләрнең иң күпчелегендә мескен сабыйларның башын дин белән агулыйлар. Бер наданлыктан икенчесенә өстерәп кертәләр. Бу ел һәм дәһшәтле, һәм матлуп тантаналы ел булыр! Канлы якшәмбенең аһ-зары Санкт-Петербургта гына түгел, хәтта монда, адашып калган казах даласында, Атбасарда да ишетелде. Халык тирән, ачы йокысыннан уянды. Бу ел безгә Петербургтан да, Казаннан да байтак укымышлы зыялылар килде. Аларны төрле сәяси оешмаларда торуда гаепләп, бу якка сөргенгә җибәргәннәр. Күбесе яшьләр, студентлар. Монда алар управада, земствода һәм дә башка мәхкәмәләрдә хезмәт күрсәтәләр һәм халык арасында мәгърифәт эшләре алып баралар. Лекцияләр укыйлар. Менә шул иптәшләр безнең күзләребезне ачуда зур ихтиһадлык иттеләр. Сез булган кыйраәтханә, әдәби кичәләр шуларның җимешедер. Мәсәлән, табиб Виктор Иванович Кулагин, өяз начальнигы писаре Петр Васильевич Линговой, пар тегермәненең механигы Дмитрий Андреевич Ушаков, укытучы Хөсәен Гыйльманов (бүгенге кичәбездә конферансье хезмәтен башкарган егет!) һәм башкалар Атбасар халкына зур хезмәт күрсәттеләр. Иншалла, сез дә алар белән танышып, аралашып, үз көчегезне кызганмассыз дип өметләнәм...

Госман бу мәҗлестә үзенә моңарчы таныш булмаган сүзләр ишетте: хөррият, җөмһүрият, инкыйлаб, милләт, мәдәният, мәгърифәт! Серле сүзләр иде алар, күңелне кузгата торган мәгънәле сүзләр иде. Озак утырдылар. Китәсе килми иде. Ул яңа дуслары белән хушлашып кузгалды. Кәрим аны капка төбенә хәтле озата чыкты һәм Госманның кулын каты итеп кысып озак җибәрмичә торды.

— Госман әфәнде, Сезне очратуыма чын күңелдән шатмын. Инде, иншалла, еш-еш очрашырбыз. Тагын шул иде, дустым,— ул нигәдер тавышын басып, колакка гына пышылдады,— алдагы шимбәдә кыйраәтханәгә килегез әле, бер мөһим эш бар. Ярый, хуш. Хәерле төн. Шимбәдә, шәт, күрешербез.

Капка ябылды. Аргы баштa так-ток иткән тавыш яңгырады. Каравылчы. Йокламый. Ай да инде шактый югары күтәрелгән... «Сөргенгә... лекцияләр укыйлар...» Димәк, тагын кемнәрдер йокламый әле бүгенге төндә Атбасарда? Йокымсыраган йортлар серле нурга төренгән табышмаклар булып тоелды Госманга. Ул юл буе уйланып кайтты. «Нинди мөһим эш икән ул?!»

Кичәге әңгәмәдән, әдәби кичәдән соң «жиргә төшү» бик авыр булса да, Госман икенче көнне үк, бик тырышып, кат-кат күчереп язган гаризасын Сергей Иванович өстәленә китереп куйды. Начальникның кәефе яхшы, әлеге кенә Күкчәтаудан кайтып төшкән, борын өстендә яңа күзлеге елык-ялык килеп тора, ул Госманның кәгазен кулына алды да, кашын җыерып:

— Бу нәрсә? — дип сорады.

— Тиздән чәчү җитә бит, Сергей Иванович...

— Күрдем, юлларда кар эри. Далада да кар кузгала башлаган. Тукта! Мондарак кил әле! — Госман өстәлгә якынрак килде.— Син монда «от Абдрашитов» дип язгансың. Дөрес түгел! Хата! «От Абдрашитова» кирәк.

— Ялгыш киткән!

— Киту генәме! Тоташ хата! «Прошу вас», дигәнсең. Өлкән кешегә мөрәҗәгать иткәндә «вас» сүзе баш хәрефтән башлана. Ә монда «и» урынына «е» кирәк! Укырга кирәк икән сиңа, Усман Умарович! Өйгә кайтуга, грамматика китабы тоттырам. Мария Петровна белән бергә укырсың. Тел белмәү гаеп! Синтаксисны узарсың. Нигә гаризаңның датасы юк? Бәлки син аны былтыр язгансыңдыр? Хәзер үк күчереп яз. Төшендеңме?

— Төшендем.

Тирләп-пешеп, оялып гаризаны тагын күчерергә туры килде.

Госман чәчүлек орлык сатып алырга начальнигыннан аванс сораган иде. Сергей Иванович укып чыкты да, бераз уйланып торгач:

— Ярый. Мария Петровна белән сөйләшеп карамын,— диде.

«Гаризаны агентство начальнигы исеменә яздым, Мария Петровнаның монда ни катнашы бар икән?» — дип Госман көне буе аптырап йөрде...

Җомга — әдәбият кичәсе.

Шимбә — «коръән хәтем кичәсе». Кызык! Анысы ничек уза икән? «Алдагы шимбәдә килми калмагыз!» — диде Кәрим. Алдагы шимбәгә кадәр эшлисе эшләр, башкарасы бурычлар муеннан!..

«Мария Петровна» дисә дә, Сергей Иванович гариза турында өйдә бер сүз дә кузгатмады. Иртән, конторага килгәч, Госманны үз бүлмәсенә чакырып кертте дә пиджагының эчке кесәсеннән бер төргәк акча тартып чыгарды.

— Мә, Усман Умарович, монда ике айлык хезмәт хакың. Үзең беләсең, безнең кассада буш яткан акча юк. Кызылъяр жалованьене ай ахырында гына җибәрә. Әмма аңлыйм: сорыйсың икән, кирәк. Бу безнең үз акчабыз. Соңыннан, үз җаең белән түләрсең. Иртәгә почтага утыр да Күкчәтауга кит. Аннан тагын почта атлары белән Имәнтауга барырсың. Акчаның барысын да драбанд бабаңа бир. Чәчүлек алсын. Бу ике айда тамагың безнең белән узар. Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың диләрме? Алдан ук хәстәрен күр.

Госманның Сергей Ивановичны кочаклап аласы килде! Булса да булыр икән мәрхәмәтле җаннар!

Барлыгы өч йөз чакрым җир узып, юлга чыкканның өченче көнендә генә Госман Имәнтауга кайтып җитте. Ул тәбәнәк өйнең җимерек диярлек ишеген какканда, дөм караңгы иде инде. Алай да, тәрәзәгә чиртүгә, анасы йөгереп чыкты.

— Улым! Выты, тәрәзәгә кагылуыңнан таныдым!

Шыгырдап, ыңгырашып, бабасы да торды. Госман үзе белән майшәм алып кайткан иде, шуны кабыздылар, әнисе кабаланып чыра телде, ул арада самовар да гөжләде. Госман җавап биреп өлгерә алмый, сорауларны бабасы белән әнкәсе алмаш-тилмәш яудыралар. Ничек эшлисең? Өйрәндеңме? Кемдә торасың? Ни ашыйсың? Керләреңне кем юа? Мунча бармы? Оекбашың тишелмәгәнме? Начальнигың ничек? Японнан

пленныйлар кайтмыймы? Тагын шуңа охшаган йөз сорау, мең сорау!

Госман жалованьесеннән кысып килгән акчага сатып алган күчтәнәчләрен сәкегә чыгарып тезгәч, йокы качты, өй эче яктырып китте: ике бөтен ак калач, өч кадак кызыл билле прәннек, бер башлы шикәр, почмакларына карлыгач сурәте күпертелгән бер такта кытай чәе.

Өйдәгеләрнең башы күккә тиде, мактый-мактый, самоварны яңарта-яңарта чәй эчтеләр. Әмма иң куанычлысы чәй уртасында булды.

— Бабакай, выты, сиңа чәчүлек алырга! — Госман шыгырдап торган ассигнацияләрне бабасының калтыранган кулына тоттырды. Аталы-кызлы елап җибәрделәр.

— Бу көнне дә күрәсебез бар икән, ярабби!

— Аллага мең шөкер.

Барысы да яхшы, ләкин, алда тагын мөһим бер-ике эш бар иде. Госман юл буе: «Бәлки, өйгә кергәнче үк Баһауны күреп сорашырмын»,— дип җилкенгән иде. Станицага бик соң кайтып җиттеләр шул...

Иртәнчәк Госман чәй дә эчеп тормады, «хәзер кайтам!» дип, староста конторасына йөгерде. (Уен түгел, хәзер ул станицада атаманнан кала икенче кеше!) Госманның беренче йомышы бик гади: язгы чәчү чорына үгезләр биреп тора алмас микән?! Икенче йомышы четреклерәк...

Контора атаман правлениесе каршындагы бер бүлмәдә икән. Баһаветдин шунда. Дуслар кочаклашып күрештеләр. Баһау тулыланып, калынаеп киткән. Битләре шоп-шома, ялтырап тора. Ә дуслык?!. Кәрәкерешкә Баһаветдин үз язмышы, үз хәле белән мактанырга тотынды. Сөйли дә сөйли. Госманга сүз әйтергә дә ирек бирми. «Юк,— дип уйлады Госман,— бу шома егеттән хәзер язга үгезләр сорап торуның файдасы булмас! Белеп, үзе тәкъдим итсә генә инде!»

Бераздан Баһау аңга килеп, тукталды, күзләрен майландырып карады да шап иттереп дустының аркасына сукты.

— Бак! Нигә кичә килмәдең? Выты, сине эзләделәр.

— Кем?

— Кем булсын, сөяркәң!

— Нинди сөяркә? Әйт инде адәм сынлы, кем эзләде?

— Кем булсын?! Маша!

— Да?! — сикереп торды Госман. Икенче йомышы шул, Маша турында беләсе, белешәсе килә иде.— Кайда ул?

— Кичә китте.

— Кая китте? — Госман дустының күзенә керә язды.— Кая?

— Кая булсын, Омскига, гимназиягә.

— Да-а? — Госман күңелсезләнгәнен яшереп тә тормады.— Ә мин аны күрермен дип кайткан идем.

— Үткән атна башында ук каникулга кайткан иде Маша,— дип аңлатты Баһау.— Минем янга килде. «Усманка кайда икән, белмисеңме?» — ди. Мин әйтәм, Атбасарда, дим. «Кайчан кайтыр икән, күрәсе килә!» — ди... Ну, матурайган малай, дама булган! Исең китәр, янып тора. Буй дисеңме, гәүдә дисеңме?..

Баһаветдин, күзләрен яндырып, кулы белән ямьсез ишарәләр ясады.

— Эх! Бер көн алдан кайткан булсам!

— «Әгәр Усманка кайтса, сәлам тапшыр. Мин җәйгә кайтам»,— диде. Әйдә безнең өйгә, Хупҗамалдан бишбармак пешертеп, бераз сыйланып утырырбыз.

Һәм Баһау Госманның ризалыгын да көтмичә үз тормышын, хатынын мактарга тотынды, Госманнан «ни хәлләрең бар?» дип сорарга да онытты.

— Юк, миңа почта атлары белән китәргә кирәк!

Күңеленнән генә «миңа шимбә кичәсенә, һичшиксез, кайтып җитәргә кирәк!» — дип уйлады, тик уен Баһауга белдермәде.

Мәрфук янына да йөгереп кенә кереп чыкты, ары-бире кыска-кыска гына хәбәр алыштылар. Иртәнге чәйдән соң ук Госман китәргә җыена башлады. Җәфрәтил карт та, Әминә дә аның ашыгуының сәбәбен аңламадылар. Машасыз Имәнтау Госманга бик ямьсез, сагышлы һәм моңсу булып күренде. Аның тизрәк моннан китәсе, Атбасарда эше, дуслары белән онытыласы килә иде. Тик ананың сүзе бетмәгән иде әле...

— Бәбкәм,— диде ул улын каршысына утыртып.— Күрәсең, мин гел авырып торам. Бабаң да сырхау. Өйгә дөнья көтәр кеше кирәк. Атаман кызы безгә иш булмас. Бу ызбага килмәс. Менә күрше Мачы Гыйлаҗның кызы җитте — җиләк сынлы, үзе тырыш, үзе сылу...

Госманның күкрәгенә ут кереп тулды, ул утырган урыныннан сикереп торды да:

— Җитәр,— дип кычкырып, ызбадан ук чыгып китте...

Аннары юл буе үкенеп барды: нигә әнкәсен рәнҗетергә иде инде? Нигә юатмыйча чыгып китте? Машаның китеп баруында аның ни гаебе бар? Күңеле белән бары тик яхшылык кына тели ич ул баласына!

Ул почта атлары белән Күкчәтауга кайтты. Ләкин Атбасарга китәсе почта әзер түгел иде әле, берәр сәгать көтәргә туры килер, диделәр. Бу сүзне ишетүгә, аның күңеленә кылт итеп бер уй төште: «Тукта! Барып чыгарга кирәк, бәлки өйдәдәр!» Ул шунда ук Миңлебай абыйларына да кермичә тау ягына йөгерде. Госманның әллә кайчаннан бирле Валерианны күрәсе килеп йөри иде. Теге, тау ягындагы мәгарәдән шаушулы кәгазьләрне алып кайтып Күкчәтауда таратканнан бирле очрашалганнары юк аларның. Фронттан кайтканда да сугылган иде, капкалары бикле иде. Ә күрәсе иде үзен, Валерианны! Хәзер, әлбәттә, офицердыр үзе. Рядовой казак белән әллә ни алыш-биреше дә булмас... Алай да... Бигрәк тә соңгы көннәрдәге яңа уйлар, яңа иптәшләр, яңа сүзләр аны яшьлек танышы Валерианга таба этәрә иде. Ул да шуңа охшашлы сүзләр сөйли иде, «ярлылар», «байлар» дип кискен рәвештә аларны каршы куя белә иде. «Азатлык» дигән сүзне дә еш әйтә иде...

Тау итәге. Әнә, урам аркылы чыккач — күл. Чат башында бакчалы йорт. Ул туп-туры парадный ишеккә какты. Ачтылар. Өйдә Юлия Николаевна үзе генә иде. Нигәдер күңелсез, йөзен сары сауган.

— Сезгә кем кирәк?

— Валериан кайтмадымы?

— Ә сез кем соң?

— Мин аның балачак дусты. Хәтерлисезме, мин сезгә килеп йөри идем. Сез мине русча укырга-язарга өйрәттегез.

— Гафу итегез, танымадым. Нинди мәһабәт ир-егет булгансыз. Узыгыз, чишенегез. Мин хәзер самовар куям.

— Рәхмәт, Юлия Николаевна, мин бик ашыгам. Узышлый гына Валерианны бик күрәсем килгән иде.

— Валериан хәзер Петербургта, медицина академиясендә укый. Язмышы бик тынычсыз булды күз нурымның...

Бераз сөйләшеп торганнан соң Госман саубуллашып чыгып китте, Юлия Николаевна аны елый-елый озатып калды. Аңламассың бу халыкны! Улы пайтәхеттә академиядә укый, ә әнисе елый! Нигә еларга инде, куанырга кирәк!..

Почта атларының дугасында пар кыңгырау чылтырый. Дала! Болытлар аз-маз таралдылар да кояш күренде. Ул инде Күкчәтау янындагы ялгыз карагайлы йомры тау өстендә. Кояш, өшәнгән болытлардан качарга теләгәндәй, акрын гына өскә күтәрелә.

Госман ерак тау башына, андагы ялгыз карт карагайга карады да тирән уйга калды. Йөрәкне нидер чәнчеп алгандай булды. Әрнеде, сагынды... Бак, гомер ничек тиз уза, толпар ат чапкан кебек. Әле кайчан гына, алар шушы ялгыз карагай сопкасы итәгеннән Шаһимәрдән

хаҗиның куйларын әйдәп Куянды юлына чыкканнар иде. Бәхет эзләп. Бәхет өчен тилмереп! Кайда ул якын дуслар, юлдашлар?! Нәсия чал? Лачынбай? Иркәтай? Нигъмәтләр? Кайда сез? Кычкырасы, чакырасы, сөйләшәсе килде. Еракта калган дусларны бүген очратасы иде, хәзер!.. Нишләделәр икән мескеннәрем? Нәсия чал үзенең Шаһимәрдән хаҗига бирәсе бурычын түләп бетереп, ата-анасы биргән хәләл исеме — Бәхетҗанга җитә алдымы икән? Ә Лачынбай? Һәм үтә усал, һәм үтә шәфкатьле юлдаш! Син ничек, калым малыңны түләп, сөйгән ярың белән кавыша алдыңмы? Үз учагыңны кабызып җибәрә алдыңмы?

Ә син, шигъри җан, моңлы һәм зарлы Иркәтай? Кайда синең күңелләрне җилкендерә торган үләңнәрең? Айдай биек, айдай сылу Айкөмешкә җитә алдыңмы, мәҗнүнем?!

Кайда син, хәйләкәр һәм фидакарь дустыбыз, туендыручы «алтын таз»ыбыз Нигъмәт?

Менә, һич уйламаганда ул Кәримне очратты, Сабир белән күреште... Ә сезләр кайларда?!

Йөрәк ярсый. Йөрәк ярсуын сүзләр белән генә аңлатып бетереп буламы соң? Госман җырлап җибәрде.

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем барсын да.
Уйлама күңлем барсын да,
Син уйлап шашарсың да!..

Нәкъ атлар алдыннан бер йолкыш куян атылып узды, атлар, өркеп, чак кына повозканы аудармадылар. Госман тезгенне чак-чак тартып, атларны юлга борып өлгерде. Күкчәтаудан чыкканнан бирле толып астында йоклап кайткан ямчы Әгъзам уянды, йокылы тавыш белән:

— Ни булды? Айдабулга җитмәдекме? — дип сорады.

— Юк әле, Зирәнде таулары гына күренә.

— Айдабулга житкәч уят, атларны алыштырабыз.

Әгъзам ваемсыз икенче ягына әйләнде дә толыбын башыннан ук тартып тагын йоклап китте. Ә Госманны уйлары тартып тора, уйлары егетне йокыга бирми. Бераздан озын үр менеп урманга керделәр һәм озакламый Зирәнде станицасына барып җиттеләр. Димәк, Күкчәтаудан алтмыш чакрым киткәннәр. Тагын йөз кырык кына барасы калган! Станицада атларны алыштырдылар һәм ямчы карт казакта чәй эчеп, тамак ялгап чыктылар.

— Инде, Госман, син бераз йоклап ал, — диде Әгъзам.

— Кая ул, йоклый алмам мин! — дисә дә, арганлык үзенекен итте, Госман пар кыңгырау моңы астында тирбәлеп татлы йокыга талды...

Шимбә кичәсенә кадәр бик күп эшләрдән арынырга кирәк иде. Госман җене кузгалгандай эшләде, агентстводагы агымдагы эшләрдән тыш берничә казах авылы — кышлауга страховка эше белән барып кайтырга да өлгерде...

«Коръән хәтем кичәсе...» Кызык, кем мондый мәзәк исем куйгандыр. Барып керүгә, Госман аптырап калды. Алай гына да түгел, ник килгәненә үкенде. Шикләнде. Шөбһәләнде. Шикләнмәслек тә түгел бит, тәрәзә капкачлары ныгытып ябылган, пәрдәләр төшерелгән. Госман килеп керүгә, ишекне яптылар да, Кәрим бер егеткә шыпырт кына: «Хәкимулла, бүген ишектә синең чират!» — диде. Егет ишек янына барып басты. «Алай-болай ят кеше шакыса, ачма, әүвәле үземә килеп әйт!» — дип тә кисәттеләр егетне. Я, ничек шикләнмисең ди инде? Җыелганнарның йөзе җитди, кырыс... Ничек шөбһәләнмисең?..

Бу юлы залда халык та аз, унбиш-уналтылап кына кеше иде ахрысы. Госман арттагы урындыкларның берсенә утырыр-утырмас, Кәрим алдагы өстәл янына килеп басты, беравык тынып, күзәтеп торды да ышанычлы тавыш белән бик сәер сүз башлады.

— Хөрмәтле әфәнделәр, бүген безнең «хәтем»дә яңа кеше бар. Ул — Госман әфәнде Әбдрәшитов (Алгы рәттән берничә кеше борылып-борылып Госманга карап алдылар). Ул Имәнтау станицасыннан. Ярлы баласы. Күптән түгел генә яраланып сугыштан кайткан. Хәзер безнең Атбасар агентствосында эшли. Ул безнең, Сабир әфәнде белән икебезнең, күптәнге ышынычлы дустыбыз. Бәс, шулай икән, Госман әфәндегә карата һичбер шик-шөбһә булмаска тиеш. Озын сүзнең кыскасы, «хәтем»не башлыйбыз. Бүген безнең «карыебыз» Дмитрий Андреевич. Ул бүген безне социал-демократлар оешмасы чыгара торган «Искра» газетасы белән таныштырачак. Пожалуйста, Дмитрий Андреевич!

Күперен торган артка таралган чәчле, 25-27 яшьләр тирәсендәге күзлекле бер кеше елдам гына урыныннан кубып, җыелганнар каршысына чыгып басты, күзлек пыялалары ялтырап китте. «Дмитрий Андреевич! Мөгаен, Ушаков! Пар тегермәнендә механик булып эшли, Казан университетыннан куылган! — дигән иде бит Кәрим. Шулдыр! Үзедер!»— дип уйлады Госман.

Ушаков куен кесәсеннән шактый нык таушалган газета чыгарды...

Шул кичәдән соң атна узды. Бүген мәнә тагын шундый очрашуларның берсе. Барыргамы? Бармаскамы? Мондый яшерен, әллә кайларда — чит илдә чыгарыла торган газеталарны укый торган җиргә йөрүнең ахыры хәерле булырмы? Ул бит казак! Падишаһ хәзрәтләренә тугры хезмәт итәргә ант биргән кеше! Җитмәсә, Георгий крестлары алган, казачествоның төп терәге!

Бу юлы Госман кыйраәтханәгә теләр-теләмәс кенә барды. Ишек бикле иде. Госман ялт кына борылып та китмәкче иде, кызыксынуы шөбһәне җиңде.

— Кем бар? — диде ишек артындагы тавыш.

— Мин. Усман Абдрашитов.

Ишек ачылды, бүген «сакчы» Кәрим үзе икән.

— Соңладыгыз, Госман әфәнде, соңладыгыз,— диде Кәрим рәнҗүле һәм шелтәле тавыш белән.— Башка чакта әйтелгән вакытка килергә тырышыгыз. Сез бөтен эшне бозасыз!

Залга күтәрелделәр. Анда шул ук беркөнге кешеләр утырышкан иде, тик аргырак урындактагы ефәк ленталы башлык кигән хатын-кыз гына Госман өчен ят... Ул, Госман керүгә, борылып карады да елмайды... Мәдинә туташ ич бу! (Ә елмаюы нинди мөлаем!) Башкалар да карадылар. Башкалар елмаймыйлар иде, соңга калган өчен шелтәлиләр булса кирәк!.. Әйе, монда катнаша алу җыелганнарның һәммәсе өчен дә үтә мөһим, үтә җитди эш ахрысы. Госман аларның кырыс карашларыннан шуны аңлады. Кәрим эшлекле тон белән кичәне ачып җибәрде:

— Мәдинә туташ... һәм хөрмәтле әфәнделәр! Аз гына тоткарлык булды, гафу итегез. Госман әфәнде казна хезмәтендә, аның ашыгыч эше булган. Әлхасыйль, чираттагы «хәтем»не башлыйбыз. Бүген Дмитрий Андреевич безне Ульянов Владимирның, партия ләкабе Ленин, «Мең тугыз йөз бишенче ел революциясе һәм аның сабаклары» дигән мәкаләсе белән таныштырачак. Рәхим итәсез.

Өстәл янына тагын теге күперенке чәч чыкты, күзлек ялтырады. Ушаковның кулында һәфтияк хәтле генә бер китап иде...

Кеше дөньяда ни өчен яши?

Ни өчен?

Ул кая бара?

Нигә бара?

Нигә берәүләр чамасыз рәхәттә, икенчеләр коточкыч михнәттә яши? Нәрсә ул азатлык һәм көрәш?

Моңа охшаш сорауларның Госман башына килгәне юк иде моңарчы. Хәзер көн туды исә аның миен сораулар тыгызлый, бабасының язмышы турында да уйлый ул. Байга кияүгә чыгып гомере буе газап чиккән Мәрфукны да исенә ала... Имәнтауның башка ярлыларын да күңеленнән

уздыра... Бак, дөньяда үзе өчен генә түгел, башка гидайлар язмышын кайгырта торган кешеләр дә бар. Выты, ул Ульянов дөрес әйтә! Шунысы начар: падишаһ хәзрәтләренә тел тидерә! Куркыныч! «Мин бит ак билет түгел, жукә аяк та[1] түгел, боевой казак! Әле өй салырга кирәк... Ат, сыер кирәк... Политика белән аларны алып булмый. Опасно! Куркыныч!»

Госман иптәшләрен озатып кайтып бара. Йорт ишегалдындагы янбакчаларда шомырт, сирень агачлары шау чәчәктә. Хуш ис... Ә күңелдә тынычсызлык... Нигә дөнья болай катлаулы икән?!

## 24

Җәй башында кыйраәтханәнең утырышлары тукталды. Кәримне Кызылъярга байның доверенные итеп күчерделәр. Элекке доверенныйнык кына урлашкан да, бай моны сизеп алган, борыны озын! Ә Сабир, көннәр җылынып, утырып китүгә үк, Гаделбәк белән авылга, кымызга китеп барды... Мәдинә туташ та байтактан күренми... Госман ничектер сагышланып, ямансулап калды...

Җәй күңелсез һәм төссез узды.

Ярый әле Сергей Иванович, бар эшне үз өстенә алып калып, егетне унбиш көнгә Имәнтауга кайтарып җибәрде. Госман чәчкән игенне урыпҗыеп, урнаштырып, кышлыкка җитәрлек печән, утын әзерләп килде. Әминә белән Җәфрәтил картның сөенече күккә ашты, алар арзан гына бәягә бер тана да сатып алдылар. «Быел кыш тук булабыз!» — дип рәхмәтләр яудырдылар алар Госманга. Ярлы өйгә күптәннән мондый куаныч иңгәне юк иде! Дөрес, аларның тагын бер ниятләре бар иде, аны башта ук Госманга белдерергә базмадылар, эш ахырына таба гына Әминә кыеп сүз катты: «Әле рәхмәт, анда-санда Мачы Гыйлаж кызы Гөлниса кереп, керен уып, су ташып булышып китә. Күз генә тимәсен, үзе сылу, үзе житез, үзе пөхтә... Кем бәхетенә үсәдер алтыным!» — дип, улының кылын тартып-тартып караса да, Госман аны-моны сиздермәде.

Кызганычка каршы, җәен дә Маша белән очраша алмадылар. Ул Госман кайтканчы ай чамасы станицада торып киткән, Баһау янына кереп сорашкан, «Нигә ичмасам бер хат язмый!» — дип өзгәләнгән.

Баһау Госман кайтканның икенче көнендә үк аны үз янына чакырып алды, «Атбасарда юк хакка әрәм булып ятасың, тот та Машага өйлән, ичмасам кеше төсле яши башларсың!» — дип ачуланды. Аның сүзен бу юлы көлемсерәп кенә тыңлады Госман. Староста Баһаветдин баеп киткән, анда-монда сәүдә йөртә башлаган, бабасы Кәлимулла бай белән борчагы бик шәп пешә башлаган иде инде. Ярлыны байдан, акны карадан аера башлаган Госман яшьлек дустының кабарып пешкән бодай калачы кебек тулышкан битләренә карап әллә ниләр уйлады. Тик аның сүзенә тиз генә ияреп китеп, Баһаветдиннең фикерен хуплый да алмады. «Нәрсә ул хат? Шулай озак күрешми торгач ни язарга да белгән юк! Ул гимназистка. Минем сүзләрдән көләр генә!» — дип хафаланып уйлады Госман кыз турында...

Шул елның көзендә страховое-транспортное агенствоның идарәсе Госманны Кызылъяр каласына үзәк агентствога күчерде.

Сергей Иванович белән Мария Петровна, бу хәбәрне ишетүгә, бөтенләй коелып төштеләр. Кичкырын Мария Петровна табын әзерләде, чоланнан тозлы кыяр, кәбестә алып кереп утыртты, балык куырды. Сергей Иванович шкафтан өч рюмка китереп куйды да түргә Госманны утыртып шешәнең сургучын боза башлады. Үзе бертуктаусыз зарланды:

---

[1] Жукә аяк — чабаталы, урта Россиядән эш эзләп килүчеләр.

— Карт юләр мин! Шыр тиле! Петропавловскига отчет белән баргән саен Фаддей Кирилловичка Усман Умаровичны мактадым. Әйтәм тегеңә: сүз тыңлый торган егет, тырыш, пөхтә. Русча да яхшы белә. Татарча да. Кыргызча белә, дим. Аракы эчми, тәмәке тартмый... Ахмак мин! Үз башыма мактаганмын!

— Ә грамматиканы ничек яхшы өйрәнә иде! Синтаксисны уза башлаган гына идек!.. Дөрес әйтәсең, җүләр син. Саескан төсле такылдап йөргәнсең дә, хәзер үзең кем белән каласың?!

Картлар чынлап торып хафага калганнар иде, аларның хәсрәтен «юу өчен» аз булса да хәмер тотарга туры килде, ризыкларны мактыймактый ашадылар. Сергей Иванович Госманны мактады, ике сүзнең берендә үзен яманга чыгарып, үкенеп утырды...

Текә, кызыл балчык яр. Ярларга кысылып, тынсыз гына елга ага. Казахлар аны Исел үзәне диләр. Исел — Ишел, ишелеп төшкән яр астындагы елга була. Руслар, аны казахчадан бераз үзгәртеп, Ишим дигәннәр һәм елга географик карталарга шул исем белән беркетелеп калган.

Ишелнең ярлары тәбәнәк, агымы акрын. Ул төньякта башлана да дала буйлап көньякка Атбасар, Акмула якларына юл тота. Елганың ике ягында да иксез-чиксез казах сахрасы. Анда гомер-гомергә көмеш диңгез булып дулкынланган кылганнар... Тик ара-тирә генә бу диңгез уртасында яшел утрау булып вак каенлыклар, тубылгы, чия, гөләп куаклары, таллыклар күренәләр дә, тагын офыкларга сузылган көмеш диңгез.

Җәйләүләр, җәйләүләр. Җәен монда көтү-көтү сыерлар, атар-атар куйлар, өер-өер жылкылар утлыйлар да, сусыл үләннәрне ашап туйгач, Ишел буена килеп, иренеп кенә сусыннарын кандыралар. Судан ерак та түгел алка-алка киез өйләр күренә. Болары — авыл. Авыл кар төшкәнче уттан-утка мал артыннан күчеп йөри...

XVII йөз башларында бу далаларга атаман Ермак командалыгында казак-урыс отряды килеп чыга. Бу киң, кара туфраклы, үсемлекле, мал-туарга, кош-кортка бай симез дала — Сары арка аларга бик ошый. Отряд Кызылъяр кышлавында туктый. Килгән казак-урыслар монда нык каралтылар сала, хәрби ныгытмалар, валлар торгыза. Бу аванпост Горькая линия чылбырында бер форпостка әверелә. Кала барлыкка килә. Бу калага изге Петр һәм Павел исемнәрен бирәләр, «Петропавловск» була. Казах халкы гына бүгенгә кадәр каланы «Кызылъяр» дип йөри.

XIX йөз ахырында, бу каланы басып, транссибирь тимер юлы уза. Мәскәүдән Владивостокка кадәр сузылган бу гигант юл Кызылъярны көнбатыш һәм көнчыгыш белән тыгыз бәйли, аңа җан өрә. Тимер юл Мәскәүдән, Петербургтан, Казаннан, Мәкәрҗәдән һәм башка үсеп барган калалардан бу далаларга яңа кешеләрне, эшкуарларны ашыгыпашыгып ташый башлый. Купецлар, поплар, промышленниклар, фабрикантлар, караклар, муллалар, фахишәләр, балта осталары, кырык тартмачылар, юлбасарлар, шпионнар һәм башкалар ит-май, йон-ябага, игенбодай исен сизеп далага агылалар. Шәһәрдә яңадан-яңа таш пулатлар, складлар, дөкәннәр, пар тегермәннәре, чиркәүләр, мәчетләр, кабаклар, фәхешханәләр, консерв заводлары һәм башкалар салына. Кала үсә. Халык арта. Инде тыгызланып килгән йортлар яр өстенә генә сыймыйча, яр астына да төшә. Ишелдә йон-ябага юу, озату пунктлары барлыкка килә, кызылъярлылар икегә бүленәләр: югары каланыкылар, түбән каланыкылар. Шулай итеп, кайчандыр дала уртасында югалып калган кечкенә генә кышлау озакламый Себернең һәм төньяк Казахстанның зур шәһәренә — экономик, политик һәм культура үзәгенә әверелә.

Сәүдәгәрләр, купецлар, заводчиклар белән бергә эшчеләр сыйныфы да барлыкка килә. Тимер юлчылар, консерв заводы, Муратов тегермәне эшчеләре, мойкада йон-ябага юучы татарлар, Шәмсетдин, Шәһвәли, Аксирәк, Күкмуен, Бүре Мөхәммәтҗан һәм башка байларда эш-

ләүче ялчы малайлар, жылкычылар, керә тартучылар, ямчылар, касапчылар, тиречеләр, күмер сүндерүчеләр, кара май кайнатучылар, балтачылар, тимерчеләр, коноваллар, лудильщиклар һәм башка бик күп «жүкә аяклар».

Байбәтчәләр эчеп алгач:

> Петропавел каласында
> Алты мәчет, биш чиркәү.
> Ялгыз жырлаулары читен,
> Әйдә, жырлашыйк икәү! —

дип жырлыйлар һәм үз калаларының «барлыгы» белән мактаналар.

Мәчет-чиркәүләрдән башка монда атаклы үзәк төрмә, бер пересыльный төрмә дә бар — эчке Россиядән Себергә сөрелгән барлык арестантлар Петропавел төрмәсенә тукталмыйча калмыйлар. Бөек Себер тимер юлы, богаулар белән чыңлаган, аһ-зарлар белән ыңгерәгән бөек газап юлы да була.

Менә шундый тарихи, мыж килеп торган шәһәргә Имәнтау казагы Госман Әбдрәшитов килеп төште...

Миңлебай абзасының ахирәтләре кайда гына юк! Монда да ирле-хатынлы берәүләр бар икән, түбән калада яшиләр. Кушаматлары бик сәер: ире Валлаһи Гыйльметдин, хатыны Билләһи Гарифә икән! «Нигә алай?»— дип сорады Госман. Миңлебай абзасы көлә-көлә аңлатып бирде: «Гыйльметдин ике сүзнең берендә Валлаһи! ди, ә Гарифә билләһисез авыз да ачмый!..»

Госман кара фанер чемоданын тотып ямчылар йортыннан чыкты да Югары каланы буеннан-буена узып Түбән калага китте. Ярдан төшеп кузна уйнап йөргән малайлардан:

— Гыйльметдин дигән кеше кайда тора? — дип сорады. Малайлар аптырашып бер-берсенә караштылар:

— Белмибез, абый.

Миңлебай абзасы әйткән сүзгә ябышырга туры килде!

— Ә алайса Валлаһи белән Билләһи кайда яши?

— Ә-ә,— диделәр малайлар берсен-берсе бүлеп.— Валлаһи абыйлар әнә теге жил капкалы йортта!

Хужалар өйдә икән. Госман авыз ачып абзасының исемен әйтергә генә өлгерде, йорт хужасы:

— Валлаһи дим, Миңлебай безнең якын кеше! Син аның энесе икәнсең, әйдә, түрдән уз! — дип сәкедән урын бирде.

— Билләһи, самоварым да кайнап тора иде! — дип, Гарифә апа чәй әзерли башлады...

Госман — күңеленнән Фаддей Кирилловичны, шундый агентствоның губерна күләмендәге башлыгы булгач, мәртәбәле урында утыргач, бик ягымлы, рәхимле галижәнап зат булыр, үзе чакыртып китергәч якты йөз белән каршылар дип өметләнгән иде. Әмма кабинетка кергәч таралып калды. Кеше урынына өстәл артында дәү бер кызыл сакал утыра иде. Кызыл сакал өстәлгә иелгән дә кыска буынлы бармаклары белән ялт-ялт кәгазьләр актара, күтәрелеп тә карамый.

— Сезнең чакыру буенча Атбасар агентствосыннан Усман Әбдрәшитов!

Кызыл сакал һаман өстәлне себерә иде, тыңкыш тавыш белән бер генә жөмлә кысып чыгарды:

— Пока сортировкага.

Бераздан:

— Иван Матвеевич янына. Аннан күз күрер. Китәргә мөмкин,— дип өстәде.

Башка тукмак белән суктыLармыни! Кайда калды нурлы йөзле миһербанлы Сергей Иванович!.. Ишегалдына чыгуга, аның үе ашыгып-ашыгып чаба башлады: «Сортировкага кереп тормаска! Хәзер үк Атбасарга кайтып китәргә! Әле кеше алып өлгермәгәннәр булыр! Мондый кызыл сакаллы түмгәкләр арасында бер минут та тормаска!» ...Уй йөгерде-йөгерде дә тукталып, тынычланып калды... «Монда зур кала... Кәрим монда... Башкалар! Сортировка эш түгелмени?! Имәнтауга кайтыр идеңме әллә? Ачлыкка-ялангачлыкка. Яки Баһаветдин сыман Кәлимулланың бәйдәге эте булыргамы?! Дөньяда яхшылык һәм явызлык барын белә башлаганда гына! Аз-маз күз ачылганда?! Юк, кызып китәргә һич тә ярамый. Сабыр һәм сабыр акыллы була белергә кирәк... Бәлки, монда Машаны очрату да җиңелрәк булыр?!»

Уйларының кайсысы өстенлек алгандыр, Госман кырт кына борылып, киң ишегалды аша узды да сортировка ишеген шакыды.

Ачса, монда кара сакал! Шулай ук киң өстәлгә иелгән, кыска бармаклары белән кәгазь актара... Тик ул кирә-кирешкә, сакал өскә күтәрелде һәм сикереп торып Госманны кочаклап та алды.

— Усман Умарович, дорогой! Мин сине кичә үк көткән идем! Нигә килмәдең?! Мин Иван Матвеевич булам...

Иван Матвеевич Госманны кочаклап диярлек түргә китереп утыртты, бертуктаусыз сорашты, үзе сөйләнде, сүз арасында калай чәйнектән чәй ясарга да өлгерде, әллә кайдан, шкаф тартмасыннан аллы-кызыллы манпаси ди тартып чыгарды, кыстады, әйләнде-тулганды, кунакның шинелен салдырып, җиң очлары чачакланган соры халат та кигертеп өлгерде. Ярты сәгать дигәндә чәй эчеп тирләгән, хуҗаның күп сүзеннән колагы тонган Госман шатланып, куанып, посылкаларны күчерә, хат тутырган капчыкларны очыртып йөртә башлаган иде инде...

Шәмсетдин байның доверенные булып алган Кәрим, әлбәттә, Госманның да Кызылъярга күчүе турында ишеткән иде инде. Беркөнне сортировкада эшен бетереп, тузанлы киемнәрен кага-кага урамга чыкса, Госман чатта үзен көтеп торган Кәримне күреп шатланып кычкырып җибәрде.

— Бак! Бу синме, Кәрим!

— Әбдрәшитов! Ишеттем, тауга күтәреләсең! Синең үзәк агентствода эшли башлавың искиткеч яхшы булган.

Кәрим, Госманның кулын озак кына кысып-селкеп торса да, ниг өчен «яхшы булуы» турында ачыклап тормады, алар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләшеп, яшь кар яуган урам буйлап киттеләр.

Урамда сүз, уйнаклап, бер урыннан икенче җиргә җиңел генә күчеп йөргән иде. Кәримнең фатирына кайтып, чәй янында икәүдән-икәү генә калгач, ул сүзне шунда ук җитди якка борып җибәрде:

...Инде сезгә иң мөһимен әйтим, Госман әфәнде. Мин сезгә ышанам. Күпне кичергән кеше дип белеп ышанам. Һәрхәлдә, ят кешегә бу серне чишмәссез.— Госман, бераз каушап, чәйле чынаягын кире өстәлгә куйды.— Кызылъярда социал-демократлар оешмасы эшли. Без алар белән байтактан белешеп яшәдек. Атбасардагы «коръән хәтем» кичәләренә алынган байтак брошюралар, газеталар алардан килә иде. Бу оешманы Омскидан килгән бер кадет төзегән. Мин ул егетне беләм. Бик кыю, яшь булса да, тәрәккый, пәрвар, нык холыклы иптәш. Инде менә шул оешмада мөселман секциясен булдыру күздә тотыла. Без секциягә тартырлык ышанычлы, эшлекле иптәшләрне күздән кичереп карадык. Мин синең монда күчерелгәнеңне ишеткәч, теге кадетка (аның партия ләкабе Артем) әйткән идем, ул нигәдер, синең белән бик нык кызыксынды. «Монда килүе белән безне очраштырырга тырыш!»— диде... Шуңа күрә бар эшемне ташлап мин бүген сине көтеп тордым. Ми-

нем йорт хуҗалары Мәүлет авылына гает чәенә кунакка киттеләр. Өй аулак. Сиңа уйларга бер тәүлек вакыт. Әгәр секция эшенә катнашам дигән карарың нык булса, иртәгә кич кырын, шушы вакытларда безгә кил. Мин Артемга да хәбәр иттерермен!

Госман, гадәтенчә, җиде кат үлчәргә ярата иде, аның аңына иң әүвәл: «Ни өчен кадет? Кадет социаль-демократ була аламы?» — дигән шикле сорау килде. Икеләнеп калуын сиздермәс өчен ул иплап кенә чәен эчеп бетерде, Кәрим кыстаса да, чынаягын каплап ук куйды.

— Килермен,— диде ул кыска гына итеп.

— Мин синнән башка сүз көтмәгән дә идем! — диде Кәрим аның кулын нык, иптәшләрчә кысып...

Яңа урында беренче көннәр, беренче атналар! Монда Атбасарның талгын хәрәкәтле агентствосы түгел икән! Почта капчыклар белән йөрми, вагоны-вагоны белән килә! Беренче тапкыр перронга почта алырга чыккач, Госман хәйран калды. Вагоннардан «тизрәк, тизрәк!» кысрыклыйлар, бәйләм-бәйләм газета-журналлар һавада оча, кочакка капчык-капчык бандерольләр, хатлар килеп төшә, кыямәт! Тартма-тартма посылкаларны каурый шикелле генә очыртып йөртәләр... Вагонеткаларны сортировка складына китереп бушаткач, кыямәтнең икенче өлеше башлана: юл документларын тогәлләү, төп кенәгәләргә теркәү, төрле калаларга, станицаларга ялгышмыйча бүлү башлана...

Ярый әле Иван Матвеевич тырыш. Гадәттә, күп сөйләгән кеше эшендә төртелә, ә Иван Матвеевич сөйли дә, эшли дә белә. Кулы кулга йокмый, теле тегермән әйләндерә...

Госманның кулы эшли, һич кенә дә сөйләшәсе килми! Бүген кич ул Кәримнәргә барырга тиеш. Хәзер икеләнергә урын калмаган! Алар һәммәсе дә бер җепкә бәйләнгәннәр. Тик күңелдә һаман да шикләр күп калган әле. «Социал-демократлар оешмасы. «Кадет!» Ул үзен аркылы-торкылы каешлар белән чорнаган кадет каршылар дип уйлаган иде, ә түрдәге йомшак кәнәфидә гап-гади киенгән, ябык кына, күпереп торган мул чәчле, зур борынлы, аз гына чыгынкы иякле кеше утыра. Госман тагын берәүне эзләп як-ягына каранып та өлгерде, юк, башка берәү дә юк. Өстенә дөя йонынннан тукылган гармун якалы кызгылт свитер, кара постаудан тегелгән туры чалбар кигән бу кешедә кадетның «к» хәрефе дә юк иде.

— Усман Абдрашитовмы!!? — диде ул зур күзләрен тутырып ачып.

— Мин.— Госман чайкалып китте. Ул арада кадет озын кулларын җәеп Госманны кочаклап та алды.

— Сөбханалла, машалла! Бу ни бу! Волик! Валериан! Валериан Владимирович Куйбышев! Ә нигә «Артем»?

Кәрим моны көтмәгән иде ахрысы, өстәл янындагы камыш урындыкка лып итеп килеп утырды.

— Сез танышлармы?

— Әйе,— диде Валериан Госманның кулын тагын да кыса төшеп.— Әйе, мин Куйбышев. Тик әлегә мин барыбыз өчен дә «Артем».

Берни аңламыйча күзәтеп торган Кәримгә «Артем» белән Госманның танышлыгы кайчан башланганны сөйләп бирергә дә туры килде. Сүз иярә сүз чыкты, Госман: «Юлия Николаевнаны очраттым, бик күңелсез иде, җылап озатып калды»,— дигәч, Валериан бер генә мизгелгә, маңгаен җыерып, уйланып торды...

— Аның мине офицер итәсе килгән иде дә, хәзер мин алай була алмыйм шул инде! — диде ул кайнарланып. Ул 9 нчы январь фаҗигасының үзенә аерата тирән тәэсир ясавын, Омск заводларында, тимер юл мастерскойларында шул уңай белән җыелышлар уздырып йөрүен, халыкны, тыныч демонстрацияне атып, меңләгән гаепсезләрне һәлак иту-

челәрне җавапка тарттыруларын таләп итеп эшчеләрдән кул куйдырып йөрүләрен, бу резолюция-протестны патшага җибәрүләрен рухланып һәм канатланып сөйләп бирде. Әнисе ни карышса да, Валериан Владимирович кадетлар корпусыннан чыга һәм Петербургка военно-медицинская академиягә укырга керә. «Корпуста минем революционерлар белән аралашуым мәгълүм булды. Офицерлар минем белән сөйләшми башладылар. Начальник карцерга яптырырга маташты!» — дип тагын бер кат Омск хәлләрен искә төшереп алгач, ул мондагы төп эшкә күчте.

— Беренче нәүбәттә сезнең һәм безнең бурыч — Петропавловскида социал-демократларның мөселман секциясен оештыру. Иң әүвәл тимер юлчыларны һәм консерв заводы эшчеләрен секциягә тартырга кирәк. Анда татар, казах эшчеләре күбрәк. Вак-төяк предприятиеләрдән дә алдынгырак эшчеләрне сайлап алып арага кертергә кирәк булыр.— Ул Госманга борылды, аның җилкәсеннән какты.— Ә Усманканың сортировкада эшләве безгә аерата мөһим! Кәрим, ул сиңа бик яхшы ярдәмче булыр дип ышанам.

Каты кул кысыштылар. Валериан ишеккә бер атлады да туктап калды:

— Кәрим, әйтергә онытканмын! Син Усман Умаровичны иртәгә халык йортына танцага алып кил. Иснәнүчеләр булыр, безне танца тирәсендә танышып дуслашкан дип уйласыннар!..

Валериан артыннан бераздан Госман чыкты.

Төн аяз. Күктә ярым ай һәм дерелдәп торган йолдызлар. Кичкегә караганда суыткан — кар, баскан саен, шыгырдап тора. Тирән уйлар белән янәшә атлаганда кар шыгырдавы күңелгә тынычлык, сабырлык бирә. Уйлары күп булса да адымнары нык Госманның, ышанычлы. Югыйсә, уйласаң уйларның очына чыгарлык түгел. Бу фани дөньяда алар икесе ике якта торалар. Госман тормышка далалар, станицалар, ярлылар арасыннан килә. Аның гомер юлында күпме фаҗига, күпме кайгы-хәсрәт очрамады! Ярлы казахлар, татарлар, руслар, казаклар!.. Һәммәсе белән бергә кичерде. Ә Валериан? Атасы полковник! Анасы мөгаллимә. Үзе башкалада академиядә укый. Юк, ул бу тормыштан риза түгел. Патшага каршы митинглар, собраниеләр, секцияләр оештыра. Ниемә кирәк инде, бер уйласаң, аңа мөселман секциясе?! Тотсалар, белсәләр, аталар — и вәссәләм! Ә ул бер туктамыйча һаман шуның артыннан йөри. Башкаларны өнди?.. Димәк, аны әле Госман белмәгән, белеп бетермәгән ниндидер көч йөртә...

Алай дисәң, Кәримгә тагын ни җитмәгән! Сары майда гына тәгәри бит, Петропавелның беренче гильдий купецның иң ышанычлысы! Ашауэчү, кием-салым, торган җире... Безнең төшкә дә керерлек түгел! Шул кеше оҗмах рәхәтеннән җәһәннәм газабына үрелә. Нәрсәгә аңа милләт, мәгърифәт, инкыйлаб! Инде мөселман секциясе оештырырга башлап йөри. Эзенә бассалар — каторга...

Нәрсә йөртә аларны? Ни куалый? Үз язмышларын үткер пычак йөзеннән йөртергә ни мәҗбүр итә?

Госман иптәшләренең җанын бөтен тулылыгы белән аңлап бетермәсә дә, аның күңелендә Валериан белән Кәримгә карата ниндидер соклану, гаҗәпләнү катыш соклану туып килә. Алар янына куеп карагач, ул үзен дә кирәкле бер кеше итеп тоя, үзенең дә олы бер эшкә катнашып китә алачагын уйлап күңеленнән генә куана, бу куаныч төрмә, үлем куркынычын каядыр читкә куа, ул турыда уйлатмый да иде. Әле генә болытлар арасына килеп эләккән ай тиз-тиз йөзеп тагын калкып чыкты, тирә-якны якты нур белән күмде. Нинди матур төн!

Кайчак менә караңгыланган кеше күңеле дә шулай яктырып китә... Аңа рәхәт була, шулай түгелме?!

Ганшин магазины чатыннан борылуга каршы квартал уртасындагы ике катлы агач йортның аскы катында былтыр «халык йорты» — «нардом» ачылды. Моны Госман белә иде. Яшьләрнең шунда танца кичләренә җыелуы да колагына чалынган иде инде. Анда русча, татарча китапханәләр бар икән, җыр-музыка түгәрәкләре оешкан, һәвәскәр театр труппасы да якын араларда татарча спектакльләр күрсәтүне күздә тота икән...

«Танца кичәсенә» дигәч, Госман эчтән генә көлеп алды. Нинди танца ди тагын? Гомерендә бер тапкыр биеп караганы юк, әле таягын ташлаганга да күпме генә, явымлы көннәрдә яралар һаман сызлаштыра. Инде аяк өстендә абынмыйча-егылмыйча йөри алса, мең шөкер!.. Алай дисең дә, икенче ягы да бар икән ләбаса! Валериан ни диде: «Безне танца тирәсендә танышып дуслашканнар дип танысыннар»,— диде түгелме?

Бусы Госман өчен тагын бер ачыш иде. Димәк, аңа хәзерге көннән сак булырга кирәк, дус бар, дошман бар, аларны аера белмәсәң, хәзер тәбегә барып эләгерсең!

Ул барып кергәндә озынча, зур бүлмә-залда танцалар соң дәрәҗәдә кызган иде. Труба, альт һәм флейталар һәрберсе үз тавышы белән җиңел генә көйне сыздыралар. Уң кулына тукмак, сул кулына җиз тәлинкә тоткан барабанчы гына, җыелган музыкантларның тавышын басып узарга теләгәндәй дөп-дөп тавыш биреп ала. Кавалерлар туташларның биленнән кысып алганнар да җиңел-шаян музыка тактына буйсынып очып-очып, бөтерелеп, бер аерылып китеп, бер очып килеп кушылып әйләнәләр дә әйләнәләр. Госман, күзе ияләнә алмыйча, беравык ишек катыннан аерылып китәргә куркып торды.

Менә ул яшьлек! Никадәр дәрт, гүзәллек, самими гамьсезлек бар яшьләрдә! Үз гомерендә биемәгән Госманның да аяклары бу сихерле өермә ихтыярына буйсынып хәрәкәтләнә, барып утырган җирдән тыпырдый-селкенә башладылар. Ул үз аякларының җайсыз гына сикергәләвен тоеп, оялып куйды — ләкин кая ул, кемнең кемдә гаме бар, берсенең дә Госманда эше юк икән!

Күзе бер яшь туташта тукталып калды Госманның. Ак өстенә күк борчаклар сибелгән сатин күлмәк. Дулкын-дулкын булып уралган өч бәбәй итәк, кабарып торган купшы җиңнәр, ачык яка. Киң кырпулы кара бүрек, кунычлары тезгә хәтле шнурланган кызыл сафьян итекләр... Зифа буй, матур сын! Ут янып торган кыз! Польканың бер бөтерелешендә ул Госманга тартылгандай булды, аңа төбәп-төбәп карады... Әллә ялгыш кына карашы төште инде? Кызлар чая халык, кемгә карамас?!

Бию кызды, барабан тагын да катырак гөрселдәде, җиз тәлинкәләр чәчрәп-чәчрәп биючеләрнең аяк астына сибелде шикелле. Тагын шул ук кыз! Бу юлы алар пар булып Госманга якын гына урыннан уздылар. Ул җентекләп карап та өлгермәде, аның янына Кәрим белән Мәдинә килеп тукталдылар.

— Госман абый! Сез дә безнең беләнме? — диде Мәдинә мөлаем елмаеп. Биюдән алар икесе дә артык нык кызарганнар, маңгайлары дымланган, тыннарын еш-еш алалар. Госман баш иеп һәр икесен сәламләде дә баягы сихерле кызны эзли башлады. Халык шактый, һәммәсе хәрәкәттә, ак күлмәкләр дә бар, кара бүрекләр дә күренә, ә кыз юк та юк! Кәрим белән Мәдинә бераз аптырашып карап тордылар да тагын бөтерелеп яшьләр арасына кереп югалдылар. Госман сискәнеп китте: ул

эзләгән кыз, инде кавалерын калдырып, ялгызы гына аның артына килеп баскан икән! Ул! Әнә ич, өске ирендәге миң очып китәргә җыенгандай туктаусыз кыймылдый, елмая кыз, елмая! Ул!

— Усманка! — Маша (Мария) гаҗәпләнеп, сөенеп кычкырып, бер мәлгә генә барабан тавышын да күмеп, Госманга ике кулын сузды. Госман ток суккандай сикереп торды...

Башта оркестр тавышыннан башка берни дә ишетмичә бер-берсенә карап тордылар, оркестр тынгач, сүз табалмыйча карашларын түбән төшерделәр. Ул арада музыкантлар янына — калку урынга Мәдинә менде һәм яңгыравыклы тавыш белән җыелганнарга мөрәҗәгать итте:

— Хөрмәтле туташлар һәм әфәнделәр! Әдәби түгәрәккә язылганнар югары катка сигезенче бүлмәгә рәхим итәсез. Чираттагы утырыш була. Залда калучылар өчен, нәни генә тәнәфестән соң, танцалар дәвам итә!

Бер төркем яшьләр, арада гимназистлар да бар иде, каты тавышлар чыгарырга тырышып:

— Танца, танцалар! — дип кычкырдылар.

Кемнәрдер тәмәке тартырга чыгып китте, кемнәрдер һава суларга чыкты. Кәрим белән Мәдинә, култыклашып, кызарынган-бүртенгән Госман яныннан уздылар. Мәдинә нәзәкәт белән баш иде һәм бик серле итеп:

— Госман әфәнде, без сезне көтәбез! — дип әйтеп узды.

Менә сиңа мә! Ничә айлар шушы кыз белән очрашуны көтеп, зарыгып, сагышланып йөр дә, инде, очраштык дигәндә генә аны чакыралар! Менәргә кирәк! Барырга! Чөнки, ул шушы кичәгә махсус чакырып китерелгән җаваплы кеше... Тик моны Машага ничек дип аңлатасың? Ә Машаны ияртеп менсәң? Ярамас! Теләсә кемне ияртеп йөри торган урын түгел ул «әдәби кичәләр!» Монысын Госман бик яхшы үзләштереп өлгерде. Ә кызга ни дип аңлатырга! Әнә, күзләргә керердәй булып яндырып карап торган җиткән кызга, атаман кызына, Госманның балачак һәм яшьлек мәхәббәтенә ни диярга?!

— Кая югалдың син, Усманка? Ичмасам, ник бер дә хат язмадың?

— Ни язасың инде? — дип мыгырдады Госман, үз тавышын үзе сөймичә.

— Алай да... Сагындыңмы мине?! — Маша кыю! Чаялыгы һаман кимемәгән! Эх, кызый синдәге чаялыкның чирегә генә булсамы Госманда! Ул сиңа әллә нуләр әйтер иде... Югалып калды шул бүген, мондый урында, кеше арасында, танца кичәсендә очрашырбыз дип һич уйламаган иде ул. Алай гынамы сиңа, ул хәзер сине ташлап китәргә мәҗбүр булачак. Менә сиңа очрашу!..

Госманны бая Маша биегән егет коткарды, ул аларны читтән үк күреп алып, туп-туры кыз каршысына килеп басты, сул мыек очына көяз генә кагылып алды. Госманның борынына кыйммәтле папирос исе килеп бөркелде.

— Мин сезне югалттым, Машенька! — диде ул.

Ул арада оркестрантлар коралларына тотындылар, баягы гимназистлар тагын да катырак итеп, бер-берсен капларга тырышып:

— Вальс!

— Полька! — дип акырыштылар.

Оркестр бер җай белән генә «Маньчжурия сопкаларында» вальсын уйный башлады. Бетерде шушы көй Госманны, тәмам телдән калдырды! Әйтер сүзен дә әйтәлмәс булды. Бу вальсны тыныч кына тыңлый алмый иде егет! Аның югалып калуыннан файдаланып, көяз мыек Машаны биленнән эләктерде һәм өертеп уртага алып кереп тә китте. Шулай, бала-чага төсле, бер-берсенә карашып узды аларның шушы күрешүләре. Госман өске катка күтәрелде, Машасы көяз егет кочагында калды...

Сигезенче бүлмәдә халык күп түгел иде. Күбрәк рус яшьләре. Берничә генә татар егете күзгә чалынды. Казахлар бөтенләй юк. Бөтенесе дә тып-

тын гына утырышканнар да кемнедер көтәләр. Озак та үтмәде өстәл артындагы ишек ачылды да, аннан җитез генә атлап Валериан Куйбышев килеп керде — «Артем» башын кагып исәнләште, маңгаена төшкән чәчләрен кулы белән артка сыпырды. Түгәрәк утырышын Кәрим ачты.

— Хөрмәтле әфәнделәр, Артем иптәш бүген безне Владимир Ульяновның «Что делать?» дигән китабы белән таныштырачак. Артем иптәш, рәхим итегез...

Артем өстәл артындагы урындыкка утырды, лампаны аз гына читкәрәк этәреп куйды һәм кесәсеннән кечкенә форматлы китап чыгарды. Госман утырган арткы рәттә караңгы дип әйтерлек иде. Артем сүзгә керешкәнче ул колагын торгызып тыңланды, аскы каттан дөп-дөп барабан тавышы менеп җитә, йөзләрчә аяклардан чыккан авазларны да ишеткән кебек булды Госман. «Маша гына китеп бармасын иде!» — дип теләде аның күңеле. Теләде дә, онытылды, Артем тигез тавыш белән «Что делать?» китабының асылын аңлатырга кереште...

Сораулар бирделәр, тирә-юньдәге бәхетсезлекләрне аңларга тырышып чыгышлар ясадылар, кичә сизелмичә узды...

Ниһаять, уку тәмамланды.

Мәдинә, Кәрим, Госман — өчәүләшеп нардомнан чыктылар. Танцалар да әлерәк кенә тәмамланган ахрысы, анда да, монда да кызлар чыркылдаганы ишетелә, кар шыгырдый. Госман як-ягына каранып кузгалса да, Маша беркайда да күренмәде. Сүзсез диярлек атлап Ганшин магазины турына җиттеләр. Сыек кына янган фонарь баганасы төбеннән бер кыз аларга таба килә башлады.

— Усманка!

Госман бер-ике сүз белән Кәрим белән Мәдинәгә Машаның кем булуын аңлатып бирде дә, алар кул биреп аерылыштылар. Бер-берсен озатышып йөрү башланды. «Тукта, мин каланы синнән шәбрәк,беләм!» — дип, башта Маша озата бара да, аннан Госман кызып китә: «Егет башым белән кызны урамда ялгыз калдырыйммы?» — дип Машаларга атлыйлар. Маша Госманның сугыштан исән-сау кайтканын ишеткәч сөенеп бетә алмавын кат-кат әйтте... «Нигә Омскига хат язмадың?» — дип үпкәсен белдерде. Ничек язасың ди? Ни өметләр белән!? Ул әнә гимназиядә!

Хәзер Маша вокзал янындагы ерак кардәшләрендә тора икән, каникулда. Нардомга танцага өченче кич рәттән бара...

Госман, моны ишетеп, хәтта ыңгырашып җибәрде: «Өченче кич... Белгән булсам!» «Белсәң ни эшләр идең, Усманка?!» Егет тагын сүзсез калды, тормыштагы тигезсезлек үзен тагын бер кат сиздерде. Баһаветдин сыман атаман каршына барып баса алмыйсың. Әле монда ярлы егете белән атаман кызы гына очрашмый шул. Госман казак булса да ахыр чиктә — татар, читтән килгән кеше! Җәфрәтил карт: «Син тумыштан казак!» дип кәперенергә чакырса да, әллә ни кылыр эшең юк!

Дөрес, Машаның ихласлыгы, чынлап торып, риясыз мавыгуы бу кичтә тормыш каршылыкларын онытгырып та торды. Әмма Госманда аек акыл уянып килә иде инде, ул тормышның каршылыкларын да, дус белән дошманның бер чакта да килешә алмаслыгын да, сыйныфлар көрәшенең асылын да белә, аера башлаган иде инде.

Маша икенче көнне таңнан юлга чыгып китте. Егетнең күңелен тагын да ныграк котыртып, һушын алып китте. Бу аерылуны Госман бик авыр кичерде һәм ике атнага якын нардомга якын да барып карамады. Ләкин аны онытмадылар, ташламадылар. Кәрим аны эзләп сортировкага килде. Мөселман секциясе төзелеп килә, аңа Госман кебек ышанычлы юлдашлар бик кирәк иде.

## 26

1907 нче ел казах даласына зәмһәрир салкыннар белән килде. Табигать кырыслыгы гына түгел, ул елны рус иленә башка михнәтгазаплар да җитәрлек килде!

1905 нче елгы тоташ давылда өркеп чыгарылган «Октябрь манифесты» аяк астына салып тапталды. I нче һәм II нче Дәүләт думалары куылды. Хөкүмәт тезгенен канечкеч Столыпин үз кулына алды. Илдә кулга алулар, хәрби судлар, сөргеннәр, ату-асулар башланды. Ирек әләмнәре урынына дар агачлары — «Столыпин галстуклары» күтәрелде. Бу шаукым казах далаларына да килеп җитте! Атбасардагы мең бәлалар белән ачылган, халыкның культура-ял үзәге булган кыйраәтханә ябылды. «Җомгалар», «шимбәләр» барлык җирдә тыелды. Сөргенгә җибәрелгән студентларны яңадан кулга алдылар. Доктор Иван Иванович та, управа писаре Семен Петрович та, управада адвокат булып эшләгән Казан егете дә (теге, әдәби кичәләрне җанлы итеп алып баручы сөйкемле конферансье егет!) жандарм бүлегенә чакырылдылар да гаип булдылар. Бары тик пар тегермәнендә механик булып эшләүче Дмитрий Андреевич Ушаков кына исән-сау. Әйтүләренә караганда, аны тегермән хуҗасы Мукомолов үзе жандармнардан сорап алып калган, имеш, «бердәнбер механик, ул китсә, тегермән шып тукталачак» икән!

Кызылъярдагы социал-демократлар оешмасы инде байтактан бирле Госман аша турыдан-туры эш йөртә. Күкчәтауга, Атбасарга китә торган почта капчыкларында байтак «Искра» газеталары, революцион брошюралар юл узды. Госман хәзер чыныккан һәм сыналган иптәш исәпләнә. Аның белән киңәшәләр, аны тыңлыйлар, аның тәкъдимнәренә һәрвакыт колак салалар иде. Абруе бар егетнең! Еллык отчет вакытларында ул Атбасарга барып килә, Фаддей Кириллович аны үз «фатыйхасы» белән озатып кала. Сергей Иванович та, Мария Петровна да Госманның килүенә бик куаналар, тик аларны Госманның ялгызлыгы, һаман үз оясын кора алмавы гына гаҗәпләндерә иде. Иске дуслардан Сабир, Гаделбәкләр белән очрашу да Госманга һәрчак күңелле була иде...

Инде оешма, секция эшләре үзенең җаена кереп бара дигәндә генә... бер көнне...

Ул көн якшәмбе иде. Агентствода ярты ял, сортировкада эшләүчеләр төштән соң гына эшкә чыгалар. (Фаддей Кириллович Госманны башка бүлеккә күчерергә уйлаган иде, Кәрим белән киңәшкәннән соң Госман сортировкадан китмәскә булды, моннан да җайлы урынны табу мөмкин түгел иде!) Хуҗалар, ирле-хатынлы, икесе дә мойкада, йон юалар, Госман бер ялгызы гына соң торып, иренеп кенә чәй кайнатып, иркенләп кенә чәйләп утыра иде. Һич көтмәгән кеше — Кәрим килеп керде.

— Ничек эзләп таптың? Монда бер тапкыр да булганың юк иде ич! Югары каладан ничек төшә алдың? Аягың нык түгел, Кәрим дус! Җитмәсә, шулай иртә!..

Госман дустын үз өендә күрү сөенеченнән сүз белән күмеп ташлады да, зиһене ачылып китеп, шып туктады. Әһә! Килгән икән, димәк бик мөһим эше бар! Нинди эш?!

— Су! — диде Кәрим, кипкән иреннәрен ялап. Госман шунда гына дустының чыраеның танымаслык булып үзгәрүен, йөзенең ябыгып, сураеп калуын абайлады. Ул, өстәлгә түгә-түгә, кабаланып чәй ясады. Кәрим чынаякны ике куллап тотып алды, пешенә-пешенә бер-ике йотты да:

— Безнең Сабир дусны япканнар.

— Әлләә?!

— Әйе. Бүлмәсеннән тентү ясап газеталар тапканнар.

— Димәк, кем дә булса чаккан!.. Ә башка иптәшләр? Аларда тентү булганмы? Кем әйтте бу хәбәрне?

— Хәмит Базарбай акагә әйтеп җибәргән.

Икесе дә Сабир язмышы турында уйлап тын калдылар.

— Димәк, монда да сак булырга кирәк.

— Мин синең янга шуның өчен ашыктым,— диде Кәрим, чынаягындагы чәйне йоткалап.— Почтада нәрсә-кара бармы?

— Беркадәр брошюралар бар да аз-маз газеталар. Күкчәтауга җибәрергә әзерләнгәннәр.
— Аларны тизлек белән юк итәргә кирәк, я башка җиргә күчерергә!
— Бәлки, бер юлга эзләмәсләр әле?
Кәрим икеләнгән кыяфәт белән алдына карап утырды да:
— Юк, Госман! Аларда нindидер фактлар элек тә бар иде, почтадан шикләнә иделәр! Хәзер үк почтага чап!
— Иван Матвеевич кунакка киткән иде.
— Бик яхшы! Алайса, синдә аулак! Ә мин көне-сәгате белән Атбасарга китәм. Омскига озатканчы Сабир дусны ничек тә йолып алырга кирәк.
Кәрим ашыгып килеп керде, аннан битәр кабаланып чыгып та китте. Әйе, Сабирның саулыгы начар, җаны тәненә чак эләгеп тора, бу хәлдә кансыз жандармнар кулы аша үтеп, хибесханәгә эләгә калса?.. Кәримнең да эше шәптән түгел: баена ни дип әйтер дә, һич уйламаганда, Атбасарга ни дип чыгып китәр? «Үзем бармыйча ярамас, миннән башка кем аны йолып ала алыр?!» — диде бит. Кәримнең өйдән бераз ераккарак китүен бозлы тәрәзә аша карап торган Госман ашыгып-кабаланып киенде дә почтага чыгып чапты... Бәхетсезлегенә каршы, өлгер Иван Матвеевич кайтып җиткән, озатасы почтаны әзерләп йөри. Тимер шкафлар артында аралыкта газеталар, китаплар... Аларны һичшиксез күздән югалтырга кирәк... Иван Матвеевичның эшләгәндә мавыгып китеп үз-үзе белән сөйләшүеннән файдаланды Госман, шактый авыр кәгазь капчыкны шкаф артыннан шудырып чыгарды да култык астына кыстырып ишегалдына чыкты. Почта атлары ял итә торган сарайга керде. Беркем дә юк дип куанган иде, ямчы казах егетләренең берсе Җанайдар, атын сыйпап, алдына печән салып маташа иде. Аптырап китте Госман, капчыгын кая куярга белмәде. Җанайдар зирәк егет булып чыкты, мәсьәләне тиз үк аңлап алды, күзен җеп калынлыгы гына калдырып елмайды да:
— Госман әкә, яшерергәме? — дип сорады. «Әйе», дип баш кагудан бүтән чара калмады.
— Монау улак астында күсе ясаган тишек бар,— диде Җанайдар һәм Госман кулыннан капчыкны алып улак астындагы дәү тишеккә батырып та куйды, тишек өстенә тирес тутырды.
— Рәхмәт, Җанайдар!
Хәзер тынычланырга да була. Таба алмаслар. Тапкан тәкъдирдә дә Госман яшергән дип кем белсен?! Җанайдарга ышанырга була, тәпле, аз сүзле егет!..

Госман Иван Матвеевичка борчылуын, дулкынлануын сиздермәскә тырышты. Алар көндәгечә җай белән эшләделәр, пакетларны күн капчыкларга — махсус сумкаларга салып, бикләп, пломбалап, посылкаларны кар кермәслек итеп брезент белән төреп, агентствоның махсус повозкаларына — чаналарга урнаштырдылар.

Гадәттәгечә, өч повозка, өч пар ат. Ямчылар, өч казах егете, уенкөлке сүзләр әйтешә-әйтешә, атларны җиктеләр, кузгалыр алдыннан, гадәттәгечә, сбруйларны карап, камыт бауларын бер күтәреп, бер төшереп, атларның ялларын тарап-сыйпап, каеш тасма дилбегәләрне кулларына алып, толыпларына төренеп чаналарга менеп тә утырдылар. Карама дугалардагы пар кыңгыраулар, тирә-якка ягымлы тавыш биреп, саубуллашырга әзерләнделәр.

— Хәерле юл! — диде Госман, нәкъ көндәгечә ямчыларны озатып, аеруча Атбасарга баручы егет Җанайдарга якынрак килеп, шыпыртырак тавыш белән өстәде.— Сергей Иванович белән Мария Петровнага сәлам әйт. Ходай боерса, җәен Имәнтауга кайтышлый кереп чыгармын.— Аннары иелеп: — Сабир Шәриповның хәлен белешергә тырыш. Тик сак бул! Ярыймы! — диде.
Иван Матвеевич йөгереп барып капканың бастырыгын алды.

Нәкъ шул вакытта кече капка-калитка ачылып китте дә, алты-җиде жандарм, шинель итәкләренә, сөйрәлгән кылычларына абына-сөртенә кабаланып килеп керделәр. Кызарганнар, бүртенгәннәр, мышныйлар, күзләре акайган.

— Капкаларны бикләргә! Беркемне кертмәскә, чыгармаска! Горбунов, капка төбенә! Башкалар — повозкаларга! Инәсеннән-җебенә чаклы тентергә! Марш!

Җирән мыеклы, тулы бәдәнле, шадра офицер тавышы белән ямчыларның юлын кисте. Ишегалдындагылар бу көтелмәгән сүзләрдән тәмам шашып, аптырап калдылар.

Боерык моның белән генә бетмәгән икән әле.

— Ямчылар! Повозкалардан төшеп атларыгызны бәйләгез. Ә сез, әфәнделәр, башлагыз! Барлык сумкаларны җиргә! Тәфсилләп тикшерегез! Бер кәгазь дә күздән ычкынмасын.

Шулай тырышып, бөртекләп бәйләнгән, сургучланган капчыкларның җиргә очуын күреп Иван Матвеевич чак елап җибәрмәде. Ул офицер алдына ук килеп басып, рәнҗүдән нык ук тотлыгып:

— Хөрмәтле офицер әфәнде,— дип сүз башлады да, ни әйтергә белмичә ияген дерелдәтеп шаккатып карап торды.— Ни бит, ни... почта соңга кала бит!

— Читкә! Комачаулама!

Тугры хезмәткәрнең үз гомерендә мондый коры кисәтүне ишеткәне дә булмагандыр, башын иеп бер кырыйга китеп тә барды.

Жандармнар барлык сумкаларны, капчыкларны чаналардан тартып төшереп, пломбаларны ватып-җимереп, хатларны, бандерольләрне, пакетларны чәчеп ташладылар.

Госман эченнән генә Кәримгә рәхмәт укый иде. «Әгәр ул килеп кисәтмәсә... кычкыртып төрмәгә алып китәләр иде!» Артык тынычланырга да ярамаганын белә Госман, эзләнә-иснәнә торгач ат сараена да барып керсәләр?! Әллә йөкләрдән генә шикләнәләрме? Нәкъ юлга чыгар алдыннан килеп керделәр бит! Димәк, алар белеп, күзәтеп торганнар! Әгәр Госманның капчык тотып уралып йөргәнен чамалаган булсалар?!

Ул арада кулына күзлеген тотып, сюртугын да төймәләмәгән, яланбаш Фаддей Кириллович килеп чыкты, ут кабынган сакалын мәзәк селкетеп чәрелдәп кычкырып җибәрде:

— Бу ни хәл?! Бу нинди башбаштаклык! Мин хәзер генерал-губернаторга жаловаться итәм! Ишетәсезме, хәзер үк туктатыгыз!

Жандармнар аның саен хәтәррәк актарыналар, пакетларны шатыр-шотыр ерталар, посылкаларны тибеп җибәрәләр, бер-берсенә нидер күрсәтәләр, көлешәләр.

— Мин сезгә правление исеменнән мөрәҗәгать итәм. Протест белдерәм, господин офицер! — Фаддей Кириллович иң соңгы көчен җыеп тагын эндәшеп карады.— Хәзер аппаратка барам! Генерал-губернаторга!

Ниһаять, офицер кулындагы пакетны атып бәрде, чүгәләгән җиреннән күтәрелде, мыекларын бөтерде, жиз кылычклар кыбырдадылар:

— Кызганычка каршы,— диде ул, игътибарсыз гына.— Мин монда нәкъ генерал-губернатор хәзрәтләренең боерыгы буенча килдем.

Фаддей Кириллович белән Иван Матвеевич телсез, өнсез калдылар... Картларның шушы хәлгә төшүләрен күреп, Госман чын күңеленнән аларны җәлләде...

Актардылар, актардылар, берни дә тапмадылар. Офицер йөгереп барып бер читтәрәк торган ат сарайларының ишеген ачып карады да, эчкә үк кереп тормады, конторага да кагылмадылар. Алар бары тик повозкаларны тентергә генә килгәннәр булып чыкты!

— Җитәр! — диде офицер сүлпән һәм түземсез тавыш белән.— Үзләренең башы катсын!

Жандармнар килгәндәге кебек житез кыландылар, бер-берсенең итәгенә тагылып калиткадан чыгып та киттеләр. Ямчылар капка ябылганны гына көтеп торганнар икән, жандармнарны суганлап-борычлап сүгәргә тотындылар. Аерата Җанайдар остарды, русчалап та, казахчалап та тегеләрне тиргәде. Агентство хезмәткәрләре ишек алдына таралган кәгазьләрне берәмтекләп җыярга керештеләр. Өч жиргә җибәрәсе хатлар, кәгазьләр хәзер аралашып, буталып беткән иде. Почтаны бүген җибәрү турында уйларга да мөмкин түгел!

Атларны тугарып конюшняга алып киттеләр. Хезмәткәрләр ишегалдындагы кәгазьләрне — почтаны җыярга тотындылар. Үч иткәндәй, җил кузгалды, эре-эре кар ява башлады. Караңгыга кадәр бил дә турайта алмадылар. Ахылдашып баскыч астына карсыз урынга барып утырдылар.

— Иван Матвеевич, тартырга бирегез әле.

— Усман Умарович! Сез бит тартмыйсыз! Хәер, мондый мәсхәрәдән соң тәмәке тарту түгел, аракы эчәрсең!

Тартканы, тартмаганы сүзсез генә тәмәке төрә башладылар.

— Иван Матвеевич! — Контора ишеге ачылды, башын тыгып бер кыз чәрелдәде: — Сезне Фаддей Кириллович дәшә!

— Карт жанны ала хәзер! — дип, Иван Матвеевич сукрана-сукрана кереп китте.

Фаддей Кирилловичның йөзендә кан әсәре калмаган. Тавыш гасаби. Сүзләр ярты юлда өзелеп-өзелеп кала.

— Бу системада утыз елдан артык тугры хезмәт итеп мондый хурлыкны күргәнем юк иде. Көпә-көндез жандармнар! Мәсхәрә! Бөтен жиргә сүзе барып житәчәк. Ә бит алар юкка килмәгәннәр! Бездә, агентствода крамола! Әйтергә тел бармый, Иван Матвеевич! Безнең сортировка аша уза торган корреспонденцияләр эченнән падишаһ хәзрәтләребезгә каршы язылган кәбахәт газеталар, прокламацияләр табылган! Хурлык! Андый кәгазьләрне Омскида басалар икән. Төп оешмалары шунда. Оештыручысы да билгеле! Касаткинмы, Кукушкинмы[1] шунда! Кәгазьләрне Күкчәтауда, Атбасарда, Акмулада да тапканнар! Менә, һәммәсе бишенче ел холерасы! Моның өчен Столыпин хәзрәтләре нишли? Ата, аса... Каторгага сөрә! Һәм дөрес эшли... Юк, бу фетнәне болай гына калдыра алмыйбыз. Ярамый! Иван Матвеевич! Сез дә, зинһар, күз-колак булыгыз. Утлы тимер белән тамырын корытыйк без моның! Чакыр хезмәткәрләрне!..

Агентство хезмәткәрләре Иван Матвеевичның чыгуын көтеп баскыч тирәсендә бөялешеп торалар. Госманга, әлбәттә, тиз үк моннан ычкынырга кирәк иде. Кәрим Атбасарга китә алдымы икән? Китсә — хәерле юл, китмәсә — мондагы кызыклы хәлләрне аңа да белдереп куярга кирәк иң! Бәлки әле Омскига да хәбәр житкерергә кирәктер?! Тик, башкалар кузгалмагач, ул китәргә яхшысынмады, бүтәннәр белән, юаш кына кыяфәттә, бүреген култык астына кыстырып начальнигы катына керде. Өстәл артында Фаддей Кириллович белән Иван Матвеевич утыралар иде. Аларны бер чакта да янәшә күрмәгәнгә игътибар ителмәгәнме, хәзер, карагач, Госман чак кычкырып көлеп җибәрмәде: кызыл сакал белән кара сакал! Иван Матвеевич сакалын нәкъ Фаддей Кирилловичныкы төсле итеп, аңа охшатып кыскарта икән бит!.. Тик көләргә вакыт булмады, Фаддей Кириллович йодрыгын йомарлап, һава бутап кемгәдер янарга тотынды.

— Сез падишаһ хезмәтендәге кешеләр! Дәүләт кешеләре! Тәхетнең тоткасы! Безгә шундый зур ышаныч белдерелгән. Җыен студент, җыен бушбугазларга ияреп сез хаталык кыла күрмәгез! Бәлки, берәрегезнең шикле иптәшләре бардыр?! Уйлагыз! Монда эш заграница белән бәйлән-

[1] Кукушкин — В. В. Куйбышевның партия ләкабе.

гэн булуы ихтимал! Моннан соң һәрбер корреспонденцияне дүрт күз белән карагыз. Шикле нәрсә абайласагыз — миңа! Аз гына шик-шөбһә булса — миңа! Минем кабинетка! Төшендегезме?! Белегез, чит кешеләрне кертмәскә, читләр, шиклеләр, студентлар белән аралашмаска!

— Төшендек,— диделәр җыелганнар.

— Алайса, барыгыз! Күземә күренмәгез!

Кысылышып ишектән чыккан чакта Җанайдар башкалар сизмәслек итеп кенә Госманның касыгына төртте.

Госман ашыга-чаба Кәрим торган фатирга барып җиткәндә, караңгылык тәмам куерган, кар тагын да тыгызланыбрак ява башлаган иде. Керергәме, кермәскәме дип икеләнебрәк барса да, Кәрим яши торган бүлмә тәрәзәләрендә ут күргәч, Госман кыюланып барып керде. Керүгә үк мичкә аркасын терәп торучы кызны танып чак кына кычкырып җибәрмәде.

— Мәдинә туташ! Сез ничек монда!?

Мәдинә туташ шушы көздә генә Казанга врачлыкка укырга киткән иде.

— Каникулга кайттым. Менә Кәрим янына керсәм, ачкыч урынында, язу-фәлән юк. Минем кайтасымны белә иде ул!

Госман итегеннән эрегән карларга ачуы килеп карап торды да бүгенге хәлләрне кыска-кыска гына сөйләп бирде. Мәдинәнең тынычсызлыгы йөзенә чыкты. «Ничек? Сабир ага төрмәдә?!. Сездә тентү?! Арага провокатор кермәгәндер бит!» Госман үзе дә бу турыда уйлап куйгалаган иде инде. Мәдинә туры сорау биргәч, үзе кылган эшләрне тагын бер кат башыннан кичереп уздырды. Юк, шикләнерлек бер кеше белән дә сөйләшкәне юк, почтада аның ни белән шөгыльләнгәнен беркем дә белми, бүгенге хәлгә Җанайдар шаһит булды, әмма ул егет тә телен теш артында тота торганнардан...

— Госман әфәнде! Ә сез, теге, Мария Романовага, атаман кызына берәр нәрсә тишмәдегезме?

Госман сискәнеп китте!

Бер сагайтты, бер ачуын чыгарды Мәдинәнең соравы! Әлбәттә, әгәр Маша атаман кызы булмаса, мондый сорауны бирә алыр идеме ул? Юк!.. Хак, Госманның Маша Романованы чынлап торып күрә, сөйләшә алганы да юк. Очрашкач, ни турында сөйләшә алырлар иде, әйтүе кыен. Бәлки, Госманның заманча уйлый ала башлавын сизгер кыз үзе дә чамалар иде... Эх, Мәдинә, Мәдинә туташ! Кыек атып туры тидердегез, Госманның йөрәк ярасына ачы тоз сиптегез!

Мәдинә егетнең аптырап калуын сизеп, сүзне ул юнәлештә озайтмады, «Гафу итегез, Госман әфәнде!» — диде дә икесенә дә бу йорттан китеп торуның хәерлерәк буласын төшендереп бирде. Ачкычны билгеле урынга куеп, икесе ике якка чыгып киттеләр, Мәдинә үзен озатырга да рөхсәт итмәде. «Казаннан кайткан студентка! Дәлилләре булмаса да, әллә ни уйлап чыгарырлар!» — диде ул соңгы сүзе итеп.

Аерылыштылар. Яшь кардан соң төн тагын да ныграк суынган, тун аша җелекләргә үтә. Алай да Госман Түбән Калага өенә кайтырга ашыкмады. Кызыл сакал белән кара сакалны искә төшереп, көлеп тә җибәргәләде. Бүгенге көн, кич аның өчен аерата истәлекле иде. Көндез жандармнар килеп керүгә аның йөрәген курку-каушау биләп алса да, ул бүген моңарчы татымаган горурлык хисе дә кичерә иде. Әйе, Кызыл сакал да, Кара сакал да аның белән янәшә, бер урында эшлиләр. Тик алар патшаның тугры этләре! (Шушы сүз килде Госманның башына, әллә башка берәүдән моңарчы ишеткән идеме ул сүзне!) Ә ул... ул башка! Аның юлы башка! «Хаклык өчен көрәш!» диде Валериан...

Валерианның Петербург академиясенә укырга керсә дә, бер дәрестә дә була алмавын Госман әлегә белми иде. Яшь революционер Куйбышев бөтен барлыгын революция эшенә багышлап өлгергән иде инде. Ул Петербургта яшәгәндә революцион рух белән алдагы көрәшләргә әзер-

ләнә иде. «Чын эш кирәк! Чын эш белән халыкка, яшьләр арасына барырга!» Финляндиядән килгән коралларны кабул итеп үзәк складка озатулар да аның бурычы... Большевистик матбугатны тарату да аңа йөкләнгән... Валериан Куйбышев Петербургта 1906 елның язына кадәр яшәде дә яңадан Омскига әйләнеп кайтты. Омск большевикларының эшчәнлеге тирә-юньдә дан алды. Революцион түгәрәкләр оештырып, аларга большевистик юнәлеш бирер өчен Куйбышев якын-тирәләрдәге шәһәрләргә, эшчеләр туплаган үзәкләргә, шул җөмләдән Петропавел каласына да еш кына килеп йөри иде.

Әлбәттә, боларның барысын да Госман белеп бетерми иде әле! Алай да, ул бүген үзен чын революционер, дөньяга һәм «алдагы көрәшләргә» кирәкле кеше итеп тойды... Аягына суык үтүен дә сизмәде, җилкәсенә салкын үрмәләвенә дә исе китмәде...

## 27

Бусы бер дә кирәкмәгән нәрсә иде! Бер дә көтелмәгән хәл! Госманның башы чатнап яна, иреннәре көя, теле наждак кебек кытыршы... Валлаһи агай белән Билләһи җиңги «Йөрмә бүген эшкә, мәтрүшкәле чәй эчеп, тирләп урыныңда гына ят!» — дип ачуланып карасалар да, Госман эшенә китте. Бүген бармыйча калырга ярамый иде. Бәлки, Кәримнән бер-бер хәбәр бардыр. Госманның кирәге чыгар. Аннары Фаддей Кириллович белән Иван Матвеевич та ни уйларлар? «Тентү булганның икенче көнендә үк н и г ә д е р эштә күренмәден?» — дип сорап куйсалар?! Юк, аларда да шик тудырырга ярамый! Барырга кирәк!...

— Я, хода! Бүген сиңа ни булды, Усман Умарович?! Менә, кара, Акмулага адресланган пакет Атбасарга салынган. Ә менә бу! «Күкчәтау» дип чекерәеп торган хат Петропавел куышында! Я, ходай!

Ә Госман бүлмә уртасына өелгән зур-зур күн капчыклар арасындагы буш урындыкка утырган да тәрәзәгә төбәлеп уйга калган, бүлек башлыгының рәнҗүен ишетми дә!

— Усман Умарович!

— Ә? Ни?

— Усман Умарович, син авыру! — Иван Матвеевич егетнең кызышкан маңгаен тотып карады.— Хәзер үк фельдшерга барырга кирәк!

Фельдшер ике дә сөйләшеп тормады, Госманны больницага озаттырды. «Сездә, кадерлем, жар! Ут янасыз! Салкын тигән булса кирәк... Үпкәгезгә күчмәсен!»

Ни хәл итәсең, медицинага каршы килеп булмый.

Госманның госпитальдән соң дару исе иснәгәне юк иде әле. Томау төшкәнен дә хәтерләми. Ә менә хәзер, иң кирәк чакта, больница караватында ауна•инде! Ул үзенең кичәге саксызлыгын хәтеренә төшереп, кан чыкканчы иреннәрен тешләде...

Йорт хуҗалары аның больницада икәнен белмиләр. Кәрим дә белми. Мәдинә дә. Кәрим сорашып агентствога кагылса ярар иде дә... Аның — чит кешенең сорашып йөрүе башкаларда шик уятмасмы? Госман ут эчендә ята. Йокыга да киткән кебек була, саташып уяна... Кипкән иреннәрен чылатып тагын уйга чума... Бик җайсыз чакта авырды Усман Умарович! Кирәксез чакта...

Менә тагын саташа. Имеш, ап-ак мех бүрек кигән, иңенә ак халат салган сылу бер кыз аның караваты янына якынлаша. Кыз кергәнен күреп палатадагы иптәшләре берәм-берәм чыгып китәләр, имеш. Менә алар икәүдән-икәү генә калалар. Кыз һаман якынлаша, якынлаша, менә аның кайнар тыны Госманның маңгаена килеп бәрелә... Бүрек астына сыймаган чәчләре Госманның битенә тиеп-тиеп китәләр дә ут булып кабыналар...

— Маша!
— Усманка!..
— Маша! Кадерлем! Каян килеп чыктың син?!

Төш түгел ич, өн бу, өн! Госман ачык күз белән Машага карап ята, кызның ике бите буйлап агып төшкән күз яшьләре тамып-тамып Госманның һушын кайтардылар. Ул әсәренеп, калкынып Машаның салкынча кулларына тотынды.

— Омскидан килдем.
— Ничек? Мине каян эзләп таптың?
— Мин сине күрергә дип кенә кайттым да, Усманка! Мин әле генә поездан дисәң дә ярый... Агентствога кердем дә, фельдшерга кагылдым, алар монда җибәрделәр.— Маша бүреген салып ташлады, алтын чәчләр тузгып иңнәренә төштеләр.

— Поездан?

Палатадан соңгы кеше чыгып китте. Госман аны күрмичәрәк торган икән, шуны гына көткән сыман, ишек ябылуга, Маша Госманның кочагына ауды. Торып тиз-тиз тунын салып ыргытты, тагын кочаклап алды, егетнең уттай иреннәрен кат-кат суырып үпте. Тагын күз яшьләренә буылып җылап җибәрде.

— Ни булды сиңа, кадерлем? Ни бар, күгәрченем!
— Алып кит мине кая булса да, Усманка! Бергәләп хәзер үк качыйк без!
— Ничек хәзер?

Госман, «минем кайдалыгымны, хәлемне күрмисеңмени?» дигән сыман, палатага кул изәп күрсәтте.

— Кичегергә ярамый, кадерлем! Мин инде китәргә дә тиеш!
— Аңлат! Кая китәргә?
— Омскига. Мәскәү поездына өлгерергә кирәк.

Госман гаҗиз булып, гасабиланып ыңгырашып кычкырды:

— Сөйлә! Аңлат!
— Әти Омскида. Ул мине көчләп бер кадетка кияүгә бирә...
— Кадетка? Әтиең?!
— Ә син ни уйладың?! Иптәш кызыма барам дип өйдән чыгып киттем дә поездга утырып монда килдем... Син мине кая булса да алып китәрсең дип уйлаган идем! Әйдә, Омскига барабыз да әтинең аягына егылып аннан хәер-фатыйха сорыйбыз. Яратмыйм мин ул кадетны, мин сине генә сөям!

Тагын күз яшьләре, тагын утлы пышылдаулар... Госман тагын оныталып, һуштан язды. Исенә килгәндә, Маша һаман аның янында басып тора, кулында Госманның киемнәре, туны, итеге, бүреге. Ничек эзләп алгандыр аларын чая кыз, аның шушы халәтен күреп, Госман соңгы көчен җыеп урыныннан калкынды, киенә башлады.

— Доктор күргәнче моннан чыгып китәргә кирәк! — диде Маша, аңа киенергә булышып.— Аптекадан дарулар алырбыз, терелерсең! Мәскәү поездыннан соңга калырга ярамый. Әти башны бетерәчәк!..

Больницадан ничек чыгып киткәннәрдер, ничек вокзалга төшеп җиткәннәрдер, анысын Госман томанлы гына хәтерли. Вокзалда Кәрим белән күзгә-күз очрашкач, ул аптырап, тетрәнеп китте. Кәрим ялгыз түгел, аның янында сөйкемле генә бер кызыкай да бар иде. Маша билет кайгыртырга киткән арада Кәрим белән бер-ике сүз алышып өлгерделәр. Сабирны Омск төрмәсенә алып та киткәннәр икән... Кәрим хәзер шуны юлларга Омскига китеп бара... Госман агентствода булган хәлләрне бер-ике сүз белән әйтә башлаган иде, Кәрим аны туктатты... Мәдинә белән очрашып сөйләшкәннәр икән инде... Ә бу, аны озатырга төшкән сөйкемле кыз, Сабирның сеңлесе Зифа булып чыкты... Зифа... Госман авырлык белән генә бу исемне хәтерләде! Теге, явыз мулла

харап иткән кыз бала була инде алайса бу Зифа... Кабәхәтләр, гөл кебек кызны мәсхәрәләгәннәр...

Юк, Маша, ни теләсә дә, Госманны алып китә алмады. Поезд килде, тик Госманның хәле үтә яман иде. Кәрим дә юлга чыгудан тыйды, «егетне харап итәрбез!» дип, аны Зифа карамагына тапшырып, Кәрим белән Маша янәшә вагоннарда Омск каласына китеп бардылар. Берсе авыру дустын коткарырга, икенчесе яратмаган кадеты белән «кавышырга!»...

Поезд китте. Баш врач больницадан качып чыкканы өчен Госманга бик нык рәнҗесә дә, авыруның хәле яман икәнен күреп, артык шелтәләп тормады. «Киемнәрен ераккарак яшерегез бу казакның!» — дип катгый боерыгын гына бирде.

Өч-дүрт көннән Зифа егеткә нәни генә записка тоттырды. Госман кәгазьне алды, җәйде. Хат! Укый башлады.

«...Усманка! Кулым дерелди... Мәнә инде яза да алмыйм. Ни булды? Мин сиңа шулай өметләнеп барган идем... Язмыштыр шул! Аннан узмыш юк!.. Син хәлсез идең... Син мине коткара алмадың. Миңа үпкәләмә. Әти бик каты куллы... Кичә мине Омск Казачий чиркәвендә никахладылар... Гаеп үзеңдә! Эзләп таба алмадың, кыюланып әтидән сорый белмәдең. Хуш, бәгырем! Без инде Харбинга китеп барабыз! Хуш!

Мария.»

Госман шунда гына Машаның үзен чынлап торып сөйгән булуын аңлап алды. Нинди тәвәккәл һәм чая кыз булган бит! Дөрес, Госманны әтисе катына алып кайтып житкерә алса да әллә ни кыра алмаслар иде, Госман атаманның үҗәтлеген дә, кирелеген дә бик яхшы белә! Тик кыз, әтисен Госманнан ким белмәгән хәлдә, ниләр кыланып тырышып карый бит! Соңгы чиккәчә өметләнә, мәхәббәте хакына сугышырга әзер тора!..

Аның хат укыганын көтеп, юаш кына басып торган Зифа:

— Күңелсез хәбәрме, Госман абый? — дип сорады.

— Юк, юк, Зифа... Бик үк күңелле дә түгел инде! Бу дөньяда нинди кешеләр бар дип уйлап ятам әле!..

Сабирның төрмәдән котылып чыгу хәбәрен дә аңа Зифа житкерде. Тик ничек-ничек, нинди мәшәкатьләр аша төрмәдән ычкынуын больницага хәл белергә килгән Кәрим үзе сөйләп бирде.

— Монда, Госман дус, миннән бигрәк, Валериан Куйбышевның тырышлыгы, дус-ишләрнең күплеге бер яктан файдалы булса... кемнәрнеңдер мал яратуы, мал өчен җан сатарга да әзер торуы икенче яктан эшкә ярады! Бару белән атаклы адвокат Якобсонны ялладым. Валерианны да эзләп таптым. Алар бергәләп, киңәшеп эш иттеләр дә мондый карарга килдек... Генерал-губернаторга үтеп керергә кирәк иде! «Аннан башка коткарып булмаячак!» — диде Якобсон. Безнең бәхеткә губернаторның туган көне якынлаша икән. Бу хәлне ишетүгә Омскиның атаклы алтынчысы Заһирдан исемле алтын балдак койдырып алдык та, Шәмсетдин бай вәкиле буларак, приемга рөхсәт алып, хуҗа катына барып кердем. Иелеп-бөгелеп губернаторның яхшы ук юан бармагына балдакны кидереп тә куйдым!.. Менә шул. Мөкяфәте — Сабир азат!

— Кайда соң ул?

— Монда булса, синең янга килми түзәр идеме? Котылу белән Гаделбәк авылына китте.

— Ник?

— Бердән, Атбасар фиргавеннәренең күзен кырып тормас өчен. Икенчедән, дәваланасы да бар! Юлга бераз акча юнәттек тә озаттык без аны.

— Алайса, Зифа да аның артыннан китәдер инде?

— Юк. Зифаны монда эшкә урнаштырабыз...

— Алайса, ярый, — дип куйды Госман, Кәримгә сынап карап.

«Аны-моны уйламадымы, янәсе?»

Сабир котылган, тик миңа...

Бу хәбәрне Кәрим ахырга калдырган икән. «Касаткинны тагын эләктерделәр! Тагын сөргенгә җибәрәләр инде!» «Ничек? Воликнымы?!»

— Инде ничәнче кат бит,— диде уфтанып Кәрим...

Әмма Куйбышев «үзенә аталган сөрген шәһәре Каинскига барып тормады, качты». Ул ай буе Петропавел шәһәрендә яшеренеп ятты. Шул арада ул берничә мәртәбә эшчеләр арасында чыгышлар ясады. Мондый очрашулар чокырлар арасында, тимер юлның аръягында уза иде. Очрашуларны Кәрим белән Госман да калдырмадылар. Тимер юлчылар, мастеровойлар арасында татар егетләренең, дала уллары казахларның да ишәя баруын күреп, алар чын күңелдән шатлана иделәр!..

•

Агентствоның ишегалдында кечкенәрәк кенә ике бүлмәле бер өй бар. Анда карт почтальон дядя Ваня яши иде. Менә, күптән түгел, рождество бәйрәмендә, суык тидереп, карчыгы үлеп китә. Карт, «Инде ялгыз тора алмыйм, улым белән киленем кулына барам»,— дип авылга күчә. Менә шул флигель бушау белән, Фаддей Кириллович Госманны кабинетына чакыртты.

Теге, 1907 нче елгы тентүдән соң, начальник бик күп вакыт сортировкада эшләүчеләрдән шикләнеп, кырын күз белән карап йөрде. Шул җөмләдән Абдрашитовтан да бик шикләнә иде ул! Әмма карт соңарган, яшерен матбугат тарату юлы үзгәргән иде инде. Хәзер Омск оешмасыннан килә торган сәяси әдәбият билгеле бер адреска гына юллана, адреслар гел-гел үзгәртелеп торыла иде. Тентүдән соң жандармнар турыдантуры эшкә катнашып йөрмәсәләр дә, Фаддей Кирилловичның колагы торган иде, сак иде. Ул хезмәткәрләрне һич көтмәгәндә үз янына чакырып ала, тормыш, яшәү хәлләрен төпченеп сораша... Акылы керделе-чыктылырак булган начальниктан Госман һәрвакыт шикләнеп йөри иде, чакыруга канатланмады, кабинетка, хәвефләнеп, сүлпән генә барып керде.

— Усман Умарович, сезгә ничә яшь?

Бу бер дә көтелмәгән сорау иде.

— Егерме дүрт белән барам. Аның ник кирәге бар, Фаддей Кириллович?

— Ник кирәкмәсен? Начальник үз хезмәткәре турында барын да белеп торырга тиеш.— Госман чынлап торып шиккә калды, иснәнә торгач, берәр нәрсә тапканмы әллә бу кызыл сакал?!.— Хатының бармы?

— Юк әле. Өйләнергә өлгермәдем.— Маша искә төшеп, Госманның күңелен үткер пычак тырнап алды.

— Сәбәп?

«Яраткан кызым кияүгә чыгып китте»,— дип әйтә алмыйсың бит инде, хурланмыйча! Госман авызына килгән беренче сүзне әйтте:

— Моңарчы мөмкинлек булмады.

— Үзем дә шулайдыр дип уйлаган идем,— диде Фаддей Кириллович.— Алайса, мин сиңа, Усман Умарович, мөмкинлек тудырырга уйладым. Син бездә байтактан эшлисең. Мин сиңа ышанам!.. Түбән Каладан килеп йөрү читендер. Тот та флигельгә күч син! Бәлкем, өйләнеп тә җибәрерсең? Туй уздырырбыз. Яшең житкән, фатирың бар... Шуның бәрабәренә син миңа да кайбер яхшылыклар эшләрсең!

— Нинди яхшылыклар ул, Фаддей Кириллович?

— Курыкма! Әллә ни сорамыйм!.. Эш арасында күз-колак булырсың. Хезмәткәрләр арасында кыек-мыек сүз сөйләүче юкмы?!

Госманның тәне эсселе-суыклы булып китте. Менә кая илтеп терәде карт төлке! Ул фатирдан кискен рәвештә баш тартты.

— Торган җирем ару, хуҗаларым да яхшы кешеләр. Миңа кирәкми ул флигель!

— Ал, җүләр! Аны сораучылар күп! Мин сине кызганып кына бит...

— Тик миннән үзегез көткән яхшылыкларны өметләнмәгез, Фаддей Кириллович!

— Ярар, ярар! Менә кире беткән казак! — дип сукранып озатып калды аны начальник.— Һич ипкә китерермен димә, басурман тек басурман! Алай да... флигель синеке,— дип кулын селтәде.

Шулай итеп, һич көтмәгәндә Госман фатирлы булды да куйды! Гыйльметдин абзый белән Гарифә апа бу хәбәрне ишеткәч коелып төштеләр.

— Валлаһи, үз улым кебек идең!— диде Гыйльметдин.

— Билләһи, бәгырьләремне өздең!— диде Гарифә.

Гаҗәп икән ул үз башыңа төтен чыгару! Борынгылар белми әйтмәгәннәр, күрәсең: олы өйгә ни кирәк, кече өйгә шул кирәк!

Госман, бер олаучы белән килешеп, үз йортына искереп беткән чемоданын, егермеләп китабын, вак-төяк кием-салымын алып килде дә, шыр ялангач суык өйнең идәне уртасына басып башын кашып куйды. Утырырга урындыгы, ятарга караваты юк! Кисмәге юк, чүмече юк!.. Шулай аптырап басып торганда, көр тавыш белән сәлам биреп, Кәрим килеп керде.

— Әссәламегаләйкем, мелла Госман. Яңа куыш котлы булсын! — Идән уртасында боегып басып торган дустын күргәч, ул чыдамады, көлеп җибәрде.— Гарасатта кабер өстендә утырган күк ник хәйран калдың?

— Хәйран калырсың! Менә бер кунак килде, аңа да утырыр урын юк.

— Ишегалдына чыгып кара әле, мелла Госман.

Хуҗа аптырап Кәрим артыннан ишегалдына чыкты һәм, кулын чәбәкләп, хәйран калды. Анда җирән кашка җигелгән кашевкада тимер караватк, җиз самовар һәм ашъяулыкка төрелгән зур гына төенчек. Менә егет дисәң дә егет бу Кәрим! Әүлия! Сәгате-минуты белән һәркемгә ярдәмгә килеп җитә!

Ул арада Иван Матвеевич та керен җитте:

— Усман Умарович,— диде ул.— Безнең складта иске-москы өстәл-урындыклар бар. Сайлап ал, аз-маз төзәткәләсәң, ярап торыр. Яхшысын баегач алырсың!

Төштән соң сортировкага Зифа килеп керде.

— Госман абый, ачкычыгызны бирегез, мин өегезне карап чыгыйм,— диде ул, оялып кына.

Госман көлеп җибәрде:

— Аның ачкычы үзендә, Зифа. Тарттың исә ачыла!

Кичен Госман беренче мәртәбә үз куышына кайтты. Кулында шул ук сортировкадан алынган җиделе лампа. Йозакны тартып ачты, кергә үк лампаны кабызды. Исе китте: мич ягылган, ике бүлмәнең дә идәннәре юылган, урын-җир пөхтә итеп җыелган. Өстәлдә кояш кебек янып торган самовар, кызыл бизәкле чәй чәйнеге, биш касә һәм таш тәлинкәләр!

Шүрлектә пөхтәләп тезелгән китаплар...

Боларны елмаеп күзәткәндә, хәтеренә ике кеше килеп төште. Берсе — Мәрфук... Бай улына кияүгә чыкты... Икенчесе Баһаветдин — бай кызына өйләнде...

Елмаюы сүрәнләнде, сүрәнләнде дә, бөтенләй югалды, маңгаена буразналар булып ике сыр ятты...

Мәхәббәт!

Әллә син дә Машаны онытырып Госманның йөрәгенә килеп життеңме?! Нәрсә ул мәхәббәт? Женси омтылыш кынамы, әллә саф илаһилыкмы? Берәүләрне күтәрә, хәлсезләнеп жиргә бөгелгәннәрне дә көч һәм дәрт биреп күкләргә очыра! Икенче берәүләрне, баһадир ирләрне, көчләре ташып торган кызларны жиргә бөгә һәм «гашыйк гариб» итә...

Соңгы айларда Госман шушы сорауга җавап эзли. Күңеле гел аптырый, гажәпләнә, зарыга. Зифа килгәндә, агентство ишегалдының иң читендәге жиргә сеңеп барган иске флигель кинәт яктырып, матураеп китә. Госманның әлегә хәтле иләс-миләс килеп ашкынган күңеле капылт кына, хәтта нинди дер бер билгесез сөенеч белән тулып балкый. Әгәр инде Зифа килми калса, торган урыны ямьсез-салкын, шыксыз... Күңел туктаусыз юксына, алгысый.

Нигә икән?

Бәлкем ялгызлык шулай чыгырдан чыгарадыр? Киңәшер кешесе дә юк. Сабир Атбасарда. Кәрим бае белән товар алырга Петербургка ук киткән. Айсыз кайтмас әле. Валериан тагын югалды. Тагын охранкага килеп капмаса ярый да... Хәзер бит аяк асты тулы шымчы. Сортировкага да бик шикле бер кешене китереп тыктылар. Эшләгән эше дә юк, тик йөри аяк арасында буталып. Иван Матвеевич әрләп тә карады үзен, кая ул, Фаддей Кириллович көпә-көндез яклагач, ул да кыеп сүз әйтә алмый. Эшкә салып та килә, иртәрәк тә тая, көндезләрен дә югалып тора. Почта төйи башлауга, ит исен сизгән песи сыман килеп тә чыга, күзләрен майландырып, хезмәткәрләр арасында бутала...

Шымчылар күбәйгәч, Кәрим консерв заводы һәм тимер юл станцияләрендәге сәяси түгәрәкләрнең утырышын җыймый башлады. Җыйганда да кыска-кыска гына сөйләшеп алалар, игътибар күбрәк газета-журналларга бирелә башлады.

Госманның күңелен иләсләндергән тагын бер вакыйга булып алды — Иван Матвеевич өйләнде. Менә дигән күкрәп-чәчрәп торган чегән кызы алды. Үзе дә чегән икән, каһәр! Яшереп кенә йөргән, өйләнгәч, барысы да ачыкланды. Чегәннәр, өере белән аның йортын камап, атна буе кунак булып яттылар. Иван Матвеевич буйдак чагында Госман белән сортировкада калып, әңгәмә чиртә иде, сөйләшергә ярата, күргәннәре дә байтак, икәүләшеп вакыт кыскарта иделәр. Хәзер эш бетәр-бетмәстә:

— Усман Умарович, алданрак шылыйм әле мин. Земфира көтә, туганнарын кунакка чакырган,— дияргә ярата.

Соң кузгалды бүген Госман. Тагын соңлады. Кая ашыксын?.. Уналты яшьлек чагы түгел, буй буйлаган, акыл утырткан чоры. Ашыкмыйча, кулларын артка куеп салмак кына атлап кайтты. Уйга мавыгып килеп житүен дә шәйләмәгән — маңгае белән ишеккә килеп бәрелде. Ишек?! Флигель! Ишек тоткасына кулын сузуга, күзе тәрәзәгә төште — үт! Димәк...

Ул акрын гына, карны артык шыгырдатмыйча атлап, тәрәзә каршысына килде, үрелеп карады. Туңган пыяла аша мич каршында күләгә төсмерләнә. Зифа! Эскәмиягә ләгән куеп кер уа. Ул тышкы ишекне күтәрә төшеп ачты, тавыш-кара чыкмады, өйалдына керде һәм туктап калды. Нинди дер бер көч аңа керми торырга боера, сулышы ешаеп, күкрәге бер менеп, бер төшеп торг иде. Чү! Өйдә Зифа жырлый! Җыр туктаткан икән аны, моң туктарга боерган. Госманның әле моңа кадәр аның жырлаганын ишеткәне юк иде. Гомумән, Зифа үзен артык дәрәҗәдә тыйнак тота. Күп сөйләшми, сораганда җавап бирә дә эшенә тотына. Эшен бетерүгә тиз үк хушлаша да, ашыга. Үзе әзерләгән чәйгә дә утырганы юк! Йөзендә гел сагыш күләгәсе, күзендә моң дәрьясы.

Ә хәзер бер ялгызы булгач, күрәсең, иркенләп моңын түгә. Ялгыз да кала алмый бит ул бичара. Заводта эшли. Фатирында да халык ишле генә. Тавышы нинди көчле икән, матур! Салкын чишмә чылтырап аккан сыман... Нәкъ Сабир кебек моңлы җырлый. Мөгаен, бу гүзәл моң нәселдән-нәселгә күчәдер. Әнә, пычаксыз да телгәли йөрәкне, бәгырьне турый...

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал!
Житкән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энже лә марҗан кызларның кулбавы...
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Менә әләкте Госман! Керсә дә, уңайсыз, белдерми дә китә алмый. Каккан казык кебек, кымшанырга да куркып үз өйалдына качып тыңлап тор инде, ә?! Нишлисең, тота җыр, кузгатмый! Никадәр сагыш, зар һәм ярсып ашкынган мәхәббәт бар бу җәрәхәтле, илаһи җырда. Ә моны җырлаган йөрәктә күпме сагыш!

Нинди генә егеткә барырбыз, дип, Гөлҗамал,
Колактан-колакка алар сөйлиләр.
Энже лә марҗан кызларның кулбавы...
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы!

Әйтерсең лә, Госманның тырпылдаган йөрәгенә алмаз хәнҗәр кададылар, ул тетрәнеп һәм калтыранып ишекне ачып җибәрде. Сихри моң шунда ук юк булды, каршысында куркынып күзләрен зур ачкан Зифа гына басып калды. Беләкләре ап-ак сабын күбегендә, зур кара күзләрендә мөлдерәп торган сагыш... Кайтып кереп тә кызны куандыра алмадың, Госман!..

* * *

— Ишеттек, кәбәм, ник ишетмәскә? Кәлимулла кода Кызылъяргa товарга барган да ишетеп кайткан, шул әйтте. Ни ди, кодага ике бүлмәле фатир биргәннәр, баеган, аягын түшәмгә чөеп яшәп ята икән, диде...

«Выты, шакал! — дип уйлады Госман, әнисеннән шушы сүзләрне ишеткәч,— выты, кода! Квартира алганны ишеткән, шунда өй котлап бер комган да алып керә белмәгән!» Бабасы Җәфрәтил дә өстәп куйды:

— Шул хәбәрне ишетүгә, мин әйтәм, кода, булмаса, Кызылъяргa товарга барганда бер олауга утыртыгыз, иншалла, мин дә бер атына башчы булырмын, дим. Онықны күреп, хәлен белеп кайтырмын, анасы бик елый, бик сагына, дигән идем, зәмәт, төсе бозылды. Белмим әле, барырбызмы, юкмы, товар дигәнең житәрлек, диде. Ә бер атнада Галимулланы өч подвод белән Кызылъярга җибәргән, мәлгунь...

— Әйтмә дә инде, атай! — Әминә еламсырап, борынын тартып алды.— Мәрфугым бай өйгә төшеп әллә бәхетле буламы дисәм...

Җәфрәтил йөзен чытып кулын гына селтәде:

— Тапкан бәхет! Тәмуг анда, чын тәмуг!

— Әйе, Мәрфук кызганыч. Аларның дәҗҗал икәнен элегрәк тә белә идегез. Ник бирдегез?

— Син алай әйтмә, улым. Язмышы... Күрәсең, чәчләре бәйләнгән булган.

— Шул канечкеч исереккә алмадай кызны әрәм иттегез!

Уллары авызыннан шундый куркыныч сүз чыккач Җәфрәтил карт та, Әминә дә аптырап, гаҗәпләнеп калдылар. Киткән чактагы юаш Госманга бер дә охшамаган иде бу кырыс чырайлы егет! Гөрләп утырган табын тып-тын булып калды, чәйнең тәме китте. Өчесен дә Мәрфукның язмышы хафаландырды. Икесен Госманның күзгә күренеп үзгәрүе хафаландырды. Житмәсә Госман:

— Ярар, арт сабакларын укытыр көн дә булыр әле бер! — дип аларны тагын да шигәйтеп-шикләндереп җибәрде. Ана түзмәде, уйларын тизрәк адаштырырга теләп, урыныннан торды.

— Кара әле, улым, син кайтасыны белгәндәй, Торналарның мунчасын сорап яккан идем. Инде җар булгандыр. Бабаң белән кереп, рәхәтләнеп юынып чык. Бабаңны да ныгытып чап. Миннек чормада, бабаң алыр, яхшылап, ашыкмыйча чабыныгыз.

— Алайса, мунча заказ булган!

Ул сикереп торып әзерләнә башлады. Торналар ерак түгел, барып та керделәр, ут атып торган эссе мунчаның ишеген ачтылар.

— Мәрфук төшкән йортта тәмуг дигән идең, бабай, тәмуг монда ахрысы?— диде шаяртып Госман. Җәфрәтил карт җитди иде, ул өйалдында озаклап чишенде, агач аягын сыйпап бер читкә куйды, стенага ябыша-ябыша мунчага керде. Госман аңа булышыйм дисә, Җәфрәтил карт няген читкә какты:

— Үзем йөри идем әле, анысы шөкер! — диде һәм, мунча сәкесенә кереп утыруга, Госманнан сораша да башлады. Дөньяда ниләр бар? Нигә кайный ул? Нинди сүзләр йөри? Ярман патшасы тагын сугыш ача икән диләр, шул дөресме? Студиннарга ни җитми? Нишләп патшага каршы сүз сөйлиләр алар?! Тагын әллә ниләр, әллә ниләр...

Госман, кулыннан килгәнчә, Җәфрәтил картка дөнья хәлләрен аңлатырга тырышты. Карт аны бүлдермичә генә тыңлады да тагын сораулар белән күмеп ташлады...

Бер нәрсә сөенечле иде: димәк, дөнья турындагы хәбәрләр Имәнтауга да килеп җитә ала икән! Патша хәзрәтләрен дөньяда бер изге дип санап, аның законнарына карышусыз буйсынып килгән Георгий кавалеры драбанд Җәфрәтилнең күңелендә дә шундый сораулар туган икән, бу инде хәл яхшыра бара дигән сүз. «Иң элек ярлы халыкның күзен ачарга кирәк!»,— дип өйрәтә иде бит аларны Валериан...

Госманның кайтуы бер дә сәбәпсез түгел. Дөрес, ул өйдәгеләрне бер чакта да онытмый; ай саен диярлек 10—15 сум акча салып тора, атлы-юллылар туры килсә, вак-төяк күчтәнәчен дә җибәргәли. Ләкин бу юлы аның кайту сәбәбе шактый җитди иде.

Торналарның мунчасы Госманга бик ошады, ул бик озаклап үзе ләүкәдә чабынды, бабасын, әйләндереп-әйләндереп, әллә ничә кат чапты.

— Булды,— диде Җәфрәтил,— син дә, улым, городской кабыгыңны салдың. Булды.


Чәй дә ифрат тәмле булды. Самоварны екканчы эчтеләр. Ник тәмле булмасын ди бу мунчадан соңгы чәй! Бердән, ямь-яшел каен миннек белән сөякләр йомшарганчы чабыну, икенчедән, кала күчтәнәчләре... Чәй-шикәр, баллы прәннекләр, алтын беләзек сынлы сап-сары клиндерләр. Үзе әчкелтем, үзе аллы-гөлле, яшелле-күкле кетердәп торган манпасилар...

— Әлхәмделиллаһи, улым, бу күчтәнәчләрең оҗмах нигъмәтләре сынлы. Беркөн кодалар өстәлендә күреп авыз суларым киткән иде. Юк шул, Мәрфук шунда табыннан алып берне дә бирә алмый! Болай бабаңны, анаңны зурлаган өчен хода үзеңә бәхет ишекләре ачсын.

— Ходай ачмаса, бәхет ишекләрен без үзебез ачарга торабыз,— дип ычкындырды Госман, бабасы белән әнисе моны ишетеп, аңлап бетермәсәләр дә, тагын хафаландылар.

— Эһем, эһем,— дип тамак кырып башлады Җәфрәтил сүзне.— Калада өй алганыңны ишетеп куандык. Бәрәкалла, бик әйбәт булган. Өйле булу ярты бәхет ул! Эһем, эһем... Өең дә булгач, аңа хозяйка да кирәктер бит инде, улым?!

— Шулай, бабай, шулай. Мич ягарга, карарга, аш-су әзерләргә бер кеше кирәк.



Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.

— Выты, мин үзем дә шуны шакыйм! Өйләнергә генә кала, алайса. Йорт-җир әзер булгач, ходайга тапшырып...

«Аллага шөкер, теге кяфер кызы күздән югалды, хәзер малайны кулдан ычкындырмаска кирәк!» — дип уйлады Әминә һәм ирләр сүзенә катнашырга булды. Бит алмалары кызарып чыкты, тавышы калтыранды.

— Әллә мәйтәм, башлы-күзле итикме үзеңне, улым?

— Әйе, әйе! — Карт драбанд да җилкенеп, яшәреп, кызының сүзен җөпләргә ашыкты.— Казах та әйтә: «Баш ике булмый торып мал ике булмый»,— ди. Дөрес әйтәләр. Малны да, чагаларны да үрчетер вакытың. Кызылъярда торсаң да, без каршы түгел. Килеп-китеп йөрерсез, шулай бит, кызым?

— Кайда торсалар да риза, бәхет-тәүфыйклары гына булсын.

Карт сикереп үк торды:

— Ананның күзләп куйган кызы, Мачы Гыйлаҗ кызын әйтәм, выты, урам аша гына тора. Менә дигән, кура җиләк сынлы. Әллә бүген үк яучы җибәрәбезме?

Икесе дә Госманга текәлделәр.

— Мин инде Кызылъярда ярәшкән идем.

— Кызылъярда? — Әминә аптырап, күзләрен зур ачты.— Тагын ни әйтәсең? Үзебезнең Имәнтауда кыз корганмы? Әллә тагын марҗага бәйләндеңме, хәерсез.

— Юк ла, мөселман. Татар кызы.

— Әйт, әйт, кем кызы ул бездән узып ярәшкәнең? Үзебездән булмагач, безне тыңлыймы ул. Санлыймы?

— Кем кызы дип, беләсез ич, минем дус Сабирны? Шуның туган сеңлесе!

— Әбәү! — Тыңлап торган Әминә еланга баскан сыман чинап кычкырып җибәрде.— Теге мулла калдыгымы? Килмешәк!

— Вәт сиңа, кәлҗемә! — Бабасы да акаеп карады.— Егет башыңны хур итеп тол хатынга өйләнәсеңме? Барча станишниклар бот чабып көләр! Гомәр азанчының улы Госман кыз таба алмаган, мулла калдырган йортка кергән, диячәкләр!

— Мин аңа йортка кермәдем. Әле өйләнмәдем дә. Сездән рөхсәт сорарга гына кайттым.

— Анысына рәхмәт. Түлке, кара аны! — Җәфрәтил карт йөнтәс, шыр сөяк йодрыгы белән янады.— Колагың ишетсен, тол хатынга өйләнергә бездән рөхсәт юк! Кәлимулла кода кайтып сөйләгәч ышанмаган идек, рас икән, кан йоткыры!

Әминә үксеп елый ук башлады. Һич тыяр әмәл юк.

Госман, бер кырыйга тартылып, урынына барып ятты. Көннең яме бозылды, күрешүнең тәме китте.

Тагын Кәлимулла кода! Менә кемгә «кан йоттырасы» иде! Бәдбәхет! Сволочь! Шунда барган арада да гайбәт җыеп кайткан. Мөгаен, Валлаһи белән Билләһи сөйләп җибәргәннәрдер. Юк, юк, алар Зифа турында яхшы сүздән башканы белмиләр дә ич! Димәк, Кәлимулланың танышлары арасында Сабир белән Зифаны электән үк белгән берәрсе бар. Зифаның Госманга тартылуын ишетеп тизрәк гайбәт таратырга керешкәннәр!.. Эх, тотып аласы иде дә, якасыннан каерып, биләдән түбән урынына шап итеп утыртасы иде!..

Төн килде. Әмма бу ызбада ут кабызылмады. Бу ызбадагы өч кеше, сәкенең өч җирендә сузсез сузылышып яттылар. Ләкин берсенең дә керфегенә йокы кунмады. Буранлы озын кышкы төнне алар йокысыз гына уздырдылар...

Өч көн торырга дип кайткан Госман икенче көнне үк Кызылъярга китеп барды. «Тагын бер көн монда яшәсәм, мөгаен, барырмын да Кәлимулла байның өй эчен туздырып кайтмый чыдамам»,— диде ул бабасына. «Туздырыр идең, Мәрфук бар! Аңа көн күрсәтәчәк түгелләр!» Туганының кайтканын ишетеп, качып кына, бик азга Мәрфук та килеп

китте... Әнисе белән алар елашып калдылар. Госман юлга чыкты. Җәфрәтил карт, аңаниләрдер әйтергә теләп капкага кадәр озата чыкса да, драбандның сирәк керфекләре дымланды, ул сүз әйтәсе урынга, кулын гына селкеде дә, өйгә, елашып утырган хатыннар янына кереп китте.

Госман Кызылъярга ныклы бер карар белән кайтты. «Юк инде! Кәлимулла кода-явызга үч итсәм итәм, бүген үк Зифаны үземә алып кайтам! Анакай белән бабай бераз чәпчерләр дә тынарлар! Мондый кызны кулдан ычкындырасым юк!»

Ул әлегә кадәр Зифага бер сүз дә әйтмәгән иде. Күз карашыннан, ягымлы мөнәсәбәтеннән чыгып, ул кыз да аны ярата, кияүгә чыгу турында уйлый дип санаган иде. Тик эшләр бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыкты.

— Юк,— диде Зифа.— Госман абый, мин сезгә кияүгә чыкмыйм.

— Зифа, мин сездән мондый җавап көтмәгән идем.

— Сез мине яратмыйсыз, Госман абый. Ярата да алмыйсыз.

— Нигә, Зифа? — Госман кызның сүз сөрешен һаман аңлап җиткерә алмый иде әле.

— Абый сезнең хакта еш сөйли иде миңа. Сез бик намуслы, ифрат саф күңелле кеше. Буямагыз үзегезне минем исем белән!

Ул ишекне чак кына ачык калдырып чыгып китте. Ишек ябып бетерергә дә көче калмады! Госман: «Зифа, тукта, тукта!»— дип өндәп караса да, кыз борылып кермәде...

## 28

1914 елның 20 июлендә Себер казаклары гаскәренең хәрби-наказной атаманы генерал Сухомлинов запастагы барлык алты полкка 22 июльгә Күкчәтау, Петропавловск, Омск җыелу пунктларында булырга боерык бирде. Менә шул приказ нигезендә беренче отделның ике полкы — дүртенче һәм җиденче полклар Күкчәтау каласыннан җиде чакрым ераклыктагы Чаглинка елгасы буендагы җәйге лагерьга килеп хәрби өйрәнүләрне башлыйлар. Әзерлек өчен бик кыска вакыт бирелгәнгә, байтак кына казакларның хәрби хезмәткә яраклы атлары да юк әлегә. Отдел атаманы тирә-яктагы казах волость старшиналарына иң яхшы атларны лагерьга алып килеп үк сатарга рөхсәт бирә! Казаклар кая да булса чыгарга да өлгерә алмыйлар: боерык үтә каты! Җирле казахлар үзләренең өер-өер атларын куып китерә башлыйлар, хәрби өйрәнү кыры берничә көнгә базар мәйданына охшап кала.

30 июль кичендә Николай II бөтен Россиядә гомуми мобилизация игълан ителү турындагы указга кул куя.

31 июльдә Германия Россиядә гомуми мобилизацияне туктатуны таләп иткән ультиматум тапшыра.

1 августта беренче Бөтендөнья сугышы башлана...

Чагала...

«Чагала» дип казах халкы акчарлакны атаган. Күкчәтау күленә көмеш диңгез булып чайкалган кылганлы даладан бер елга агып килә — Чагала үзәне. Руслар аны «Чаглинка» диләр...

Каян башлана торгандыр бу дала ялгызагы! Әмма бик ерактан килә, ашыкмыйча, шауламыйча, нәкъ ерак юлга чыккан чын казах төсле, калгып, моңланып кына ага да ага. Ләкин күлгә турыдан-туры төшә алмый! Күкчәтау тирәсендә үркәчләнеп күтәрелгән кәрван-кәрван таулар үргә басып Чагаланы күлгә җибәрмиләр. Әмма Чагала ачуланмый, киреләнеп кире дә борылмый, тын гына ага-ага да, Төн кызы тауларына житкәч, Җәһәннәм чокырына төшеп китә. Монда нәни генә күл хасыйл була, үзе төпсез, үзе шомлы, караңгы. Бу Җәһәннәм чокыры тирәсенә

мал-туар да аяк баса алмый, яздан көзгә хәтле энәле-керпеле куак-үләннәр үсә. Тубылгы, гөләп, бүре-эт җиләкләре, чия-шомырт, тал-тирәк арасында Африка урманнарындагы лианалар белән ярышырлык, бер-берсенә чия-ләнеп уралган үрмә гөлләр; колмаклар, әрекмән-кычыткannар җайлы урын тапканнар. Җәйге челләдә дә бу чокырдагы су бозздай салкын, монда коену-юыну түгел, кушучлап су эчәргә дә куркыныч, күр дә тор, ялбыр чәчләрен селкетеп, Су анасы килеп чыгар да төпкә тартып алыр...

Искиткеч гүзәл дә, куркыныч та бу Җәһәннәм чокыры, Төн кызы дип аталган Кара су буйлары!.. Шунда, Күкчәтаудан килгәндә, тип-тигез далага тап буласың. Монда Чагала ярлары да артык текә һәм киң түгел. Менә шушы хәтфә тигезлектә, уртада дүрт почмак рәвешендә мәйдан калдырып, зур-озын бараклар, ашханә, пекарня, мунча һәм конюшнялар салынган. Барысы да юан-юан бүрәнәдән. Түбәләр калай белән ябылып, кызылга буялганга, болытлы көннәрдә дә янып торалар. Тәрәзә, ишек яңаклары, кәрнизләр чәчрәп торган сарыга манчылган...

Чагала яры кырыенда ук, башка каралтылардан читтәрәк, аеруча пөхтә эшләнгән, такта белән тышланып бөтен җире сарыга буялган, эре-эре тәрәзәле тагын бер бина тора: офицерлар клубы.

Бараклар артында турниклар, баганага җеп белән асылган бөҗралар, баскычлар, күн тышлы «кәҗәләр». Каралтылар артында берничә чакрымга сузылган плац. Монда ат уйната торган манеж. Махсус утыртмаларга кадалган тал чыбыклары — лозалар. Шунда ук капчыктан тегелгән, эченә салам тутырылган карачкылар. Ат сикертә торган киртәләр, чокырлар, су җыелмалары. Плацның аргы башында мишеньнәр, окоплар.

Иртәнге сәгать алтыда яңгыр булсын, кар булсын, Төн кызы тирәсен шыңгырдатып быргы уйный. Быргы тавышы тынып та бетми, ишекләр ачылып китә, яланбаш, күлмәксез, чалбар гына эләктергән казаклар атылып чыгалар да саф-саф булып Чагалага юынырга йөгерәләр. Шуннан башлана, башлана! Тын тартырга да вакыты юк гаскәри казакның! Гыйбадәт. Физзарядка. Иртәнге аш. Төнге уттан кайткан атларны юу, тазарту, кыру... Аннары атта җилдерү, чабу, кинәт туктап калу, борылып атакага ташлану. Аерым-аерым ат белән барьер алу, киртәкорталардан, чокыр-канаулардан, сулыклардан сикереп чыгу.

Атлар шыбыр тиргә төшә, авызларыннан ак күбек оча, казаклар кулларын күтәрә алмыйлар.

Төшке аш тәмамланганда тагын быргы! Казаклар капкан ризыкларын чәйни-чәйни «җәяүле сугышка» — плацка чабалар. Үрмәләү, шуышу, сикерү. Тагын чыбык чабу, капчыкны мылтык-сөңге белән астан, өстән кадау-чәнчү...

Болардан да иң җәфалысы «манежная езда». Казак җәяүләп, ат өстендә утырган сымак, аякларын камытландырып 150—200 сажин йөгерергә һәм шулай барышында кылыч белән талчыбыкны кыярга тиеш. Дөрес кыймасаң... бетте! Хорунжий, подхорунжий яки сотник сине уңлысуллы теләгәнчә яңаклый. Егылган казак сикереп торып әле уң яңагын, әле сулын куеп өлгерергә тиеш! Офицер сафьян пирчәткәсе белән киерелеп тагын суга. Казак сикереп тора, кара кан белән бергә җиргә тешләрен дә төкерә. Тик ыңгырашмый — ыңгырашырга, йөз җыерырга рөхсәт юк! Монда инде закон да, чорт та юк, жаныңа да, тәнеңә дә офицер хуҗа. Офицер казакны ялгыш туры караган өчен дә канга батырып кыйный, теләсә гарип итеп ташлый, теләсә үтерә. Чөнки ул монда патша хәзрәтләренең күзе, колагы, кулы...

Июль быел коры, эссе. Ай буена күктә бер болыт әсәре күренмәде. Дала керпеләнеп, үз уңаена кыштырдап тора. Чөнки сәмум утлы теле белән аны туктаусыз ялый. Кояш иртәдән кичкә кадәр лагерь өстендә — кыздыра, яндыра, көйдерә, мине кайната. Ә казак иртәдән кичкә кадәр кояш астында. Күләгәгә кереп хәл алырга аның минуты да юк! Ул

һаман плацта, хәрәкәттә — йөгерә, чаба, ата, егыла, үрмәли, шуыша. Кояш кыздыра. Офицерлар аның саен явызлана, аяусызлана баралар.

— Тиз, тиз!

— Тиз, тиз!

Мәйдан мәж килә, кайный — атлар, казаклар, тозлы тир белән бер көндә агарган җилкәләр, кылычлар, пикалар, ат хырылдавы. Команда, боеру, сүгену, тавышсыз ләгънәтләү һәм кан аралаш дала үләненә барып төшкән таза, ап-ак тешләр...

— Түз, казак, түз! Атаман булырсың!

Госман кичә сотня буенча дежурный иде, тәүлек буена аяк өстендә булды. Бүген менә иртәнге подъемнан дежурлыгын башка хорунжийга тапшырды да, иртәнге ашны аннан-моннан гына капкалап, баракка кайтты. Бүген аның ялы. Башта, Күкчәтауга барып, Миңлебай абзаларына кагылып, Имәнтау хәлләрен белешергә дип ниятләгән иде, баракка кайтып сәкегә утыруга, йокы басты да китте. Әйтерсең лә, күз кабакларына эретеп кургаш тутырганнар. Күзне ачып булмый, баш иелеп-иелеп китә! Ул чишенеп тә тормады, бар буена сәкегә сузылды да гырлап йокыга да китте (мондый йокыны халыкта гафләт йокысы диләр!).

Әллә озак, әллә бик аз йоклады, ул мылтык аткан тавышка сискәнеп уянды. Әллә уянды, әллә уянмады, башы иңге-миңге. Кем атсын? Мишеньнәр еракта, аткан тавыш бер чакта да килеп җитми... Ул онытылып тагын йокыга изри башлаган гына иде, тагын мылтык аткан тавыш ишетелде. Шау-шу, кычкырулар. Юк инде, бу төш тә, саташу да түгел! Госман сикереп торды да, баш очына элеп куйган кылычын алып, каешын бәйли-бәйли тышкы ишеккә йөгерде.

Барак янында ыгы-зыгы, шау-шу. Казакларның барысы да ярсыган. Йөзләр чытык, күзләр ачулы, күбесе кылычларын кыныларыннан чыгарып, сүгенеп, кемгәдер кизәнәләр. Тирә-яктагы бараклардан бу гаугалы мәйданга тагын ишле казаклар йөгерә.

— Кем атты?

— Ни булган?

— Ни булсын, әнә сволочь Бородихин Данилов белән Булатовны атып үтергән.

Госман аптырап, тукталып калды. Йокылы-уяулы күз белән төп нәрсәне шәйләмәгән икән, нәкъ аның алдында боҗра булып ураган казаклар уртасында җирдә ике казак ята. Берсе кымшанмый, авызборыныннан күбекләнеп кан ага, бирге якта мәһабәт гәүдәле Булатов, Нижний Бурлук станицасының казагы, җирне тырнап кычкыра, бите-күзе кан гына!

— Туганнар, булышыгыз! Күзләрем! — Менә ул ыңгырашып, хәлсезләнеп аякларын сузды.— Туганнар!

— Әнә, теге подлец клубка чаба!

— Тотыгыз, кан йоткырыны!

— Без Ватанны сакларга сугышка барабыз, ә ул, гад, монда казакларны үтерә!

— Орыгыз!

— Үтерегез кара еланны!

Казаклар, барысы да кылычларын чайкап, сүгенеп, ачудан исереп, офицерлар барагына табан качып баручы есаул Бородихин артыннан йөгерделәр. Ә ул, аз гына йөгерә дә, борылып, үзен куып килгән казакларга револьвердан ата. Менә кылычын селтәп, инде офицерны басып килгән казак чайкалып китеп егылды. (Ату кораллары — револьверлар бары тик офицерларда гына, рядовой казакларга әле мылтык бирелмәгән, алар, устав буенча билгеләнгән салкын корал — кылычлардан гына иде әле.)

Әмма бу хәл казакларны чигендермәде, киресенчә ярсытты, ачу, үч алу тойгыларын көчәйтте генә.

Бородихин өстенә таш, тимер кисәкләре, алардан да көчлерәк булып сүгенү, куркыту авазлары яуды. Госманның да каны кызып, ачуы ташып китте. Бигрәк тә юаш Василий Даниловның үлеп ятуын һәм Булатовның үлем газабы белән тартышып ялваруын ишеткәч, күзләрен кан басты. Ул да, кылычын кынысыннан тартып алып, качып барган Бородихин артыннан йөгерде. Казакларның ачулы ташкынын туктатырлык түгел иде.

Лагерьдагы башка казаклар, гәрчә гаугага соңарып кына якын килсәләр дә, ике иптәшләренең җирдә ятуын күргәч, чыдамадылар, кылычларын айкап ачу елгасына кушылып киттеләр. Кем таш, кем ашханә янында өелеп торган утын яркаларын алып есаулга ата, куа, кысрыклый башладылар...

Бородихин лагерьдагы барлык казакларның теңкәләренә тигән, кыска гына вакыт эчендә үзен канечкеч итеп танытkan, иң явыз, иң әшәке кансыз офицерларның берсе иде. Үзсүзле, гөрбиян. Ул казакларга бәйләнергә сәбәп кенә эзләп йөри. Әгәр бер казакның йөреше, җавап биреше ошамаса, хәзер бугаз киереп акыра:

— Смирно!

Казак мескен сын булып ката. Ә Бородихин уңлап-суллап тегене канга батырганчы кыйный. Әгәр ул узып барганда, казак, онытылып китеп, честь бирмәсә, аның боерыгын тиешенчә үтәмәсә — бетте. Анда инде кул белән генә түгел, очына кургашын үрелгән нагайка белән дә кыйный. Ак күзле, карсак бу есаулдан офицерлар да шүрли иде. Госман аны беренче көннән үк яратмады, күрә алмый башлады. Җитмәсә, аның яшьлек дусты Баһаветдин шул канечкечнең койрыгына әверелде, буш вакытларында икәү йөриләр, рядовой казакларның ипи шүрлегенә менеп төшәргә Кәлимулла бай кияве дә күп сорамый иде. Госман бер көн эчендә Баһаветдин белән телгә килеп, аның белән бөтенләй сөйләшмәс булды...

Кичә ул дежурный иде бит, кичке аштан соң, Госман янына Сандыктау казагы Василий Данилов килеп тәмәке тартып, сөйләшеп утырды. Имәнтау белән Сандыктау — күрше станицалар. Госман яшьрәк чакта анда еш кына була, Даниловны күптәннән белә иде. Шуның өстенә алар бер наряд казаклары, япон сугышында да бергә, бер полкта сугыштылар. Менә, күңелен бушатырга килгән.

— Станичный атаман смотрда атымны яраксыз тапкан иде. Актыккы ике үгезне сатарга туры килде. Хатынны ике малай белән аталарына озатырга мәҗбүр булдым. Шулай итеп, өченче көнне, мондагы бер кыргыздан строевой ат сатып алдым.

— Күпмегә?

— Алтмыш биш сум.

— Әй, яхшы бәя биргәнсең. Аты ничек?

— Ат түгел — ут. Тик ни белән бетәр.

— Ул тагын ни? — диде Госман.— Акчасын түләгән, ат синеке.

— Анысы аның алай да... Хатын, балалар авызыннан өзеп түләдем. Менә, нарядташ, эш нәрсәдә.— Василий тартып бетермәгән папиросын төкереп сүндерде дә җиргә ташлады. Итеге белән баса төшеп таптады һәм тирә-якка карады.— Атны Бородихин алырга йөргән булган, ләкин хакны кимрәк биргән. Ә мин, ат ошагач, кыргыз күпме сорады, шул хакны бирдем.

— И шабаш. Пусть акчасына атланып йөрсен. Син нигә аның өчен борчыласың, Василий?

Василий зур, түгәрәкләп кырылган кара сакалын селкетеп башын чайкады.

— Бик явыз кеше, онытмас.

— Господин дежурный, сезне штабка сотник чакыра! — диде мышнап, йөгереп килгән посыльный яшь казак.

Госман штабка китте, сүз очланмыйча киселде...

Бүген Бородихин лагерь буенча дежурный икән, бараktан баракка кереп тәртип тикшереп йөргән. Василий торган баракта аерата хиреслек

белән казына есаул. Данилов барак алдында гимнастеркасын ямап утырып Бородихинның килгәнен шәйләми кала. Ә Бородихинга шул гына кирәк тә, бар бугазын киереп кычкыра:

— Аягүрә бас! Смирно!

Василий каушавыннан инәсен бармагына кадый, гимнастеркасын төшереп җибәргәч кенә аягүрә баса.

— Нигә офицерга честь бирмисең?

— Гаеплемен! Мин сезне күрмичә калдым, господин офицер.

— Ә, күрмәдең?! — һәм Бородихин сул кулы белән бар көченә «смирно» басып торган казакның йөзенә суга.— Вот, икенче тапкыр күрерсең!

Василий егыла, авыз-борыныннан кан ургыла. Ул арада, узып баручы казаклар туктала, болай да Бородихинны яратмыйлар, бу хәлне күреп тавышлана, нәразыйлык белдерә башлыйлар.

— Бу нинди башбаштаклык?

— Бүген-иртәгә Ватан өчен кан коярга барабыз, ә Бородихин безне эт урынына да күрми.

— Җитәр, күпме түзәргә була?!

Казаклар бөҗра булып урап Бородихинны кыса башлыйлар.

— Нәрсә? Уставны оныттыгызмы?! — Бородихин, револьверын чыгарып, беренче авыз ачкан казакка — Булатовка ата.

Булатов егыла.

Чыгырдан чыккан казаклар кылычларына тотыналар. Бородихин моны күреп калкына башлаган Даниловка ата...

Бородихин, курыккан куян кебек сикергәләп, офицерлар клубына таба йөгерә. Мөгаен, ул андагы офицерлар аны яклар, аралап алыр дип уйлый. Әмма бөтен лагерьның ярсып Бородихинны куып килгәнен күргән офицерлар (аларның да күбесе бу мактанчык, тәкәббер бәндәне үз итеп бетермиләр иде!) клуб артындагы ат бәйләгечләргә бәйләп куелган, иярләнгән атларына менәләр дә Күкчәтауга таба чабалар.

Бородихин йөгереп барып клубка керә дә ишекләрне бикли. Казаклар йөгереп килеп җитеп ишекне вата башлыйлар. Ул арада тәрәзәдән атып Бородихин тагын бер казакны яралый. Башкалар стена буена ышыкланалар. Нишләргә? Бородихинны ничек йолкып алырга? Шул вакытта кемдер кычкыра:

— Ут!

— Яндырырга сволочьны!

Каннары кызып, ачулары соң чиккә җиткән казакларга шушы сүз җитә кала. Берәүләр ашханәгә, берәүләр пекарняга йөгереп барып коры утын яркаларын ташый башлыйлар. Ә берәүсе исә пекарнядан бер олы шешә керосин күтәреп чыга да клуб стенасына бәрә. Шырпы сызалар, гөлт итеп ут кабына һәм такта белән тышланган, буялган коры стеналарны шундук ялап ала.

Нәкъ шуны гына көтеп торган кебек, көньяктан, Күкчәтау ягыннан җил кузгала. Казаклар мавыгып киттеп клубның икенче почмагына да керосин сибәләр. Күз ачып йомганчы ут бинаны бөтен яктан урап ала, стена-түбәләр дөрләп яна башлый. Тәрәзә пыялалары шарт-шорт ярыла, коела, көне буе кояшта кызып-көйрәп утырган бина ут фонтаны булып күккә ыргыла. Дәһшәт! Җәһәннәм! Якын килерлек түгел. Инде үз эшләренең кая таба барганын чамалаган казаклар бер-берсен дәртләндерергә тырышалар:

— Эткә эт үлеме — янсын!

— Көлен күккә!

— Бородихиннан шашлык!

Эшнең соң дәрәҗәдә мөшкел икәнен сизеп, Бородихин Чагала елгасы ягына караган тәрәзәләрнең берсеннән тышка сикереп чыга. Тәтен белән

ышыкланып казакларга күренмичә кача. Ишекләр бу якта булгач, казаклар ул як турында уйлап та карамыйлар. Югыйсә Бородихин, ак күзләрен кан баса!..

Әнә Чагала. Аны йөзеп чыксаң, аргы якта куаклык, ул төтенгә тончыга-тончыга ярга таба атыла. Инде яр ерак та түгел!

Шул вакытта яр астыннан ике казак менеп киләләр. Алар монда коенырга, балык тотарга төшкәннәр. Лагерьда ут-ялкын барын күргәч, корыкларын ташлап, шунда йөгерәләр. Карасалар, каршыларына револьвер тотып, шашкан кыяфәттә, танырлыгы калмаган офицер чаба. Ул казакларны балык тотып утыручылар дип белми, «кáмадылар!» дип уйлап ала да дерелдәгән кулы белән револьверын уң чигәсенә тери...

Ату тавышын ишетеп барак артына башка казаклар йөгерешеп чыгалар һәм кылычлары белән җирдә яткан Бородихинга ташланалар. Һәрберсе, бер генә тапкыр булса да, бу явыз офицерның тәненә кылычын батырырга, шуның белән үч ачуын басарга тели.

Башкалар белән килеп җиткән Госман да кабәхәт җанлы офицер янына килеп кылычын уйната, тешләрен шыкырдата.

— Данилов өчен! Булатов өчен!

Ул арада офицерлар клубы янтаеп ишелеп төшә, ялкыннар кызыл төлке булып күккә ыргыла...

Төн...

Лагерь өстенә китек дага булып ай эленгән. Чагала буендагы янып җимерелгән бинаның соңгы кисәүләре көйри, пыскый... Бу хәрабәдән ерак та түгел яр буенда мылтыклы казак арлы-бирле атлый. Аның алдында иске одеял белән капланган, әле кичә генә бөтен казакларның каннарын эчеп йөргән гаярь есаул Бородихинның теткәләнеп беткән гәүдәсе... Барак алдында күзләре акаеп, катып калган тагын бер мәет сузылган. Бусы инде рядовой казак Василий Данилов. Аның янында сакчы юк, ул ялгызы.

Лагерь тып-тын. Баракларның ишеге ябык. Бараклар эчендә караңгы. Кабер тынлыгы. Казаклар озынга сузылган ике катлы сәкеләргә тыгызланып ятканнар да уй чоңгылларына батканнар. Ара-тирә генә пышылдашкан авазлар ишетелеп куя.

— Петро, ничек уйлыйсың? Инде ни була, ә?

— Ни булсын? Берәүләрне аталар, бер өлешебезне каторгага куалар. Полкларны расформировать итеп, номерларын бетерәләр.

Тынлык. Көрсенү. Кыштырдау — казак әле бер якка, әле икенче ягына борылып ята, аннан торып утыра.

Көндез кабәхәт Бородихиннан үч алганда алар күбәү иделәр. Берсенә берсе гайрәт-көч өсти ала иде алар. Ә хәзер, төн уртасында, барак сәкесендә казак ялгыз, берүзе. Такыр итеп кырылган ялгыз башы һәм андагы очсыз-кырыйсыз уйлары.

— ...Инде ни булыр?!

Сигезенче баракның ин төпкерендә яткан IV полк I сотня подхорунжие Гомәр угылы Госман Әбдрәшитов та шул чияләнгән бер төенне чишә алмый:

— Инде ни булыр?

Юк, Госман үзенең бүгенге чуалышка катнашуына үкенми. Бородихин зарарлы, йогышлы шеш иде! Шеш кайчан да булса тулып ярылырга тиеш. Бүген ул ярылды! Җаны җәһәннәмдә! Ә шулай да... Күпме акыллы сүзләр тыңлаган, ак белән караны бик яхшы аера белә башлаган, Валериан Куйбышевтан күпме акыл алган кешегә мондый вак үч алу хасмы?.. Революцион түгәрәкләр, оешмалар турында хыялланган Госман өчен ялгыш адым булмадымы бу?!

Имәнтау хәтеренә төште. Хатыны Зифа. Улы Нияз, кызы Галия... Ике баласы булганчы, ул үзенең өйләнгәнен Имәнтауга хәбәр дә итеп

тормады. Зифа белән араны көйләделәр дә никах укыттылар. Бабасының да, анасының да ризалык бирмәслеген ачык белә иде Госман!..

Казах халкы юкка гына «Бала — бал, баланың баласы — җан!» — димәгән икән! Дөрес исәпләгән Госман, оныкларын күргәч, әби белән карт бабайның да күңелләре йомшады. Дөрес, башта алар оныкларын гына үз иттеләр. Әминә аларны катык-сөт белән сыйлады, ә карт драбанд титаклап аларны Казантауга чиягә, җиләккә алып барып йөрде. Төрек сугышында күргәннәрен, сөйләгән саен бераз арттырып, сөйләгән саен бераз матурлап, кабартып сөйләде. Зифа Имәнтауга кайткан араларда печән чапты, урак урды, урман кисте. Станичниклар башта «гөнаһларын юа!» дип мәкерле елмайсалар да (Кәлимулла бөтен дөньяны сасыткан, Зифаның яшьлегендә күргәннәрен теләсә кемгә сөйләп йөргән иде!), торабара Зифаның уңганлыгына, эшчәнлегенә соклandылар. Әби белән бабай да «килен!» дип авыз тутырып әйтә башладылар.

## 29

Полк һәм сотняларны сискәндереп, дежурныйларның бар тавышларына кычкырган командалары яңгырады:

— Тизрәк линейкага!

— Сотнялар, тезелергә!

— Ти-зе-рәк!

Иртәнге гадәти эшләр — юыну, физзарядка, иртәнге аш, атларны кыру, юындыру, шул тирәдәге шау-шулар бүгенгә онытылды. Казаклар тиз-тиз киенеп, бер-берсенә күтәрелеп карарга да куркып, командир боерганча, устав кушканча, бараклар алдындагы мәйданга чыгып сафларга тезелделәр. Бераздан сафлар алдына җәяү, кискен адымнар белән ашыгып атлап, озын, чандыр буйлы, әллә кайдан ерактан күренеп торган кызыл тукмак борынлы (махмыр көннәрне аерата кызарып китә торган!), сирәк, җирән сакаллы войсковой старшина подполковник чыгып басты. Ул да Бородихин сыңары, шундый ук явыз, гәрбиян, начальство алдында ялагай, үзеннән түбәннәр алдында ут чәчәргә яратучы кансыз бер бәндә иде. Казаклар аны үзара «фаланга» — агулы кара корт дип атыйлар иде.

Полклар мәйданга шакмак булып тезелеп баскач, дежурныйлар берәм-берәм аның алдына килеп кырт кисеп рапорт бирделәр.

— IV полк стройга басты!..

— VII полк...

Госман буйга озын, шуның өчен беренче шеренгада һәм уң флангта — беренче казак. Һәммәсе аның күз алдында. Ул сафлар алдында кәпәренеп, сыны катып басып торган подполковниктан күзен алмады, уйлар һаман бер юнәлештә агылдылар. «Хәзер моның авызыннан ак эт кереп, кара эт чыга башлар!»

— Вольно! — диде «фаланга» кулын чигәсеннән алып. Ул, барлык казакларның гаҗәпләнүенә каршы, сүзне артык чәпчеп башламады.

— Безнең ата-бабаларыбыз, менә инде өч йөз елдан артык рус падишаһ хәзрәтләренә тугрылыклы хезмәт иттеләр. Рус тәхетенең сакчысы һәм таянычы булдылар. Бу изге хезмәт — безгә алардан сакланып килгән иң кадерле мирас...

Ул шулай бик ерактан урап-чурап тотынды, тавышы да азып китмәде, моңарчы казакларның ата-бабаларын, аларның кабер такталарын аты-юлы белән тозлап-суганлап сүгүче «кара кортның» бүген тәкъва суфый сыман Инҗил сүзләре кыстырып, үгет-нәсихәт таратып торуы гаҗәп, бер үк вакытта куркыныч та иде!

Үгетләү, намуслы булырга чакырулар тынгач, войсковой старшина полк командирларына команда бирде.

— Дүрт шеренгалы рәтләр белән тезеп җәяүле адым белән маршка!

Аның сүзен күтәреп алып ашыгыч командалар яңгырады.
— Дүртенче полк, уңга!
— Җиденче полк, уңга!
— Поход колоннасы белән турыга марш!

Кояш Күкчәтау сыртлары артыннан яңа гына күтәрелә башлаган иде. Әле һава тын, салкынча. Чык исе борыннарны рәхәт кытыклый. Эшелон, поход колоннасы белән лагерьдан чыгып, туып килгән яңа көнгә таба атлады. Кояш нәкъ аларга карап күтәрелеп килсә дә, казакларның күңелләрен яктыртмады, атлыларның уйлары артык караңгы, гадәттән тыш борчулы иде. «Фаланга» үзенең кара корт төсле чем-кара аргамагына атланып, эшелон артына төште. Ат менгән командирлар, офицерлар аның шыпырт күрсәтмәләрен тыңладылар да берничәсе колоннаның алдына чыкты, икешәрләп-икешәрләп уң һәм сул флангларга да таралдылар. Бу да артык хәвефле һәм куркыныч күренеш иде.

Бер сәгать чамасы баргач, колоннага туктарга команда бирелде... Туктадылар. Казаклар ярыйсы ук тирләгәннәр иде. Моннан ерак түгел күл. Шул яктан сиздереп кенә җил исә. Сулыш алырга иркенрәк булып китте. Әби чәчләрен тузгытып-көмешләнеп торган куе кылганлыкка карагач, Госманның елыйсы килеп китте. Баядан бирле күңелендә чыңлап, сызлап торган уйлары ачык бер төс, мәгънә алдылар. Әйе, «кара корт»ның төче диярлек тавышы юкка түгел. Күңеленә бөялгән ачулы зәһәр агуны чыгармас өчен шулай тыелып торды! Баһау белән күзгә-күз очрашуга, Баһау күзләрен тизрәк читкә борды, Госман белән якынаерга курыкты. Димәк, ул да нидер белә! Төне буе Госманны борчыган уй бер генә, ул хатыны Зифа, балалары турында сызланып уйлады. «Алар нишләр? Ни күрерләр? Ничек яшәр?»

Тагын команда яңгырады, казаклар башларын гадәттәгечә чак кына югары чөеп, күз кырыйлары белән уртага карап катып калдылар.

Полк командирлары «кара корт» белән нидер киңәштеләр дә, барысы бергә, атларын Күкчәтау юлына таба бордылар, юртып китеп, озакламый күздән дә югалдылар. Уртада ат менгән офицерлар, сотниклар гына калды.

Таш булып сеңгән казакларның һәммәсен дә шул ук бер уй, бер сорау борчый: ни булып бетәр? Нинди язмыш көтә аларны? Җәзасыз калдырмаслар, әммә нинди җәза?.. Сугыш чоры, законнар каты, офицерлар кансыз...

Тек катып торалар, бушанырга һаман боерык бирелмәде, көн шактый ук кыздыра башлады, авызлар кипте, иреннәр карындык белән капланды. Тел авызга сыймый башлады. Эчәсе килә. Атлар койрыкларын чәнчеп тынычсызланалар, үрелеп бер-берсен тешләргә азапланалар. Хуҗаларының гадәттән тыш көн кичергәнен алар да сизә бугай...

Инде каннары ката башлаган казакларның тәннәре чымырдап китте: ниһаять, күренделәр! Күкчәтау ягындагы тау өстеннән әүвәле бик күп сөнгеләр, аннары солдатлар күренде. Алар бөтен тау иңенә чылбыр булып сузылышып яттылар. Мылтыклар «смирно» баскан казаклар колоннасына төбәлде.

Күзләр сулга карадылар — тау өстеннән аларга пулемет муеннары сузылган. Юлны иңләп кавалерия җилдерә! Алда, ак аргамакта, ак җәйге мундирдан генерал чаба. Алтын погоннары, аксельбантлары кояш нурында чагылып, янып китә.

Атлылар якынлашты, уйсулыкка җитәрәк юлдан борылып эшелонга ике йөз адымнар кала тукталды. Генерал уң кулын күтәрде. Госман танып та өлгерде. Генерал II отдел атаманы Усачев иде. Ул биеп торган аргамагының тезгенен җәя бавы кебек киереп тартты да алгарак чыкты, ачулы караш белән рәтләрне сөзеп, карап үтте. Карт булса да, күзләреннән зәһәре коелып бетмәгән әле, ачуташ төсле елтыр-ялтыр килеп торалар. Ул гырылдаган авазлар белән кычкырып сүзен башлады:

— Себер казак гаскәре Куканд-Бохара-Акмәчет экспедицияләрендә зур батырлык күрсәтеп, падишаһыбыз хәзрәтләре каршында дан казанды. Рус падишаһлары борын-борыннан Себер казачествосын үз гвардиясендә исәпләде һәм тәхетне саклау кебек бөек вазифаны аларга ышанып тапшырды... Падишаһның тәрәге булган һәр офицер сезнең атагыз, остазыгыз. Офицерга кул күтәрү — тәхеткә кул күтәрү белән бер дәрәҗәдә гөнаһ һәм җинаять. Билгеле, сезнең арада да намуслы, уставка тугрылыклы казаклар бар. Мин менә нәкъ шуларга мөрәҗәгать итәм дә! Үз арагыздагы мөртәтләрне себереп чыгарыгыз! Сафлар алдында аларның каһәрле исемнәрен атап үзегезне аклагыз!

Гыргылдап сүзен тәмамлаган генерал кесәсеннән ак батист яулык чыгарды да тырышып-тырышып муеннарын, битен сөртә башлады. Рәтләр, тын алырга да куркып, аннан күзләрен алмадылар. Атлар гына эссегә, черкигә чыдый алмыйча койрыкларын чайкап сугалар, тояклары белән җирне казыйлар...

Генерал яулыгын әле чыгара, әле бөтәрләп кесәсенә тыга, офицерлар аңа карап катканнар, селкенергә дә базмыйлар. Күзләре казаклар сафы буйлап йөри. Беркем кыймылдамый, беркем дә сүз башларга базмый. Шактый вакыт узды. Генерал яулыгын төшереп җибәрде, шуны гына көтеп торган сыман, «кара корт» яулыкны һавада тотып алып хуҗасына кайтарды, барыбер рәхмәтен ишетмәде. Генерал бакырып кычкырып җибәрде, акбүз аргамак сикереп куйды.

— Әйтмисезме? Бунтовщикларны яшереп калырга тырышасызмы?.. Алайса һәрбер унынчы казакны атарга!

Тынлык тагын да авырайды, һава тагын да ныграк чыңлап, кайнарланып бугазларга барып тыгылды. Кузгалып киткән аты генералны чак кына артка аудармады.

— Господин подполковник, бирегез исемлекне!

Дәһшәтле кәгазь бер кулдан икенче кулга күчте.

— Бездә ул фетнәчеләрнең исемлеге бар! Исемнәре аталганнар, стройдан чыгып, биш адым алга бассыннар!

Колонна дерт итеп китте, димәк, арада шымчы-провокатор да булган![1] Йөзләр агарды, кабаклар тартылды. Эчләр «жу» итеп китте.

Генералның күзләре исемлектә. Менә ул тамагын кырып, өзәнгегә басып калкынып, тавышына көч-гайрәт өстәргә тырышып, исемлекне игълан итте.

— Рядовой казак, Арык-Балык станицасыннан Алексей Валчаев!

Иң арткы рәттән яшь кенә, сөйкемле матур күзле егет чыгып баскач, генерал үзе иманеп китте.

— Лобаново станицасыннан рядовой казаклар Максимов белән Рузеков!

— Чалкар станицасыннан рядовой казак Балагаев!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

— Имәнтау станицасыннан подхорунжий Абдрашитов Усман!

Дәһшәтле, кот очарлык исемлек буенча стройдан чакырып чыгарылган унтугыз казакны солдатлар конвое урап алды.

Эшелон тетрәнеп башын игән иде. Конвой камалышта калган казакларга җикеренә-җикеренә аларны Күкчәтауга таба алып китте.

* * *

Бүген 1915 нче елның 13 нче август иртәсе.

Унөч тәүлек инде ерак Көнбатышта рус-герман чигендә канлы сугыш бара. Ике яктан да йөзәрләгән, меңәрләгән бер гаепсез кешеләр кырыла.

[1] Мәгълүматлар судтан соң гына беленә: чуалыш вакытында Күкчәтаудан килгән урядник Каминский арада булган. Ул Бородихинны үтерүдә катнашучыларны шыпырт кына үзен дәфтәренә теркәп йөргән.

Меңләгән тап-таза ирләр гарип-гораба булып кала. Күпме балалар үз аталарын күрә алмыйча ятим-үксез булып үсәчәк! Күпме хатыннар — тол, житкән кызлар ирсез кала. Күпме калалар, авыллар яна, җимерелә, хәрабәгә әйләнә. Әле сугыш башлануга унөч кенә тәүлек! Күпме көнатналарга, ай-елларга сузылыр ул? Күпмегә барыр бу дәһшәтле орыш? Кем белә?.. Мөгаен, хода хәзрәтләре дә бу сорауга җавап бирә алмый торгандыр?!

Бүген үндүртенче елның унөченче август иртәсе.

Кукчәтау күгендә калын кара болытлар. Алар суга манылган ябага йон булып укмашып, сәлберәеп, каралып өстерәләләр. Өстәвенә төньяктан, бу вакытта һич булмый торган салкын җил исә. Көзге җил.

Кукчәтау күле чайкала. Яшькелт-кара дулкыннар тузгып, ак чалмалы ярсулы башларын күтәреп, бер-берсен куалар да ярларга барып сугылалар, челпәрәмә киләләр. Чигенәләр дә тагын сугылалар шыксыз дулкыннар!

Бик иртә әле. Көн яңа туып килә. Алай да бөтен халык кара таңнан урамда. Кала халкы гына түгел, Кукчәтау урамнарына бүген авыллардан, якындагы станицалардан да кеше килеп тулган. Олысыкечесе гел бер якка ашыга, чырайлар чытык, башлар иелгән... Рәнҗүле иреннәр күгәргән, дерелди. Күзләрдә ачу, хәсрәт һәм нәфрәт. Ак сакаллы картлар да, таякка таянган карчык-корчык, хатын-кызлар, аналар, ирләр, бала-чага — һәммәсе дә бер якка, тау ягына агыла. Ул якта каланың казак-урыслары яши...

Монда, тау итәгендә, кала читендә, таштан салынган караңгы бер бина. Әйләнә-тирәсе очлары казык сыман юнылган юан, биек-биек баганалар белән уратылган. Бу — Кукчәтауның өяз төрмәсе. Төрмә тирәсендә халык тагын да ишлерәк. Халыктан да күбрәк булып төрмәне мылтыклы солдатлар, кылычлы офицерлар, җайдак казаклар камаган. Алар төрмә тирәсен генә түгел, якын-тирәдәге бөтен юлларны, тыкрык-урамнарны япканнар. Берәүне дә артык якынга җибәрмиләр, берәүне дә төрмә капкасы ягына уздырмыйлар.

Төрмә тирәсендәге йорт түбәләрендә, капка башларында, койма өсләрендә дә кеше, яшьрәкләр агач башларына үрмәләгән, фонарь баганаларына кунаклаган. Карыйлар. Көтәләр. Тетрәнәләр. Җайдак офицерлар чаба, кычкыра башладылар. Төрмә алдына ашыгыч адымнар белән бер рота кораллы солдатлар килеп басты.

Барлык күзләр төрмә капкасына төбәлде. Күзләрне авырттыра торган, колакларны саңгыраулата торган тынлык. Менә төрмә капкасының йозаклары шалтырады. Авыр капка чинап, шыгырдап ачылып китте. Алдан ялангач кылычларын иңнәренә күтәргән атлы офицерлар күренде. Алар артыннан сөңгеле мылтыкларын кулларына җайлап тоткан солдатлар чайкалды. Ишле булып богау зыңы ишетелде. Ялан аякларына богау уралмасын өчен чылбырларын кулларына күтәреп әкрен генә тоткыннар килеп чыкты. Алар барысы да таушалган, ертылган, пычранган Себер казаклары формасыннан. Чалбардагы кызыл лампаслар керләнеп каткан. Башлар түбән иелгән. Арада язмышка бөгелмичә туры карап атлаучылар да бар. Төрмә. Йокысыз төннәр. Допрос. Ачлы-туклы паек. Йөзләр суырылган, агарган. Кашлар җимерелгән.

— Зың-зың!

Халык шаулашып, акырып-иңрәп кораллы сакчылар өстенә ишелде. Нәкъ шул вакытта барлык шау-шуларны сискәндереп, колакларны кисеп, җан авазы белән кычкырган бала тавышы яшен булып яшьнәде:

— Әти, җаным!

Халык ярсуын ничек тыярга белмәгән солдатлар каушап-куркып бер-бер артлы, тәртипсез рәвештә һавага ата башладылар. Ачулы команда халыкның юлын кисте.

— Алга, марш!..

Халык дулкынын икегә ярып алдан, штыкларын текә тотып солдатлар атлады.

Лагерьдагы чуалышның икенче иртәсендә канечкеч «кара корт» алып килгән казаклар таулар уртасындагы уйсулыкка юнәлделәр. Әмма ул хәзер беркөнгегә караганда тараеп, кысрыкланып киткән сыман күренде. Уйсулыкның уң як канатында җәяүле стройда IV, VII полк казаклары басып тора. Начальство аларны куркытырга, «гыйбрәт алырга» шушы тамашага алып килгән... Күзләр үзләренең богаулы полкташларын сөзеп-көтеп ала. Кичәге полкташлар, наряддашлар, якташлар, авылдашлар... Һәрберсе уйлый, хәтерли... Менә бу богаулы куллар, аяклар бик таныш ич аңа! Бала чакта бергә уйнап үстеләр! Язгы өйрәнүләргә бергә чыктылар. Бергә хезмәт иттеләр. Бер-берсен аяп, саклап, дошманга каршы атакага бергә ташландылар. Бер-берсенең тәннәрен дә, җаннарын да ничә тапкыр саклап калдылар...

Кансыз Бородихинның үлеменә алар гаепле идеме соң?.. Һәм бу очрашу иң-иң соңгысымы?!

Сул канатта — ялангач кылычларын иңнәренә күтәргән атлы офицерлар эскадроны. Кара-каршы килгән ике тау сөзәгендә атарга команда гына көтеп торган пехота ротасы! Халык алай-болай тынычсызлана башласа, алар әзер, әзер!..

Сопка итәгендә сигез багана. Сигез карагай. Баганалар артында әле яңа гына казылган тирән канау. Кызыл балчыгы да үзле-дымлы, кипшенеп тә өлгермәгән.

Баганалар алдында атлы начальство — генерал үзе, подполковниклар, хәрби трибунал членнары һәм хәрби врач.

Есаул Бородихинны үтерү һәм лагерьдагы офицерлар клубын яндыруда гаепләнеп җавапка тартылган казакларның эшен караган ашыгыч, хәрби трибуналның приговоры кичә кич, төрмә ишегалдында игълан ителгән иде. Сигез казак үлем җәзасына, егермесе төрле срокларга каторгага хөкем ителде.

Госман үзенә чыккан «өлешне» — егерме ел каторганы ничектер артык исе китмичәрәк тыңлады. Ничек кенә батырланма, үлем — соңгы чик. Аннан һәр җан иясе чиркана! Ә каторга, егерме ел булса да, тормыш, яшәү, аның бик еракта шәйләнгән чиге бар. Аннары, унике тәүлек буена бертуктаусыз дәвам иткән сорау алулар, мыскыллау-җәфалар, кыйнаулар, камчы, нагайка белән ярулар дөньяда яшисе килүне киметеп, битарафка әйләндерә дә язган иде. Алай булса да риза, болайга китсә дә ярый — бары тик бу чамасыз кимсетүләрдән, хурлыклы көнтөннәрдән генә котылырга!

Ул хәзер каторгага хөкем ителгәннәр арасында, тагын уң флангта басып тора. Яралы аягы богауларга артык сизгер булды, тоташтан сызлый, әрнеп авырта. Уй күктәге аяусыз болытлар төсле бер җыела, бер тарала, менә бу нахак, кабахәт үлем җәзасы башкарылачак дәһшәтле мәйданнан бер Имәнтауга күчә, бер Күкчәтау урамнарына. Күз алдына бер-бер артлы Җәфрәтил карт, әнисе, хатыны Зифа һәм сабыйлары Галия белән Нияз килеп торалар...

Баягы бала: «Әти, җаным!»— дип кычкырып җибәргәндә Госман тән яраларын, сызлауларын онытып, җаны ачыткангa түзә алмыйча чак кына үкереп җибәрмәде. Кысылган иреннәреннән кан саркып тамды... Әллә бала бөтенләй кычкырмадымы? Госманның колагына гына ишетелеп калдымы?! Кем кычкырды икән? Кайсысы? Галияме? Ниязымы?!

Уйны челпәрәмә китереп барабаннар сугылды. Үлем җәзасына хөкем ителгән җиде казакны (сигезенче казак Булатов Бородихин пулясыннан сукырайган иде, аны вакытлыча больницада калдырдылар. Алгарак китеп әйтергә кирәк, Булатовны да дәвалаган булып больницада бераз тоттылар да шушы сигезенче баганага бәйләп аттылар, шунда-

гы чокырга күмеп, таптап киттеләр) чокыр алдындагы баганаларга китереп тераделәр.

— Хөкем ителгәннәр, соңгы үтенечләрегезне әйтегез! — диде җәзалау процессын үз кулына алган генерал Усачев.

Тынлык. Җыелганнар муеннарын сузып тыңладылар. Сискәндереп богаулар чыңлап алды. Бишенче багана алдында торган Алексей Волчаев — озын, баһадир гәүдәле дип әйтерлек таза Арык-Балык станицасы казагы (Госман аны да бик яхшы белә, Алексей һәр яз Сабан туена Имәнтауга килә, көрәшеп бер-ике сөлге, яки ашъяулык алмый китми иде) ялт итеп башын күтәрде дә, генералга таба борылды.

— Император хәзрәтләреннән дә, сездән дә рәхим-шәфкать көтмибез! Тизрәк атыгыз! — Ул аз гына тыелып калды, тирән сулыш алып сүзен ялгады. — Шунысы жәл, Бородихин белән «фаланга»ны да алып китеп булмады! Өлгермәдек.

— Молчать!

— Аңа да чират җитәр! — диде аңа күрше баганада торган казак.

«Фаланга» генерал янында гына тора иде. Арык-Балык казагының үләре алдыннан әйткән сүзләре аңа ап-ачык килеп ирешә, улияр өстендә чайкалып китте. Генерал зәһәр, кискен итеп команда бирде.

— Башлагыз!

Хөкем ителгән казакларны тартып ук китереп баганаларга бәйләделәр, башларына капчык элделәр, кул-аякларындагы богауларны ачып-бушатып алдылар.

— Әзерләнергә!

Бүген бөтен командалар туп-туры йөрәккә барып тияләр иде, җыелган халык кына түгел, солдатлар да тетрәнеп китә, алга сузылган мылтыкларының сөңгеләре дерелди...

Мылтыклар бичараларга төбәлде, сигезенче багана гына буш, ул ниндидер өн кебек, янаучы бармак сыман караеп, шыраеп утыра. Генерал ак батист яулыгын болгады.

— Пли!..

Госманның үлем белән беренче очрашуы гына түгел. Аның үзен дә ничә мәртәбә кадый, атып үтерә яздылар, ничә тапкыр баш очында кылыч уйнады. Әмма бүген ул үлемгә күтәрелеп карый алмады. Бу башка үлем иде, вәхшиләрчә үлем... Бер канечкеч кабахәт җан өчен ничә кешенең гомерен кыйдылар! Бармы бу җирдә хаклык? Әгәр бар икән, ни өчен җәзага менә бу гаепсез рядовой казаклар тартылды?!

Команда кискен булса да, мылтыклар берьюлы шартламады. Өзек-өзек яңгырады ул, ертык булып, җанны талап. Тагын ниндидер командалар яңгырады, барабаннар дөп тә дөп дөньяны шаулаттылар. Атылганнар арасында Госман да була ала иде бит! Я, ни гаебе бар иде аның? Ни гаебе бар иде Арык-Балык казагы Алексей Волчаевның?!

Ул күзләрен авырлык белән генә ачканда баганада берәү дә юк иде инде. Солдатлар сапер көрәкләргә ябышканнарын кул сырты белән кыра-кыра канау читендәге балчыкны ашыга-ашыга аударалар, күмәләр. Озакламый канау өсте җир белән тигезләнде [1].

1914 нче елның 20 нче август көнендә Омскидагы Акмула губернаторы ставкасыннан Петербургка, полиция департаментына, махсус фельдкурьер белән биш җирдән сургуч белән пичәтләнгән, «Аеруча яшерен!» дип билгеләнгән пакет җибәрелде. Пакетта менә нинди документ бар иде.

---

[1] Хәзер бу урында чирәм җирләрне үзләштерергә килгән яшьләр хөрмәтенә «Первоцелинник» монументы тора.

Эчке эшләр министрлыгы.
Акмула губернаторы өлкә Правлениесе карамагында Яшерен отдел.[1]
20 август 1914 ел

№ 7114

Омск шәһәре.

1914 елның 31 июль көнендә, кичке сәгать 5 тә, Күкчәтау сбор пунктына мобилизацияләнгән IV һәм VII полк казаклары хәрби баш күтәрү ясадылар: барлык җиһазлары белән офицерлар барагын яндырдылар һәм офицер подесаул Бородихинны үтерделәр.

Ошбу елның 11-12-13 августында барган Хәрби кыр суды, хәрби бунт оештыруда, офицерлар барагын яндыруда һәм подесаул Бородихинны үтерүдә гаепләнгән 39 кешенең эшен карады. 11 кешене аклады, 8 кешене үлем җәзасына, калганнарын төрле срокларга каторга эшләренә хөкем итте.

13 августта, иртәнге сәгать 7 дә, Күкчәтау каласыннан ике чакрым ераклыктагы, дүрт ягы да тау белән уратып алынган уйсулыкта, Хәрби кыр суды хөкеменең бер өлеше гамәлгә ашырылды — үлем җәзасына хөкем ителгән 8 казакның 7 се атып үтерелде. Ә үтерелгән Бородихин тарафыннан авыр яраланган берсе сәламәтләнгәнче исән калдырып торылды. Каторгага хөкем ителгәннәр җәзалаучы отряд сагы астында Омск каласына озатылды, җирле төрмәгә ябылды.

Хөкем ителгән казаклар үлем җәзасына хөкем карарын тыныч тыңладылар. Хәрби кыр судына һәм император хәзрәтләренә үз язмышларын җиңеләйтү турында үтенеч белдермәделәр, шулай ук атылыр алдыннан баганаларга бәйләгәндә үзләрен тыныч һәм салкын тоттылар, бары тик эшелон начальнигыннан тизрәк атуны сорадылар.

Губернатор: (Имза)
Аеруча мөһим эшләр чиновнигы: (Имза)

Күкчәтау белән Омск арасы дүрт йөз чакрымнан артыграк. Шушы араны 20 арестант богаулы аяклар белән җәяү үттеләр. Кансырап Омск пересыльный төрмәсенә килеп егылдылар. Моннан инде «олы юлга» озатачаклар. «Төп йортка». Әмма-аңа кадәр, барлык башка төрмәләрдәге кебек, монда да хөкем ителгәннәрнең «гамәл дәфтәре» әзерләнә башлады.

Башта бастырып, утыртып, уңга, сулга каратып фотога төшерделәр. Аннан «кара пылау ашау» — бармакларны махсус буяуга манып бармакларны кәгазьгә ышкыдылар — тамга алынды. Аннан килеп, арестантны шыр ялангач калдырып чишендерделәр, бар әгъзаларын, ояттаурәтне алдан, арттан капшап «аерым билгеләр» — миң, җәрәхәт эзләре һ. б.ларны эзләделәр, тапканнарын «гамәл дәфтәренә» теркәп куйдылар.

«Гамәл дәфтәре» Госманга да тутырылды.

СТАТЕЙНЫЙ СПИСОК № 23

«Бунт эше буенча Омск төрмәсенә ябылган арестантка.

Акмула губернасы Күкчәтау өязе Имәнтау станицасы казагы подхорунжий Абдрашитов Усман Умарович.

Хөкемгә кадәр нинди эш башкарган — Петропавловск транспорт-страховой җәмгыяте агенты.

Кабиләсе — татар. Туган теле — татар теле.

Русча сөйлиме — сөйләшә.

Тоткан дине — ислам.

Гаилә — — никахта тора. (Беренче никах).

1914 ел 10 августта Күкчәтауда төзелгән Хәрби кыр суды белән хөкем ителгән. Беренче тапкыр.

Җәза — 20 ел каторга.

28 кеше составында хәрби баш күтәрүдә гаепләнә: 75 ст. лит. Б. II часть, 98—100 һәм 279 пунктлар, XXII с. В. П. 1869 ел.

Җинаять эшләгән вакыты — 1914 ел 31 июль.

Җәза срогы кай вакыттан хисаплана — 1941 елның 13 августыннан.

Приговор кайчан гамәлгә кертелгән — 1914 елның 18 августыннан.

Советник: (Пухальский)
Эш башкаручы: (Меньшиков).

Сентябрь аеның соңгы, яңгырлы көннәренең берсендә, таң яралганда Омск пересыльный төрмәсенең авыр, тимер капкасы тавышсыз

[1] Губерна Акмолинский дип аталса да, губернатор ставкасы Омск шәһәрендә иде. Бу документның төп нөсхәсе Омскида генерал-губернатор архивында саклана. Монда кыскартып алынды. (Автор)

гына ачылды. Әүвәле аннан атлы конвой чыкты. Алары башлыктан, өсләрендә япанча, аякларында озын кунычлы күн итекләр. Һәрберсендә мылтык, кылыч. Аннан рәт-рәт булып арестантлар чыкты. Соры иләмсез шинель, соры малахай бүрекләр, сөйрәлеп йөри торган дәү ботинкалар. Билгә богаулар бәйләнгән. Алар атлаган саен шөкәтсез тавыш чыгарып шалтыр-шолтыр киләләр.

Этап шактый ишле, өч йөзгә якын кеше. Колоннаның һәр ике ягында атлаган саен ырылдап баручы явыз овчаркалар. Колонна артыннан өсте брезент белән ябылган бернichә бричка һәм өч дрожка иярдә. Болары арыганда начальствога ял итү өчен булса кирәк. Капка тавышсыз гына ябылды, төрмәдәге үлем тынлыгы тагын да көчәйде. Бернichә көн туктаусыз ишеп яуган мул яңгырлардан изрәгән шәһәр урамнары баскан саен аска төшеп китә, чылбыр-богаулар пычрак суга күмеләләр.

— Рәтне сакларга! Бозмаска!

— Ятьрәк атлагыз, анагызны... политиканнар!

— Кем пышылдаша?! Тыел!

Команда яңгыраган саен кеше тавышларына дәһшәт өстәп этләр ырылдый, аерата явыз овчаркалар арттарак калганнарның шинель итәкләрен кабып-кабып алалар. Кемдер бераү абынып суга егылды. Якындагы эт шунда ук аның өстенә сикерде һәм тарткалап-йолыккалап талый да башлады. Конвоир килеп житеп, эттән араларны дип торганда, приклад белән берне бәхетсезнең сыртына китереп кундырды.

— Тор, падла! Юлга чыкмас борын филонить итәсең!

Арестантны көч-хәл белән күтәреп торгыздылар, ә овчарка әле һаман аның шинелен җибәрми, ырылдап асылынып бара.

Этап пычрак ярып шап-шоп атлый.

Богаулар зың-зың килә.

Ямьсез уйлар кузгата торган этапның иң алгы сафында кырыйдан, озын буйлы бер тоткын атлый. Бу — 20 ел каторгага хөкем ителгән каторжан Госман Әбдрәшитов. Ул башын аска иеп богаулы аяклары белән корырак урыннарны эзләп атлый да атлый. Богау чыңын ишетми дә, колак та салмый ул. Ул үзе монда булса да, уйлары ерак Имәнтауда...

Яңгыр сибәли, үзәккә үтә торган вак, суык яңгыр. Күзге яңгыр. Алда иксез-чиксез, гаҗәп шыксыз Себер киңлекләре. Алда егерме елга сузылачак авыр, богаулы юл — арестант язмышы.

## Икенче кисәк

### I

Кәрим сагаеп тыңланып бара иде. Тыкрык чатына житкәч, атын Яңа мәчет урамына бора гына башлаган иде, кинәт, чаттан өч кораллы жайдак чыгып, аны урап алды һәм ачулы тавыш боерды.

— Тукта!

Төн караңгы, атлыларның йөзе күренми. Кәрим сул кулы белән жирән кашканың тезгенен тарта биреп, уң кулын галифе кесәсендәге наганга сузды һәм тыныч, басынкы тавыш белән эндәште:

— Сез кемнәр?

— Патруль!

— Пароль?

— Күп сөйләмә, парольне үзең әйт.

— Йолдыз.

— Уй-бай, монау үзебезнең комиссар Кәримҗан гуй — Аты белән Кәримне сул яктан яхшы ук китереп кыскан колга буйлы кавалерист куанып кычкырып җибәрде. Аты сискәнеп җирән кашканы башы белән чөеп китә язды. — Кор, кор, әй, тукта! — Хуҗа, тезгенне тартып, аны

тынычландырды.— Мондый җиде төн уртасында каян килә җатырсыз, комиссар?

— Ташҗан әкә, бу сезме? — Кәрим кулын кесәсеннән алды.— Ничек, вокзал тынычмы? Чехлар кыймылдамыймы?

— Хәзер генә шул яктан урадык. Хәзергә ул-бу сизелми. Чехлар вагоннарында.

— Иптәш комиссар! — Әле һаман атын тыя алмый борылып йөргән яшь үсмер егет, Кәрим белән Ташҗан арасына керде.— Кайчан бу чехлар коралларын ташлый башлыйлар?! «Иртәгә дә иртәгә!» Кайчан моның бер соңы булыр?

Кәрим, аты белән юлны кисеп, туктаусыз як-ягына карангалап торган зур сакаллы кешегә иелә төште һәм пышылдап кына сөйли башлады.

— Әле генә семеркада [1] шул мәсьәләне карадык. Бүген, төнге уникедә коралны тапшыра башлау турындагы килешүнең срогы тулды. Артык көтә алмыйбыз! Таң алдыннан вокзалны урап алачакбыз. Иптәш Тодьяш! — Кәрим кара сакаллыга төбәп карады.— Мадьяр эскадроны на иптәш Зайкин китте. Сез аның житәкчелегендә хәрәкәт итәрсез.— Тодьяш «төшендем» мәгънәсендә башын иде. Кәрим Ташҗанга таба борылды.— Ташҗан әкә, тагын бер тапкыр вокзал якны урагыз! Тыңлагыз, карагыз.— Кәрим соңгы сүзләрен аерым басым ясап әйтте.— Сак булыгыз! Тозакка эләкмәгез, егетләр. Хушыгыз! Ә-ә, онытa да язганмын! Бүген штабта иптәш Алиев дежур тора, ул-бу сизелсә, ашыгыч аңа хәбәр итәрсез.

Атлар берьюлы юртып юлга чыктылар һәм кара төн эченә кереп югалдылар. Тик, йокымсыраган төнге урамда, ераклашып барган ат тоягы дөбере һәм анда-санда иренеп өргән кала этләренең карлыккан тавышы ишетелде. Бераздан ул да тынды. Кызылъяр каласы тирән тынлыкка чумды. Тик бу тынлыкның алдавыч, хәвефле икәнен комиссия рәисенең урынбасары Кәрим Сутюшев бик яхшы аңлый иде!

Ул тезгенен тартып атын мәчет ягына борды.

— Әйдә, кашка! Ашыгырга кирәк! — диде. Җирән кашка әллә хуҗаның сүзләренә төшенеп, әллә инде үзе торган куранын якын булуын тоеп, ашыгып юртты.

Болытлар тагын да куерды, анда-санда ялтырап алган ай китеге бөтенләй күренмәс булды. Кәрим өенә якынлашып килгәндә шәһәрдә олы хәвеф барын искәртергә теләгән кебек, күкне әллә ничә кисәккә бүлеп утлы камчы ялтырады. Еракта, таулар артында, тонык кына булып күк күкрәде...

Ул суык чәйне голт-голт йотып кына, аягүрә эчте. Чынаягын каплауга, бүлмәне икегә бүлеп торган күк ситса чаршау артыннан пышылдап кына эндәшкән хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Абыең күренмәдеме?

— Хәзердә генә юк.



---

[1] 1918 нче елның 25 маенда Кызылъяр шәһәр советы республика реввоенсоветыннан: «Кызылъяр тимер юл станциясеннән үтүче эшелоннардагы Чехословак корпусы гаскәрләрен коралсызландырырга, буйсынмасалар, эшелоннарга паровоз бирмәскә!» дигән боерык ала. Шул көнне ике эшелон чехословак гаскәре, Омск шәһәрен үз кулларына алу нияте белән, Кызылъяр станциясенә туктамыйча, турыдан-туры Омскига уза. Аның артыннан ике эшелон-артиллерия һәм интендант гаскәрләре килеп туктый. Иртәгәсен тагын бер эшелон гаскәр килә. Кызылъяр советы эшелоннан корал тапшыруны таләп итә, югыйсә паровоз бирелмәячәген белдерә. Чехлар сөйләшүләрне сузып маташалар һәм астыртын рәвештә шәһәрне үз кулларына алырга планлаштыралар. Кызылъярның түбән каласындагы казаклар, чехлар белән килешеп, советка каршы көч тупларга тотыналар. Совет каланы камалыш хәлендә дип игълан итә һәм җиде кешедән Кызылъярны саклау хәрби комиссиясен оештыра. Комиссиягә түбәндәге иптәшләр сайлана: Дубинин Исидор Дмитриевич — председатель, Сутюшев Кәрим — урынбасар, членнар: Зайкин, Троцевский, Идрисов В. Г., Базарбаев, Батырбаев. 31 нче май төнендә шушы комиссиянең ашыгыч утырышы була. Сүз шул комиссиянең карары турында бара.

— Кайда олагып йөри торгандыр инде!.. Син дә вакытсыз йөрисең, энем. Өстәлне җыештырма, үзем карармын, ят.

— Миңа китәргә кирәк, җиңги.

— Нәрсә? — Чаршау артындагы тавыш сыгылып китте.— Китәм? Кая олакмакчы буласың тагын?! Суыгаяк абыеңнан үрнәк алмакчы буласыңмы? И-и, алла!...— Кәрим ишек тоткасына барып җитә дә алмады, җиңгәсе сузып-сузып еларга ук кереште.— Бу нинди хәл? Өй дими, бала дими... Чыгып китә дә олага. Җитмәсә, үзем хәл эчендә. Бала да сәламәт түгел. Нигә бу хәтле рәнҗетәсең, раббым!

— Җиңги, без бит азып-тузып йөрмибез. Хөррият өчен бит, азатлык өчен, Бибиҗамал җиңги.

Бибиҗамал буылып йөткерә башлады.

Инде нишләргә? Кәримгә тоткарланырга ярамый, ашыгырга кирәк! Алай да, буылып ютәлләгән җиңгәңне кая куярсың?!

— Хәзер, хәзер! — Кәрим өстәлдәге суынган самовардан чынаякка чырылдатып су агызды да, кыяр-кыймас кына чаршау артына сузды.— Мә, җиңги, бер генә йотыгыз әле.

Чәчләре тузып маңгаена ябышкан Бибиҗамал чак кына калкынып бер-ике тапкыр су йотты да тагын мендәренә ауды.

— Ярый, җиңги, рәнҗемә!

Бибиҗамал тагын калкынды, нидер әйтә башлаган иде, тоташ ютәл аны буып алды, ул күзләреннән яшь атылып чыкканчы озак итеп йөткерде. Мич арасында сайрашкан чикерткәләр дә бу сәер тавышны тыңлап торып үз җырларын оныттылар. Тавышка Рәшит уянмаса ярар иде дип борчылды Кәрим. Аңа китәргә, ашыгырга кирәк иде. Штабтаниләр бар икән дә вокзалда хәлләр үзгәрмәдеме икән?

— Җиңги, мин китәм.— Ул Бибиҗамалга тагын су китереп куйды. Авыру чынаякка ике куллап ябышып, төшермәс өчен аны корсагына куеп торды да, бер-ике йотып хәл алгач, тагын Кәримгә эндәште.

— Онытып торам лабаса, монда сине эзләп килгәннәр иде.

— Кем? Кайчан?

— Кем дип, дәү генә бер мишәр. Ике тапкыр кереп чыкты. «Кайда да кайда?» — ди. Синең кайда йөргәнне мин каян белим? Үз иремнең кайдалыгын да белмим, мин әйтәм.

— Анысын дөрес әйткәнсең. Дус бар, дошман бар...

— Озын гына адәм! Аксыл-соры мыеклы.

— Мыеклы?

— Мыеклары колагына җитеп тора.

— Усманмы?

— Усман диде бугай шул.

— Әбдрәшитовмы?

— Анысын да шулай диде шикелле.

— Усман! — Кәрим шатлыгыннан кычкырып та җибәрде.— Нигә әллә кайчан әйтми торасың, җиңги.

— Сезнең кайгымы миндә хәзер? Сезнең үз хәлегез, минем үземнеке. Бала гына кызганыч!

— Бәхетең бар, җиңги. Имәнтауда бер дустым бар дип әле генә телгә алган идем. Шул дустым инде, Госман! Кемдә тукталды икән, аны-моны әйтмәдеме?

— Түбән калада авылдашы бар икән, шуларда туктаган. «Иртәгә таңда берәр кая китеп барса, газраил булып душасын суырып алырмын!» — дип әйтеп китте.

— Усман! Ул!

— Тагын берәү сине эзләде әле.

— Кем?

— Аш өстәле өстендәге клеенканы кайтар, күрерсең.

Клеенка астында зәңгәр конверт, тышында һичбер язу, адрес юк.

Гажәп! Кәрим конвертны ертмыйча пычак йөртеп кенә ачты. Открытка — кояш кебек янып торган көнбагыш сурәте. Хушбуй исе аңкый. Хатның икенче ягында энҗе хәрефләр...

«Хөрмәтле Кәрим әфәнде! Хәерле көн!

Бүген бит минем туган көн. Шул уңай белән бүген кич безнең өйдә бәләкәй генә мәҗлес булачак. Чит кунаклар юк. Минем дус кызлар һәм туганнар гына. Барысы да сезгә таныш туташлар һәм ханымнар. Рәхим итәсез. Көтәм. Ихтирам белән Мәдинә.

31 май 1918 сәнә, шәһри Кызылъяр.

P.S. Кәрим, назланмыйча гына вакытында кил. Килмәсәң, үпкәлим».

— Менә сиңа кәлҗемә! — Кәрим хатны тоткан килеш тагын кабатлады.— Кәлҗемәнең дә шәбе!

Маңгаена тир бәреп чыкты егетнең, җиңгәсе төсле үк итеп ютәлләп алды — чирләп китмәсен тагын!.. «Назланма!» дигән, «килмәсәң, үпкәлим», дип кисәткән. Җиңги, җиңги! Бүгенгә бу язуны бирми торсаң да ярыйсы икән лә!.. Алданрак хәбәрләшкән булсак, бүләк-санак алган булыр идем... Үзем дә шәп! Шәп! Егет әфәнде үз туташының туган көнен дә белми! Эх, картлач! Карт егет! Көнен әйт тагын, көнен!»

Мәдинә туташ Кәримне телдән дә чакырып киткән икән.

— Соң булса да, чакырылган җиреңә барасыңмы әллә, кайнем? Яка белән манжетларың...

— Юк, җиңги.— Кәримнең җавабы да тиз табылды, тавышы да үзгәреп кискенләште. Ике уйлап торырга да, икеләнергә дә вакыт калмаган иде. Чехлар! Шәһәр! Вокзал! Реввоенсовет карары! Әле Бибиҗамал җиңги үзенең чире-зарлануы белән егетне бераз тоткарлый алса да, газраил түгел әллә кем килсә дә, икеләнә торган чак түгел.— Мин таңнан кайтаммы-юкмы, белмим. Усман килсә әйт, туп-туры консерва заводына барсын.

Кәрим открытканы френч кесәсенә яшереп җиңгәсенең идәнгә төшеп җитә язган юрганын күтәреп япты. Тыңлады, Рәшит тәмле итеп иренен чапылдата-чапылдата йоклый.

— Борчылма, җиңги, һәммәсе хәерлегә булыр, хәерлегә. Хәмит абыйны да йолыккалама! Хәвефле вакыт, хәтәр чак. Ул да анда булырга тиеш!

Кәрим штабка килеп кергәндә ыгы-зыгы гадәттәгедән дә көчәйгән иде. Берәүләр керә, берәү чыга. Өзек-өзек сөйләшүләр, шау-шу. Тәмәке төтене һәм төче май исе. Почмактагы кечкенә өстәлдә куыгы шартлаган лампа лып-лып итеп утыра. Стенада телефон. Дежурный телефонда сөйләшә. Ишектән Кәрим килеп кергә ул ялт кына карап алды да нигәдер сөйләшүен өзде. Шунда ук йөзенә елмаю чыгарып өстәл артыннан чыкты, смирно басты һәм көр тавыш белән рапорт бирде:

— Иптәш комиссар, штаб буенча дежурный рота командиры Али Алиев.

— Вокзалдан ни хәбәр?

— Тынычлык. Без аларны гел күзәтеп торабыз. Солдатлары вагоннарда. Мин әле генә вокзал янындагы пост белән сөйләштем.— Алиев, сүзен расларга теләгәндәй, телефон трубкасына карап алды. Ул килеп кергә дежурныйның сүзне ярты юлда бүлеп, тынып калуы Кәримгә никтер ошап бетмәде. Алиевның елмаюында да астыртынлык шәйләгән кебек булды. Һәм ул штаб дежурныена башкарак күз белән, җентекләп, тукталып карады. Уртачадан калкурак гәүдә. Чем-кара, күпереп торган бөдрә чәч. Шундый ук куе кара кашлар. Очлары бөтеренке купшы мыек. Гадәтенчә, ул бүген дә шома итеп кырынган. (Кайчан өлгергән диген. Кәрим ирексездән кытыршы ияген капшап алды). Френчендә дә, галифеда да бер җыерчык юк. Алиев үзе Кызылъярдан

түгел, читтән килгән кеше. Мәскәү ягы мишәре диләр, теле каты. Элек тә каладагы җирле команда штабында хезмәт иткән тәҗрибәле офицер. Революциядән соң ук большевиклар ягына күчкән, байтак хезмәт күрсәтеп өлгергән ышанычлы кеше. Моңарчы шулай иде, Кәрим дә, башкалар да шулай дип беләләр иде, Алиевка бер сүзсез ышаналар иде. Хәрби хезмәтне бик аз белгән завод эшчеләре арасында Алиев үзенең тышкы кыяфәтенең төгәллеге белән генә түгел, тәртибе, таләпчәнлеге белән дә аерылып тора иде. Хәрби эшне белә генә түгел, ярата, кушканнарны һәрвакыт төгәл һәм җиренә җиткереп үтәгәнгә Исидор Дмитриевич аны үз янында тотаргарак тырыша, мөһим, иң ашыгыч эшләрне аңа тапшыра.

Кичәге ярлы-ябагай, бүгенге кызылгвардиячеләр аны өнәп бетермиләр, үз артында гына түгел, алдында да кырын карыйлар, сүзләр дә ычкындыралар. Әйе, кичә генә патша армиясенең поручигы булуын алар оныта алмый! Нигездә һәрберсе диярлек патша офицерларыннан кыен ашаган, камчы татыган кешеләр шул монда. Дөресен әйткәндә, Кәримнең мөнәсәбәте дә аңа артык җылы түгел, тик ул аны башкаларга сиздермәскә тырыша. Инде комиссарның кырын караганлыгы да башкаларга беленсә, әйбәт үк булмаячак. Хәрби белгечләргә, офицерларга мохтаҗлык зур, шәхси мөнәсәбәтләргә нигезләнеп эш йөртеп булмый. Алай да бүген, шушы авыр кичтә, Али Алиевның бәйрәмчә киенгән булуы да, ясалма елмаеп рапорт бирүе дә Кәримнең борчулы күзеннән читтә калмады...

Алиев штаб начальнигы кабинетының ишеген ачты.

— Рәхим итегез, сезне көтәләр, иптәш комиссар.

Бүлмә уртасында өстәл. Өстәлдә карта. Өстәл тирәсендәге бишалты кеше шул карта өстенә иелгән. Ишек ачылуга барысы да калкынып Кәримгә карадылар.

— Ә, Сутюшев, кер, кер, брат! Без сине көтәбез! — Шатаб начальнигы Исидор Дмитриевич Дубинин калын тавыш белән гөрләде.— Ну, ничек? Нинди яңалыклар?

— Постларны тикшереп чыктым. Чехлар вагоннарда. Юлда Хәмитне очраттым. Мәүлеттән килә. Андагы иптәшләр семафор алдындагы полотноны сүтә башлаганнар.

Хәмитне кайчан һәм нинди хәлдә күрүен ул Бибиҗамалга әйтеп тормаган иде. Нигә аның болай да җәфаланган җанына тоз сибәргә?.. Соңыннан, дошманнарны җиңгәч, һәммәсен белер, аңлар...

— Ә Хәмит үзе кайда?

— Үзәккә, мөселман яшьләре дружинасына китте. Семерканың карарын аңа белдердем. Ул дружинасын әзерләячәк.

— Яхшы! Уз! — Дубинин Кәрим белән сөйләшкәндә дә картадан күзен алмады, кулындагы карандашы белән нидер билгеләп куйды.— Хәмит вакытында кайтып җиткән!. Без монда командир иптәшләр белән отрядларның дислокациясен билгели идек. Ә бер нокта, әйтергә кирәк утлы нокта, буш кала иде. Уз, Сутюшев!

Өстәл тирәсендәгеләр бераз чигенеп юл ачтылар, ияк кагып кына исәнләштеләр, аларның борчулы, авыр карашларын тоеп Кәрим дә җиңел генә баш иде.

Ул өстәл янында урын алуга, Дубинин тагын карта өстенә иелде, башкалар аның тирәсендә тыгызландылар.

— Монда Меновой двор.— Карандаш карта өстеннән җинел генә шуып китте.— Анда безнең кавалерия эскадроны тора. Командир ышанычлы егет Бөркетбаев. Менә бу урында, татар зираты янындагы ахун йортында, ягъни үзәктә, пехота ротасы һәм Хәмит Сутюшев оештырган мөселман яшьләре дружинасы булачак. Шулай буламы, Кәрим?

— Алар әзер дип беләм һәм ышанам.

— Яхшы. Менә монда — чиркәү мәйданындагы Ганшин йортында интернациональ отряд. Венгр, латыш ирекләләре. Тире заводында кызыл гвардия отряды. Менә монда вокзал — ул карандашның икенче очы белән күк төстәге божра урады,— козгыннар оясы! Удар шушы яктан булачак. Димәк, без аларның нәкъ каршысында. Монда бар мөмкинлекләрне уйлап әзерләнү кирәк!

— Бәс, шулай икән?..— Командирларның берсе, карт тимерче, аз гына бөкресе чыккан Галимҗан мылтыгын бер кулыннан икенчесенә күчерде.— Илаһи оптым алганда без ничә штык булабыз инде?

— Барысын җыеп исәпләсәк,— диде Дубинин аз гына уйлап торып,— бер мең дә бер йөз илле кызыл сугышчы булабыз, Галимҗан абый.

— Чехлар өч эшелон! — диде Таран.

— Шулайра-ак,— дип суззы картадан башын калкытып Дубинин.— Алар өйрәтелгән, инде сугышта булган, утны-суны кичкән өч меңгә якын солдат һәм офицер.

— Аларда артиллерия! — дип авыр гына сүз катты Николай Новиков.

— Алары шулай,— дип сүзгә катышты Кәрим.— Безнең якның көчен дә исәптән чыгарырга ярамый!

— Әйе,— дип аны куәтләде Дубинин.— Дошман безгә караганда ике мәртәбә артык. Сан ягыннан! Ләкин аларда бер нәрсә юк. Нигез юк аларда. Безнең терәк тә бар, нигез дә нык! Халык, юксыллар безнең якта. Без аларның азатлыгы өчен көрәшәбез. Шуның өчен ул безнең якта. Ә тарих өйрәтә, халык кайсы якта булса, җиңү шунда! Чехлар — килмешәкләр. Алар...

— Иптәш начальник! — Алиев кабаланып килеп керде.— Сезне телефонга!..

Дубинин шактый калынайган гәүдәсен җиңел генә йөртеп алгы бүлмәгә чыкты һәм телефонга тотынды.

— Тыңлыйм. Кем? Хәмит? Әйе, нәрсә... Вот сволочьлар! Хәзер үк кавэскадронны түбән калага! Үзең дә дружинаң белән шунда төш. Мин бер взвод укчылар җибәрермен! Ашыгыгыз! Алар чехлар белән кушыла күрмәсен!

Дубинин трубканы урынына куярга да онытып аптырап торды. «Нәрсә булды?» дип аптырап көтеп торган иптәшләре янына керде. Авыр итеп көрсенде, сүзләр сызланып чыкты:

— Түбән каладыгы казак-урыслар баш күтәргәннәр!

Бу бик авыр хәбәр иде. Андый мөмкинлек булуы ихтималы турында күз алдында тоткан иде алар, шуңа кабаланалар да иде, казаклар кузгалганчы чехларны нейтрализовать итеп өлгерергә кирәк. Димәк...

Ул арада тышкы ишек ачылып китте, аннан йөгереп — мышнап Ташҗан әкә килеп керде, ярым русча, ярым казахча кычкырып җибәрде:

— Уй-бай, чехи! Вокзалдан чыгып монда килә җатыр! Идут сюда, җылдам! Идут, они идут!

## 2

Чехословаклар Түбән калада чуалышлар башлануыннан хәбәрдар иделәр. Алар бары тик шул кузгалышны гына көтәләр иде. Хәбәр килүгә үк, төн караңгылыгыннан һәм кызылларның ваемсызлыгыннан файдаланып, консерва заводына урнашкан штабны камап алырга карар бирделәр. Бу эшне алар бик тиз һәм җиңел башкарып чыгарга уйлаганнар иде. Алар шыпырт кына вагоннардан төштеләр, песи кебек сак кына атлап, чылбыр булып сузылып штаб ягына кузгалдылар. Әмма кызыллар штабы кичтән үк вокзал артындагы чокыр-чакырларга, канауларга гаскәр китереп өлгергән иде инде. Кара күләгәләр күренүгә

алар тиз-тиз әзерләнә башладылар, чехларны аз-маз якынрак җибәрделәр дә, ике яктан ике пулемет дошман өстенә ут яудыра башлады. Пулеметларга мылтык тавышлары да кушылды. Аягүрә торып ата-ата килгән солдатлар кинәт ятарга мәҗбүр булдылар. Яралылар ахылдады, кемдер нәзек тавыш белән ыңгырашты. Кара-каршы ятып ату башланды. Чехлар моны һич тә көтмәгәннәр иде, киңәш өчен вагоннарга кеше йөгерттеләр һәм бу хәл аларның алга баруын нык кына тоткарлады. Ул арада заводның цехларында дежурда торган эшчеләр — кызылгвардиячеләр чыгып, каралтыларга ышыклана-ышыклана алдынгы линиягә якынлаштылар, штабтагылар да аларга кушылды.

Заводтагы Кызыл гвардия отряды командиры Галимҗан белән Кәрим бергә туры килделәр. Карт тимерче караңгыда да үткен күрә иде, ул:

— Комиссар иптәш,— дип пышылдады.— Әгәр мин үземнең егетләр белән әнә теге суыткыч сарайлары артыннан узып, яшел ыштаннарның артына төшсәм?.. Аларны вагоннардан аерып алсак, ә?!

Аның пышылдаганы шактый еракка ишетелгән ахрысы, берничә пуля алар яткан канау кырындагы түмгәкләрне тишеп узды — ком коелды.

— Ят тизрәк!

— Этләр, сөйләшергә дә ирек бирмиләр!

Кәрим прицелын түбәнрәк төшереп атып җибәрде, канаудагылар бердәм залп бирделәр. Чехлар тынды.

— Иптәш комиссар!..

— Барыгыз, Галимҗан абый. Тик тозак корам дип үзегез барып эләкмәгез!

Галимҗан артка чигенә башлаган иде, чокырга мәтәлеп төште, аннан чыгып үз егетләрен бора гына башлаган иде, чехлар тавышланып, үз телләрендә кычкырып, ата-ата якыная башладылар. Вагоннардан аларга ярдәм дә килеп өлгерде ахрысы. Кәрим кирпеч өеме артына урнашкан пулеметчыларга команда бирде:

— Башла, Николай!

— Башла, «Максим», диген...

Ике яктан да куе, тоташ атыш башланды. Пулялар чиный-чиный әле ул яктан, әле бу яктан узып төн караңгылыгын теткәли башладылар. Кызылгвардиячеләрнең уңайлырак булса да, пулялар аларны да эзләп тапты, кемдер авыр гына кычкырып куйды.

— Балта әкә, сезме? Кай җирегезгә тиде?

— Сул кул... Зарар юк. Бәйләделәр.

Урам сугышларында Кәримнең тәҗрибәсе никадәр аз булмасын, ул дошман ягыннан очкан пуляларның күбрәк булуын да, чех солдатларының аз-мазлап кына булса да һаман якынрак килүен дә чамалады. Аның иптәшләре канау өстенәрәк менеп, төбәбрәк ата башладылар.

Көнчыгыш як алсуланды. Салкынча җил исте. Болытлар тарала башлады. Чехлар ачыктан-ачык күренмәсәләр дә, ерактан төсмерләнәләр. Алар инде торып-ятып, куз иярмәслек арада урыннан-урынга күчеп һаман якынлашалар. «Эх, тагын бер-ике «Максим» булсачы!» — диде эченнән әрнеп Кәрим. Пулеметлар туктый-туктый гына атарга мәҗбүрләр, патроннарны сакларга кирәк!.. Көн ачылуы бер дә кызылгвардиячеләр файдасына түгел иде, чехларның өйрәтелгән гаскәре көн яктысында тагын да кыюрак, хәрби фән таләпләренчә хәрәкәт итәчәк. Штабка хәбәр итеп, ярдәм-киңәш сорарга кирәк иде. Кәрим үз янындагыларның берсен штабка Дубинин янына җибәрде. Исидор Дмитриевич гомуми җитәкчелек итәр өчен әлегә штабта торып калган иде...

Хәлнең кискенләшә баруын башкалар да сизенде, Галимҗан Кәрим янына кире борылып килде:

— Үткәрмиләр, сволочьлар! Ике кешебезне югалттык...

— Бу яктан катырак торыйк! — диде Кәрим. Шул чакта аның күзе сул якка төште, өстенә салкын су сипкәндәй булды. Бер төркем

чехлар канау өстенә үк менеп киләләр! Нигә атмый инде бу пулемет! Ул тиз-тиз шуышып барып караса, пулеметчылар икесе тиң авыр яралы. Берсе: «Ах, җәл... кырып бетереп булмады»,— дип ыңгырашып ята. Нишләргә? Чигенергәме? Кая? Артта завод, штаб. Юк, юк, кузгалмаска! Кәрим пулеметының үтын әле уңга, әле сулга борып, канау өстенә менә башлаганнарны бер мәлгә куып төшерде. Ләкин, көчләр тигез түгел иде. Сул канат сынды, чигенә башлады. Монда ике уйлап торырга мөмкин түгел иде. Кәрим «Ур-ра!» кычкырып өскә сикереп чыкты. Алга!

Әле генә масаеп алга ашкынган чехлар һөҗүмгә түзә алмыйча артка, вокзалга таба чигенә башладылар. Шуннан файдаланып Галимҗан үз егетләрен сарайлар артына күчереп өлгерде...

Ике як та яттылар. Көн тәмам ачылды, анда да, монда да үлгән гәүдәләр шәйләнә башлады. Нидер эшләргә, бу мөшкел хәлдән көн тәмам яктырганчы котылырга кирәк иде. Кәрим бер эшче белән пулеметны Галимҗаннар янына, сарай артына күчерергә булды. Аннан торып атканда чехлар ачыклыктарак булачак иде. Ул арада тагын атыш башланды, ике яктан да кычкырган, янаган тавышлар яңгырады, чехлар ягыннан команда тавышлары ишетелде. Кәрим пулеметын сөйрәп сарайлар артына чыгып килгәндә кинәт туктап, таш булып катып калды. Май кайната торган баздан бер-ике генә адым арырак Галимҗан һәм аның сугышчан иптәшләре таралып яткан иде. Галимҗанның күкрәгеннән, кызыл бант өстеннән кубекләнеп-кубекләнеп куе кан ага.

Шушы мизгел Кәримне харап итте, аның пулеметы аз гына тынып торды, чехлар сикерә-сикерә канау өстенә менеп җиттеләр, яман акырып, каушаган, югалып калган кызылгвардеецлар өстенә ташландылар.



## 3

Кызылъярның бу ягында җатак-казахлар, ломовойлар, тире җыючылар, касапчылар, айгыр печүчеләр, тимерчеләр, балтачылар, йон юучылар, суык аяклар, фәхишәләр, караклар һәм башка шуның ишеләр яшәп ятканга «Әтәч каласы» дигән дан алган. Кич җитте исә, Әтәч каласы халкы урамда. Гармун, җыр, сүгенү, акыру, елау, сугышу. Бер генә төн дә монда пычаксыз, кансыз, үтерешсез үтми диярлек.

Шушы Әтәч каласында инде утыз елдан артык гомер сөргән касапчы җатак Меңбай әкә бүген капкасыннан чыгып, урамның әле бер, әле икенче ягына карап торды да башын чайкады.

— Уй-бай, ходаем, монау гаҗәп, гуй: бер адәм җук! Җорт кырылып калдымы?

Бу тынлык искитәрлек хәл иде. Һәм моның сәбәбен Меңбай әкә бик яхшы белә!

Таң да яралып-туып бетмәгән иде, Әтәч каласы урамнарына атлы урыс-казаклар ябырылып керде! Йортларны астын-өскә китереп тентеделәр, хатын-кызларны куркыттылар, бала-чагаларны тибеп-тибеп очырдылар, кемнәрнедер эзләделәр... Ир-атларга нагайка да эләкте, шикле күренгәннәрне каталажкага илтеп яптылар.

— Ходай, үзең сакла. Ул кяферләрне монда юнәлтә күрмә, мәүләм,— дип рәнҗеп Меңбай әкә комганын эргәгә куйды да ялгыз тәрәзәсенең калтырап торган капкачларын япты. Капкага бастырып салынды. Алабай чылбырдан ычкындырылды. Чал кураның аргы башындагы киез өй төсле итеп түгәрәкләп чымнан[1] салынган тушалага[2] таба юнәлде.

Тушала ишегендәге йозак шалтырауга, Кәрим язып утырган кәгазен каршыдагы дәү мичкә астына тыкты да шәмне сүндерде. Үзе колгага

[1] Чым — кәс.
[2] Тушала — ит каклый торган кечкенә бина, коптилка.

әлеп киптерергә куйган тире артына яшеренде, револьверын кулына алды.

Ишек акрын гына ачылды.

— Әһем, әһем, караңгы гуй...

— Ата? Хәзер.

Кәрим тире артыннан чыгып тартма өстендәге шәмне кабызды. Тушала яктырып китте. Чал ишекне ябып алга узды.

— Карның ачып калган чыгар, балам,— Меңбай әкә комганының капкачын ачып, аннан кушкабырга — каклаган каз һәм бер төргәк чыгарып мичкә өстенә куйды.— Аз-маз йөрәк ялгап ал. Сораган кәгазьләреңнең дә кайберсен таптым...

— Рәхмәт. Ни хәбәрләр бар, ата?

— И, бала, нисен сорыйсың? — Чал гадәтенчә сакалын учлап авызына капты.— Башым әйләнде... Кара кайгы. Зиратта булдым.

— Кемнәрне җирләдегез, ата җан?

— Ой, нисен әйтәсең? Үзең белгән сары нугай Гарифҗанның улы Галимҗан. Үзебезнең мәргән Балта әкәне, җәнә Әхмәтбәкне, черкес булса да мөселман гуй, байгыш.

— Ни дисез? — Кәрим сискәнеп китте, чалның авызына керердәй булып үрелде.— Әхмәтбәк?! Булмас! Ялгыша торгансыздыр, әкә. Ул заводтан бергә чигенде, Әтәч каласына минем белән бергә килде. Ата?!

— И, балам... — Чал ашыкмыйча, сабыр тавыш белән сүзен дәвам итте.— Дөньяны кортып торган яман күз гуй. Ул күрми каламы? Кичә төндә Әхмәт байгыш кулга төшкән. Ләкин ул хәзрәти Галидей гайрәтле җан гуй. Осталган җирендә ике казак пычаклап качкан.

— Шуннан, ата?

— Байгыш, башка барыр җире калмагач, үзебезнең мәчеткә барып кергән... Таң иртән халык белән бергә иртәнге намазын укыган, муллага садака биргән. Ә намаздан таралганнан соң, озакламый унберунике казак килеп мәчетне урап ала.

— Кемдер күрсәткән!

— Байгышны мәчет ишегалдында кылыч белән турап ташлаганнар, мәлгуньнәр.

Карт хәле китеп шундагы буш тартма өстенә килеп утырды, башы иелеп төште. Тушала кинәт тып-тын булып калды. Мичкә өстендәге шәм чатнап куйды. Тушала артында эт шыңшыды.

— Эх! — дип әйтеп алды Кәрим.

Чал, башын күтәреп, ике кулы белән битен сыйпады, ниндидер дога укыды. Кәрим дә картның ихлас күңелен хөрмәтләп, кулларын күтәрде.

— Амин.

— Ата, энегез Ташҗанның хәле ничек?

— Безнең күршедә сырхау бер әйәл бар, ахун хәзрәтнең доктор кызы шул әйәлне караганнан соң безнең өйгә дә кергән. Ташҗанның яралы кулын карап, май яккан, бәйләгән... Доктор киңәше белән ул башка өйгә күчкән. Ташҗанны әйтәм, ходай саклаган үзен... Ул китүгә өенә өч казак-урыс кереп тентү ясый, хатын, баласын орган. Ләкин эзләгәнен тапмый, мәлгуньнәр. Уй-бай, оңытканмын гуй.— Чал иелде, кәвешен салды, олтырак астыннан бер кәгазь алып, Кәримгә сузды.— Хәтер дигәнең гуй. Онытып барам. Бу амәнәтне ахун кызы сезгә тапшырырга кушты.

Меңбай әкә амәнәтен тапшыргач, тиз генә кәвешен киеп, комганын алып тушаладан чыгып китте. Кәрим шәмнең көеген бармагы белән өзеп бераз яктыртты да иелеп хатны укый башлады.

«...һаман кулга алулар бара. Дубинин, Идрисов, Зайкин... барысы да төрмәдә. Имәнтауның Абдрашитов сезгә барган икән аны да то-

тып япканнар. Бүген төндә бер төркем венгр доброволецларын аталар икән дигән хәбәр таралды. Аннан Али Алиевны аклар штабында күргәннәр. Һәммә җирдән сине эзлиләр, сак бул, дустым. Зинһар саклан.

1918 сәнә 1 июнь. Дустың.

Кирәк сүзләрең булса, шушы почта белән юлла. Хуш, үбәм».

«Алиев аклар штабында?» Кәрим хатны тиз-тиз ике тапкыр укып чыгып үзе белән үзе бәхәсләшә башлады:

— Булмас! Ул кадәргә барып җитмәс. Мөгаен, башка кеше белән бутыйлардыр... Әгәр алай булса, алай икән, ул чагында...

Һәм үзләренең җиңелүе, кызылгвардеецларның тар-мар ителүе, аның сәбәпләре берәм-берәм ачыкланып, моңарчы билгеле булмаган шикле сәбәпләр бергә төйнәлеп Али Алиевка барып тукталдылар... «Димәк,— ул! Безне харап итүче төп сәбәпләрнең берсе, бик мөһиме ул! Венгр дусларны харап итүче ул!..» «Бүген төндә» дигән. Алар әлегә исән булсалар кирәк. Тик ничек аларны коткарырга? Ничек?!

Шушы аулак, ташландык дип әйтерлек тушаладан торып ни эшләргә мөмкин?!

Ишек ачылды. Кәрим сискәнеп, уйларын чәчеп урыныннан торды. Бу ни бу? Әллә күзгә күренә инде? Юк! Ишеккә көчкә сыеп, зур бер капчык кереп килә. Кәрим ни уйларга да, ни әйтергә дә белми аптырап калды.

— Меңбай әкә?!

— Ия, улым, мин гуй.— Чал капчыкны тушалага этеп кертеп, ишекне ябып, келәсен салып куйды.

— Ата, монавыгыз ни?

— Сабыр, хәзер әйтәм.

Кинәт Алабай өрә башлады. Тушаладагы ике кеше тын да алмый катып калдылар.

— Син инде, Кәримҗан, яшерен. Мин аллага тапшырдым.

Чал чыгып китте һәм озак та үтми унбер-унике яшьләрдәге бер баланы ияртеп керде.

— Уф алла, казак-урыс килеп калдымы дип курыккан идем... Монау, сары нугай Гарифҗанның кече улы икән. Сине сорый, Кәримҗан...

— Кил, якынрак кил,— диде Кәрим.

— Мине әти җибәрде,— диде бала.

— Исемең ничек синең?

— Сабирҗан.

— Әйт, Сабирҗан.

— Бүген, бүген... абыйны күмделәр.

— Беләм, җаным. Абыең кебек батыр булып үс.

Чал бер урында тыныч кына утыра алмый иде, күз яшьләрен сөртеп Кәримгә эндәште:

— Син, Кәримҗан, бала белән әңгәмәләшә бир, мин курага чыгып күз-колак булыйм.

Тушала ишегенә килә салганда чал: «Хәзер курамда ике кешенең жаны, язмышы»,— дип куркып уйлады.

— Сөйлә, Сабирҗан. Әтиең кайда? Ник җибәрде?

— Әти әйтте, ни диде... Әй, анда Әхмәдулла абзыйларга теге хәреф җыючы Җамал апа килде бит. Ул да әйтте... Монда килеп кәгазьләр алып кайт, диде.

Малайны озак тотарга ярамый иде. Кәрим почмактагы мичкә төбеннән бер төргәк кәгазьләр алды.

— Менә ул кәгазьләр, Сабирҗан. Тик син аларны ничек яшерерсең?

Сабирҗан башындагы зур, тимер юлчылар фуражкасын салды да астарын әйләндерде.

— Бир монда, абый. Алдан ук астарын сүтеп куйдык.

— Акыл! — Кәрим кәгазьләрне ыспайлап эчкә тутырды да, френч кесәсе капламасыннан җепле инә алып, астарны тегеп тә чыкты. Фуражканы кагып-сугып Сабирҗанның башына кидерде.

— Йөгерә башласаң, башыңнан төшеп калмасын!

— Курыкма, абый, төшермәм.

— Әтиеңә әйт, кәгазьләрне Җамалга тапшырсын. Рәтли бирсеннәр. Төшендеңме?

Сабирҗан үпкәләп карады:

— Ниенә төшенмисең инде аның?

— Ярый, алайса, йөгер.— Кәрим кычкыра төшеп Меңбай әкәгә эндәште.— Ата, бу баланы озатып куегыз.

— Ә, булады гуй. Хәерле сәгатьтә.

Бераздан ул кире әйләнеп килеп җитте.

— Ата, бу нинди капчык? Аны нигә монда алып килдегез?

— Сабыр, сабыр кыл, балам,— Меңбай чал иплəп кенә капчыкны бушата башлады. Аннан яшел бәрхеттән алты өлгеләп тегелгән казах бүреге, буй-буй яшел чапан, бөрмә ыштырлы кара бумази чалбар, читек, кәвеш килеп чыкты.

Кәрим аңлап алса да:

— Боларыгыз ни, Меңбай әкә? — дип сорау бирде.

— Күршебездә бер сырхау әйәл бар дип әйткән идем гуй. Ал,— чал кинәт тавышын басып, бик серле итеп сүзен дәвам итте.— Сол әйәл иртәгә җәйләүгә йөреп китмәк. Мин аның туышлары белән сөйләштем: алар риза. Инде сезгә, сол әйәл белән җәйләүгә йөреп киту мәгкуль. Төсне үзгәрту кирәк.

— Ата...— Кәрим сөенеп карады. Аптырады да. Тыны кысылды. Әйтәсе сүзе бугазга тыгылды.

— Курыкма, улым,— диде чал, аны тынычландырырга тырышып.— Иншалла, аман-сау камаудан котылырсың. Юлчыларың ышанычлы адәмнәр.

— Ата! — Кәрим сикереп торып картны ике кулы белән кочаклап алды.— Сезгә зур рәхмәт. Әмма...— аннан артка чигенде.— Әмма юлдашларым камауда, тоткында ятканда үз башыңны алып җәйләүгә, аулакка качу егетлек булмас!

Чал еларга җитешеп, ялварып Кәримнең күзләренә карады.

— Уй-бай, монау ни дигәнең? Бол җирдә, Кызылъяр туфрагында калу куркыныч! Әйткәнне эшлә, өлкәннәргә каршы торма. Болай да күпме адәмнәрнең җаны кыелды!

— Юк, ата.— Кәрим башын чайкады.— Булмый, ата.

Кинәт, якында гына диярлек ике тапкыр мылтыктан аттылар, тушала селкенеп китте. Атлар чабып узды. Эт өрә башлады.

Меңбай әкә ашыгып-каударланып чыгып китте. Кәрим Мәдинәнең хатын шәм утында тотып яндырды да көлен идәнгә сипте...

### 4

Көмеш кыңгырау чыңлауга гарнизон дежурные — озын, чандыр гәүдәле, кыска гына сары мыеклы офицер ашыгып атлап кабинетка керде:

— Полковник әфәнде?..

— Поручик Алиевны чакырыгыз!

— Тыңлыйм, полковник әфәнде!..

Ашыгыч адымнардан идән такталары сыгылып, шыгырдап китте. Кабинет ишеге дә тавышланып кына ябылды. Дежурный офицер полковникның «авыр аяк»ларны яратмавын белә. Әйткән икән, яшен тизлеге белән башкарылырга тиеш. Поручик Алиев аның катында булсын!.. Озакламый ишек тагын ачылды. Бу юлы йомшак кына, ишетелер-ишетелмәс кенә. Адымнар да йомшак, идәнгә иркәләп кенә басалар.

— Полковник әфәнде, сезнең боерыгыз буенча поручик Алиев килде.

— Утырыгыз, Али Алиевич! Кәефегез ничек?

— Илтифатыгызга рәхмәт.— Поручик гәүдәсен сыгылдырмый гына, хәрбиләргә төс тәкәллеф белән баш иде һәм өстәл янындагы йомшак урындыкларның берсенә әдәпле генә, җәелеп китмичә, кырыена гына чүкте.— Аллага шөкер, кәефләр зарланырлык түгел.

Полковник баядан бирле өстәлдәге кәгазьләрен караштыра иде, беренче мәртәбә күтәрелеп карады, елмайды, өстәлдәге көмеш ай сурәте төшерелгән папирос кабына үрелде. Ачты. Бер папиросны авызына капты һәм капны ихтирам белән поручикка тәкъдим итте.

— Рәхим итегез.

— Рәхмәт, полковник әфәнде. Мин тартмыйм бит.

— Тантана хөрмәтенә берне мөмкин! Ерактан килгән күчтәнәч. Төркиядән. Болайча әйтсәк,— полковник аталарча рәхимлек сиздереп, башын чайкамыйча гына көлде,— мөселман тәмәкесе, курыкмыйча тартыгыз. Дуслар бүләге! Гомумән, бүгеннән җиргә катырак басып та йөри аласыз, поручик!

Поручик та елмайды, икесе дә кабыздылар, ашыкмыйча, тәмләп суырдылар. Бүлмәгә ефәк төсле сузылып, дулкынланып зәңгәр төтен таралды, хуш ис аңкыды.

Полковник кулыннан алган затлы папирос төтене белән Али Алиевның күңеленә нindидер бер бөек сөенеч тулгандай булды. Я, алла, нинди гүзәл бу дөнья! Әйләнә-тирә ничек яктырып, матураеп китте бүген! Әнә, полковникның да кәефе күтәренке, елмая, көлә, үз итеп татар телендә сөйләшә! Мондый хәл икәүдән-икәү аулакта очрашу сирәк очрый бит! Мондый бәхет күпләргә тәтеми! Эти мәрхүм әйтмешли, форсат — ганимәт!..

Полковник Дмитрий Иванович Орлов белән Али Алиев күптәнге тынышлар. Шуның өчен полковникның хәзер дә татарча сөйләшә башлавы поручик өчен гаҗәпләнерлек хәл түгел. Гомумән, себер казак-урыс офицерларының күбесе татарча, казахча яхшы белә. Чөнки алар балачактан бирле казак-татар балалары белән уйнап, якыннан аралашып, сугышып, талашып, татулашып үсәләр. Ә бала хәтере мәңгелек. Күкчәтауда атаман Иван Васильевич Орлов, Аның тау буендагы яшелгә буялган өе шәһәрнең атаклы коммерсанты Шаһвәли Усманов кибете белән рәттән иде. Димка Шаһвәли һәм касапчы Җылкайдар балалар белән бергә уйнап үсте, аларча сөйләште. Җирле халыкны кулда тотар өчен аның ышанычын казанырга кирәк. Ә тел — ачкыч. Аның белән иң авыр йозакларны ачарга була. Тылмачсыз гына турыдан-туры сөйләшә белү — алдагы тормышның, язмышның нигезе. Менә шуның өчен хәйләкәр, күпне татыган Иван Васильевич улының, булачак офицерның, булачак атаманның инородецлар белән аралашуына каршы төшмәде. Хатыны Василиса Николаевна: «Ни хәл бу, бердәнбер улыңны гололобый татар малайлары белән уйнатасың. Ул бит аларның хуҗасы буласы кеше!»— дип гарьләнеп рәнҗегәндә дә Иван Васильевич рәхәтләнеп көлә генә иде.

— Эх син, матушка, Василиса Николаевна! Дөрес әйтәсең! Ялгышасың да! Әлбәттә, хуҗалары булыр! Тик төпле һәм озак хуҗа булыр өчен ул татарларның телләрен белү дә кирәк. Телләрен беләсең икән, сине бераү дә алдый алмый. Серләрен дә яшерә алмаячаклар!

Атаман төрек сугышыннан кайтмады, әмма аның акыллы киңәшләре Дмитрийга һәрвакыт кирәк булды, әле бүген дә ярдәмгә ярап торалар...

Японнарга каршы да сугышты Дмитрий Орлов, герман сугышында каты яраланып, яралары бәрабәренә полковник йолдызлары һәм тагын бер крест тагып Кызылъяр гарнизонына кайтты. Менә шунда ул штабта хезмәт итүче чибәр, елгыр, сүз тыңлаучы поручик Али Алиев

белән тынышты. Хәрби хезмәтне бик яшьли татыганга, полковник татарларның искиткеч кыю һәм тәвәккәл егетләр икәнен белә иде. Али Алиевны ул үзенә якынайтты һәм поручикның үзе өчен утка да, суга да керергә әзер икәнлегенә ышана иде...

Бәхетсезлеккә каршы, озакламый дөньяның асты-өскә килде, падишаһ әгъзам хәзрәтләре тәхеттән ваз кичте, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, солдатлар заманы башланды. Кызылъяр гарнизоны да бу куркыныч шау-шудан читтә калмады, баш күтәрде, Совдеп ягына күчте. Безнең дуслар давыл якынлашуын икесе дә алдан сизделәр һәм икесе өчен дә файдалы булган саклану чараларын эзләделәр. Полковник пар атка утырып караңгы төндә Күкчәтау ягына чыгып югалды, ә поручик, аның киңәше белән солдатлардан да алдарак, Совдепка барып, үзенең большевиклар платформасын кабул итүен белдерде...

Чехословак корпусының баш күтәрүе, Казанны кулга алуы турындагы хәбәр йөри башлау белән, язгы караңгы төннәрнең берсендә, кызыл гвардия командиры Али Алиевның фатирына бер кеше килде. Тәрәзәне дә бик сак шакыды. Ул керүгә йортта ут сүнде. Әңгәмә башланды. Кунакның кайчан, ничек чыгып киткәнен беркем дә күрми калды, ул ихатадан чыкты да юк булды, эреде, югалды. Ишел буендагы балыкчылар кемнеңдер бик соң гына каекка утырып Биш күл ягына киткәнен шәйләп калдылар.

Баш күтәрү төнендә Али Алиевның хезмәте бәяләп бетергесез зур иде. Штаб дежурные буларак, ул Совдеп отрядларының бөтен хәрәкәтен күзмә-күз күреп, килешелгән шифр белән, телефон аша хәбәр биреп торды. Кызыл отрядларның болай тиз һәлак булуына, нигездә, ул сәбәпче булды! Аның бу хезмәтенең зурлыгын полковник Орлов бик яхшы аңлый! Юкка гына чакыртып алмады ул аны, янына утыртып тәмәке белән сыйларга тотынмады... Әле болай гына булырмы? Алда, монархиягә турылыклы гаскәрләр илне большевиклардан тәмам азат иткәч, Али Алиевның күрсәткән хезмәтләре ярап куячак!..

Бер-берсенә шатлыклы елмаюлар бүләк итеп, полковник белән поручик папиросны тартып бетерделәр. Орлов шуннан соң гына, бер күзен кыса төшеп, Алиевка эндәште.

— Төнге операция ничек узды дип уйлыйсыз?

— Уңышлы узды дип беләм! Совдеп членнарының һәммәсе диярлек кулга алынды. Полина Калюжная белән Анастасия Прокопьева Әтәч каласындагы бер кыргызның өендә яшеренгәннәр икән. Ул кыргызны да кызыллар штабы буенча белә идем... Алар да килеп капты! Бер төн эчендә бөтен юнәлешләрдә тар-мар иттек без аларны, полковник әфәнде. Сезнең шигегез бармы әллә?!

Полковникның елмаюы кинәт юкка чыкты. Аның кырыслыгын, ярсуын күреп Алиев шунда ук аягүрә басты.

— Гафу итегез, полковник әфәнде!

— Мин сезне тәмле тәмәке белән сыйланыр өчен генә чакырды дип беләсезме әллә, поручик?! «Тар-мар» дисез! Ә бу нәрсә? — Полковник өстәл тартмасыннан кәгазь алып, җирәнеп кенә аны поручикка таба ыргытты.— Бу нәрсә?

Кәгазьне кулга тоту белән Алиев елан чаккан кебек калтыранып, сикереп алды.

— Бу... бу... бу бит прокламация!

— Таныйсыз икән, поручик әфәнде, — диде мыскыллап Орлов,— әйе, хак, бу большевиклар прокламациясе. Рус телендә... Ә менә бусы...— полковник өстәл тартмасын тагын ачты һәм шундый ук форматтагы икенче бер юка кәгазьне тартып чыгарды.— Бусы нәрсә дип сорыйм мин сездән?!

— Бусы да... прокламация. Татарча.

— Да?! — Полковник кинәт шаркылдап, бөтен бүлмәне яңгыратып

көлә башлады, күзләреннән яшьләр атылды. — Татарчамыни?! Ә мин кытайча дип торам! Кызыкмы?! Чамадан тыш мәзәк! — Орлов көлүеннән кинәт туктады, гасабый бер тавыш белән акырды.— Подлец! — Шул минуттан ул русчага күчте, татарча бик яхшы белсә дә полковник Орлов сүгенгәндә күбрәк үз теленә җибәрә торган иде.— Подлец! Идиот! Бөтен кала большевиклар өндәмәсе белән тулган, ә ул, дурак, операция уңышлы үтте дип җәелеп утырган. Баба!

— Мин... мин...

— Молчать! Бабник! Белмиләр дисеңме! Фәхишәләр артыннан йөреп, иң куркыныч бүрене ычкындырдың. Бу акылга сыймаслык хәл! — Полковник өстәл тартмаларын ачып аннан русча, татарча кәгазьләрне күтәрәме белән поручикның йөзенә бәрде.— Иснә, суккин сын, иснә! Сутюшев эше булыр бу. Аның исе килә. Ул гына! Кайда ул? Нигә аны муенчаклап монда, минем каршыма китермисең?!

— Мин аны эзлим, полковник әфәнде, ләкин ул...

— Җитәр! — Алиевның калтыраган, хәлсез тавышын полковник калын, гөрелдәп торган бас белән күмеп ташлады.— Җитәр, койрыкны күп болгадың. Сиңа да урын табылыр. Ишетсен колагың: Кәрим Сутюшев бүген монда, минем катымда булырга тиеш. Я үле, я тере... Тере килеш! Марш!

Тормышта шундый борылышлар да була икән! Полковник сөекле поручигын эт итеп куып чыгаргач, бераз дәшмичә генә уйланып утырды. Аның йөзендәге дәһшәтне елмаю алыштырган иде: «Ярый. Бик артык кыланмасын, үзенең чамасын һәм урынын онытмасын, гололобый! Моннан соң ул житезрәк һәм тырышрак булачак! Әтне сыйла, ара-тирә типкәләп тә очыр. Хуҗасына аннан да тугры эт булмый!»

Али Алиев полковник яныннан ничек чыгып киткәнен дә сизмәде, чыгышлый ул дежурный офицерга күз төшерергә дә өлгерде. «Ишетеп торып офицерлар арасында данны таратмаса ярый инде!» — дип уйлады. Алиев полковник белән якынлыгына бик нык горурлана һәм урыны туры килгән саен аны әйтеп сүз кыстырып узарга ярата иде.

Кулыннан килсә, очратса, ул хәзер Сутюшев Кәримне өзгәләп, юк өзгәләп кенә түгел, чәйнәкләп ташлар иде!

Кызылъяр каласының бакчасы шәһәрнең нәкъ урта бер җиреннән башланып китә дә, сузыла торгач, татар-мөселман зиратына барып тоташа. Зират зур. Монда Кызылъярдагы бөтен мөселманнар: татарлар, казахлар, үзбәкләр, кавказлы халыклар — черкеслар, ингушлар, чеченнәр, уйгурлар инде йөз елдан артык үзләренең мәетләрен җирлиләр һәм һәрбер кабер өстенә язулы таш кую, чардуганнар кору белән берләттән, берничә төп агач та утырталар. Менә шушы нәни агачлар, еллар үтү белән зураеп, урман булып күтәрелә. Элегрәк бакча белән зират арасында такта койма да булган, еллар узу белән баганалар черегән, койма ауган. Һәм бакча белән зират тоташ бер кара урманга әверелгән.

Хәзер, бакча белән зират чигендә тимер түбәле, баркатлы агач өй — зиратчы өе генә тора. Бу өйнең түр тәрәзәләре урамга карый, ә ишек алды — кура-киртә, келәтләр, бакча-зират эченә кереп киткән. Менә хәзер, шушы тып-тын кичтә, зиратчы курасының эчке капкасы ачылды да, ике кеше күренде. Алар сагаеп кына бакча куелыгына таба атладылар.

Сукмак. Карагайлар. Китек ай. Ике кеше. Уңда ир кеше. Уртача буй. Чандыррак гәүдә. Кара костюм-чалбардан. Башында фетр эшләпә. Кулында трост. Ул сул аякка аз гына аксап атлый. Сулда хатын-кыз. Ул буйга ир кешедән азга гына кайтыш. Аның өстендә аксыл-сары костюм-күлмәк. Ул да эшләпәдән. Зәңгәр тасмалары иңенә төшеп, атлаган саен, җилфердәп ала...

Алар янарак кына очрашканнар иде ахрысы, әле юньләп хәл-әхвәл сорашырга да өлгермәгәннәр. Икесенең дә тавышы каушап-калтырабрак чыга иде.

— Мәдинә...

— Кәрим!

— Мин сине монда очратырмын дип һич уйламаган идем.

— Ә минем сине бик күрәсем килде, Кәрим.

— Рәхмәт, Мәдинә.

— Нигә син болай иркенләп, күзгә чалынырлык киемнәр киеп йөрисең? Үзеңне ничек эзләгәннәрен беләсеңме?! Бөтен җирдә шпиклар.

— Беләм, Мәдинә, беләм...Ничек киенү турында төрлечә уйлап карадым... Ничек киенсәм дә, күзләренә чалына калсам, танырлар дип беләм.

— Саграк булырга иде.

— Нишләргә соң, Мәдинә? Эзлиләр дип качып, ябылып ятып буламы? Ә иптәшләр?! Үзең беләсең, хәзер алар нинди хәлдә? Аларны ничек тә булса зинданнан коткарырга кирәк. Ул миңа фарыз!

— Әй аллам, нинди генә газиз башлар әрәм булмый. Нинди заман! — Мәдинә тетрәнеп китте, узган төндәге куркыныч вакыйгалар тагын күз алдына килделәр.

— Мин синеңниләр кичергәнеңне чамалыйм, син дә минем хәлләремне бел инде, Кәрим,— диде ул...

Гадәттә, татар халкы кабер өстенә истәлек өчен язулы таш һәм чардуган куя. Ә менә үзбәкләр, казахлар (билгеле, хәллерәкләре) кабер өстенә кирпечтән, таштан тәрәзәсез-нисез гөмбәз өй салып калдыралар. Кызылъяр зиратында да берничә шундый мазар бар иде. Менә шундый мазарларның берсен кемдер кеше мүкәләп керерлек итеп тишкән. Алар әнә шул янтыгы тишек мазар кырына барып утырдылар...

Үткән төн Кызылъяр хәрби госпиталь врачы Мәдинә Урманова өчен аеруча тынгысыз, хәвефле төн булды. Кичен бертуктаусыз яралы урыс-казакларны ташыдылар. Палаталар гына түгел,коридорлар да шул дәү сакаллы, яман күзле казак-урыслар белән тулды. Ыңгырашу, акыру, сүгенү, самогон исе... Бигрәк кабахәтләр үзләре, яраланганнар, канга тузып яталар — анда да шәфкать туташларын чеметкәләп калырга маташалар... Кызлар елап Мәдинә янына керә. Өлкән врач бу кичтәге хәлләрне күтәрә алмыйча йөрәге сызлап егылды. Бар авырлык Мәдинә өстенә өелде. Кара, дәвала, операция яса. Врачның хәлен үзе генә белә! Эчтә нәфрәт уты дөрли, дөмектерер идең шул кабахәтләрне, үзләрен туп-туры җәһәннәмгә озатырдай буласың, ярамый! Син врач. Дәваларга тиеш...

Ә төн уртасында... Иң хәвефлесе әнә шул төн уртасында булды да инде...

— Ярый әле, хәтәрне алдан сизендем. Югыйсә барыбыз да һәлак була идек.— Мәдинә Кәримгә таба сыгылып төште, йөрәге чәнчеп тыны кысылды.— Ярый әле, ходай коткарды ул эттән!

...Мәдинә утыз беренче май төнендәге бәрелештә бик каты яраланган ике кеше — Николай Новиков белән Микола Таранның өенә барып кайтты. «Хатын-кызлары чирләгән икән!» — дигән булып барып, сугышчыларга перевязка ясады, дарулады. Николай Новиков та, Микола да Кәримнең дуслары иде. «Егетләрнең хәле начар», дип хәбәр иттеләр аңа. Һәм ул, гангрена башланудан куркып, аларның икесен дә бик зур саклык белән, яшертен генә госпитальгә алдырды.

Мәрзия аклар штабында машинистка булып эшли иде, ул кичкырын килеп казак-урысларның госпитальдәге яралыларын берәмтекләп тикшерергә җыенуларын әйтте...

Мәдинә ике Николайны да процедурага дип чакыртты да шунда ук подвалдагы моргка озаттырды. Ярдәмчеләре ишекне бикләп өскә

күтәрелгәннәр генә иде, кылычларын сөйрәп, шпорларын шалтыратып бер төркем казак-урыс килеп керде. Берничәсе ишек төбенә басты, беркемне чыгармыйлар да, кертмиләр дә. Өчесе рөхсәтсез-нисез Мәдинә бүлмәсенә килеп керделәр. Башлыклары — яшь бер офицер.

Чакырылмаган кунакларның болай килеп басуыннан каушап, ни әйтергә дә белмичә, иңге-миңге басып торганга, ул офицерның йөзенә күтәрелеп тә карамады.

— Әллә Мәдинә туташ танымый да инде? — диде ясалма, салкын бер тавыш.

Күтәрелеп караган иде, имәнеп китте Мәдинә! «Әллә саташаммы?» — дип тә уйлады.

— Без гарнизон начальнигы полковник Орлов боерыгын үтәп палаталардагы авыруларны, яралыларны тикшереп чыксак... сез каршы түгелдер бит, Мәдинә туташ?

— Мин монда туташ түгел, ә врач, Алиев әфәнде!

— То есть... офицер әфәнде!

— Гафу итәсез.— Мәдинә күкрәгенә тулган нәфрәт ачысын яшерә алмыйча агарынып китте. Иреннәре дерелдәде, шушы хәлне сиздермәс өчен, ишек төбендә куркудан дер-дер калтырап торган шәфкать туташы Машага эндәште. — Офицер әфәндегә халат бирегез! Али Алиев Мәдинәдән күзен алмыйча ашардай булып карап тора иде, халатын да күзен йөртмичә генә киде, киенгәч аның алдында боргаланып алды.

— Сез шатланмыйсыз шикелле, врач әфәнде?

— Нинди шатлыгым бар соң минем?

— О-о, сез бит могтәбәр Ахун хәзрәт кызы! Большевиклар богавыннан котылуыгызга сез дә сөенергә тиеш идегез...

— Без госпитальдә, офицер әфәнде. Биредә йөзләгән авырулар ята. Үзем турында уйларга көчем юк.

— Без алда очрашырбыз дип өметләнәм? — диде күзләрен уйнатып чибәр Алиев.

— Кызганычка каршы, минем вакытым булмас дип уйлыйм.

— Чыннан да, кызганыч,— диде Алиев, үзе Мәдинәгә тагын бер карап алып, күңеленә усал уйлар салып куйды. «Әллә кая бара алмас! Кәрим дигән тәти кошны да аягыннан каптырырбыз... Һәм нәкъ менә син миңа булышырсың да!»

Ул барлык палаталарга кереп, һәрбер авыруның йөзенә җентекләп карап, тикшереп үтте дә коридорга чыкты, ишек катындагы казак-урысларга пышылдап нидер әйтте. Алар бераз читкәрәк китеп, сөңге кебек кадалып калдылар. Али Алиев процедура кабинеты янында торган Мәдинә янына шак-шок атлап килеп басты да, күзләренә сынау белән карап, коры гына эндәште:

— Тагын кайда, нинди авырулар ята, врач әфәнде?

— Бар булганы күз алдыгызда. Белмим... сездә ничектер, бездә авыруларны чормага яки подвалга качыру гадәте юк.

— Сез үз сүзегезгә җавап бирәсезме?

— Әлбәттә!

— Алайса,— Алиев уң кулын фуражкасына күтәрде.— Борчуыбыз өчен гафу үтенәм! Киләчәктә күрешәчәгебезне тагын бер кат искәртүне бурычым саныйм!

Аның кул хәрәкәтенә буйсынып стена буенда кадалып торган казаклар да елгыр гына чыгып киттеләр.

Ишек ябылуга Мәдинә хәлсезләнеп авып китте, ярый әле Маша тотып калды, процедура кабинетына алып кереп, кушеткага салды, дару каптырды. Минут уздымы икән, Маша нык кына аның янтыгыңа төртеп куйды... Мәдинә күтәрелеп карады һәм ишек ачыгында торган Алиевны күрде. Али Алиев кулъяулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә көлә иде.

— Врач әфәнде, әгәр монда чит кешеләр, безнең дошманнарыбыз юк икән, нигә шул кадәр каушадыгыз?!

— Кабахәт! — Мәдинә үзенең ни әйткәнен сизми дә калды.

Алиевның яңак сөякләре тартышып алды.

— Мин сезнең бу сүзегезне ишетмәдем. Әткәгез хөрмәтенә,. әлбәттә... Нигә шулай ямьсез сөйләшергә? Тупас большевиклар заманы узды, врач әфәнде... Ярый. Мин сезгә матур сүзләр әйтергә дип кергән идем, мондый хәлдә күргәч... Хушыгыз!

Алиев нидер белә, дип уйлады Мәдинә. Ике Николайны монда калдырырга һич тә ярамый иде. Бары тик төн уртасында гына ул аларны хәвефсезрәк саналган урынга, Ишел аръягына озата алды...

Әлбәттә, ул боларның барысын да Кәримгә сөйләп тора алмады, вакыты да, урыны да ул түгел! Али Алиевның кем икәнлеген сөйли башлагач кына күптән түгел булып узган хәлләр яңарып аның күз алдыннан тезелеп уздылар...

— Али Алиев өчен син мине дә гаеплисеңме? — дип сорады Кәрим.

— Нигә?

— Аның хаин икәнлеген мин белергә тиеш идем! Мин алдан сизәргә тиеш идем!

— Кыйналмыйча камчының ничәдән үргәнен күреп булмый шул,— диде Мәдинә, кайдадыр ишеткән сүзен хәтерләп...— Тукта! Нигәдер күңелем бик курка. Кәрим, аннан кемнәрдер килә түгелме?..

— Алар күләгә якка чыгып төрбәгә сеңеп беттеләр. Караңгылыктан: «Кү-кү!» — дип аваз килде.

— Безнекеләр! — диде жиңел сулап Кәрим.— Безнең кешеләр.

Шәүлә башта берәү генә кебек иде, якынлаша башлагач, аларның дүрт кеше икәне ачыкланды. Сүзсез генә кул бирештеләр дә тишектән шуышып мазар эченә кереп киттеләр. Кәрим Мәдинәне озатты:

— Син зиратчы йорты тирәсеннән еракка югалма! Без хәзер...

Мазар эче караңгы. Таш плитәдә утыручылар бер-берсен күрмиләр дә. Сөйләшү бик сак, пышылдау белән генә бара.

— Анда ни хәлләр?

— Күзәтергә кешеләр куелды. Алай-болай булса хәбәр итәрләр.

— Болай, иптәшләр,— дип башлады Кәрим сүзне.— Операцияне таң алдыннан башларга кирәк. Шуннан да соңга калырга ярамый. Алынган хәбәрләргә караганда, аларны берсекөнгә суд аша уздырырга һәм атарга җыеналар.

— Корал ягы ничек соң, корал? — диде аңа янәшә генә утырган карлыккан тавыш.

— Корал бар, ләкин азрак. Тимер юлчыларда ике пулемет сакланып калган. Хәмит төрмә сакчыларының берничәсен белә икән. Безнең егетләр! Җае да чыгып тора: алар иртәгә төнгә каршы сакка басалар.

— Менә бусы ярый, бик ярый,— диде карлыккан тавыш.

— Гарифҗан абый, син инде үзеңнең егетләреңне кичтән үк төрмә янындагы кабакка алып бар. Шау-шу күбрәк булсын өчен Әгъләм гармунын да алсын. Калада беренче гармунчы, аны белмәгән беркем дә юк! Уйнасын, җырласыннар, шик-шөбһә калырлык булмасын. Әйт, эчкән булып, җырлап-сүгенеп утырсыннар. Операциянең вакыты житкәч кабакчы: «Житте, вакыт бетте, ябам!» — дип сезне өерләп чыгарсын. Шикләнмәгез, ул безнең кеше. Сез гармун белән төрмә ягына таба барырсыз. Ә сез, Петр белән Василий,— Кәрим кырыйдагы егетләргә төбәлде,— сез, Маслаковның ломовиклары буларак, кичтән үк, йөк төягән булып, ике пулеметны, мылтыкларны һәм патроннарны арба асларына яхшылап яшереп, өстенә солы, печән тутырыгыз да күчәр сынган булып төрмә янында туктарсыз. Сез дә үзара сүгешегез, шау-шу күбрәк булсын! Кузгалу минутын иртәгә билгеләрбез. Хәмит кайбер

кешеләрне күреп һәммәсен дә ачыкларга тиеш.

Ул арада мазар тишегенә ук шикелле бер малай килеп кадалды.

— Абый! — дип пышылдады ул.

— Ә, Сабиржан. Я?

— Мине доктор апа җибәрде. Зиратчы өенә бер эфисәр килгән, Кәрим абыйны сораша, ди.

— Рәхмәт, Сабиржан! Егетләр, иплән кенә таралыгыз. Иртәгә кайда күрешүне шушы малай хәбәр итәр!

— Абый, абый! — Сабиржан Кәримнең кулыннан тартты.— Доктор апа монда якында гына сине көтә. Килсен, диде. Әйдә, үзем алып барам.

Кәримне Мәдинә белән очраштырды да Сабиржан юкка чыкты. Кәрим аның елгырлыгына сокланырга да өлгермәде, Мәдинә аны кочып алды, кайнар сулышы белән яндыра-яндыра пышылдады:

— Җаным, теге бәдбәхет монда ук килеп җиткән!

— Минем эздән йөри. Шунысы шикләндерә! Мин Меңбай әкәләрдән чыгып китүгә үк бастырып анда барып кергәннәр. Тушаланы ватып, актарып ташлаганнар. Хәзер ул монда...

— Әллә чыннан да җәйләүгә китеп торасыңмы? — дип пышылдады Мәдинә. Алар кулга-кул тотышкан килеш куе агачлар караңгылыгында чак шәйләнгән тар сукмак буйлап баралар иде.

— Ул турыда сөйләмә дә! Иптәшләр хәвеф эчендә. Мин иректә. Озакламый Хәмит килеп җитәргә тиеш. Мин ул билгеләгән урынга барам. Иптәшләр белән элемтәне дә өзәргә ярамый!..

Тагын бераз бардылар, сукмак тарайганнан-тарайды да бөтенләй бетте.

— Әгәр Хәмит уңайлы урын табалмаса?

Кәрим бу сорауга җавап бирмәде, җавап бирә алмады, чөнки ул үзе дә бу турыда кич буе уйлый иде инде, Алиев этләре бөтен шәһәр буйлап иснәнеп чабалар, Кәрим тирәсендәге боҗра тарайганнан-тарая бара иде.

— Хәл җиңел түгел, Мәдинә.

— Кәрим!

— Ни диден, Мәдинә?

— Әллә син бездә торып торасыңмы? Ничек кенә әйтмә, безнең әти Кызылъярда мәртәбәле кеше, ахун.

— Ничек сезгә барыйм соң мин?

— Әти дә, әни дә өйдә юк. Мәүлеткә киткәннәр иде, анда тимер юлны сүткәннәр, кайта алмый калдылар. Бер-ике көн тора аласың. Аннары тагын күз күрер. Кайдалыгыңны Хәмиткә дә, башка иптәшләргә дә белдерермен.

— Сине куркыныч эченә кертәм бит, Мәдинә! Болай да...

— Мин һәммәсенә дә риза. Барысына да түзәрмен!..

Кәрим белән Мәдинә ахун йортына кеше күзенә чалынмыйча гына үттеләр. Кәримгә шушы төнне һәм алдагы көнне яшеренеп уздырырга кирәк иде. Алдагы төндә алар төрмәгә һөҗүм итәчәкләр. Иптәшләрне коткаргач эш үзеннән-үзе җайланып китәчәк. Бергә булганда яшәү җиңелрәк булачак! Мәдинәнең хәлен авырайтса да, ул аларда урнашып торырга риза булды, «иптәшләр хакына!» диде.

Мәдинә ахун хәзрәт йортының икенче катындагы зур, иркен бүлмәдә яши. Анда кереп аны-моны капкалап алганнан соң ул мендәр, одеал биреп Кәримне чормага озатты...

Мәдинәнең әтисе ахун хәзрәт урта хәлле генә бер кешенең баласы булып, бу олы дәрәҗәгә ачык зиһене һәм тырышлыгы аркасында ирешкән иде. Бетәшкән кара динле кеше булмаса да, ул өй эчендәгеләрне каты тота, кызын Казанга җибәреп укытып кайтарса да, өйдә чакта

аның һәр адымын белешеп, сорашып, җентекләп күзәтеп тора иде. Соңгы айларда ата белән кыз арасына «кара җил» керде, хәзрәт сораша — кызы җавап бирми. «Әткәй, алдыйсым килми, дөресен сөйләргә ярамый!» — дип кенә куя. Ничек алай?! Бу җавап ахунның акылына сыймый! Бөтен Кызылъярда аны акыллы, аңлы кеше дип саныйлар, бик күпләр аңа киңәшкә килә, ярлысы, бае, бәхетлесе, бәхетсезе, ә монда үз каның, үз балаң шулай карышып маташсын әле! Белә ахун, патшаның тәхеттән колак какканын да белә, совдеплар туып яралуын да белә, күпчелек байларның сарык тиресе ябынып, мыштым гына тыңланып кына йөрүен дә күрә, шуның өчен кызына да өзеп ачулы сүз әйтми, аны тыя да алмый. Ләкин ата күңеле бик рәнҗи, бик рәнҗи. Кызын шикле кешеләрдән аралап аласы килә, бердәнбер баласы бит! Гомер-гомергә үз янында сыендырып кына яшәтәсе килә. Байлыгы җитәрлек, абруе бар, ике якка да бөгелеп сәлам бирә ала, советлар да аны артык кысмады, аклар кире кайтса да йөзе ак, тик менә кызы гына... Каян шул Кәрим белән бәйләнешеп, танышып китте дә каян шул Кәримне комиссар итеп куйдылар. Маслаков булып Маслаков, бер көнне кибеттә очратып: «Хәзрәт, сезнең кызыгыз большевикка кияүгә чыга диләр, расмы шул сүз?» — дип сорады. Татар агайнесе арасында, мөселманнар тирәсендә генә түгел, урыс-улак арасында да Мәдинәнең Кәрим белән төрле түгәрәкләрдә чыгыш ясавы мәгълүм булып җиткән икән!..

Мәүлет авылына ул җаны тынычсызланып китте. Калада төрле хәбәрләр йөри, хәбәрләрнең иң кәттәләрен төрле авызлар ахун хәзрәткә җиткереп торалар иде. Чехлар турында да ишеткән иде ул, урыс-казакларның күтәрелеш әзерләве дә аның колагына чалынмады түгел, ишетелде. Али Алиев белән дә очрашкан кешеләр алар, тик ахун хәзрәт аны бер күрүдә яратмады, аның ясалмалыгын да, икейөзле булуын да бик сизде. «Аннан ераграк йөр, кызым!» — диде Мәдинәгә. «Рәхмәт, әткәй»,— диде Мәдинә һәм, чыннан да, бер чакта да Алиевка ачык чырай күрсәтмәде. «Кәримнән дә ерак йөр, кызым»,— дип кисәтеп карады ата, әмма бу юлы сүзе суга акты да китте...

Мәдинәне урта кул гына кибетче Шаһназар улына сорап килделәр. Башка вакыт булса ахун хәзрәт андый ыбыр-чыбыр белән сөйләшеп тә тормас иде, бу юлы ул яучыларны өметләндереп җибәрде: «Ноктасын куймасак та, иншалла, кыз үзебезнеке, уйлаша торырбыз»,— диде.

Мәдинә бу турыда ишетергә дә теләмәде. Укыган, тирә-якта абруе үсә барган доктор кызын яткырып кистерә алмый бит инде ахун! Ул бу кирелегеннән дә йотты кызының, әмма кырысланды. Шул көннән керде алар арасына «кара җил!»

Ул Кызылъярдагы чуалышлар турында ишетеп кайтты. Большевиклар белән төрмәләр тулуын да белде. Шуның өчен абыстайны Мәүләттә калдырды. Тимер юл рәткә салынмаган иде, ат яллап кайтты ахун, аны белеш татарлары китереп куйдылар. Шушы ук олау белән ул Мәдинәне каладан җибәреп торырга дип кайтты. Абыстайга да шуны әйтте: «Шәһәр баш-күз алганчы кыз белән монда торып торасыз»,— диде.

Мәдинә әтисеннән китү турында сүз чыккач коелып та төшмәде, йомшамады да, беренче итеп госпитальдәге хәлне алга куйды:

— Баш врачыбыз йөрәк хастасы белән егылып ята. Күпме яралылар бар? Мин аларны ничек калдырыйм? Соңыннан кеше күзенә ничек күренермен?

— Анда әнкәң хәл эчендә ята, халыкка да шулай белдерербез.

— Юк, юк, әткәй, мин сезне бик хөрмәт итәм, һәр сүзегезгә колак салам, әмма бу юлы кушканыгызны эшли алмыйм.

Башта йомшак сүзләр белән үгетләп маташкан ахун тора-бара кызды, баласына авыр сүзләр әйтте, тик барыбер килешә алмадылар, Мәдинә үз юлына эшкә китте, ахун мәчеткә юнәлде...

Мәдинә госпитальгә барышлый берәүләргә кереп чыкты, аларның

балалары бик каты авырый, аның чирле икәнлеген бөтен урам күршетирәләр белә, шуның өчен докторның кереп чыгуы беркем өчен дә гаҗәп түгел иде. Шунда ул Хәмит белән очрашты.

— Кәримне кичке эңгердә зират бакчасында кушкарама төбендә көтәчәкләр. Соңармасын! — диде ул.

— Яхшы,— диде Мәдинә...

Ул көне буе баш күтәрмичә эшләде диярлек, авыруларны карап чыгарга, дәвалар билгеләргә, шәфкать туташларын тынычландырырга кирәк иде. Ул соң гына госпитальдән чыгып китә алды. Тизрәк, тизрәк Кәрим янына кайтып җитәргә, эткәсе мәчеттән кайтканчы аны тиешле урынга озатырга да кирәк иде.

Госпитальдәге авыр һава аның башын авырттырган иде, ул чыгып бераз баруга ук җиңеләеп китте, адымнары ешайды, кадерле кешесе белән азга гына булса да, очрашу бәхете аның йөзенә алсулык йөгертте. Тормыш авыр, чуалчык булса да, яшьлек үзенекен итә, мәхәббәте бар кеше кайчан да кеше булып кала...

Банк урамы чатын чыгуга Мәдинә аптырап туктап калды. Урамның аргы башыннан бер төркем халык килә. Нидер кычкыралар, таяк белән кизәнәләр. Төркемне ярып алга казак-урыс чыкты. Ул нигәдер бертуктаусыз артына әйләнә, кулындагы озын камчы белән суга. Кемгә?! Кемгә икәне билгеле инде. Тагын бер бәхетсезне каптырганнар. Тагын берәүне төрмәгә озаталар. Монда Кәримнәр иптәшләрен коткарыр өчен җан атып йөргәндә тагын берәүне тотканнар... И-и, ходаем, Кәрим андый-мондыйсыз гына теләгенә ирешә алсын иде!.. Төркем якынайды, аларның ни дип кычкырганнары да ишетелә башлады.

— Мә сиңа!

— Мә, кызыл эт!

— Теләгеңә ирештеңме, комсыз комиссар!

«Комиссар?» Мәдинә коелып инде, әмма аны-моны сиздерергә ярамый иде, ул егылып китмәс өчен туп-туры басарга тырышып, төркемгә каршы ук китте, якынайды.

— Я алла, нишлисез сез?!

Кыйналучының Кәрим икәнен белсә дә, ул аны танымады. Кәримнең бөтен җиреннән кан ага, куллары артка каерылып бәйләнгән, атлаган саен сөрлегеп алга егылып китә. Ярсып акыручыны да таныды Мәдинә, шәһәрнең ломовой извозчикларын тотучы явыз Маслаков иде бу кеше. Менә ул кулындагы авыр, тимер таягын югары күтәрде дә бар көче белән Кәримнең башына сукты.

— Мә, җәһәннәмгә дөмек, мәлгунь!

— Господин полковник!

— Мин сезгә Сутюшевне исән-аман китереп җиткерегез дидем, поручик.

— Юлда очраган толпа, казакларның боерыгына буйсынмыйча, комиссарны кыйнап ташлаган. Ул исән...

— Халыкның үз дошманнарын шулай каршылавы начар түгел, поручик. Ләкин миңа тере комиссар кирәк!

— Башта без аны төрмәгә озатырга уйлаган идек, аннары госпитальгә салуны уңайлырак күрдек.

— Баш врачны алып килегез! Кисәтегез, нык карасын.

— Баш врач авыру.

— Авыру булса да килсен. Поручик, мин сездән тагын канәгать түгел. Беркемгә йомшарырга ирек бирмәгез!

— Виноват, полковник әфәнде!

«Тагын шул Кәрим аркасында!» — дип уйлады ирennәрен тешләп Алиев. Ул кызарынган, тагын да чибәрләнеп киткән, моңарчы салкын торган күзләре ут булып яналар. Ул баш врачны чакыртасы урынга, Сутюшевны өзгәләп кенә ташлар иде!... Ярамый! Әлегә ярамый!..

Инде ярты тәүлек үтеп китте. Ә Кәрим әле һаман аңына килә алмый. Мәдинә төн буенча керфек какмады, аның янында булды, мөмкин булган барлык чараларны күрде, дәвалады. Яраларын юып текте, бәйләде, компресс куйды, төрле уколлар эшләде. Инде тәмам аптырагач, үзе хәл эчендә яткан Мойсей Абрамовичка шалтыратып, телефон буенча гына булса да консультация алды. Ул авыруга кан коярга киңәш итте. Анализ Кәримнең каны икенче группа икәнен белдерде. Беренче группа канлы Мәдинә иң әүвәл ана үз канын бирде. Шәфкать туташлары, санитарлар үз каннарын бирергә ризалык белдерделәр. Алар яраткан докторларының ничек һәм ни дәрәҗәдә кыйналуын күреп торалар, теләсә нинди ярдәмне күрсәтеп, аның хәлен җиңеләйтергә әзер иделәр.

Иртәнге күлемдә Кәрим иреннәрен тибрәтте һәм ыңгырашып кына су сорады... Аңа кадәр Кызылъярда хәлләр булып алган иде инде!

Төнге сәгать икеләрдә, һичкем уйламаганда, беркем көтмәгәндә бер төркем коралланы кешеләр төрмәгә һөҗүм итәләр дә тоткынлыктан иллегә якын кешене коткаралар... Иртән тикшерү вакытында сакчылардан өч кешенең үлүен, бишесенең яралануы билгеле булды. Иң гаҗәбе, төрмә сакчыларыннан дүрт кеше тоткыннар белән гаип булган иде.

Орлов, моны ишетү белән, тәмле йокысын бүлеп гарнизон штабына чабып килде һәм иң беренче чиратта Алиевны чакыртты.

Али Алиев үз гомерендә беренче мәртәбә каты курку кичерде. Бер караганда аның гаебе юк та кебек иде, икенче караганда... Полковник кызган чагында ачуын кемгә булса да чыгарырга тиеш! Андый чагында штаб офицерлары аның күзенә күренмәскәрәк тырышалар. Бүген, мөгаен, Алиевнын соңгы кичедер... Бүген я кала, я бетә дигән сүз!

Полковник тәрәзә янына баскан да туктаусыз папирос суыра. Шул ук хуш исле төрек папирослары, шул ук бүлмә, тик мөнәсәбәт кенә башка... Али Алиев беренче мәртәбә полковник янында калуына үкенеп куйды...

— Я,— диде Орлов, аңа карамыйча гына.

— Тыңлыйм, полковник әфәнде.

— Инде моны ни белән аңлатасыз?!

— Мин аңлата алмыйм, полковник әфәнде. Һәм, гафу итегез, ни өчен мин генә моның өчен җавап бирергә тиеш?

— Син генә! Чөнки син алар арасында булдың. Син барын да күрдең. Син барын да беләсең! Нишләп йөрдең син алайса?! Кем оештырган бу эшне? Корал каян тапкаынар? Һәм кая киткәннәр алар? Табарга! Берсен дә җибәрмәскә!..

Полковник тавышыннан тәрәзә пыялалары калтырап, зыңгылдап торды...

Кәрим аңына килеп беренче җөмләсен әйтте:

— Кара, ничек озак йоклаганмын.

Мәдинә аңа өстәп сүз кушарга да өлгермәде, ишектә Али Алиев пәйда булды.

— Хәерле иртә, врач әфәнде.

— Сез нишләп монда? — Мәдинә кычкырып җибәрде, артка чигенде.— Сез? Нигә килдегез монда, Алиев әфәнде?!

— Гафу итәсез, Мәдинә туташ, курыкмагыз. Хәл белергә кердем. Иске дусларны онытып бетерергә ярамый бит. «Старый друг лучше новых двух»,— ди бит рус халкы, ялгышмасам.

— Аның хәле авыр, аның янына керергә рөхсәт итмим.— Мәдинә үзендә һичбер вакыт ишетелмәгән ачулы, нәфрәт тулы тавыш белән кычкырып сөйләшә иде.— Мин врач! Рөхсәт итмим, ишетәсезме, рөхсәт юк!

— Мәдинә туташ! — Али Алиев бишкә бөгелеп, гаять йомшак, хәт-

та ялварулы тавыш белән үтенде,— гафу итегез. Мин бит чыннан да изге ният белән йөрим. Хәле авыр дип ишеткәч, полковникка сиздермәс өчен шулай иртә килдем. Ни әйтсәң дә, ахыр чиктә, без мөселманнар. Әйдәгез, бергәләп сөйләшик. Аңлашыйк. Минем хәлем дә җиңел түгел.

Ә дигәнче Али Алиев Кәрим яткан караваг янына килеп басты.

— Кәрим дус,— диде ул җылы, туганнарча тавыш белән,— хәлегез ничек?! Курәм, шәптән түгел... Минем хәл шәп дип беләсезме әллә?!

«Төрмәдән качуны ишеткән дә килеп җиткән!» — дип уйлады Мәдинә...

Кәрим бинт белән уралган башын чак кына кыймылдатып куйды, сыңар күзен ачты, үз ятагы өстенә иелгән кешене таныды һәм бер сүз әйтте.

— Ни диде ул? — Али Алиев Мәдинәгә сынап карады.

— Ишеттегез ич,.провокатор, диде.

— Мәдинә туташ,— диде Али Алиев кош сайраган тавышлар чыгарып,— чыгып торыгыз, ирләр диалогын тыңлау сезгә килешмәс.

— Мин сезнең палатадан чыгып китүегезне таләп итәм!

— Шулаймы? — Мәдинәне гаҗәпләндереп Алиев шаркылдап көлә үк башлады, аның сабыры сынган иде.— Шулаймы, ка-дер-лем? Калдырып тор дисеңме?!

Мәдинә, әллә бу котыра башладымы дип уйлаган иде, юк икән, котырмаган, гасабый, иблис тавыш бераздан шаркылдаудан туктады. Иреннәр җыелды, салкын, күк күзләр Мәдинәгә кададылар.

— Юкка, сез, Мәдинә туташ, фәрештә булып күренергә тырышасыз! Мин сезне аңлыйм. Кәримне бу хәлгә төшерүче сез үзегез бит, хөрмәтле ахун кызы!

— Ялган!

— Борчылмагыз.— Али Алиев гәүдәсен турайтып башын артка ташлады.— Ничек дисезме? Хәзер исегезгә төшерәм. Кичә соң гына, сезнең әтиегез, ахун хәзрәт, үзе гарнизон начальнигына килеп, Кәрим Сутюшевны, Большевиклар комиссарын кызым алдап безнең өйгә алып килде, качып киткәнче кулга алыгыз, диде. Хәзер аны яклаган булып маташасыз!

— Моның булуы мөмкин түгел! Ялганлыйсыз, хаин. Хаин!

— Кәрим Сутюшевның сезнең чормада икәнен тагын кемнәр белә иде? Беркем дә! — Али Алиев яңадан караваг янына килде.— Менә, барын да ишеттегез, барын да беләсез. Иптәш Сутюшев, кемгә ышанып башыгызны харап итә яздыгыз. Ишетәсезме?

— ...

— Юкка газапланасыз. Мин ахун кызы төсле икейөзле түгел. Иске танышлык хөрмәтенә ирләрчә ярдәм дә итә алам. Язмышыгыз үз кулыгызда.— Ул тагын Кәрим өстенә иелде.— Әйт, төрмәгә һөҗүм итүдә кемнәр катнашты? Корал каян алдыгыз? Төрмә сакчылары белән кем эш йөртте? Качканнан соң алар кая юнәлергә тиешләр иде?!. Шушы сорауларга җавап бирсәгез... Яшисез, иптәш Сутюшев, яшисез!

— Җитәр! — Палата калтыранып китте. Үлем хәлендә яткан гәүдә кинәт күтәрелде, куллар офицерның муеныннан кысып алдылар.— Провокатор! Сатлык җан! Хаин!

Али Алиев гәүдәне караватка төртеп җибәрде, френчын тиз-тиз рәтләде, йөгереп барып палатаның ишеген ачты.

— Конвой! Өстәгез!

Казаклар атылып кереп Кәримне караваттан өстерәп төшерделәр һәм нагайка белән кыйный башладылар.

— Ә сез, Мәдинә туташ, врач әфәнде, карап торыгыз. Большевикларга ярдәмегез өчен бусы сезгә җәза булыр. Ха-ха-ха!..

Тоткыннар төрмәнең бер канатыннан гына качарга өлгерделәр. Качучылар арасында Дубинин да, Идрисов та, Зайкин да бар иде. Госман Әбдрәшитов кача алмады, ул бөтенләй башка коридорда, почмактагы камерада калды...

Сул як күрше камера стенасыннан сак кына бер-ике тапкыр шакыган тавыш ишетелгәндәй булды. Әле генә мыж килеп торган камера тынып калды. Тоткыннар төнге ыгы-зыгыны да, атыш тавышларын да ишеттеләр, әмма анда ниләр барын берничек тә белә алмыйча газапланалар иде. Төрлечә юраулар китте...

Калын таш стена артыннан теге тонык тавыш тагын кабатланды.

— Уй-бай, стенаны тишеп ятырмы? — диде нәкъ шул стенага терәлеп утырган яшь бер казах егете, кысык күзләрен зур ачып.— Әнә, тагын чиртәләр.

— Тс-с! — Билгесезлектән калгып киткән Госман бу тавышка сискәнеп, сикереп торды. Тавышын басып кына боерды.— Шым булыгыз! Бер кеше ишеккә! Тишекне-волчокны капласын.

Үзе тиз генә теге егет утырган сәкегә атлады һәм егетне торгызып аның урынын алды.

Озын буйлы, кара сакаллы мадъяр аркасы белән ишекне каплады, барысы да кызыксынып Госманны күзәтә башладылар. Госман колагын стенага куеп тыңлап торды да өзек-өзек итеп йодрыгы белән бер-икене шакылдатты. Теге яктан үлчәмле бер пауза белән чиртә башладылар. Госман һәр чиртүдән соң тавышлап хәрефләп әйтеп торды.

— И-л-л-е-г-ә я-к-ы-н к-е-ш-е к-а-ч-к-а-н... К-и-ч-ә К-ә-р-и-м-н-е у-т-е-р-д-е-л-ә-р...

Бераз тын торганнан соң күршедән тагын чирту ишетелде, тик Госман кабул иткән хәбәр шул кадәр кот очыргыч иде ки, ул сан исәбен, хәрефләр тәртибен югалтып, зиһене чуалып калды. Камерадагылар да «соңгы хәбәрләр» турында кызып-кызып, борчылып гәпләшә башладылар, ишектә надзирательнең тавышы ишетелде, волчокта күз күренде.

— Нинди тавыш?! Нигә волчокны каплыйсыз, этләр?!

Тормышның иң каты сынауларын узган, ачыны, хәсрәтне йөкләпйөкләп татыган Госман Әбдрәшитов хәлсезләнеп сәкегә чүкте...

*Беренче китап тәмам.*

## Җубан Мулдагалиев,

казах шагыйре.

### Күңел тавышы

Күңелемдә гел бер борчу минем,
Әллә үзем шундый тумыштан:
Тәнемдәге һәрбер күзәнәгем
Тора сыман тоташ бурычтан...

Мин бурычлы Адәм атабызга,
Һава анабызга, Җиремә,
Утларына аның, суларына,
Даласында искән җиленә.

Мин бурычлы Кояш белән Айга,
Ял һәм йокы биргән төннәргә.
Туган илгә булган бурычымны
Гомрем җитәр микән түләргә?

Күңелемдәге булган хәзинәне
Башкаларга бирим өләшеп.
Бу бәхетнең беләм уртак булуын,
Мин туганчы ук аны өлкән буын
Октябрьдә алган көрәшеп.

Яңа эшләр, зур бурычлар белән
Башланырга тиеш һәрбер көн.
Бурычың бетте, дисә әгәр заман,
Ул чагында гомер учагыма
Соңгы сулышымны өрермен...

Гомер көнем кичкә бара авышып,
Чәчәк коя инде гөлләрем...
Бурычларың әле бетмәгән дип,
Дулкынланып тибә йөрәгем.

## Сырбай Мәуленов,

казах шагыйре.

### Уйлану

Мин тауларны җәллим — алар өнсез,
Дулкыннарны җәллим — алар сүзсез,
Күкне җәллим — аваз салмаганда,
Таш кыяны — кузгалмаган мәлдә...

Таулар уянсамы — ялкын сулый,
Дулкын кузгалсамы — җырлый, елый.
Күк яңгырын койса кипкән җиргә,
Таш кыялар хәтта төлгә килә...

Кайчак шулай тоела: мин — зур таумын,
Диңгез дулкыныдай ярсу җанлы!
Болытлы күк сыман уйчан, моңлы
Күңелемдә — кыя горурлыгы...

Яңгыр болытлары килә
Төрле сурәткә кереп...
Кара аргамак булып ул
Җиргә сикерер кебек.

Күкне дөбердәтеп чаба
Бүредән качкан сыман.
Яшен утлары сибелә
Җитез тоякларыннан.

Чү, бүре бәреп ектымы,—
Яллары тузды җилдә.
Сузылып төшкән ялы буйлап
Күз яше акты җиргә.

Хәтфә үләннәр булып ул
Күтәрелде болында.
Күр, аргамак әверелгән
Кыңгыраулы колынга.

## Гафу Каирбәков,

казах шагыйре.

### Бодай бөртеге

Учымда бодай бөртеге,—
Елмая кояш нурыннан.
Туган далам киңлекләре
Бөртек сырларына сыйган.

Учларымда җәйри дала!
Һич күренми иге-чиге!
Нәни бөртек сөйли миңа
Адәмнәрнең бөеклеген.

### Чаң-патша

Чаң дисәң чаң! Чорлар сокланырлык.
Моны Алып батыр койгандыр.—
Ни турында хыялланган оста
Иҗат иткән чакта бу чаңны?

Бәлки бөек трибун булгандыр ул,
Бар халыкны җыеп бер мәлне,
Теләгәндер шушы чаңын кагып,
Уятырга бөтен Рәсәйне...

Шамил **МАННАПОВ** тәрҗемәләре.

Уралхан Бүкиев
казах язучысы

# ЯЛГЫЗ АУЧЫ

ПОВЕСТЬ



Арчалы авылы белән казахның җире бетә. Аннан ары — бүтән ил, бүтән дөнья. Ә Актаң өчен, кай яктан гына якынлашса да, әлегә атның башы Арчалыга килеп терәлә.

Әлбәттә, казах халкының җире киң, иркен дип, аңа шактый зур берничә мәмләкәт сыя, дип ишеткәне бар аучы мәргәннең. Тик Арчалыдан ары беркая да аяк басмаган егет өчен аның мәгънәсе барыбер томанлы. Әкият кебек. Әүвәл, ул әле бала чакта, Әсән карт сөйли торган иде: «Әй, без күрмәгән ил, без басмаган җир калмагандыр. Әнә-ә теге Каратаудан алып Чуарагачка чаклы ат арытып йөргән заманнар бар иде. Ризыгың тартса юлың җир читенә илтер, дигәннәре бик хак икән — Катон-карагайга да барып ирештем бер».

Әсән карт озаклап сөйләгән ул сәфәр-юлларның Арчалыдан нибары җиде-сигез чакрымга гына сузылуын кем белгән соң ул вакытта. Хак әйтәләр, һәркемнең үзенә үз тавы биек шул инде.

Бүген Арчалы авылында алтмышлап йорт бар. Әмма иртән торып карасагыз, бары тик иң кырый өй өстендә генә сыек төтен баганасы абайларсыз. Калган илле тугыз учакның морҗасы ябулы булыр. Әлбәттә, моны читтән күзәтеп торган кешенең, бу авыл тәмам мәрткә киткән ахры, дип уйлавы ихтимал. Ләкин монда берәү дә мәрткә китмәгән — авылы белән күченгәннәр генә. Сыек төтен бөркүче морҗа иясе исә шушы буш йортларны, тирә-яктагы эрбет, карагай урманнарын каравыллый һәм ауга йөри.

Әйткәнебезчә, Арчалыдан ары казахның җире юк, әмма анда да Актаңның ырудашлары яши, диләр. Сөйләүләренә караганда, катлаулы теге заманнарда, Яңа Көн туган чорда, халыкның байтагы таулар артына качкан булган. Билгеле, андыйлар арасында көтү-көтү елкы-ат куып китүчеләр дә, аларның ялчы-ирярченнәре дә булган. Соңыннан шуларның бик күбесе җәяүләп үз илләренә дә әйләнеп кайткан, әлбәттә. Тик анда торып калучылар да бар икән әле. Менә шуларның барлыгы Актаң күңеленә һич тынгылык бирми. Хәер, кемнең кайда каңгырып йөрүе аның өчен бик пошырмый да сыман инде. Атасының анда үлеме яисә тереме икәнлеген уйлар вакыт та үтте диярлек. Әйе, ул ата назын күреп, аның «улым» дигәнен ишетеп үсмәде. Ихтимал, ишетми үсүе яхшыгадыр да. Ә бәлки, бергә булсалар, яшәү кадерен беләрәк төшәр иде...

Арчалыга машина юлы юк. Бары тик Акболак үзәне буйлап, тау-таш арасыннан ат сукмагы гына сузыла һәм ятим авылны дөнья белән тоташтыра. Ә инде калын кар каплап киткән кыш көнендә атналар, айлар буе ул юлга җан иясе аяк басмаган чаклар да булгалый. Тау табигате кырыс шул. Шуның кырыслыгына чыдамаган Арчалы кешеләре бер заман ике-өч көн эчендә үзәнгә, андагы үзәк утарга күчеп киткән иде дә инде. Халык түгел, дүнгәләк, дип, авылдашларын хөкем итеп калган иде Актаң ул вакытта. Җил уңайга иссә, рөхсәт булса, алар, мөгаен, шулай тәгәри-тәгәри ерак калага ук барып җитәрләр иде.

Әйе, Актаң аларга иярмәде, Өрелегә күчмәде. Бу йортларны караштырып торырга кеше кирәк, дигәч үк калырга булды. Очар күгем — Алтай киңлеге, эчәр суым — Акболак, иярләр атым Кашка, бар, дип, әле дә шушында яши бирә. Аны моны дәшмәс анасы да теләр-теләмәс кенә калырга ризалык бирде. Кыскасы, Актаңның әле бүгенгә чаклы туган авылын ташлаганы юк иде.

* * *

Гадәтенчә, бүген дә ул бик иртә уянды. Тау сыртларын калын томан томалап алган: авыл өстендә караеп торган кыя-ташлар да, телсез кара урман да күздән югалган. Хәер, кулың сузсаң бармак күренмәслек куе шул томан. Хәтта

сулу алырга комачаулый. Әчке киемнән генә чыккан Актаң, тәненә шундук чиркандыргыч дым үтеп кергәч, тиз генә өйгә борылды. Шунда әнисенең ыңгырашып куюын ишетеп алды. Аның янәшәсендә генә кап-кара «тун»лы мәчеләре киерелепсузылып уянып килә иде.

Актаң тимер мич янына чүгәләп, алдан әзерләп куйган коры утынга ут элдертеп җибәрде — өй эченә якты шәүлә иңде, җан керде. Һәр туар көнне ул шушы хезмәттән башлый. Көн саен аның моржасыннан иң элек төтен бөркелә. Тик бүген ул төтенне күрә алмассыз — томан.

Аучы, тау кәҗәсе тиресеннән тегелгән тунын бөркәнеп, утка карап ятты. Йокысы инде ачылган, тик гадәтенчә шулай уйга бирелеп, онытылып ята бирде. Хәер, уйлаганы, искә төшергәннәре дә аның бер үк уй, бер үк хатирәләр диярлек. Кичә дә, бер атна элек тә, хәтта былтыр да күз алдында шул ук күренеш, күңелендә шул ук уйлар иде бугай. Дөрес, көннән-көн кылган гамәле дә шул ук ич инде: иртүк торып саф һавага чыгып керә, тимер мичкә ягып җибәрә, корымланган кара чуенга су салып, аны ут өстенә куя да, тунын бөркәнеп, чәй кайнап чыкканчы күпмедер вакыт кабат ятып ала... Мичтәге ялкын телләре сикерә-сикерә Актаң-аучы хатирәләренә үрелә сыман. Ара-тирә берәр чаткы очып китеп я аның тунына, я мичкә елышкан мәчесе өстенә төшә һәм өйгә көйгән ис тарала. Кайвакыт аучы, онытылып китеп, көйгән төк, тире исен дә тоймый башлый, хыялга бирелеп ята бирә. Ялгыз кеше һәрчак хыялчан буладыр, күрәсең.

Әнисе дә һаман шулай әле ыңгырашкалап, әле йокы аралаш гырылдап куйгалый. Карт шул инде ул. Әгәр дә мәгәр өн чыгармый озаграк торса, Актаң аның янына килә һәм сулышын, йөрәк тибешен тыңлый. Вакыт-вакыт аның да кем беләндер эче бушаганчы сөйләшәсе, серләрен уртаклашасы килә. Тик анасы телсез, туганнан бирле дә бер сүз алышканнары юк шул. Дөньяда иң кыен нәрсә шулдыр, мөгаен: сер бүлешер кешеңнең юклыгыдыр.

Актаң тагын атасын күңеленә китерде: дөньяда бармы икән соң ул, әллә күптән үлеме? Мөгаен әллә кайчан җир куенына кергәндер. Кермәсә, кайларда йөрер икән? Ник бер дә хәбәре юк? Үлмәсә — нишләп мие шартлап чыкмый икән? Эт булып эт тә туган җирен сагына, бер булмаса бер кайтырга тырыша. Әгәр атасы исән булса, «артымда ялгыз хатыным, ятим балам калды, гүй, алар йөдәп, аптырап яшидер», дип, бер булмаса бер уйлар, бер кайтмаса бер кайтыр иде. Үз учагының утын үзе сүндергән ир ата буламы соң?

Ә бәлки инде күптән яңа учак, яңа тормыш коргандыр? Һәрхәлдә, элегрәк, атаң исән, ул аргы якка чыкты, диючеләр бар иде. Хәер, кем җанын кем кайгырткан да кемгә — кем кирәк. Иң аянычы шул: Актаң атасы башкалар кузгалганда түгел, бары тик Бөек Ватан сугышыннан соң гына юкка чыккан бугай. Алай булуы мөмкин эшме? Инде мең-мең елкы куалап китүчеләр дә берәнсәрән илгә кайткан чак лабаса! Ә аның атасы тәмам юк булды. Озак көтте Актаң аны, минем дә әтием бар, дигән өмет белән бик зарыгып көтте. Тик читтән кайтучылар арасында ул юк иде.

Шушы көнгәчә Актаң атасы хакында бик аз белә. Авыл халкы әллә ни сөйләмәде. Әнисе телгә зәгыйфь. Белгәне шул: буйга бик биек, бер чигәсендә зур кара миң, аягында кунычы киез белән эчләнгән казах итеге. Шул билгеләр буенча эзләп кара!

Дөрес, кара мөһер сугылган кәгазе килүчеләрне дә эзләп, һиң югы каберен табучылар әзмени? Тик Арчалыдан хәбәрсез югалган башка адәм юк.

Вакыт-вакыт аңа әтисе шушы ялгыз бүлмәле агач өйнең берәр җирендә посып торган кебек тоела һәм ул сузылып-сузылып як-ягына карана башлый, ымсынып куя.

Ә әнкәсе иренә бик каты рәнҗегәндер, күрәсең. Улы бу хакта сүз башлау белән, я читкә борыла, я нидер мыгырданып, яныннан китеп бара...

Аучы, торып, учакка утын өстәде. Тышта инде яктыра, томан да тарала төшкән иде — һәр зат, һәр әйбер аермачык күренә башлады. Актаң урамга чыкты — томан сыекланган, ерактагы Каратау белән Актау бил тиңентен аннан арынып, ап-ачык күренәләр иде. Әмма һава салкынча, өскә шундук чык куна, киемнәрне суга манчый иде. Көз галәмәтләре шул бу. Кабат җылы өйгә борылып керәсе, тун белән томаланып кузгалмый ятасы гына килә. Әйе, Актаңның алай да эшләп караганы бар. Берүк, күләгәдә үскән үлән кебек, вакытсыз саргаясы килмәвен күптән аңлап алган иде. Шушы тау илендә дөньяга килеп, тауның кырыс һавасын иснәп үскән, кырыс табигатен татып гомер иткән кеше ич — кырыслыгын да, җайсызлыгын да тоймый ул аның. Дөрес, аннан ялыккан чаклары да булгалыйдыр, әмма үз дөньясыннан чак кына аерылып торса да, бик тиз сагыныр иде ул.

Егет тагын Актау ягына карап алды — кояш әле күренми икән. Томан, мөгаен, төн гомерен озайткандыр. Таң җиле томанны таратыр әле, Актау җаеннан исә бугай әнә.

Актаң ат абзарына юнәлде. Ат абзары өй эргәсенә салынган иде. Ишеге һәрчак колакны ярып, шыгырдап ачыла иде, бүген тавыш бирмәде — тупсага да дым үткәндер, күрәсең. Сукыр кашка инде ашыйсын ашап бетергән, ал тоягы белән җирне тырмаштыргалап тора иде, иясен күрүгә сабыр гына кешнәгән булды. Аучы аны йөгәнләп абзардан алып чыкты, уң аягын өзәңгегә куеп, ат өстенә менеп атланды. Кайчандыр күзенә ак төшкән бу кашка ат даладай киң билле, озын торыклы булса да, Актаңның аягы җиргә бер карыш кына җитмәенчә, сөйрәлеп үк диярлек килә. Әйе, алар бер-берсенә мач килгәннәр, эре гәүдәләләр.

Өч көн яуган яңгырдан соң Акболакның суы бермә-бер арткан иде. Әле кичә генә елга уртасында калкып торган кара таш юкка чыккан. Ә су яр буйларында ярсып, таштан-ташка сикереп, күбекләнеп ага, шаулый иде. Әй, тилетинтәк бу ташкын, тирә-юньдә башка елга юклыгыннан масая төшеп, шулай тавышлана, үкерәдер, мөгаен. Әйе, Акболак — Алтай тауларының бу тирәсендә бердәнбер шул, ялгыз бала шикелле вакыт-вакыт теләсә ни кылана, шуклана. Ялгызларга тинтәкләнү дә килешә дип раслый сыман.

Сукыр кашка бу озын төндә печәнне күп ашаган иде, суны да күп итеп эчте. Актаң, ат муенына мәтәлеп китмәс өчен, артка каерылыбрак утырды да агым суга карап тора башлады. Хәтта күзе эленеп, онытылып та китте бугай, кашканың су чөмерүдән туктавын абайламый да калды. Ә ул, хуҗасының үкчә белән янтавына төртеп алуын көтеп, тик кенә тора бирде.

Агымсу Актаңны үзәнгә, кешеләр янына әйди иде сыман. Билгеле, ничәмә атналар буе бер ялгызы монда каңгырып йөреп тә ялыккан иде Актаң. Ирексездән күңелендә: «Аска төшеп менәргәме әллә», дигән уй бөтерелеп-бөтерелеп алды. Әмма ул алай да әйтә алмый — инде айдан артык авыру анасын калдырып китәргә базмый интегә иде. Аңа бит монда чәй кайнатыр бүтән кеше дә юк. Аучы үзен өенә арканлап куелгандай хис итте бу көннәрдә.

Ул ат эчереп кайткан арада инде чуендагы су кайнап чыккан иде. Аны ул берничә жиреннән яньчелгән озын гомерле җиз самавырга агызып алды, самавыр морҗасына берничә утлы күмер ташлап, табынга алып килде. Кичәгедән калган суык кәҗә ите белән беразката төшкән төче күмәчне дә табынга куйды. Ул арада, ягымлы гына мияулап, сырт йоннары көйгәләгән мәче дә табын тирәсендә урала башлады. Актаң исә, чәй әзер дип, әнисенә ым какты. Карчык, хәлсез генә кузгалып һавага чыгып керде, битен-кулын юган итте. Аннары иңкелди-иңкелди атлап барып түрдәге агач сандыкны ачты, тәсбихын алды. Һәм, авыз эченнән нидер мыгырданып, кыйблага карап, бик озак утырды ул иске җәймә өстендә. Гадәттә ул, кайберәүләр кебек, намаз уку белән бик мавыкмый. Иртән һәм кичен берәр тапкыр иман шартын кабатлау белән чикләнә. Анда да әле намазлык өстенә кырык кат чүңкәеп маташмый, аңа маңгаен бер-ике генә тидереп ала да, тәсбихын тарта-тарта, авыз эченнән генә нидер укыган булып пышылдый иде. Бүген никтер бу эш озаккарак сузылды. Чәйләре әллә кайчан суынды.

Ниһаять, ана, пышылдаудан туктап һәм күптән интектергән бил авыртуын кузгатмаска тырышып, җайсыз гына иелде дә маңгаен намазлыкка тидерде... һәм шуннан тора алмый катып калды. Актаң барып аны күтәреп торгызды. Шунда әнисе: «Бар, чәйне үзең генә эч», дигәнне аңлатып ишарәләде дә кабат намазлыгы өстенә иелде. Ул тагын бер намаз бетергәндә Актаң инде капкалап, чәй эчеп өлгергән, самавырга күмер өстәп, чәйне яңадан кайнатып чыгарган иде.

Аннары ул арткан кайнар су белән үзенең һәм анасының кием-салымын юып, чайкап, урамга чыгарып элде. Көн тагын да ачыла төшкән, кояштагы ташлар, мунча кергәндәй, тирләп күренә иде. Урман гына никтер һаман моңсу, җансыз тоела. Ә Арчалы йортларына исә, киресенчә, җан кергән кук, аларның түбәләреннән бу бөркелә иде. Әйтерсең лә ул өйләрнең хуҗалары кинәт кайтып төшкән. Актаңның хәтта, ул ябулы ишек-тәрәзәләргә кагылып, шакып, сөенче, дип сөрән салып йөгерәсе килеп китте.

Әй, күңел, күңел! Аның кодрәтеннән килсә, бу авыл халкын күптән инде ул яңадан үз урыннарына күчерткән булыр иде. Әлегә кысыр хыял гына шул бу, тиле өмет кенә.

* * *

Актаң, куш көпшәле мылтыгын алып, җәһәт кенә кашка атына атланды да тирә-юньне бер урап керү нияте белән авылдан чыгып китте. Ә күңеле әле һаман

Арчалыда — аның узган заманына бәйле хатирәләр белән юана иде. Әйе, ишек-тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадакланган ул өйләр кайчандыр гөрләп тора иде бит. Аларның һәрберсенең үз язмышы бар. Ул өйләрдә гөрләп туйлар узган, аннан җеназалар чыккан. Ниһаять, сабый балалар туган, аларга, кычкырып, матур-матур исемнәр кушканнар. Һәр өйнең учагында иртә-кичен гөрләп ут янган, төнлекләреннән бөркелеп-бөркелеп төтеннәр чыккан...

Дөньяда иң явыз эш ни дип сорасалар, Актаң, уйлап та тормыйча, «үз учагыңны үзең сүндерү, үз дөньяңны үзең җимерү», дип җавап кайтарыр иде. Тап-таза йортларын, дөньяларын ташлап күченеп киткән авылдашларын ул шул үз учакларын үзләре сүндерүчеләргә тиңли, күңеле һәрчак шуңа рәнҗи аның. Арчалы язмышы менә ничә ел инде аның йөрәген һаман әрнетеп, бораулап тора иде.

Авылның аргы очында элек бер карт яши иде. Әсән исемле. Үзе нигәдер һаман бала-чага тирәсендә булырга ярата иде. Бигрәк тә җәйге җылы кичләрдә, авыл артындагы сөзәк калкулык түбәсенә утырып, төрле юк-барны сөйләп ярты төнне уздыра иде. Авылдашларының берише «тел бистәсе» дип, берише «ялганчы» дисә дә, асылда ул саф күңелле, намуслы карт иде. Баксаң, ул шул чор малайларын авыл халкының үткәненә кагылышлы бик күп хәлләр белән тоташтыручы соңгы җеп, соңгы чишмә булган икән. Югыйсә, кайберәүләр уйлаганча, ул шулай теленә салынып, бала-чага белән юана, «әкият сатып» вакыт уздыра торган иде.

«Исәр кеше козгын гомерен яши икән,— ди торган иде Әсән карт үзе хакында.— Элек-электән Арчалының иң мәҗнүне мин идем, инде ничәнче буын үсеп буй җитте, әле дә йөреп торуым. Ниләр генә булып бетмәде ул гомер эчендә. Иң аянычы — барлык азамат ирләр яу кырында ятып калдылар, тормыш хәзер хатыннар кулында. Безгә баш булып алды, азды хәзер хатын-кыз. Әй бит, белмәсегез килсә, ул гайбәтчеләрнең унысы миндәй бер картка да торырлык түгел. Ни белә соң алар? Ни күргән? Тыңлагыз, мин сезгә бер гыйбрәтле хәлне сөйлим әле хәзер».

Әйе, әңгәмәне шулайрак итеп башлар иде Әсән карт. Ә Арчалыда, чыннан да, аннан да өлкәнрәк кеше юк, «козгын гомерле» ир затыннан ул гына. Ул да гүр иясе булса, авылның үткән-сүткәнен белүче дә калмаячак иде. Картның гайрәтлерәк яшьтәшләре исә илне ирекле итәбез дип әүвәл үзара канга-кан бәрелеште, аннары яралары ямалып, яңа буыннар калкып чыгарга өлгермәде. Бөек Ватан сугышы башланды. Шулай итеп, Арчалының батыр ирләренә картаерга, авылның мөхтәрәм аксакалына әверелергә язмаган икән. Менә шуннан соң инде авылда гел яшүсмер дә хатын-кыз гына өелеп калды, сакал йөртүче бер Әсән карт кына иде.

Шул вакытта инде Арчалының «хатыннар патшалыгы» дигән яманаты чыкты. Актаң чак кына хәтерли әле, сугышка киткән ир-ат арасыннан бары тик аның атасы гына әйләнеп кайтты бугай. (Хәер, ул шундук юкка да чыкты). Алтмыш йортлы авылда алтмышлап тол хатын торып калды. Ирләрен искә төшереп еларга тотынсалар, бөтен дөнья үксеп үкерәдер сыман тоела, ходай булса, мөгаен, ул да бу моң-зарны ишетми калмаска тиеш иде. Барлык хатыннарның да үз ирләрен гел мактап, «алпамшадай алтыным идең», дип алып батырга тиңләп, ил-көннең терәге идең дип, тезә-тезә искә алулары әле дә Актаң колак төбендә яңгырап тора шикелле. Хәтеренә аерата сеңеп калганы — Зибаш исемле хатынның җыйнак гәүдәле ирен искә алып елаганда, башкалар кебек үк, «алыптай батырым минем», дип кат-кат кабатлавы булды.

Әйе, Арчалы бер заман тәмам хатыннар дөньясына әверелгән, кемгә генә күтәрелеп карасаң да, аның башында бары тик ап-ак яулык кына күрер идең. Ерактагы сугышның кара канаты әнә шулай хатыннарны тол, балаларны ятим итте. Бала-чага күңелендә җуелмас эрну, югалту эзе калдырды. Барлык кешеләрне вакытыннан элек картайтты бу афәт. Күңелләргә иртә кырау салды.

Бу кырау Актаң бәгырен дә өшетеп узды. Әле кечкенә малай чагында ук ул, аналар зарын күрмәс һәм ишетмәс өчен, урманга качып китәргә гадәтләнгән иде. Үзенең хыялында әллә ниткән батырлыклар эшләп ташлау, тиңсез могҗиза күрсәтеп авылның ирләрен өйләренә кайтару иде. Шундый хыялларга батып ул урманның әллә кай тарафларына килеп чыга. Ә күңелендә әле һаман өметләр, тәкатьсез яхшыга омтылу яши. Йодрык чаклы гына йөрәге һичнидән өрекми бу мизгелдә, кирәксә, зур-зур тау-ташларны актарып ташлар сыман ашкынып китә. Һәм ул малай, мәче баласыдай, бик житез генә биек-биек карагайлар башына үрмәләп менеп китә, шул югарылыктан тирә-юньгә өметле карашын ташлый — авыл ирләре күренмиме, янәсе? Әлбәттә, ул көнчыгышка озаграк төбәлеп тора — ымсынып атасын карый. Ләкин юк, һичкем дә күренми иде шул.

Ә күк, зәп-зәңгәр күк, менә генә кул сузымында гына сыман! Тирә-якта исә кара-куючкылланып торган урман өсте генә. Бер читтәрәк, еракта, авыл шәйләнә. Әйе, монда үзенә бер дөнья. Син инде авылдагы елау-сыктауны да, карурманның шомлы шавын да ишетмисең. Актаңның кул сузымында гына зәңгәр күк,әмма күңел әле тагын дә үргәрәк, биеккәрәк ашкына сыман. Дөрес шул, агач башыннан гына бар нәрсәне дә күреп бетереп булмый. Актау, Каратау сыртлары артында ни булганын да чамаласаң икән!

Һәм Актаң, шуны уйлый-уйлый ярым канәгатьсезлек кичергән хәлендә, биек карагай башыннан җиргә төшә, үзе дә сәбәбен әйтеп бетерә алмаган бер хискә бирелеп, шунда күпмедер вакыт ялгызы елап утыра торган иде.

«Әтием, син кайда соң? Киез кунычлы итегең дә тузгандыр инде. Ә уң як чигәңдәге миңеңне әле танырлыктыр...» дип, күңеленнән генә кабатлап, такмаклап елар иде Актаң.

* * *

Тәмам шуышында йөреп картайган, бар нәрсәгә ияләшеп беткән сукыр кашка урман эчендәге ялгыз сукмактан җай гына атлап килә. Хәер, бу сукмакны ул үзе салган һәм үзе генә таптый да диярлек була. Актаң белән атның бу юлдан ничәнче йөз мәртәбә үтүен бер ходай да исәпкә алмыйдыр, мөгаен. Ялгыз аучы сукмагы бу, башкаларга хәзер аның хаҗәте юк. Сукыр кашка белән аңа бу юлдан тагын, тагын күпме мәртәбәләр узасы бардыр, монда ни-нәрсәләр күрәчәкләрдер, әйтүе кыен.

Дөрес, монда бөтенләй үк ялгыз дип булмый аларны. Әле генә атның борын төбеннән үк диярлек бер көтү болан йөгереп үтте. Дәү мөгезле башларын бик югары тотып, эре-эре сикеренгәләп, нарат, карагайлар арасына кереп югалдылар. Актаң аларны кай заманнан бирле ашата һәм эчертә дигәндәй, тик һаман иялəшми бу кыргыйлар. Ә бәлкем аларның кулга иялəшмәве хәерлерәктер. Әнә бит, иялəшкән ат малының ничек көн күрүе күз алдында.

Алда биек Тәңрекоймасның каракучкыл кыя-ташлары күренде. Бу кыя-таш чыннан да тәңрегә ашкан сыман, бер очы уктай очлаеп күтәрелгән иде. Әмма кешеләрне таң калдырган тагын бер хикмәте бар бу тауның — аның нәкъ угы өстендә, циркач таягының очындагы тәлинкә сыман, бер җ...пәк таш тора. Гасырлар буе шулай дәвам итә, чак эләгеп торса да, егылып төшми икән ул тылсымлы таш.

Ә тау итәгендә табигатьнең тагын бер тылсымы яшерелгән — төбенә һичкем төшеп җитә алмаган бер упкын-кое бар анда. Тау төпкеле. Әйтерсең лә бу тирәгә аяк басарга җөрьәт иткәннәрне сынар өчен, беленер-беленмәс тар сукмак әнә шул упкын белән кыя-таш арасыннан үтә. Табигать үзе яраткан кыямәт юлы шушы буладыр, күрәсең. Бу сукмактан үткәндә хәтта тирә-як халкы «Кыргый болан» кушаматы таккан Актаңның да йөрәге каударлап тибә башлый иде. Андый чакта ул атын еш-еш камчылап, моннан тизрәк узып китәргә тырыша. Тик соңыннан үзенең бу кыланышына үзе дә таң кала: Тәңрекоймасның әллә чыннан да берәр сихере бармы икән соң, нишләп шулай каушата соң әле ул?

Дөрес, авылдашлар, тәгаенлирәк төшсәң, әлеге шул исәр Әсән карт — Арчаның танылган телдәре бу тауга бәйле бик күп хикмәтләр сөйли иде. Актаң инде аның ике әкиятен генә хәтерендә саклый, калганнары кичке әңгердә эреп югала барган кыя кебек, күңелдән юылган иде.

— ...Борын-борын заманда,— дип башлый иде Әсән карт,— бу таулы, урманлы төбәктә бер казах ыруы гомер иткән. Шушында алар ауга йөргән, ишле мал асраган, йорт-кура корган. Иң элек бу тигез, тыныч тормышлы халыкны Алтай аръягыннан чыккан Җонгар явы тынычсызлый. Бу албастылар ыру халкын талап, илне айкап ташлыйлар. Безнең казах, көч туплап, аларны тау артына кабат куып чыгарырга өлгерми — рус сәүдәгәрләренең басып керүе башлана. Алар алдап-даулап ыруны яшәгән җиреннән кысрыклыйлар. Мәгәр ырудашлар үз җир-суларын беркадәр саклап кала. Ә инде аклар белән кызыллар сугышын, ул чакта бик яшь булсам һәм үзем катнашмасам да, яхшы хәтерлим. Бик күп ырудаш һәм авылдашларым ул хәтәр көннәрдә дә билен бирсә бирде, илен бирмәде. Әйе, бик күпләр ул вакытта халык өчен башларын салды, көрәш кырында ятып калдылар. Әмма, ходай саклап, хөкүмәт ил-җиребезне үз канаты астына алды. Ә аңа чаклы халык инде тәмам тинтерәгән иде. Хәтта, әнә шул тыныч кына яшәр җай беткән авыр көннәрдә, тәмам котылыр чара кал-

магач. Казахстанның үзәгендәге комлы далага күчәргә өндәп, шул табан камчы төртеп күрсәтүчеләр дә табылды. Берүк арттан ут, алдан ук, ядрә эзәрләгәндә дә бирешмәде безнең ыру казахлары, шушы җирнең һәр тавы һәм һәр ташына сеңгән ата-баба канын, тирен саклап, илендә кала бирде. Менә чыны да, ялганы да шул, малайлар. Хәлегездән килсә, шул хәлләрне онытмассыз, киләчәккә җиткерерсез, дим.

Шул сүзләрдән соң Әсән карт бер ара кичке алсу шәфәкъка карап эндәшмичә утырды, тел астына бер чеметем насыбай салды. Иске-москыга төренгән Арчалы малайлары тын да чыгармый, түзем генә аның хикәятенең дәвамын көттеләр. Шулчак җилгә каршы утырган Актаңга хәтта ниндидер бер ят ис тә килгән күк тоелган иде. Кайсы дөнья исе булгандыр ул. Аның серенә фәкать бүген төшенде аучы — Әсән карт аша аларга нәсел-ыру исе килгәндер, күрәсең.

— Әйе, әйткәнемчә, авылның бае, ярлысы үзара якалашканда, берәүләр әле ак, әле кызыл булып чуалышканда мин яшьрәк идем,— дип дәвам итте карт бераздан.— Әйе, һичкайсына баш бирми, ау белән көн күрдем. Аннары аклар җиңелде. Рәсәйдән качкан өерләр Арчалы аша ерак чик буена таба сыпырта башладылар. Ул вакытта бу Алтай тауларында барган сугыш-кырылышны сезгә тасвир итәр өчен тоташ өч ай җитмәс иде. Инде аклар тәмам җиңелеп беткәч тә әле күпмедер вакыт Балтабай дигән берәү үз иярченнәре белән безгә көн күрсәтмәде. Арчалыны гына ике мәртәбә камап, җанны-малны аяусыз кырып чыкты. Әй бит халык әле путасын чишеп, билен яза гына башлаган иде.

Ул көздә мин өйгә кача-поса гына төнлә кайтам да аннан таң беленүгә чыгып тая идем. Чөнки авылда юньле ир-ат заты калмаган, Балтабай ишеләрне кызыл гаскәр эзәрлекләсә дә, тиз генә җиңә алмады. Хәер, безнең бу тау-таш арасы, урманнар илле-алтмыш кешелекне генә түгел, күбрәк санлы гаскәрне дә сыендырырлык иде шул. Әйе, кулымда гаскәри мылтык. Каян килгәнме? Кирәккәч, бер качкыннан талап алган идем. Югыйсә, Балтабай башкисәрләренә ышаныч зур түгел. Әйе, бер көнне таң алдыннан Таңрекоймас үткеленә җитеп киләм. Күрәм — тау итәгендәрәк ике ат утлап йөри. Җәнлек ауларга килгәндәй яннарына сак кына атлап якынлаштым. Бер яшь карагай төбендә, мин сиңа әйтим, бик усал кыяфәтле бер сары мыекбай мылтыгын кочып яткан. Ә янәшәсендә — бер мескен кыз бала. Үзебезнең казах кызы. Карагайга бәйләнгән хәлдә йокымсырый бу, ә күз төбендә — яшь эзләре. Күп булса уналты яшьтер үзенә, ләкин йөзен кайгы, сагыш картайткан.

Минем сагаеп тагын бер-ике адым атлавымны ничектер тойды да бу, үз ырудашы икәнемне шәйләп булса кирәк, кычкырам дип ачылган авызын томалады. Сүзсез ялварып миңа карап тора башлады. Миңа ул соңгы өмете итеп, коткаручысы итеп карый иде. Әйе, сезгә бу әкият, ә миңа чын... Хәзер энә чиләк өстендә утырып, сыер җиленен тарткалап маташучы кара карчыгым шул кыз була инде. Әйе, түзмәдем, кызның аккошныкыдай муенын, нечкә билен, калку күкрәген агачка бәйләгән кыл арканны ике-өч урыннан чалып җибәрдем. Ул арада җирән мыегы тирәсендә әле генә ике-өч кара чебен чуалган теге бәндә сикереп торды, як-ягына каранып, мылтыгын эзләргә керешә. Ә ул инде миндә иде, үз коралының үзенә төбәлгәнен күрде дә бу Таңрекоймас үткеленә таба йөгерә башлады. Билгеле, шундук атып та үтерә алган булыр идем мин аны, тик ни өчендер, әлеге тирән упкын авызына гына куалап керттем үзен. Хәтта әле, теге бәндә таш арасына кысылып калган бер мәлдә, артына тибеп булышып җибәрүем дә хәтердә. Ә кызны, әйткәнемчә, авылга алып кайттым, бик озак үгетләгәннең соңында үземә кияүгә чыкты. Шуннан соң теге мыекбайга ни булгандыр, тәгаен әйтә алмыйм.

Дөрес, берничә көн буе ул мәртәтне сагалап тордым әле. Чыкмады, каһәр. Тагын бер ай чамасы күзәткәләп йөрдем — күренмәде. Көзге көннәрнең берсендә үзем ул төпкелгә төшеп карарга ниятләдем. Йөрәк кага, күңел шомлана, малайлар. Әйе, серле Таңрекоймас күңелне өркетә дә, тарта да икән үзенә. Шунда күргән-кичергәнемне сез яшьләргә күрсәтмәсен. Дөм караңгы, мин сиңа әйтим, төн уртасы диярсең. Ә битемә шул төн куеныннан салкын бәрә. Кыя-таш арасыннан тирәнәя барган бу тау куышы нинди серләр саклыйдыр — шуны ачарга комар җан, мөгаен, әле тумагандыр. Чөнки әле берәүнең дә моңаирешкәне булмады. Мин исә... мин ул мәгарәгә кердем, ләкин бик тиз үз дөньяма кайтырга теләп:

— Ачыгыз юлымны, әрвахлар!— дип кычкырдым.

— Синең ише гөнаһлы кешене якты дөнья кабул итмәс. Әйт әле, бәндә, иң Бөек атаң кем?— диделәр серле мәгарә ияләре.

— Аны белүдән миңа ни файда?!

— Әй, мәлгунь, йөрисең син дә казах булып. Үз ыруыңны, үз нәсел атаңны

белмәү хурлык. Әнә Тәңрекоймас угына менеп карар идең, белмәгәннәреңне белер идең шунда. Инде безне тыңла... Әнә, Җиһангир бабаңнар дөньяда иң көчле, иң батыр булганнар. Күрәсеңә.. Таныш. Менә бу бихисап сөякләрнең итен алар ашаган...

— Миңа чын, сезгә ялган дигәндәй, әгәр шунда күргән-белгәннәремне бәян кылсам, кеше-кара һич ышанмас,— дип, Әсән карт тел астындагы насыбаен суыра-суыра, соңгы сүзләрен мыгырданды да тынып калды. Аннары, берара өнсез, сүзсез утырганнан соң, капылт кына урыныннан кузгалып, әллә ниткән бер олысымак кыяфәткә кереп һәм сузая төшеп, якында гына челтерәп, шаулап аккан инешкә таба китеп барды. Аның бу кыланышы бик сәер тоелды малайларга. Ярым сүнгән учак тирәсендә утыручылар шаккатып һәм, хәтта, ниндидер шикләнү, курку тойгысы кичереп, чынында Әсән карт идеме соң бу, дигән бер шик белән аның артыннан карап калдылар. Караңгы урман артыннан исә тагын да очлая, сузая төшкән Тәңрекоймасның сихри шәүләсе калкып, шомландырып торган төсле тоелды. Актаң, шушы сәер хәлдән өркеп, иң беренче булып, авылга карап йөгерде...

Инде ул хәлләргә ни гомер үткән — Тәңрекоймас тау серен, аның кышын-җәен бозлы сулыш өреп торган мәгарәсе серләрен Актаңның әле булса да ача алганы юк. Әсән карт, шәм яндырып, кайчан да булса сез яшьләрне шул упкынга ияртеп төшәм әле, дигән иде дә, вәгъдәсен үтәмичә генә дөнья куйды. Ул үлгәннән соң авыл балаларына инде хәзер картлар гына белгән шәҗәрә серләрен, риваять, әкиятләрне һичкем сөйләмәс булды. Хәер, авылның үзе дә юк ич инде хәзер. Әнә, буш йорт-җир арасындагы Әсән карт биләмәсендә дә көзге суык җилләр генә уйный. Бу авыл балаларына моннан соң аның ише итеп җор сүз, әкиятләр сөйләүче булмастыр инде, күрәсең. Ә Тәңрекоймас сере яши әле, сихри упкын янәшәсеннән үткәндә әле дә әнә чак кына шомландыра да, уйландыра да сыман. Аучы Актаң күңеленә ул балачакның бер сихри дөньясы, сере булып сеңеп калган иде.

Әйе, мондый хәл бары тик балачакта гына була ала. Фәкать шул вакытта гына кеше җиһандагы яхшы белән яманның, ак белән караның чын бәһасын аермый. Чөнки әле ул барлык нәрсәгә нарасый күз белән карый, дөньяны якты итеп күрә — кешенең уйлары да, кичерешләре дә сабыйларча була. Шуңа күрә дә олыгаеп, маңгай тирең түгеп, төрле авырлыклар кичереп яши башлаган көннәр килгәч, сабый балачакның шул аяз күген һаман саен ешрак сагына башлыйсың, шуны эзлисең. Әйе, безнең күңелләрдә саф балачак хисләренә, әкиятләренә һәрчак урын бар, тик бераү дә инде ул көннәрне кабат кире кайтара алмый.

Менә хәзер Тәңрекоймас үткеле буйлап барганда да аны балачак хатирәләре биләп алды ич. Хәтта шул ерак көннәргә хас бер тетрәнү, шомлану хисе дә күңелен кытыклап тора әнә. Әйе, Актаң һич тә Тәңрекоймас тирәсеннән сабыр гына үтеп китә алмый. Һаман да аның күңелен тау итәгендәге әлеге бозлы сулышын өреп торган билгесез упкын җилкендерә, ярсыта сыман. Бу тау итәгенә күтәрелә башлау белән йөрәге лепелдәп тибәргә тотына. Ул Бозтау төпкелен бер кереп әйләнеп чыксаң икән, дигән уй да кайчаннан бирле яши, тик ул хыялын әлегәчә никтер үтәргә генә базмады. Нинди сер ята анда? Әнә бит, мүктәй яшеллек баскан үткел тирәсенә якынлашу белән, дерелдәп туңа башлыйсың. Түбәннән һәрчак суп-суык һава бәреп тора. Ми кайнарлык эссе челлә көннәрендә монда җиләс, җанга рәхәт шул. Күңел бәлки шуңа да сихерләнә торгандыр.

* * *

Тау башына күтәрелгән саен җил көчәя, һава һаман салкыная төште. Актаң ат башын кире борырга да уйлады. Көзнең бу кара, күңелсез көннәрен, аның юешләгән, былчырагын яратып бетерми иде ул. Бигрәк тә бүгенгедәй томанлы урманда үзеңне япа-ялгыз хис итәсең. Бая тарала башлаган кебек тоелса да, агач араларында ул әле дә куе иде. Тиздән кыш җитәр. Ап-ак кырпак кар белән каплап киткән Алтай урманнары күз алмастай булып үзгәрер. Андый көннәрне Актаң, табанына колын тиресе кадакланган чаңгысын киеп ала да ауга чыга. Төлке, тиен елдан-ел ишәя бара. Авыл халкы күчеп киткәч һәм кош-корт, мал-туарның кычкыру-мөгрәүләре тынгач, киек-җәнлекләр, кошлар ирек алды, үрчи төште. Тик бер нәрсәгә гаҗәпләнә Актаң — соры тычкан никтер юкка чыкты әле. Аның

эзләрен элек Арчалының каралты-куралары тирәсендә дә бик еш очрата иде. Инде аларның күренмәвенә ике кыш. Агач төпләреннән дә караштыргалады — ник берсе күзгә чалынсын. Әллә аларны өченче җәй май уртасында явып киткән кар юк иттеме, әллә үзләре берәр төрле бозлавык яки бүтән каза буласын сизенеп качтылармы — белмәссең.

Үз иркенә куелган сукыр кашка инде күптән авыл сукмагына төшкән иде. Актаң, шуны искәреп, атны ерак Күккүл ягына борды. Томан эчендә чак шәйләнгән кояш табагы уңдарак калды. Әле бая ап-ачык күренеп торган Актау белән Каратау, берәрсе урлап киткән диярсең,— тәмам күздән югалган иде. Инде тау елгасының шат өне дә тоныклана төшкән, ераклашкан иде. Хәтта Акболакны да куе томан каплап, шавын баскан, күрәсең.

Актаң, туган йортына ашыккан кебек, сагындырган Күккүлгә таба юырттыра бирде. Күккүл — үзенә бер ят дөнья шул. Утыз еллар әүвәл бу күл тирәсендә дә тормыш гөрләгән: тауның Себер битләреннән килгән халык та, казахлар да яшәгән монда. Техникасыз заманда, кул көче белән, көрәк тә кәйлә белән җир куеныннан мәгъдән казып алганнар, сыңар тәгәрмәчле кул арбаларында шуны күл буена ташып юа торган булганнар. Аннары йөзләгән пот вольфрамны дөя өркәчләренә асып, еракларга, мәмләкәтнең үзәгенә таба озатканнар. Әлбәттә, боларны Актаң күреп белми. Хәтта ул күлнең икенче яры чит дәүләткә караган бу чик буе мәгъдән учагында атасының нинди хезмәт башкаруын да тәгаен белми. Чөнки бу бистә, бик тиз оешкан кебек, бик тиз таркалып та бетә. Бары тик аның корылмалары гына күл буенда моңаеп утыра бирәләр. Хәзер бу хәрабәләр Күккүл белән Актаң өчен үзенә бер истәлекле урын гына. Аучы монда шатлыклы һәм кайгылы мизгелләр кичерә. Онытылып барган шушы дөнья белән өч-дүрт атнага бер очрашуны куанып көтә дә кебек. Күз алдында җан биреп, тәне суына башлаган танышы алдына килгәндәй, монда һәрчак сәерсенеп, сагаеп та калган сыман тоя ул үзен. Кайчандыр кешеләр шау-гөр килеп яшәгән, тормыш кайнап торган матур күл буе, югыйсә. Мөгаен, әле үткән заманның ерак хатирәләре аны ирексездән шушы күл буена тартадыр да. Бәлкем шушы үксез бистә, үксез язмыш белән үз язмышы арасында ул нindидер охшашлык, уртаклык та тоядыр. Шуңадыр, күрәсең, иң ·боек, иң сагышлы көннәрендә аңа Күккүл буе бер сердәше кебек була. Нindидер өмет җепләре өзелгән саен хәрабәләргә тартылуы арткан сыман тоела.

Әйе, җан иясе әлеге дөньяда гел көлеп, уйнап кына яшәми, сагышланган, хәтта төшенкелеккә бирелгән вакытлары да булгалый аның. Кешегә көлми дә, еламый да яшәү һич хас түгел. Тик шулай да гомер сагышларын Актаң кебек бик тирәнтен кичергән, ара-тирә булса да үз кыләчәген, үз язмышын Күккүл буе хәрабәләр белән тиңләп, авыр хисләргә бирелгән кеше сирәктер шул. Хәер, кешеләрнең күпчелеге ялгыз аучы Актаңны да, Күккүл язмышын да белми һәм белергә дә теләми булыр. Ә Актаң үзе аларны яхшы беләме соң? Юк, әлбәттә. Чөнки кешеләр белән бик сирәк аралаша, газета укымый, радио тыңламый, киногa йөрми диярлек. Бөтен көндәлек тормышы аның үзе өчен генә яраклы кануннарга буйсынган, япа-ялгыз киекнеке кебек. Юк, бөтенләй үк кеше арасында булмый дип раслау килешеп бетмәс. Хәзер дә исенә келт итеп совхоз утары Өреледәге кибет килеп төште. Шундагы кирпечкә охшаган радиоалгычны сатып алырга ничә омтылды. Тик, «Эткә тимер ник кирәк?» дигән уй белән ниятен үтәми килде. Ансыз утыз ел гомер ителгән, тагын шуның кадәрене дә шәт транзистор тыңламый уздырыр әле дип, үз-үзен юата иде. Киң дөньяда ниләр булганын ишетми-күрми җитмеш ел буе гомер кичергән әнисе, әнә, яши ич. Әйтсәңче, Әзимбай дигән берәүнең анау Алма-Атада аспирантуралар бетереп кайткан улы Каһән әллә Актаңнан артыкмы? Һич юк. Хатыны белән балаларына көн күрсәтми, һаман эчеп-исереп йөргән, инде райүзәктән дә эштән куылган һәм очраган берәүдән: «Баш чатный, малай, түзеп булмый, бераз акча биреп торчы»,— дип сoранып көн күргән кешедән ни өмет!? Хәзер Өреледә клуб мөдире исәпләнә бугай үзе. Алимент хакына эшлидер, күрәсең. Йөри шунда, мәгънәсез җан, эттән кадерсез булып. Биек-биек затлы йортлар, затлы машиналар арасына кереп шул шөкәтсездәй адаштың ни дә үзеннән урман-таулардан гайре берни күрми, шушында гомер иттең ни. Кем белә, моның кайсысы аяныычрактыр. Һәрхәлдә, Актаң ул «ил гизгән, дөнья күргән укымышлы» мөртәтне һич өнәми. Шул тинтәк, шул сәләмә баш әле, җитмәсә, Айгөл тирәсендә бөтерелә икән, муенын бәреп сындыргыры. Үпкәсен авызына китерәсе җан. Ачуын бик чыгарса, Актаң аны шулай бер ботарлап ташлар да әле.

Айгөл!

Актанның Алтай тау-урманнары аксыл томаны эченнән күпме эзләгәннен соңында табылган ак болашы ич син. Төбе төшкән чиләктәй бушап калган күңелнә яңадан җан өргән, тансык язгы җылы җилдәй рәхәтлек биргәне бит син. Сине искә алу белән үк моң-зарлары тарала, сагышлары яктыра сыман. Үз-үзен онытып, әйтик, кавыша алмаудан тингерәп, урманнар гизеп, таулар кичеп йөргәндә, син җибәргән берәр китап коштай очып килеп төшсә, куанычның чиге булмый. Аучы ул кирпечтәй калын китапларны, һич укып чыга алмаса да, гел үзе белән йөртә, чөнки аннан фәкать Айгөлгә генә хас тәмле-татлы бер якынлык, сөенкелелек бөркелэдер шикелле. Көз башында соңгы мәртәбә очрашуларын Актан әле дә онытмый. Айгөл китапханәдә япа-ялгызы утыра иде. Баеп барган кояшның алтын нурлары ачык тәрәзәдә уйный, кызның буй-сынына төшеп, аны да ямьләндереп, йөзен ачып җибәргән иде. Актанның ашыгып килеп керүенә кыз әһәмият итмәде, сәламен дә алмады: әллә ишетмәде, әллә теләмәде. Аучы исә, кызга озак тилмереп карап торды-торды да капылт борылып чыга башлады. Шунда гына Айгөл аның артыннан: «Актаң! Актаң!»— дип кычкырып калды. Әйе, беренче мәртәбә аңа шулай исеме белән эндәштеләр. Әмма ул моны — үз итеп эндәшүме, әллә юкмы — төшенә алмады: чөнки бу Айгөл — өне дә, түгел дә иде. Бәлки, һич күңегелмәгәнчә, сискәндереп үз исеме аталуны шулай кабул иткәндер ялгыз аучы. Аңа ул вакыт бу аваз, «кил» диюдән бигрәк, «кит!» дигәнне төшендергәндәй тоелган иде. Һәм хәзер дә әле шул мәгънәдә колак төбендә яңгырап торадыр шикелле.

Соңыннан Айгөл дә, бәлкем, шушы тунбаш егетнең күңел дөньясын аңлый алмавына интеккәндер, төн йокыларын калдырып шул хакта пошынгандыр. Ә инде алдан уйлап, суык акыл белән аны биздерү ниятеннән эшләнгән эш булса, бик аяныч, әлбәттә. Тик шунысы хак: кызның аңа башка суккандай, үз исемен әйтеп кычкыруы һич күңеленнән китми. тик кабат ул тирәгә барганы юк иде. Айгөл шундук әле арттан чыкса икән...

Шуннан бирле инде ике ай вакыт узды. Бәлки кыз күңеле көн дә шул тирәдә чуалган теге «укымышлы» исерекбаш Каһәнгә «җепшегән»дер. «Иркеңне аңа биреп, аракыдан сасып йөргән ул оятсызны үз тирәңдә бөтерелдерсәң, капкаң да кызарыр. Син шуның ятьмәсенә эләгеп харап булма. Актанны чынлап югалтуың бар».

Актан җәй көне беренче очрашуларын исенә төшерде. Кыз аңа:

— Нишләп сез китап укымыйсыз?— дип сүз кушты. Аучы ни әйтергә белми, бер ноктага карап уйланып утыра бирде. Тик берникадәр вакыттан соң гына күзен кызга текәп:

— Айгөл, әгәр мин шушы китапханәдәге барлык китапны укып чыксам, мөгаен, бик үзгәрер идем,— диде.— Бәлки акыллырак һәм хәйләкәррәк булыр идем. Минемчә, китап кешенең күңел күзен генә ачмый, аны чиктән тыш нескәләндерә, хәйләгә дә өйрәтә. Ә минем әлегә китапча гына яшисем килми, китапча уйлый, көлә, сөя белмим. Үземчә, үз белгәнемчә яшисем, көләсем, сөясем килә. Һәм минем шул иркемә, теләгемә һичкем кул суза алмый!

Айгөл, әлбәттә, аптырап калды. Аулакта ялгыз яшәүче аучыдан ул мондый җавап көтмәгән иде.

— Алайса, үз-үзегез өчен генә яшәргә ниятлисезме?— диде кыз, никтер куркынганрак төстә.

Актаң кызны тагын баштанаяк күздән кичерде. Айгөл, уңайсызланып булса кирәк, йөзен читкә борды.

— Әйтче, кем кеше өчен яши? Үзе өчен яшәүдән кемнең ваз кичкәне бар?— диде аучы күзеннән ут чәчеп.

Әйе, танышулары аучы мәргәннең кирпеч-кирпеч калын китаплар ала башлавы да шуннан башланды.

...Китапханәнең ишеген каты итеп ябып чыкканнан соң, Актаң ул көзге кичтә юл өсте генә кибеткә сугылды. Анда Җәсирә исемле тол киленчәк — трак торы астында калып үлгән дустының хатыны сату итә. Шуның сәбәпле, ул монда үз кеше, хәл-әхвәл белешми китми иде. Актаң ишектән икегә бөгелеп килеп кергәч тә, Җәсирә аны эчтән яктырып, үз итеп көлемсерәп каршылады. Җәсирәнең, гомумән, күзе-кашы, йөзе болай да янып тора иде. Әмма Актаң аның үз итеп, елмаеп каршылавына әһәмият бирмәде, хәл-әхвәлен генә сорашты. Бер йотым шәраб сорап алып, шуны капылт кына эчеп куйды. Аннары:

— Кара аны, елтыр күз, монда бик кыланма,— диде.— Минем дустым исеменә тап төшермә, ике баланны рәнҗетмә.

Җәсирә аучы кулыннан ычкынырга ашыкмады, беләген тартып алмады, түзде. Аннары бер дә аптырап тормастан:

— Алай-болай шаша башласам, башкага хур булганчы, үзеңә җим булырмын,— диде. Дустың, исән булса, мөгаен, үзе дә кичерер иде. Ул сине миннән дә артыграк күрде, гүй.

Аучы, моңа ни әйтергә белми, читкә тайпылды. Аннары, озын аягын сузып, сатучы өстәленә сөялеп:

— Тагын салып бирсәнче?!— диде.

Җәсирә исә чак кына моңсуланып, җитдиләнеп, үткәнне искә төшереп алды.

— Хәтереңдәме, Актаң,— диде ул,— без сине «Кыргый болан» дип атаган идек. Шуннан соң бөтен яшьләр, соңрак совхоздагы барча адәм сине «Кыргый болан» дип ирештерә башлады. Чөнки синең бөтен йөреш-торышың, холкың бераз кыргыйрак бит. Хәзер дә шундый. Нишләп соң әле сиңа кеше арасына монда күчеп килмәскә, яңа тормыш учагы кабызып җибәрмәскә?

Бу сүзләр һәм ач карынга эчелгән бернichә йотым әче аракы «кыргый болан»-ның башын тәмам әйләндерде бугай. Бераз төксе генә тыңлап торганнан соң, китапханәдәге хәлләрне дә күңеленнән кичереп, ахрысы:

— Син дә, Айгөл дә, башка берәрегез дә, бөтен авыл, аңламыйсыз мине,— дип ачынды ул.— Чит-ят сез барыгыз да миңа, төшенмисез күңелемдәгене. Таулларымны ташлап айга бер авылга төшәм, айга бер аракы авыз итәм, шуны да күпсенәсез. Син дә шулай... кыргый дип, ау белән көн күрә дип көнләшүеңме, кызгануыңмы... Затлы җәнлек аулап, тире сатуым хак... Ә кемем бар? Атам язмышы билгесез, анам хәле аяныч. Үземнең ике аягым да ике кулым... Тик барыбер берегезне дә... шушы ике кулдан... ычкындырмам... Ишеттеңме?..

Күпмедер шулай үзалдына сөйләнеп торганнан соң, аучы егет сөялгән җиреннән идәнгә шуып төште һәм шунда йоклап та китте. Кибетче бу хәлгә башта аптырап калды: берәрсе килеп керсә, юк-бар гайбәт бик тиз таралыр. Әмма «Кыргый болан»ны, озын сыйрагыннан сөйрәп, урамга чыгарып та ташлый алмый иде ул. Хәтта бөтенләй чит-ят кешегә дә алай рәхимсез кагыла алмас иде Җәсирә. Актаңның айнырлык чамасы күренмәгәч, ул үзенең җәйге пальтосын аның өстенә алып килеп япты да, чак кына иртәрәк булса да, кибетен эчтән бикләп алды. Кешене ялгыз ташлап китә алмый ич, егетнең йокы аралаш мыгырдану, теш шыгырдатуларын тыңлап боегып бик озак утырды, алҗыды. Тәмам куе төн җитүенә дә карамастан, аучы һаман исенә килә алмый, я саташкалап, янсә буылып хырылдый-хырылдый йоклый да йоклый иде.

Актаң таң беленгәндә генә уянып китте. Төне буе аны сагалап чыккан Җәсирә исә өстәлгә башын куеп кына изрәп йоклап киткән иде. Аның һәрчак ягымлы, түгәрәк алсу йөзе сулган, аңа саргылт шәүлә кунган, авызы балаларныкыча ачыла төшкән иде. Ул, ахрысы, берәр төш күрә иде: ара-тирә йөзе яктырып китә, ирене, нидер әйткәндәй, кыймылдап-кыймылдап куйгалый. Кем белә инде, үлем яшьли аерган тракторчы ирен исенә төшерүедерме, «Кыргый болан»га нидер әйтеп шулай елмаюы булгандырмы...

* * *

...Аучы егетне бу хатирәсеннән каршыга килеп чыккан ике дәү болан үгезе аерды. Бик симезләр, бер дә ялыкмаганнар, мөгаен, ябулы яткан маллардыр. Әйе шул, икеме-өчме боланның киртәне кыйратып качканлыгы аңа да ишетелгән иде. Димәк, шулар. Әнә ничек уйнаклап, горур сикеренгәләп баралар. «Әһ, атып алсаң үзләрен! Һичкем белмәс, ә күпме симез сугым булыр иде. «Аучы, шулай уйлап, үгезләр артыннан кызыгып карап калды. Мәгәр үзенең алай эшләмәсен дә белә ул. Хайваннарны да аяу кирәк. Өстәвенә, әле болар, кешеләр кебек үк, ирекә сусаган — киртә җимереп чыкканнар ич.

Урман эчен куе томан каплаган иде. Кояш бөтенләй күренми диярлек. Аяк асты да, Актаңның киеме дә, Сукыр кашка тәне дә лычма су булган иде. Ат инде арый да башлады ахрысы, ешрак тая, бигрәк тә үр төшкәндә шуыпшуып алгалады. Ниһаять, агачлар сирәгәйде, сукмак аларны ачыклыкка алып чыкты. Алда җәйрәп яткан Күккүл өстендә томан сыеграк кебек, аны җил тарата иде, күрәсең. Яр буенда кыя-ташлар, мәгъдән белән чыгарылган җир өеме, иске корылмалар күренде. Элек эшчеләр яшәгән озын барак караеп бер читтәрәк утыра. Актаңга ул күзгә күренеп чүгә төшкән сырхау дөя үркәче шикелле тоелды. Ишек тәрәзәләре ачык-тишек бу зур агач өй хәзер ярканатлар оясына әверелгән иде. Беркөнне тирә-якка шом салып, аллә йөзләгән шул шөкәтсез җан берьюлы чинап кузгалып, аучыны чак кына бусагадан бәреп төшермәде. Вакыт бик тә

рәхимсез, дип уйланды Актаң, җимерек хәрабәләр арасыннан мәгъдән учагы авызына якынлашканда. Ул шунда аты белән кереп китәргә ниятләгән иде, әмма сукыр кашка никтер карышты, җир куышына кермәс булды. Аучы аны шунда ялгыз карагай кәүсәсенә бәйләп калдырды да, камчысын тотып, эчкәре үтте. Монда ярым караңгы, шомлы иде. Мәгәр ул, йөрәге кагуга да карамастан, анда-санда аунап яткан эре мәгъдән кантарларына абынгалап, ярыйсы ук эчкә керде, җир асты юллары берничәгә аерылган урында гына тукталды. Бу тар юлларның берише, мөгаен, сихри Тәңрекоймас астына ук барып тоташадыр әле... Болай йөрү, әлбәттә, куркыныч, кирәкмәс бер тәвәккәллек уены гына иде. Чөнки җир асты юлларының терәк баганалары инде ышанычсыз, өстенә катлам ишелүе дә ихтимал. Мәгәр, никтер күңеле шушында тарта, әйдә әле, керик, нинди серләр бар икән анда дип котырта. Актаң, аяк астындагы коры-сары, йомычка җыйнаштырып, бер яссы таш өстендә учак ягып җибәрде, һәм, өс-башын бераз кипшендерү нияте белән, утка якын ук барып чүмәште. Җир куены караңгылыгы чигенә төште, ут шәүләсе якындагы җир стенада, аның ярыкларында, түшәмне күтәреп торган терәкләрдә уйнарга керешге. Җылы рәхәтеннән оеп, аучы кабат үзенең бетмәс уй-хатирәләренә чумды. Инде ул кай тарафтандыр ишетелеп калган ниндидер авазларга да әһәмият итмәде. Хәер, сукыр кашка шулай тынгысызлана дип юравы булгандыр.

Ә күңелендә — үксез үткән балачак хатирәләре, кысыр хыяллары җанланды. Китапханә ишеген кирза итеге белән гөрс итеп ябып чыгып китүен хәтерләде. Кайсы соң моның мәхәббәт? Билгеле, атасы алай сәер рәвештә югалмаса, анасы башкалар кебек «улым, балам» дип аралашырлык хәлдә булса, Актаң да укуын ялгап китәр — хәзерге кебек авыр хискә бирелеп, миен җәзалап утырмас иде. Кеше белән сөйләшмәвенә бүген төп-төгәл ике ай. Хәер, аңа бу ике ай үзенә бер дәвер кебек, мең көн, мең ай кебек тоела башлаган иде инде. Үз гомерен кайта-кайта күңелдән кичерүләрен бергә кушсаң, мөгаен, әле шулай килеп чыгадыр да. Көне-төне ялгыз башы ич, вакыт-вакыт үзе белән үзе сөйләшә, бәхәсләшә башлый. Бу хәлне үзенчә Актаң белән «аучы бәхәсе» дип атый. Әмма, ни генә дип атама, үз-үзеңне алай даулап җиңә аласыңмыни? Әйе, кешенең бер заман тынгылыгы бетә, «Ни җитми? Нишләргә?» дип үз-үзен туктаусыз бимазалый башлый икән. Картаюмы әллә? Мәрхүм Әсән карт бу очракта ни дияр иде икән?

Актаң, исенә килеп, ярым-ярты янган учакны рәтләп җибәрде. Бая гына туңган дөньясы тәмам җылынып, киеме дә ярыйсы ук кипшенә башлаган иде. Бары тик җилкә уртасы гына өшүдән һаман чемердәп, язылып китә алмый әле. Ул утка арты белән борылып утырды. Ни уйлый иде соң әле? Ә... Әсән картны. Әгәр ул терелеп монда килсә, ни кызык сүз табар, ни сөйләр иде икән?

— ...Безнең бабаларыбызның берсе найман ыруыннан Мәметек би булган икән,— дип сөйләгән иде ул бервакыт.— Үзе тиңсез бай, үзе батыр да, бик хәйләкәр, акыллы да булган, ди. Безнең бу тирәләргә ул казахлардан гайре һичкемне аяк бастырмаган. Ят халык хәтта Күрчем үткеленә дә якын килә алмаган. Бервакыт ул нишләптер Умбы шәһәренә барып чыга. Анда ак патша исеменә язу язып, егерме биш еллык килешүгә мөһер суктырып кайта. Чөнки ат-елкысы бик күп булган имеш моның. Көтү-көтү атлары берьюлы төшеп су эчә башласа, инешелгалар бер мәлгә агудан туктап кала икән. Килешү төзеп кайтып, күпмедер торгач, безнең тауларга бик зәһәр кыш килә, кар да күп була. Мәметек бинең көтү-көтү маллары меңәрләп кырыла. Арчалы картлары: шул кышта бинең алышып атланыр аты да калмаган, дип әйтә иде. Үзе өчен генә Текеш дигән икенче байдан барып алмакчы булган — тегенең тәкәбберлеген ошатмый кайтып киткән имеш. Җитмәсә, бу Текешнең мең елкысы арасында мин менәрдәй бер чапкы аты да юк икән, дип тегене хур итеп киткән. Шуннан би озак аптырамый, кыйблага карап, Мәккәгә, хаҗга китә. Дөнья күреп, күп гыйбрәтләр ишетеп, хаҗи булып та кайта бу. Шуннан би үз якыннары белән Арчалыдан күчеп китмәкче була. Имеш, каядыр карлы таулар артында кыш булмый торган Таиланд дигән бик гаҗәеп җир бар, анда ел әйләнәсе ямь-яшел үлән үсә икән. Атка төялеп илле ир чыгып китә болар. Бик батыр, бик түзем булалар, шуңлыктан эзләп табалар әлеге матур илне. Ерак җир ошый боларга, киләсе язда бөтен ыру белән шунда күченергә карар бирәләр. Ләкин әллә бәхеткә, әллә үкенечкә — ыруыбыз анда күчә алмый кала — бабабыз Мәметек би үлеп китә...

Әсән картның бу хикәяте кай ягы беләндер бүген Актаң хәләтенә туры килеп тора сыман. Шулай булмаса, ул хәтергә төшәр идемени? Әсән карт сөйләгән чын булып, авыл күптән мәңге җәй иленә күченеп киткән булса, ул соң кайсы

якны үзенең ата-баба җире дияр иде? Ниндиләр ерак Таиландка барып җитмәсәләр дә, Өрелегә күченүләре хак. Анда бармыйм дип карышып караган Әсән карт үле ды китте түгелме соң? Укытучы улы аңа: «Буш авылда калып мин сине укытыммыни?» — дигәч, Әсән карт җавапсыз калган. Бер елдан соң аны Арчалы кырына китереп җирләделәр җирләвен. Тик юаныч бирә аламыни бу?!

* * *

Нәрсәдер кышгырдап куйдымы, әллә болай гына күтәрелеп каравы булдымы Актанның — тышкы дөньяның ап-акка төренүе күзенә чалынды. Әллә кар ява башлаган инде? Көннең кай вакыты икән соң әле? Сукыр кашка нишли икән анда? Тынычсызланмый шикелле, бер дә тавышы ишетелми. Аучы бер кузгалмакчы булып та талпынды, тик җылы учак яныннан һич китәсе килмәде, монда рәхәтрәк иде. Йомычкаларны рәтләбрәк җибәрде дә тагын үз-үзе белән сүз көрәштерергә кереште.

**Актаң «мин»е:** Әй син, болай утырып инде сөремләнеп барасың түгелме? Күпме яшәп, тормыштан ни алып, ни бирдең?

**Аучы «мин»е:** Болай ялгыз утыруның мәгънәсе югын үзем дә беләм. Ләкин меңләгән кеше арасында яшәп тә, үзеңне ялгызак сизүең бик ихтимал гуй. Адашам дигәнең, кулына көндез шәм тоттырып җибәрсәң дә, юл тапмас, диләр. Әйе, бу тормышта әле биргәнем булмаган шикелле, алганым да чамалы. Хәзер үз-үземне югалта баруым да рас, тик мин Әсән карт сөйләгәннәрне әлегә онытмыйм, ә башкалар әнә оныттылар. Димәк, әле тәмам югалып бетмәгәнмен.

**Актаң.** Ул әкиятләргә үзең ышанасыңмы соң? Алар буш хыял гына түгелме соң? Күз нурым, төшеңдә ни күрсәң, шул тормышка ашкан чорда яшибез ләбаса. Әсән карт әкиятләренең бүген хакы бакыр биш тиен ләбаса, тоямсың шуны?

**Аучы.** Рас әйтәсең. Кайбер кыйссаларны Әсән карт белән икәү генә үз итүебезне дә күптән чамаладым. Тик мин монда һичбер ахмаклык таймыйм. Кеше укыпмы, яисә кемнәндер ишетепме, яхшы белән яманны аерырга юл ача икән, димәк инде ул ахмак түгел. Әсән картның бабабыз Мәметек би турындагы хикәяте дә минем өчен бик гыйбрәтле. Һич кыш булмый торган, чәчмичә дә ел әйләнәсе иген үскән оҗмахтай җирне эзләп өч ел буе каңгырып йөрү әле ахмаклык түгел, минемчә.

**Актаң.** Ә минемчә, бабаларыбыз Мәметек би артыннан күчсә, бу чын ахмаклык булыр, без казах ыруларының берсен югалтыр идек. Алтай ярты ел кыш хакимлек итсә дә, — үз илебез. Халкыбыз монда гасырлар дәвамында күнеккән, җайлашкан инде. Үзең дә, буш фәлсәфә, картлар әкияте белән юанмый, буыннарында көч-куәт барында авылдашларың артыннан күчәр, кешеләргә файдалырак берәр эшкә керешер идең.

**Аучы.** Кайда эшләү файдалырак булуын кем әйтеп бирә ала? Минемчә, дөньяда иң файдалы шөгыль — дөньяда мәңге яшәргә килмәгән үзеңдәй кешеләргә һич тә хыянәт итмәү. Өрелегә күчү — кеше арасында булу, күп төрле яхшы һәм яман холыклар белән аралашу ул. Билгеле, анда дусны гына түгел, дошман кешене дә очратачаксың. Кемдер синең уңышыңнан, тормышыңнан көнләшми калмаячак. Андый бәндә белән әйткәләшми, талашмый да булмас, мөгаен. Үзең әйтмешли, көч-куәтем әлегә җитәрлек, кешегә гозерем төшми. Дөньям иркен әлегә.

**Актаң.** Хаклымы, түгелме икәнлегеңне киләчәк күрсәтер. Әлегә синдә балалык аңкаулыгы бетмәгән. Үз эчеңә бикләнеп, ялгыз яшәүне кешеләргә хыянәт итмәүгә исәплисең. Ә алар синең ул тормышыңнан көләләр. Аңсыз җанварга тиңлиләр үзеңне. «Кыргый болан» кушаматы такканнар. Тикмәгә түгел бит бу. Дөрес, кемнәрдер, мөгаен, син аулаган затлы җәнлек тиреләренә, байлыкка кызыга торгандыр да. Ләкин аларны да синең япа-ялгыз көн күрүең кызыктырадыр дип раслыйсам, күзем чыксын әгәр. Берише хәтта: аучы тәмам кыргыйланган, атналар буе байгыш анасын ташлап, югалып йөри икән ди. Яше утыздан ашып барган ир энеме соң ул, янәсе. Ирлегенә шикләнеп караучылар да бар гуй. Ә син, әкиятләр белән мавыгып, дөньяңны онытып, беркемгә «хыянәт итми» яшәргә телисең. Юк, замандашларыбызга хас фәлсәфә түгел бу. Егерменче гасырның икенче яртысында яшәүчеләр ул әкияти үткәннәрдән күптән арынганнар, кыргый чор узылган. Хәер, табигатьнең үзендә дә аулар лык киек тәмам бетүгә баруын аучы буларак беләсең гуй. Әйе, гыйлем заманасында әүвәлге өмет, юануларга урын калмый бара...

Актаң үз күңелендә барган менә шушы бәхәстән соң авылны бик сагына башлады. Элек һич тә алай булганы юк иде әле. Кибеткә йомышы төшсә яки совхоз идарәсеннән акча аласы булса гына, сукыр кашкага ияр сала иде. Ә кичәле-бүгенле ул төне буена йоклый алмады. Күккүл янәшәсендә бугазына кыларкан салган билгесез бәндә белән саташып чыкты. Күзе эленергә өлгерми, я буыла башлый, я тегенең аянычлы тостә: «Сак йөри күр... Тау токтыны булма... Тау ул — төрмә»,— дип кисәтүләрен ишетә дә тагын уяна, тагын уйлана, борчыла, тынгысызлана. Ике төн инде менә аксыл томан эченә кереп югалган өрәккә мылтыктан ата. Ләкин һич тидерә алмый. Арчалының иң оста мәргәне дә димәссең. Ә бит чынында ул күз күреме ераклыктан кошның бәбәгенә тидерә ала.

Менә шушы хәлләрдән соң ул, әнисенең ризалыгын алып, Өрелегә төшеп менәргә булды. Көн бүген дә болытлы, кар белән яңгыр аралашып ява, җил үзгәреп торучан иде. Аяк асты пычрак, ат тоягы тәмам батып китә. Актаң каерылып тагын бер мәртәбә дымланып каралган йорт бурасына, түбәсе җир-балчык белән генә капланган келәткә күз ташлады. Әйе, бу бушлыкта ул да әнә теге ялгыз ала карга гына каркылдап йөри шул. Ә каргага ни: аны-моны табып, тамагын туйдырып алса, каркылдап оча бирә. Җәйнең бүз тургайлары түгел инде алар, берәү дә тансыкламый. Әллә бар алар дөньяда, әллә юк.

Дөрес, көн генә түгел, Актаң күңеле дә төксе, болытлы, шуңадыр инде, әнә, уй-фикере дә күңелсез, тискәре бүген. Табигатьтә ала карга да кирәктер, ә менә тормышта Актаң ишеләргә урын бармы икән соң? Буй җитеп, ир-егет булганның соңында да ак белән караны, яхшы белән яманны аера белмәгәннәргә? Әллә моның өчен, аучы кебек, үлем белән яшәү чигендә адашып йөрү хаҗәтме? Әйе, битараф булмый, һәрдаим уяу, алга карап эш иткән генә чын кеше саналадыр, күрәсең. Алга карап эш итү, фикерле белү фәкать кешегә генә хас сыйфат. Шул сыйфатны югалту — кыргыйлану түгелме?.. Рас, кешелек сыйфатлары моның белән генә чикләнми...

Сукыр кашканың сабыр адымына җайлашып, шушындый тынгысыз, аяусыз уйлар бәрелешендә юлның байтак өлешен узды Актаң. Аннары күз алдына Өреле хәлләре килә башлады. Янып торган карашлы, сүзгә чая, төскә матур Җәсирәнең яңгыратып көлү авазы, сөйләшү рәвешләре балкып чыкты. Чибәрлеккә аннан да чибәррәк Айгөл генә никтер бүген тонык күренде.

* * *

Авыл, үзгәрмәсә дә, бик моңсу тоелды. Урамда ник бер кеше очрасын, яу килеп, барысын да кырып-бетереп киткән диярсең. Тар урамнан үткәндә аучы фәкать аратирә тәрәзәдән кызыксынып карап калган башларны гына шәйләде. Сиракмирәк корсак асты йоннары пычракка әвәләнеп беткән этләр чәңгелдәп, сирәк юлаучыны озатып кала. Дөрес, Өреленең әле бер, әле икенче очыннан сыер мөгрәүләре, анда-санда киленчәкләрнең чиләк шылтыратулары да ишетелгәли. Морҗалардан сыек төтен бөркелә. Димәк, тормыш дәвам итә.

Совхозның бүлекчә идарәсендә дә баш бухгалтердан гайре кеше юк иде. Ул Актаңга маңгай астыннан гына сөзеп карап алды. Аучы, киез кадаклап җылытылган ишекне ябып, туктап калды. Бүлмә кечкенәлеге белән дә, тәмәке төтененә ысланып, каралып беткән стенасы, ишек-түшәмнәре белән дә берәр авыл мунчасын хәтерләтә иде. Чөнки ир-атның эше булганы-булмаганы да иртә-кичен монда җыела, туктаусыз тәмәке төтәтәләр. Бүген монда һичкем булмаса да, шул тәмәке сасысына тончыгырлык иде. Баш хисапчы (Бух!) башын күтәрми генә аңа:

— Я, ни йомыш? Хатын-кызны аздырырга йөрисеңме?— дип эндәште.

Бу карсак буйлы, озын муеклы ир уртасы кеше башкалар белән һәрчак шулай чеметкәләп сөйләшергә ярата иде. Актаң аңа ни дип тә җавап бирми, кыр якка караган тәрәзә каршына барып утырды. Инде кич якынлашып килсә дә, беркаяда ут алынмаган икән. Ә бүлмә, сасы исенә чыдасаң, бик җылы иде. Бух исә, кулындагы каләмен бер читкә куеп, утырган килеш кенә киерелгәләпсузылгалап алды. Аннары авызын зур итеп ачып иснәде дә:

— Ник эндәшмисең? Авызыңдагы мәрҗәнең коелыр дип шүрлисеңме әллә?— диде.— Тәмәкең бармы? Югыйсә, авызыңа төкерим, бу кәнсәгә килгән берсе мине талый.

Шулай сөйләнә-сөйләнә ул Актаң сузган «Прима»ны авыз читенә кыстырды.

— Шырпымны да кесәләренә тутыра, оятсызлар.— Ә үзе, тәмәкесен кабызуга, Актаң шырпысын сырмасының ян кесәсенә салып та куйды.

— Я, батыр, тауларда ни яңалык? Киек-җәнлек күпме урманда? Миңа да бер бөреклек өлеш чыгарасыңмы инде? Яхшылыгың җирдә калмас. Ун ел буе акчаңны аз чутламадым. Һәр тиенең өчен күз маемны түккәнне беләсең.

Актаң беркадәр аптырабрак, ни әйтергә белми, аңа карады. Бухның әле сүзе бетмәгән икән.

— Әйтче, чынмы ул, күп итеп мумия даруы тапкансың имеш. Арчалылар бик мактыйлар бит аны.

— Табуым рас. Тик шулмы ул, әллә башка берәр нәрсәме, аныклыйсы бар.

— Үземә бир, агын-карасын аерып, сортлап, дигәндәй, кулланырмын.

— Яңа һөнәр үзләштермәкче икәнсез алайса.

— Әй, авызыңа төкерим, ни кыенлыгы бар дисең аның. Тел өстенә салып суырып карадың — беләсең гуй. Ай-яй, үзеңдә ни генә юк. Боланның теге көч өсти торган нәмәстәкәен дә киптерәсең, имеш, диләр. Чын булса, ала килер идең, югыйсә җиңгәң зарлана башлады, ха-ха!— дип, һаман чегәнләнүен белде мыекбай Бух.

— Юк инде, анысы булмас,— дип кырт кисте аучы.— Бердән, болан үгезен атарга ярамый. Үзең үк, «аучы, әнә, ата», дип әләкләвең ихтимал. Икенчедән, комсызланып күп куллануың һәм үлүең бар. Андыйлар юкмы әллә?

— Юкны сөйләмә. Шапырынасыңдыр әле, булса үзең дә авыз итми, авыл хатыннарын аздырмый калмас идең. Әҗәл даруы түгел, булып, өлеш чыгармасаң да, үпкәм шул чаклы гына. Әйткәнемчә, үзең белән карт анаң әҗерен күрсен.

— Бик шаярмыйк әле, агатай, болай да шартлыйм дип тулышкан күңелемә тимә. Юк сүзне калдырып торыйк.

Бу сүзләрне Актаң ачынып, үртәлеп әйтте. Шулкадәр юл үтеп, берәрсе белән киңәшим-сөйләшим дип ерактан килүчегә Бухның мәгънәсез сүз тезүенә рәнҗегән иде ул. Шуңа күрә икесе дә берникадәр вакыт тынып калдылар. Әгәр дә инде тәмам караңгыланган бүлмәдә вакыт-вакыт ике ут җемелдәп алмаса, каракаршы ике почмактан бөркелеп төтен чыкмаса, монда беркем дә юктыр дип уйлар идең.

Ә урамда әле аерым әйберләрне шәйләрлек кенә яктылык бар барын. Тик анда да төн япмасы инде ябылып килә.

Түшәмдәге лампа бер генә мизгелгә күзне чагылдырып кабынды да кабат сүнде. Актаң бүлмә хуҗасының талчыккан, нурсыз кыяфәтенә игътибар итте. Ул исә утныңмы, ут бирүченеңме ата-анасын телгә алып, «авызына төкерә» иде. Актаң үз эшен яратып башкарганы өчен генә дә бу кешене үз итә, ихтирамлый. Зыянсызга шулай телләнеп алу гадәте бар барын, әмма холкында хөсетлек, үзендә кәкре куллык сизелми. Югыйсә, әнә совхозның башка бүлекчәләрендәге хәйләкәр бухгалтерлар берничәшәр мәртәбә алышынды инде. Ә бу егерме ел эшли, киләчәктә дә үз урынында утырачак, билгеле. Эшен белү белән бергәттән әле ул эчү белән дә мавыкмый. Бәлки аны кырын юлдан, азып-тузулардан бала-чагасының ишле булуы, шул сабыйлары хакы да саклыйдыр. Ун бала, егерме күз сагалап тора бит үзен.

Ә бит бер уйласаң — белеме биш-алты класстан ашмый үзенең. Ләкин тормышны белми бу дип әйтә алмыйсың, әлбәттә.

Бу карсак буйлы, төртке телле абзыйны Актаңның үз итүенең тагын бер сәбәбе бар иде. Ул китапханәче Айгөлнең абыйсы була. Бүген туп-туры Бухның эш урынына килүенең дә сере шунда иде. Ярыйсы ук киң күңелле Бух өенә чакырмый калмас дип өметләнә егет. Нәкъ шулай килеп тә чыкты. Тәмәке төпчеген изеп сүндерүгә, Бух аңа:

— Әйдә, батыр, сүз бетсә, өйгә кайтыйк,— диде.— Беләм, синең Өреледә куй суеп, кочак җәеп каршылардай туган-тумачаң юк. Дөрес, җиңгәңнең дә калҗалары чамалыдыр, өмет итмә. Ә чәе, мөгаен, кайнагандыр.

Урамга чыккач:

— Ә теге мумия, болан нәмәстәкәйләре дип шаярттым гына, авызыңа төкерим, нәрсәгә кирәк алар миңа. Болай да йорт тулы бала-чага, ни чара күрергә белмәссең,— дип өстәде.

Бухның тәкъдименә аучының бик күңеле булды. «Гаҗәп кеше. Олы җанлы абзый... Ялгышмаганмын икән»,— дип уйлады ул, җанлана төшеп.

Ишек ачып, өйгә кергәч тә Бухны бала-чага сырып алды, чыр-чу килештеләр. Аталары артында әле кунак абый да барын күргәч кенә ыштансыз кечерәкләре бер читкә тайпылды, югалып калдылар. «Кыргый болан» үзе килгән ич аларга. Боларның берише хәтта: «әнә ул», «әнә үзе», дип пышылдашып та алды. Хуҗаларның ун баласы да шау малайлар. Зурраклардан кемеседер дөрләп янган

тимер мич каршында, утка текәлеп, нарат чәере чәйнәп утыра, бер-икесе нәрсәдер караштырган була, кечерәкләре һаман әле аталары тирәсендә чуалалар иде. Бухның тәбәнәгрәк буйлы, юантык гәүдәле, җирәнсу чәчле хатыны авылда пошмас холкы белән танылган иде. Аның турында: артында җир ярыла башласа да, һич ашыга белмәс, адымын тизләтмәс, симез ана үрдәктәй як-ягына чайкала-чайкала, кабаланмый юлын дәвам итәр, диләр иде. Бу хатынның бөтен уңганлыгы — Бух өенә ел саен диярлек берәр малай кайтарып торуы гына булгандыр. Хәзер дә ул, кунак белән теләр-теләмәс кенә исәнләште дә, аягын сөйрәп атлар-атламас кына ире артыннан икенче бүлмәгә кереп китте. Бух тиздән, киемен алыштырып, тагын зур якка чыкты, кыюсыз гына ишек төбендә басып торган «Кыргый болан»га:

— Әй, син анда нишләп басып торасың, өс киемеңне сал да, шундагы чөйгә эл. Хәзер чәй эчәрбез, насыйп булса. Кунарсың ук дип кыстамыйм, ятар урын табылмас бездә,— диде.

Айгөл күренми иде. Хуҗабикә бик ашыкмый-кабаланмый гына чәй табыны хәстәрләгән арада кунак белән хуҗа шашка уйнарга керештеләр. Һәр отылган шакмакны кулдан-кулга күчереп, этешә-төртешә янңарында унлап «судья» карап торды уенны. Үзара чеметешү, чинашу, елашулар да һич өзелеп, туктап тормады диярлек. Тик бу хәлгә ни ата, ни ана әһәмият итмәделәр. «Куегыз, шаулашмагыз, талашмагыз»,— дип, ник авыз ачып бер әйтсеннәр.

Әллә унынчы уен башлангач, Айгөл дә кайтып керде. Актанга беренче күргәндәй гаҗәпсенебрәк карады да сабыр гына исәнләште кыз. Ә «судьялар»ның унысы берьюлы инде аңа ябырылдылар.

— Айгөл апа, кәнпитең бармы?.. Нәрсәң бар сумкаңда?— дип, аның тирәсендә сикерешә, кыз кулындагы нәни сумкага үрелә башладылар. Ыштансыз батырлар тагын үзара төрткәләшсә, елашса да, эти-әниләре аларга бу юлы да берни дә әйтмәде. Бу балалар, инде аерылган кәҗә бәтиләре кебек, һаман үз ирекләрендә иде. Болай итү яхшыгамы, ямангадырмы, һәрхәлдә аучыга бик ошап бетмәде.

Үзе ул баядан бирле онытылып Айгөлгә карап тора иде. Мондый хәлдә, болай якын ук итеп аның әле кызны беренче күрүе, әллә шул сәбәпле инде, Айгөл аңа аеруча ягымлы, үз тоелды, хәтта аннан ниндидер кайнар дулкын аучыга килеп бәрелгәндәй һәм исертеп җибәргәндәй булды. Айгөл исә үзе дә моны сизенде шикелле, бит алмалары тагын да алсулана төште, ул бераз уңайсызланган кыяфәттә, сак-сак кына басып, тиз генә түр бүлмәгә узды. Үзен күргәч тә кызның да дулкынлана башлавын тою Актанга ошады. Аны бу халәтеннән Бухның кырыс авазы бүлде.

— Әй, нишләп калгып утырасың, син йөрисе гуй,— диде ул, аучыны татлы уй-хыялдан аерып.

— Агай ...җиңелдем бугай мин... Биреләм...

— Хуп, монысы да минем отыш иде,— дип җупләде хуҗа.

Ул арада хуҗабикә кайнап чыккан ак самавырын табын уртасына утыртты, аннары аның янәшәсенә сәкегә үзе дә менеп, юан карагай түмәреннән юнылган борынгы сын кебек тураеп кунаклады. Шуннан соң ләм-мим сүз сөйләшми, тын гына чәй эчтеләр. Касәсен борын төбенә илтеп төрткән кешегә генә чәй ясый икән табында да ярым йокымсырап утырган «җиңәчи». Актаң беренче касәсен бушаткач та үз алдына гына куйган иде, аның бушлыгын күрүче дә, эч дип кабат кыстаучы да булмады. Ә үзе сорап алырга кыенсынды, дәшмәде егет.

Айгөл дә никтер табын янына килмәде, бая кереп китүдән соң бу зур якка гомумән дә чыкмас булды. Агасы чакыргач та, ул:

— Соңыннан балалар белән эчәрмен әле,— дип җавап бирде.

Балаларның кайсы кайда: берише сагыз күшә, инде сүнеп барган тимер мич тирәсендә кайнаша, ә кечерәкләре идәндә дә, сәкедә дә әүмәкләшәләр иде. Актаң урындыгын алып бер читкәрәк утырды. Бух белән хатыны, чукраклар кебек сөйләшми генә әле тагын күпмедер тамак туйдырдылар. Шуннан соң гына Бух, кунакның китәргә җыенуын чамалап:

— Төне бик караңгы, кунып кына каласыңмы әллә? Ничек тә сыярбыз әле,— диде.

— Рәхмәт, агатай. Мин көндезгә караганда төнлә йөрүне яратарак төшәм.

— Беләм анысын,— диде Бух.— Синең ул гадәтеңне авылда белмәүче юктыр. Шуңа күрә дә «Кыргый болан» диләр гуй үзеңне. Тик кайчанга кадәр шулай япаялгыз йөрергә уйлыйсыңдыр. Җиткәндер инде синга да, авызыңа төкерим, күпме уйланып, сайланып була? Акылым артык булганга акыл өйрәтүем имәс гуй. Үзең дә бик башлы егет, синдәй акыллы башлар ишлерәк булса, болайга калмас та

идек. Ташла шул Арчалыны, күченеп кил бирегә. Берүзе анда утыра, мескен, дип сине җәлләп берәү дә кабат анда күченергә җыенмый, бел шуны.

— Уйлармын ага, тагын бер уйлармын.

— Бик озак уйлыйсың шул. Ничаклы гына сузсаң да, гомереңне арттыра алмассың. Онытма, нибары илле-алтмыш яшь яшибез бу дөньяда. Уйлармын, имеш. Айгөл белән сүз куештыгызмы әллә? Ул да, ни генә киңәш итсәң дә: «Уйлармын, агай, уйлармын», белән котыла. Олы башымны кече итеп әйтәм: ташла шул бүредәй ялгыз яшәвеңне. Ташла...

Актаң моңа каршы елмайды гына, ни дип әйтсен соң?

Ә Айгөлне ул кабат чыгып китәм дип ишек ачканда гына бер мизгелгә күреп калды. Түр бүлмә пәрдәсе артыннан кыз аңа кыюсыз гына карап куйды.

Урамда тау куышындагыдай караңгы иде. Халыкта мондый очракта «үлек чыгарган төндер бу», дип әйтәләр. Актаң кармаланып баргандай барып, коймага бәйләп куелган ат тезгенен чиште, җайлап кына атка атланды. Хәзер дә авылның тик бер төбәгендә генә тышкы ут яна, ә урамны шәйләрлек яктылык кайбер өй тәрәзәләреннән генә сирпелә иде. Тыкрык чатында Актаң икеләнеп калды. Таугa таба борылып туры Арчалыга китәргәме соң? Әллә... Әйе, Каһән белән кичтән очрашулары, тегенең яман сүзе онытылмый, күңел түрендә пыскый иде әле. Аны искә төшерү белән кара мәче әле дә тырнагын аучының бәгыренә тидереп алгандай булды. Чынмы соң ул сүз, әллә ялганмы? Шул сасык авызлы Каһән аның дустының хатынына кул сузып, ястыгына үрмәли түгелме?

Шушы уйларга бирелгәч тә, күз алдында кыяр-кыймас кыяфәттә гәүдәләнгән Айгөл төсе тәмам юкка чыкты, бер читкәрәк тайпылды. Аның урынын ачык карашлы, чая, уңган Җәсирә биләп алырга өлгергән иде. Һәм Актаң атының башын каерып алып кире якка борды да, тыңлаучан сукыр кашка, куш тоягы белән тирә-якка пычрак ата-ата, авыл урамы буйлап юыртырга кереште.

Актаңның ишек тоткасына үрелүе булды, Җәсирәнең үҗәтләнеп кычкырганы ишетелде:

— Кит дип кугач эт тә китә! Кит дим сиңа!

Актаң аптырап тукталып калды, чөнки «кит» дип аны куалар төсле тоелды: ачылган чолан ишеген ябып чыгып китәргәме, нишләргә белми ни ары, ни бире баралмый бусагада туктап калды. Шулчак икенче чәрелдек аваз, ир-ат авазы колагына килеп бәрелгәндәй булды.

— Бурычыңны бүген үк түлә дә китәм! Шунсыз селкенмим дә! — дип Каһәннең карышканы ишетелде.— Кибетеңә тикшерү килгәндә кем сиңа ярдәм итте? Ул район тикшерүчеләрен кем юмалавын яхшы беләсеңме гуй. Шул бурычны кайтар! Ул чакта мин кирәктем, мин коткардым сине. Ә дустыгыз «Кыргый болан» кайда иде? Урманында яшеренеп яттымы? Хәзер дә әнә аның уе синдә имәс, Айгөл агасы белән атка атланып баралар иде, үзем күрдем, ха-ха-ха!

Актаң инде ни булганын чамалап өлгергән иде. Ул ике сикерүдә өй ишеген йолкып ачты да, һавадан төшкәндәй, тегеләрнең икесен тиң куркуга салды. Күзләре шар булды Җәсирәнең дә, Каһәннең дә. Икесе дә өркеп сүзсез калдылар. Аннары клуб мөдире аңга искә килде, көтелмәгәндә пәйда булган аучыга карап елмайгандай итте.

— Әһә, үзе... Сиңа каршы торырдай көч-куәт юк миндә, көч белән син җиңәсең, әлбәттә,— дип башлады ул сүзен, килешүгә исәп тотып. Мәгәр, сөзергә торган яшь үгезнекедәй карашы зәһәрле, бәбәкләре акайган, усал күренде.— Берүк шуны да уйла, аучы, хәзерге җиңү, мине тәпәләп ташлау әле чын җиңү булмаска мөмкин бит. Кемнең ашыгы кайчан отачагын алдан әйтеп булмый. Синең дә холыкны мактамас идем мин, «Кыргый болан» тип тикмәгә ирештермиләрдер... Бу өй сиңа да, миңа да авыл клубы түгел, югыйсә. Кайчан телисең, шунда ишеген тибеп ачу бер дә килешле имәс. Суны да сорамый эчмиләр, беләсең килсә. Җәсирә дә колхоз биясе түгел, аңа кем кайчан тели, шунда менеп чаба алмый. Төшенденме инде? Алайса нишләп әле төн уртасында айгырланып аның өенә килеп керәсең?!

Актаң каушап калган иде, ни дип тә җавап бирергә белми аптырабрак торды. Дөрестән дә, ни дип кеше өенә бәреп керде соң әле ул? Җавап эзләп, зиһен туплап өлгергәнче ул балаларчарак итеп:

— Синең нишләп йөрүеңне беләсем килгәнгә килдем,— диде.

Җәсирә дә бик уңайсыз хәлдә калган иде. Хәзер ул нишләргә белми, куркынган кыяфәттә ялт-йолт егетләрнең икесенә карангалап, сагаеп түрдәрәк басып тора. Каһән исә һөҗүмен дәвам итте:

— Вай, тикшереп йөрергә ни хакың бар синең? — диде ярым мыскыллап. Аннары ашыгып кесәсеннән папирос алды да, аны авызына капты. — Я, әйт, ни хакың бар? Бәлки монда минем хакым күбрәктер, бик беләсең килсә, әнә киленчәк үзе расласын.

— Ә мин сезнең икегезгә дә кабатлап әйтәм, — дип көр тавышы белән арага төште ниһаять мөҗабикә. — Китегез, берегезне дә көтеп алганым юк! Сез юк дип үлеп әлсерәп ятмыйм әле! Бай ашаган ризыкны кызганып карап торган ярлы байгыш хәлендә калмагыз. Ирсез өй дигәч тә, уйнаш әс түгел бу. Сезне сагынып күзем каралтканым юк. Бик кирәксенсәм үзем сайлый белермен киләчәктә. Бер көн аулакта түнеп йоклап, аркылыны буйга алып салмый киткән кайберәүләрнең аһ итмәм, үзем кешесен табармын.

Шулай дип Җәсирә Актаңны ярыйсы ук гарьләндерде. Каһәннең исә моңа бик күңеле булды, авызы ерылып колагына җитә язды. Урынында басып тора алмыйча, ул, йөгереп барып, хатынның йомры аркасыннан кагып алгалады.

— Вай, менә әйттең ичмасам, әкыллы тинтәгем, — диде ул сөенеп. — Карлыгачым, былбылым син минем. Кан дошманымны үзең тез чүктердең гүй, рәхмәт яугыры. Ир-ат өчен моннан да югары мактау сүзе булырмы. Рәхмәт... Рәхмәт яусын, җаным...

Каһән, шулай татлы телләнеп, бөтергәләнде Җәсирә тирәсендә. Җәсирә исә аның бер сулыштан, әзми-куймый кабатлаган бу мактау сүзләрен читсенә төшебрәк тыңлый иде. Каһәннең бу кыланышыннан ул да каушап, аптырабрак калды шикелле. Актаң исә тәмам нишләргә белми исәнгерәп тора сыман, аны әле гомерендә беренче мәртәбә шулай ачыктан-ачык мыскыл итәләр, түбәнсетәләр иде. Ул тешен кысып, ачу белән боларның икесенә атап бары бер җөмлә сүз әйтте:

— Хатын-кызны юкка тавыкка тиңләмиләр, кем тары сипсә — шуныкы инде алар!

Шулай диде дә, чын кыргый житезлек белән Җәсирәгә кулын сузып торган дошманы өстенә очып барып та кунды.

— Күрсәтимче синә ничек тез чүктергәнне! Мә, ал! — дип ул клуб мөдирен бөтәрләп аяк астына салды, тегенең биленнән суырып алып шул бил каешы белән дошманының кулын артка китереп бәйләде. Аннары Каһәннең уй-бай килеп череләвенә һәм сүгенүенә дә игътибар итмәстән, арт санына тибеп ишектән чыгарып та җибәрде.

— Уй-бай, мәхлук-ай, ул байгышның ни гаебе бар соң? Үтердең гүй, шунча куәт каян килә синә, — дигән, яклаган атлы булды Җәсирә. Үзе никтер дер-дер калтырый иде.

Актаң аның әйткәннәрен әллә ишетте, әллә юк, утны барып сүндерде дә ашыгып чишенергә керешете. Аннары Җәсирәгә әйтте:

— Көч кулланганны көтмә, чишен, исән чакта. Этка җим булганчы үз куеныма кер! Дустымның рухы, ичмасам, әзрәк рәнҗер.

Җәсирә әүвәл ни әйтергә дә белмәде. Ә таң беленгәндә инде «Кыргый болан» белән «кеше» үзара килешкәннәр иде.

* * *

Көн болытлы. Төн ягыннан әче җил исеп тора. Арчалы белән Өреле авыллары арасында зур кара калкулык бар. Шуның итәгендә ике авылга уртак каберлек урнашкан. Зиратның бер читендәрәк, нечкә нарат киртә белән тотып алынган кабер өстендә, киеме балчыкка пычранган бер алып батырдай ир ята. Ул каберне ике кулы белән кочып җир өеменә капланган да, иңрәп елаган кешедәй, ике иңбашын иреексездән калтыратып куйгалый иде. Ара-тирә аның дәү гәүдәсе тартышып-тартышып ала, аннан тыелгысыз үксү авазлары ишетелгәли иде.

Ә зират киртәсе буенда зур гәүдәле атның сабыр гына басып торганлыгы күренә. Искән җил аның ялларын, койрыкларын буташтыра иде.

Яңа кабер өстендә бәргәләнеп, сызланып ятучы кеше билгеле, аучы Актаң иде. Табигате белән саф күңелле, әлегәчә чын кайгыны да, зур шатлыкларны да татымаган бер кеше буларак, бүген ул бик авыр хисләр кичерә, шуңа гаҗиз калган. Кешеләрнең бер төрле генә булмауларына да аның җаны кыйнала. Югыйсә бит һәркем ата-анадан алай ук кансыз да, явыз да булып тумый. Актаңның да әлегә чаклы күңеле пакь иде. Үз-үзенә хыянәт итү өчен дә әллә ни кирәкми икән ләбаса. Аны-моны абайламый утка килеп кергән күбәләктәй буласың да куясың икән. Әнә бит ул да, гомердә төшенә дә кермәгән әрсезлек, яманлык эшләп ташлады бүген төнлә. Моңа кем гаепле? Үземе? Каһән белән Җәсирә дә катнашамы бу

эшкә? Халыкта шушындый очрак хакында: сынасы теш булса, боламык ашаганда да сына инде ул, дип әйтәләр түгелме соң? Димәк, барысы өчен дә иң әүвәл үзен гаепләргә, үзен җаваплы хис итәргә тиеш була. Ашкынып авылга төшүе, ни сәбәптер Җәсирә өенә юл тотуы — билгеле, очраклылык кына да түгел. Акланусыз, әлбәттә. Һәм шуны тою, аңлаудан аңа аеруча ямансу иде дә шул. Хәер, нәкъ үз гаебен тану өчен ул, иртәдән үк дустының кабере өстенә килеп тезләнгән, ауган да инде.

— Син мине кичер, җан дустым,— дип, бүген ничәнче кат кабатлавы булгандыр.— Кичер ахмак дустыңны, мин синең чиста түшәгеңне пычраттым... Башкалар аңа шакшы җаннары белән кагылмасын дип тырышты мин дустың... Шул намуссызлыкны эшләдем, кичер мине. Беләм, син инде бу дөньяга һичкайчан әйләнеп кайтасы түгелсең. Җир йөзендә яшәүчеләрнең бер-берсе алдында хәрәмләшеп, алдашып яшәүләренә син кабат шаһит булмассың. Мәңге-мәңгегә син ул эшләрдән азат хәзер. Беләм, берәр могҗиза булып бу дөньяга кайтсаң, син, мөгаен, үткәннәргә үкенер идең, кыш көнедәй кыска гына гомереңне башкачарак уздырырга теләр идең. Әйе, ул вакыт синең өең дә, тормышың да, гаиләң дә башка булырлар иде.

Ә шулай да... син әлегә миннән бәхетлерәк: исемеңне кабатларга сабыйларың калды... дәвамчыларың... Дөрестән дә, бу дөньяга кайта алсаң, нишләр идең икән, дустым? Беришеләребезнең ярым йокымсырап, оеп гомер кичерүләренә рәнҗер, уттай сүз белән аларны «төртеп» уятырга, яшәү кадерен белегез, дип кисәтергә тырышыр идең, мөгаен. Үлем казаңа сәбәпче хәлләрне һич кабатламас идең. Ул кадәр күп акча эшләүгә гомеремне юкка сарыф иткәнмен, дип үкенер идең, билгеле.

Әйе, шул иске «ДТ»ыңда көн-төн акча артыннан куалавыңның сәбәбен мин бүген төнлә генә ачыкладым шул. Син Җәсирәнең муенына уралган мең сум бурычын капларга тырышкансың икән, ләбаса. Шуны киметү өчен төннәр буе кемгәдер утын, кемгәдер печән ташыгансың. Соңгы төнеңдә дә син Арчалыга тормозы тотмаган тракторың белән кемгәдер утынга дип килгәнсең икән. Сигез төп юан карагай төялгән арбаң сине тракторың белән Акболакка чумдырганны белә идем инде. Елга төбеннән башкалар эзләп-эзләп тә тапмагач, бер айдан соң үле гәүдәңә тап булучы да мин идем бит. Шунда күңелемә беркеткәнем — тормышымны синнән үзгә итеп кору иде. Ни аяныч, дустым, бүген нәкъ минә синең юлыңа кундым, юлыңа төштем. Нишләп болай? Нигә, әйтче, дустым, синең тәкъдиреңне кабатлыйм икән?

Гаепсез җаннарны җәберләп үз бәхетен коручыларны яратмавымны беләсең. Инде үзем шул эзгә басам түгелме? Бәхет нәрсә соң ул? Син шуңа инде төшендеңме? Әллә ул бәхет дигәнебез икенче берәүгә карата эшләнгән яманлыкның җимеше генәме соң? Бәхетле буласы килгән һәркем шулай икенче берәүне рәнҗетергә тиешме? Һич аңламыйм, гаделлек дигәнебез кая кала соң алайса? Һәрдаим яхшылыкка омтылу кирәк дибез, яманлык каян туа соң, аңлатчы, дустым!..

Бер уйласам, үз урман-тауларымда барысы да ачык миңа, андагы барча киек-җәнлек таныш та, якын да миңа. Ә менә авылда, кешеләр арасында... шул хәтле катлаулы сораулар туа. Соңгы сәфәремдә мин анда тәмам буталдым, адаштым бугай, кичер мине. Арчалыда бергә-бергә уйнап үскән вакытны хәтерлимсең? Алар һәрчак минем исемдә: кичке ахшам вакытлары җитә, көтүлектән мал-туар кайта башлый, без ашкынып Әсән карт әкиятләрен тыңлыйбыз... Аннары хыялга бирeләбез... Исеңдәме, мин беркөнне Тәңрекоймас очындагы таш өстенә утырып, очы-кырые күренмәгән киңлекләрне күзәтсәң икән, дидем. Чиксез һава диңгезендә ак каекка утырып йөзгән кебек хис итәр идем үземне, дидем. Ә син мине бүлдердең дә: «Үсеп җиткәч, мин очучы булам, синнән дә биеккәрәк күтәрелеп, синнән дә ераккарак очачакмын,— дидең.— Үзебезнең Актаудан очып туп-туры Америкага барып чыгам»,— дип масайдың. Ә мин: «Тупчы мәргән булам да, ул самолетны атып төшерәм»,— дип каршы төштем. Шулай күпмедер вакыт сүз көрәштергәч, син миңа: «Гомергә дус булу өчен, үсеп җиткәч, әйдә, бер кызга өйләник,— дидең. Аннары:— Бик кызык булыр иде бу»,— дип тә өстәдең. Ул чакта мин җавап бирми генә башымны түбән идем. Әйтерсең лә, үсеп җиткәч ни буласын белеп, шулай гаепле сыман кыланганмын...

Җил тагын да көчәйде, көн суыта төште. Зират киртәсенә бәйле сукыр кашка сабырсызланып иясенә карап-карап куйгалый башлады. Инде аның эче тәмам тартылган иде. Актаң инде көн авышкач, һавада сирәк-мирәк кар очкалый башлагач кына яткан җиреннән торды. Җир өсте пычраклары туңа, изелгән

балчык кэзләнә — димәк, җир кар төшүгә хәстәрләнә иде. Көзнең иң соңгы көне шушы булыр микәнни?

Шуларны күңеленнән уздырып, Актаң зират урнашкан үрдән түбәнгә, Өреле ягына карап туктап калды. Авыл шактый ерак, елганың ике ягы буйлап тезелеп киткән агач өйләр ике җепкә тагылган муенсаны хәтерләтә сыман. Ул йортларда, ул урамнарда кешеләр... Алар ни сөйли икән бүген? Мөгаен, «Кыргый болан»ның төнге маҗарасын телдән төшерми чәйниләрдер инде. Ул гайбәтне ишетү, әлбәттә, Айгөл өчен бик уңайсыздыр... Ә Җәсирә өчен... бик авырдыр, бәлкем. Ул Актаңны үзе атка атландырышып озатканда:

— Кулың белән эшләгәнне муеның белән күтәр инде,— диде.— Дус-дошман алдында оятка калдырасың килмәсә, бер әйләнеп кайтырсың. Кайтмасаң, миңа гына түгел, якын дустыңа карата да зур яманлык кылган булырсың. Аны кабат үтерүгә тиң булыр моның хурлыгы...

Әйе, карлы-бозлы җилгә дә игътибар итмәстән, аучы Өрелегә бик озак текәлеп уйланды. Ара-тирә аңа түбәннән искән җил белән төтен исе ирешә кебек тоела. Хәер, төтен исе генә дә түгел, борын эчен гомумән кешеләр күп яшәгән торак урынга хас тагын әллә ниткән исләр дә кытыклап уза кебек иде. Әлбәттә, анда яхшы кешеләрнең дә, әйтик, Айгөл ише саф, пакь җаннарның да, аннары Бух ише, «адашасы кеше кулына шәм тоттырып җибәрсәң да адашачак», диючеләрнең дә, ниһаять, Каһән ише һаман саен яманлык уйлап кына йөрүчеләрнең дә ис, рухлары бардыр.

Билгеле, Җәсирә өлеше дә бардыр анда. Ул, мөгаен, әле дә: «Дус-дошман алдында оятка калдырасың килмәсә, бер әйләнеп кайтырсың», дип көтәдер. Әйе, никадәр катлаулы бу тормыш. Анда Айгөл дә, Бух та, Җәсирә белән Каһән дә сыеша. Барысы да бер һаваны сулый.

Шулчак сукыр кашка түземлеген тәмам җуеп,«кайтыйк»дип кешнәп, иясенә аваз салды. Бу вакыт инде ишелеп-ишелеп кар ява, буран башланган иде.

* * *

Күпме генә үрсәләнеп ятса да, Актаң әле һаман йоклап китә алмый азаплана. Күз кабагына шырпы кыстырылгандыр, диярсең. Һаман бер үк уйлар, юлсыз-тәртипсез рәвештә, башында чуала, меңләгән чишелмәс сораулар туа. Шулар тәмам камап алган, һич котылыр җай юк, ул бихисап сорауларга бер генә дә ныклы җавап юк. Инде нишләргә? Нигә болай булды? Ни өчен? Мөгаен, кеше өчен иң кыены үз-үзе белән көрәшүдер, үз уйларына камалып җиңелү куркынычыдыр. Шуннан да куркынычрак тагын ни бар дөньяда?

Актаң шундый төшенке, үкенечле уйларга бирелеп бик озак ятты. Почмак яктан аңа анасы белән сырт йоннары янган мәченең ваемсыз гына сулыш алганнары ишетелә. Ян тәрәзәдән сирпелеп кенә тыштагы кар яктысы төшеп тора. Әйе, бүген бөтен дөньяны пакьлап җиргә ап-ак кар ятты. Тирә-юньдәге ул аклык, пакьлык күңеленә килү белән үк күз алдында Айгөл шәүләсе гәүдәләнгәндәй булды. Аннан да сабыр гына булып сафлык, игелеклелек нуры сирпеләдер сыман иде. Әйе, билгесез ул нурлар аучы күңелен һәрдаим үзенә әйдәп, тартып торгандай. Мәгәр, ул чамалый, аңлый: андый сихерле сылулыкка кызыгып... алдануың бик мөмкин. Әнә бит карның пакьлыгы да озакка бармый, бик тиз эреп юкка чыга. Андый сихри сылулык ерактан гына җылытучан, якынайган саен аның суыгы сизелә булыр. Мөгаен, аның «ДТ» дускае да шундый ук сихрилеккә баш игәндер...

Хәер, ул әнә үзе дә килгән түгелме? Ак нур сирпелгән тәрәзәгә аның шәүләсе ятты түгелме? Әйе, ул, иске «ДТ» хуҗасы. Никтер аның йөз-кыяфәте бик моңсу, сагышлы... Актаң аның янына килде, ак кар өстендә ике тирән эз калдырып, яланөс, яланбаш, яланаяк килеш алар каядыр китеп баралар икән. Тик никтер эзләренең берсе кызыл, берсе кара булып кала. Ак дөнья, ак нурлар һәм кара эз... Шунда Актаң тегеңәрдән:

— Син ни дә булса күрәсеңме?— дип сорады.

— Аксыл тирәлектән башка берни дә...

— Мин дә шулай,— диде аучы.— Ап-ак дөнья... Ә син тиңмыйсыңмы соң?

— Юк, миңа бик эссе, мин эсседән кибәм бугай...

— Бәлки иртә өйләнгәнгәдер? Бик иртә өйләндең син.

— Мөгаен, иртә үләсемне белгәнмендер, дустым... Никтер... ашыктым шул... Нинди дөнья бу, үзе ак кар кебек, үзе эссе...

Шул мәлдә Актаң яшьлек дустыннан аерылды. Теге: Мин карга эвереләем, диде дә күздән югалды.

Актаң күзен ачып җибәргәндә анасы янында утыра, кулын аның маңгаена куйган иде. Ул берәрә: «Кайда соң мин, кай гомер бу?» — дип, аңа аптырап карап ятты да аннары анасының җылы күкрәгенә кайнар башын салды.

— Нишләдем икән соң мин? Ник борчылам болай?! Нәрсә булды миңа?! — дип иңрәп-иңрәп куйды, сукранырга керешүе ул.

Әмма аңа ни дип тә әйтүче, җавап бирүче юк иде.

* * *

Актаң, табаны колын тиресе белән тышланган чаңгысын киеп, ау мылтыгын асып, урман-кырларны гизәргә чыккан иде. Өйдә ашарларына калмаган, берәр җәнлек атып аласы бар иде аның. Тик әлегә дөньяның тынлыгын бозып мылтык тавышы чыгарасы килмәде. Ат... түгел, катырак аваз бирсәң дә, җир өстен каплаган ул ак җәймә юкка чыгар, табигать сискәнеп уяныр төсле. Менә аучы кар ас... тыннан оч-очлары гына күренеп торган үсентеләр арасына килеп керде. Бу нәни чыршыларны ул бер елны үзе утырткан иде. Арчалы әле авыл булып яшәгәндә агачларны утынга киселгән зур мәйданны аның яңадан урман итәсе килгән иде. Унбиш-егерме ел үтәр, бу чыршылар күтәрелеп зур агач булырлар, аларга кошкорт сыеныр, дип өметләнә иде ул.

Актаң, шуларны күңеленнән кичереп, алан уртасында туктап калган иде. Томак бүреген салып кулына тоткан, баш өстеннән күренер-күренмәс кенә бу күтәрелә. Әле кайчан гына чем-кара бөтеркә чәчен ак бәс сарган, диярсең. Юк шул, бәс кенә түгел, соңгы көннәр уй-хәсрәте нәтиҗәсе иде бу.

* * *

Анасы бер кулы белән аны маңгаеннан сөеп сыйпаганда:

— Улым, чәчең нишләп болай агарды? — дип сорады.

— Әни, син сорама, мин әйтмим. Бик арыдым, ачыктым әле,— диде аучы анасына.

Иртәгесен исә аларга чаңгыда Каһән килеп керде. Муенына мылтык аскан, куенында тагын нәрсәседер бар. Шешә икән, ишектән керә-керешкә аны тартып чыгарды да:

— Актаң, синең белән татулашырга исәп әле, - диде.— Шуңа күрә эзләп килдем үзеңне. Теге көнне бер җүнсез хатын өчен тукмашкан идек, әйдә, моны эчик тә килешик, булмаса.

Актаң ни дип җавап бирергә белмичә анасына карап алды. Карчык, «үзең белгәнчә эшлә», дигәндәй, кулын изәгәч, табын әзерләргә керешүе. Аракы эчәрдәй махсус савыт-саба юк иде бу өйдә, чәй касәләре куйды. Кунак аны хуплап:

— Бик әйбәт, тамызып кына эчкәнне яратмыйм мин,— диде.

Актаң, аның комсызланып эчүенә хәйран калып, шешә төбендә калган өлешне дә кунагы касәсенә койды. Каһән ипи катысын авызында әвәли-әвәли:

— Әй, син нишләп эчми утырасың? Үзгәргәнсең дә димме, чәчең ап-ак булган. Буятмагансыңдыр ич?

— Юк. Үзе агарды миңа... никтер...

— Заманасы шундый ахры. Хәзер япь-яшьләр дә чал башлы. Минем дә, әнә, ярты башым ак гуй, күрәмсең? Ике буйдак, икебез дә чал, димәк. Төкер! Безгә дигән кызлар бетмәсен, дип, әйдә касәләрне күтәрик.

Каһән, гадәтенчә, туктаусыз сөйләнде.

— Сиңа бик каты рәнҗегән идем, инде менә үзем килдем. Без, ике ир-егет, ике буйдак арасында ни булмас?.. Онытыйк. Аннары бергәләп ауга барырбыз. Синдә мумия күп, имеш. Шуны миңа да бераз бирсәңче. Никтер ашказаным талап тора, шул дәвадан өлеш чыгармассыңмы, дип тә өметләнеп килдем иде.

Кунак күбрәк лыгырдаган саен аучының ачуы кабара барды. Тик аны теге төндәгечә арт сабагын укытып чыгарып җибәрергә анисеннән базмады. «Мумия юк бит», димәкче иде дә, әйтмәде. Түрдәге аркылы-торкылы ак калай белән сырланган сандык янына килеп, аннан кечерәк төенчек чыгарды һәм шундагы «дару»ның бер өлешен Каһәнгә сузды.

— Тик алдан килешеп куйыйк: моннан гайре Айгөл белән Җәсирә тирәсендә кыткылдап йөрмисең. Югыйсә терелэй тиреңне тунармын!

Каһән «дару»ны кулына алгач:

— Рәхмәт, мең яшә, яхшылыгыңны онытмам,— диган булды.— Алай-болай улым туса, синең исемне кушармын.
— Балаң түгел, хатының да юк ич әле.
— Ә Алма-Атада калганы? Хатыным, ике балам... Хәер, аларны тәгаен үз балаларым дип нинди җүләр генә әйтсен икән? Әмма ләкин алиментны мин түлим үзләренә...
Тимер мич инде күптән сүнгән, карт анасы тунын ябынып күптән үз урынына менеп яткан иде. Актаң аның ачылып киткән өстен барып рәтләде.
— И, караңгыланып та килә икән, шушында куныл, иртә белән генә китсәм, каршы килмәссеңме?
Актаң икесенә дә ятак әзерләргә тотынды.
— Чын егет син. Кала җирендә синдәйләрне аеруча яраталар.
Каһән, бәлки, моны чынлап әйткәндер, ләкин аучы:
— Авылга да сыйдырмыйлар әле,— дип кенә куйды.
— Юкны сөйләмә. Моңдагы иркен тормыштан үзеңнең аерыласың килмидер. Иркенлеккә ни җитә. Дөресен әйткәндә, синең тормышка үзем дә кызыгып бетә алмыйм. Белəм, сине байлык та, дан да тотмый. Сагынырдай үткәнең, өметләнердәй киләчәгең — барысы шушында. Ә мин... меңләгән китап укыган, зур кала тормышын күргән егет, синдәй яши алмыймдыр, ахры... Юк, юк, син башка...
Аннары Каһән, йокымсырап киткәндәй, берара онытылып, дәшми-тынмый ятты. Хәтта бермәл гырылдап та куйгалады. Актаң исә тиз генә йоклап китә алмый, нәрсәгәдер борчылып, урынында әйләнгәли иде әле. Каһән аңа тиктомалдан:
— Гомер-бакый исеңдә тот, яшь дустым, кешегә ышанма, һәрчак дошманыңа беренче булып сугарга омтыл, белдеңме?!— дип эндәште.
Шулай диде дә, гырылдап тагын йоклап китте.

* * *

Кемдер без белән төртеп алгандай, сискәнеп уянды Актаң. Инде таң атып килә икән, ян тәрәзәдән Тәңрекоймас шәүләсе шәйләнә иде. Аучы анасы яткан якка карап, аның тыныч кына сулыш алуын тойды. Кунак ятагы исә буш иде инде. Өй эчендә күренми, урамга чыккандыр, мөгаен, дип, Актаң да, яланаяк кына итеген сөйрәп, ишегалдына таба атлады. Теге монда да күренми иде. Тик кичә яуган кар гына тирә-якка сафлык, пакьлык өстәп җемелдәп ята.
Ат абзарының ишеге никтер ачык иде, Актаң шунда юнәлде. Анда сукыр кашканың идәндә тәгәрәп ятуын күреп, аптырап калды. Атның авыз-борыныннан кан саркый, башы янәшәсендә канлы балта аунап ята иде. Каһән эшеме бу? Ул аптырап өйгә, әнисен уятырга ашыкты. Шунда гына түрдәге сандыкның да актарылып ташлануын, әнисенең намазлык, күлмәкләре идәндә чәчелеп ятканлыгын абайлады. Мумие, «дару»лар тутырылган төенчек урынында юк иде. Менә сиңа кунак!
Тагын бераздан Актаң юньсез Каһәннең ау чаңгыларын да сындырып киткәнлеген ачыклады. Куып җитмәсенгә эшләгән инде ул моны. Актаң ачыргалынып үзалдына:
— Шул хәтле яманлык белән кайтарырлык ни гаебем, нинди җазыгым бар соң минем?— диде.— Нишләп болай игте икән? Әллә Арчалыда яшәвемне күпсенәме, шуңа үчләнәме бу явыз? Аһ, куып җитсәм үзен! Якасыннан тотым алсаммы ул этне! Әйдә, әни, киен, җыен — китәбез!
Ишекле-түрле йөренгән Актаң әнә шундый карарга килде дә әнисе каршына барып тукталды.
Анасы аны-моны әйтеп тормады, идән астына төшеп китте дә, тирегә урап бәйләнгән бер озын нәрсәне аңа сузды. Бу кемнәндер калган иске чаңгы иде. Атасыныкы булгандырмы ул, Әсән картныкымы... Аучы әлегә анысын төпченеп тормады, тиз-тиз генә аны үзенә җайлады да кереп мылтыгын алды, тунын киде. Әнисенең дә үзе белән алыр төенчеге әзер иде.
— Кил, аркама атлан,— диде ул анасына.— Син мине биш яшемә чаклы күтәреп йөргәнсең, инде мин сине күтәрим...
Аннары ул ак карны шыгырдатып, Каһән калдырган эз янәшәсеннән Өрелегә таба шуып китте.

Казахчадан **Лирон ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Шерхан Муртазаев

# ЧИКЕРТКӘ ҖЫРЫ

хикәя



Хәдичә, илаһи бер рәхәтлек кичереп, ләззәтләнеп чәй эчеп утыра. Маңгаеннан бәреп чыккан кайнар тир чигәләре буйлап муенына, түшенә, аркасына агып төшкән. Кайчаннан бирле һәм күпме эчкәнен дә оныткан инде. Ара-тирә чәйнекнең капкачын ачып карап: «Бәлки җитәрдер дә инде, эчә-эчә эреп китүең бар»,— дип уйлый да ул, чәйнек эченнән килгән хуш истән исереп, янә пиалага үрелә. Аңа чәй коеп яңадан эчә башлый. «Чәй ул май түгел, күңелне болгатмый»,— дип үз нәфесен үзе үрти.

Ниһаять, Хәдичә эскәтер чаклы ак яулыкны ирене кенә кулына алды, ашыкмыйча гына битен, муенын сөртте, ниндидер тавыш ишетеп, ачык ишек аша тышка күз салды. Андагы эсселек күзгә күренерлек иде. Арык буенда үскән үрмә үлән дә эсседән әлсерәп, саргылт еланны хәтерләтеп, җиргә сыланган, иләмсез шайтан таягының чатлы-чотлы яфраклары күгәргән калайдан ясалган сымак, алмагач яфракларын да соры тузан баскан. Алмаларның кояшка карап торган яклары инде кызарган. Кукуруз чәкәннәре ефәк чукларын коя башлаганнар. Көнбагыш да нечкә муенын бөгеп, табак битле йөзен җиргә төбәп йокыга талган. Помидорлар исә шартлар дәрәҗәгә җитеп тулганнар, кызарганнар. Аларның күбесен әрсез тавыклар чукый-чукый тишкәләп бетергәннәр.

— Каһәр суккан үләт кыргыры нәрсәләр,— дип сукранып алды Хәдичә.

Быел бигрәк уңды инде помидор. Җыеп бетерә торган түгел. Җыйса да, аның берүзенә күпме генә кирәк соң. Кайнесе Шалабайның балаларына, җыеп алыгыз шуларны, дип әйткән иде дә бит, кая инде, кул гына селтәделәр:

— Үзебезнекен кая куярга аптырыйбыз,— диделәр.

— Тамагы туйды халыкның,— дип көрсенеп куйды Хәдичә,— ризыкның кадерен белмиләр.

Оясы күләгәсендә телен чыгарып сузылып яткан җирән эттән гайре урамда җан иясе күренми. Тирә-як эсселектән йончып тирән тынлыкка чумган. Тигәнәк, әрем араларында даладагы иптәшләренә кушылып чикерткәләр генә чертләшә. Йокыны китерә торган тынлык. Татлы төшләр күрә-күрә ярау урында изрәп кенә йокларлык.

Хәдичәнең дә күзенә ишелеп йокы төште. Ул табын янынннан да кузгалмыйча баш астына бишмәтен салып яткан иде, урамнан:

— Фото! Фото! Сурәт! — дигән тавыш ишетелде.

Хәдичә, башын чак кына күтәреп, тавышка колак салды.

— Фото! Сурәт!..

Тынлык кинәт чәлпәрәмә килеп бозылды, тын өйләрдән урамга бала-чага, кыз-кыркын, яшь-җилкенчәк йөгереп чыкты. Аул район үзәгеннән шактый ук читтә булганлыктан, биредә һәр ят тавышның ишетелүе, һәр чит кешенең күренүе зур вакыйгага әйләнә иде.

— Мәтәлеп кенә китсәң иде шул сурәтләрең белән,— дип уфтанды да Хәдичә бишмәтенә башын куйды. Һәм шунда аул саен йөреп сурәт ясаучы бер фотографның монда да килеп чыгуы, күршесе Акшай карчыкның яшь чагында алынган иске сурәтен зурайтып-яңартып бирүе исенә төште.

— Тилерә үк башлагандыр бу Акшай,— дип янә уфтанып алды Хәдичә.— Кыланышы кырга сыймый. Үзенең иске сурәтен зурайтып Куракбас карт сурәте янына куйган. Җитмәсә әле шуларның өстенә чиккән сөлге дә элгәндәй иткән, кыланчык.

Күрше карчыкның яшьләр сыман кыланып йөрүеннән чыккан ачу, урамдагы ыгы-зыгының көчәя баруы Хәдичәнең йокысын качырды. Уфтанып алды да ул торып утырды. Аул халкының фотограф белән сөйләшкәнен, фотога төшәргә җыенучы яшьләрнең чыркылдап көлешкәннәрен тыңлап уфылдады. Аннары, ни эшләргә җыенганын да белештереп бетермичә, үзе белән яшьтәш иске сандыгы янына килде. Сандыкны ачып, аның төбеннән ап-ак чүпрәккә төрелгән бер катыргыны алды. Ул катыргыга Мәксутның хәрби киемдә төшкән фотокарточкасы ябыштырылган иде. Иренең бердәнбер рәсеме. Сугышка хәтле төшкән рәсем.

Мәксут Халхин-Гол янындагы сугышта кавалерист булып сугышкан иде. Хәрби киемнәр киеп аулга кайтты да, армиядә өйрәнгән осталыгын күрсәтеп, аул халкын шаккаттырды. Бар куәтенә чапкан атның ияренә куллары белән генә тотынып башкадала торуын, ат корсагы астыннан чыгып, иярга аркылы ятуын, ат өстендә биюен күреп, аул картлары тел шартлаттылар. Югыйсә, алар үзләре дә ат өстендә гомер кичергән аксакаллар иде. Егетнең даны аулдан аулга күчеп тирә-якка таралды. Нәкъ менә шул чакта очрашты да инде аның белән Хәдичә...

Бердәнбер рәсем. Сугышта хәбәрсез югалган иренең бердәнбер фотосы. Озак итеп карап торды ул рәсемгә Хәдичә. Карый торгач аның күзенә Мәксут үзе тере килеш күренгәндәй булды. Кара тутлы, киң җилкәле, киң маңгайлы, үткен карашлы егет бусагадан атлап керде дә... Хәдичәнең башы әйләнеп китте, иреннәре көл төсенә кереп агардылар.

Хәдичә, исенә килеп, тиз генә җыена башлады. Ишегалдына чыкты. Күләгәдә телен салындырып яткан Майлаяк, өй хуҗасын күргәч, нәрсәдер өмет итеп, койрыгын болгарга керешкән иде. Хәдичәнең кулында кәгазь генә икәнлекне аңлагач, авызын зур итеп ачып иснәде дә күзләрен йомып, элеккеге кыяфәтенә кайтты.

Фотограф карточканы кулына алып карады да:

— Малаеңмы? — дип сорады.

— Күзең чыккан мәллә? — дип кабынып китте Хәдичә.— Рәтләбрәк кара. Ирем ич ул минем.

Фотограф бер карточкага, бер Хәдичәгә күз ташлап алгач:

— Ә-ә... Мин малаеңдыр дип уйлаган идем,— диде.

— Күп уйлама. Уйлаучы табылган имеш. Тавык мие эчкәннәргә мондый кызуда уйларга ярамый. Зурайтырга кирәк бу сурәтне, беләдеңме? Кара аны, югалтасы булма. Әгәр дә югалтсаң...

Теле ярыйсы ук әче булса да, Хәдичә кешеләрнең күңелен рәнҗетерлек сүз әйтми иде. Бу юлы аның сүзләре тупас булып ишетелде. Фотограф егет үпкәләргә җыенган иде, карчык кешенең күптәнге ярасына кагылганын аңлап, уңайсызланып гафу үтенгәндәй елмайды да:

— Иreң белән бергә төшкән карточкаң бармы синең? — дип сорады.

Мондый мәгънәсез сорау Хәдичәне чыгырыннан ук чыгарды.

— Аңгыра сарык икәнсең! Нәрсә лыгырдаганыңны беләсеңме син? Каян килсен ди миңа андый карточка. Кай арада төшеп өлгерик ди без андый карточкага. Төшмәкче идек тә, сугыш башланды. Безнең вакытта карточкага төшү бар идемени ул. Хәзер генә бит ул өйләнешкәнче үк кочаклашып карточкага төшеп куялар.

Фотограф тагын бер кат карточкадагы хәрби киемле егеткә карап алды.

— Яшь чагыңда үзең генә төшкәне дә юкмы?

Җыелган яшь-җилкенчәк, карчык-корчык гаҗәпләнеп фотографка карап тордылар.

Хәдичәнең кыз чагы белән кызыксынып төпченүе аларны аптыраш-та калдырган иде.

Хәдичә фотограф кулыннан Мәксутының рәсемен тартып алмакчы булып үрелгән иде, нидер уйлап туктап калды.

— Минем яшь вакытым сиңа нигә кирәк? Юк минем үзем генә төшкәнем. Иптәш кызым белән төшкән идем бер.

— Кайда ул?

— Ятадыр шунда сандык төбендә. Кемгә кирәк ул.

— Бар, алып чык әле шуны.

Фотографның тел төбен аңлый алмый интеккән Хәдичә тагын кызып китте.

— Менә бәйләнде! Ниемә ул сиңа?

— Алып чык диләр бит! Аннан күз күрер,— дип, фотограф та үзе-некен тукыды.

— Бар инде, бар, алып чык сорагач,— дип, җыелган кешеләр дә үгетли башлагач, Хәдичә өенә кереп китте, кайчандыр иптәш кызы белән янәшә утырып, елмаешып төшкән рәсемен алып чыкты. Фотограф ике карточканы ике кулына тотып, әле берсенә, әле икенчесенә күз ташлап уйланып торды да Хәдичәгә карап елмайды, ни өчендер башын чайкап куйды.

— Нәрсә, әллә мин түгел дип уйлыйсыңмы? Әллә ышанмыйсыңмы? — диде Хәдичә.— Менә күр, монысы мин, бусы дус кызым Улбосын. Бергә үстек. Бер партада бергә утырып укыдык. Ул кияүгә чыгар алдыннан төшкән идек. Аның да ире сугышта югалды. Бердәнбер улы белән ялгыз калды Улбосын. Бәхетенә малае әйбәт кеше булып үсеп җитте. Хәзер әнисен кадер-хөрмәттә генә тота.

Фотограф Хәдичәне карточкалардан күзен алмыйча гына тыңлады, ул әле һаман йөзен җыерчыклар каплаган каршындагы карчык белән рәсемдәге көләч яшь кыз арасындагы охшашлыкны табарга тели иде. Юк шул, әз генә дә охшамаганнар. Тик карчыкның сүнеп бетмәгән күзләре һәм кызның көләч карашында гына уртак чалым бар...

Бер атнадан соң фотограф килеп тә җитте. Аның тирәсенә тагын җыелдылар. Авыл халкына ул яңа төшерелгән һәм искеләрен яңартып зурайткан карточкаларны өләште. Кешеләр шаулаша-көлешә үзләренең, бүтәннәрнең карточкадагы сурәтләрен карадылар.

— Карале, кара, шәһәр көязләреннән бер дә ким түгел...— И-и, монысын күр әле, нәрсә кигән ул өстенә,— диештеләр.

Фотограф, осталыгыннан масаеп, горур кыяфәт белән елмаеп басып торды.

Масаерлык та иде шул. Башкалар кебек иске карточкаларны ничек булган булса, шулай гына яңартмый иде ул. Кайчандыр карточкаларда мәңгеләшеп калган йөз-кыяфәтләрне генә элеккәчә калдырып, кигән киемнәрен заманча итеп үзгәртеп ясый иде. Әйтик, кемдер заманында бишмәт, чапан яки чикмән киеп төшкән булса, фотограф яңарткач, соңгы мода буенча тегелгән куртка, я джинси, хәтта фрак кигән булып чыга иде. Болай «кыландыруы» өчен аны ачуланмыйлар иде бугай рәсем иялэре. Фотографның уе изгелектә булуын, кешеләрне һәрвакыт матур, пөхтә, заманча итеп күрергә теләвен аңлыйлар иде шикелле.

Сурәткә төшерүче килгәнен ишеткәч, Хәдичә дә ашыгып өеннән чыкты. Фотограф, аны күреп өлгерүгә, сумкасыннаан зур гына катыргы алып, карчыкка сузды. Хәдичә катыргыга ябыштырылган рәсемне әйләндереп-әйләндереп карады, әмма һични дә төшенмәде. Яулыгы бе-

лән күзләрен сөртеп, карточканы сраккарак куеп карагач: «И, ходаем»,— дигәнен үзе дә сизми калды.

Төркемдәгеләр, аны уран алып, рәсемгә төбәлделәр. Бу юлы Хәдичәнең күршесе Акшай карчык та өённән чыккан иде.

— Ой-бай-ай! — дип кычкырып җибәрде ул.— Синме соң бу, Хәдичә? Нишләп әле синең Мәксутың синнән йөзен борып төшкән? Талашкан идегез мәллә сурәткә төшәр алдыннан?

Чыннан да, Хәдичәнең карточкадагы ире, аны өзелеп яраткан Мәксуты, Хәдичәсенең янында утырса да, читкә караган иде. Шул турыда әйтмәкче иде Хәдичә фотографка, Акшайга сер бирмәс өченме, телын дәшми калды.

— Карашо! Карашо! — дип кенә кабатлады.

Карчык тавыш-фәлән чыгармагае дип шикләнгән фотограф җинел сулап куйды. Бактың исә, карточкадагы Мәксутның читкә карап торуы өстенә, аның киемнәре дә үз рәсемендәге кебек түгел иде. Фотограф ирке белән ул хәрби киемнәрен салган, Хәдичә янынннан кисеп алынган Улбосын урынына кара костюм, ап-ак күлмәк киеп, галстук бәйләп утырган. Тик башындагы фуражкасы гына үзенеке. Күрәсең, аны эшләпә белән алыштырырга фотографның осталыгы җитеп бетмәгән. Бәлки, арттырып үк җибәрәсе килмәгәндер.

Хәдичә карточкадан күзен алмыйча арык буена чүгәләде. Мәксуты, яңа кием кигәненә уңайсызланган сыман, кашларын җыера төшеп үз алдына карап утыра. Хәдичә аның иценә башын салып көлеп тора. Улбосын белән төшкән рәсемдә алар башларын башка куеп төшкәннәр иде шул.

Хәдичә янына Акшай килеп чүгәләде.

— Кайчан төшеп өлгергән идегез? Мин күршедә яшәп, бер дә сурәткә төшкәнегезне хәтерләмим,— дигән булды.

— Хәтерләмәссең дә,— диде Хәдичә,— сиңа әйтеп тормадык шул. Туйдан соң районга бардык та төштек. Нәрсә белмәгәнгә салынасың, бу карточканы син әллә ничә тапкыр күргәнең бар минем өемдә. Хәтерең бик начар икән. Без Мәксут белән гел бергә булдык, карточкабыз да бергә эленеп торачак. Сез генә ул Куракбасың белән икегез ике карточкада. Без һәрвакыт бергә...

Бу сүзләрне әйткәндә, Хәдичәнең тавышы яшь чагындагы сыман челтерәп чыкты, күзләрендә очкын кабынды.

— Менә зурайттырып алдым,— дип дәвам итте Хәдичә.— Өемнең түрендә эленеп торачак. Без һәрвакыт бергә! Ходайга шөкер, һәрвакыт бергә.

Шуннан соң ул фотографны чакырып алды.

— Тагын берне шушындыйны яса. Төлкебастагы кызыма җибәрәм. Карашо, да? — диде.

Акшай дәшми-тынмый гына китеп барды. Башкалар да таралдылар. Арык янындагы агачка аркасын терәп чүгәләгән, карточкадагы Мәксутның күзләренә карап елмайган Хәдичә ялгызы гына калды.

Тирә-як тып-тын. Тигәнәк, әрем араларында, даладагы иптәшләренә кушылып, чикерткәләр генә чертләшәләр.

Юк, чертләшмиләр — сайрыйлар, җырлыйлар бугай алар.

Казахчадан **Туфан МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәсе.



## Марат Акчурин

*Марат Акчурин — Мәскәү шагыйре. Ул татар, грузин һәм казах шагыйрьләрен русчага тәрҗемә дә итә.*

●

Тын йокыга чумган йолдызлыклар...
Төренгән Җир төнге болытларга
Һәм йөзә ул чиксезлекләр буйлап —
Кая бара? Туктар кайсы ярда?
Язгы җиле исә зәңгәр төннең
Иңләп-буйлап айлы киңлекләрне
Һәм тибрәнә япа-ялгыз гына
Узган көздән калган әче әрем.

Төнге болытларның күләгәсе
Язгы боздан тып-тын гына уза;
Сыенганнар ярга тал-тирәкләр —
Ботаклары әле юеш бозда.
Йөзә Җиркәй... Шәрык түрләреннән
Саркып кына күтәрелә якты.
Шагыйрь җанга нидер сөйли җиһан
Яз хакында якты таңга чаклы.
Гомерләре чикле кошлар хәтта
Чутылдыйлар үлемсезлек сорап.
Чиксезлекләр буйлап йөзә Җиркәй,
Һаман йөзә... Барыр юлы ерак...

## Декабрь

Төшләремә син керәсең һаман:
Тәрәзәгә, имеш, җәй сыенган,
Һәм бүлмәгә ургып керә якты,
Гөл таҗында — көмеш тамчыларда
Җемел-җемел килә ялтыр чаткы!
Яланаяк син йөрисең өйдә,
Җыр җырлыйсың бәхетле бер көйгә...
Күрмәгәндәй булып икебезне
Һәм онытып тешли белүен дә
Көзге каршысында шөпшә безли.

Русчадан **ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәләре.

# Ташкент Тарих музеендагы дәфтәрдән бер язма

Хәнҗәрләрнең ялтыравы
Алып тора күзнең явын,—
Мин кораллар караштырам,
Дуслар белән бер гәп корам.
Ә кайдадыр чаптар менеп,
Тугыз гасыр гына элек
Коңгырт тәнле ерак бабам
Киң даланы иңләп чаба.
Ияренә береккән ул,
Иркенлеккә күнеккән ул.,
Ә бәхәсләр чыкты исә,
Аны хәнҗәр бик тиз чишә;
Гел тураклар-кисәр өчен
Ашкындырган шашкын көче,—
Ул музейда тора бүген
Ялтыратып үткен йөзен...
Аһ, җиңүнең татлы мәле —
Һинди геннар аша бәреп,
Ул миңа да килеп житте:
Ут дулкыны битне өтте!
Дала җиле исте дисәм,
Йортта яшим мин югыйсә.
Фатирдагы киштәләрдә
Китапларым — дистәләгән.
Тик юк алар арасында
Хәнҗәрләр дә, кылыч-кын да...
Ник соң бүген тирән уйда
Басып калдым мин музейда?!

*Урамда үз хатынын кочаклаган өчен чит ил дипломаты, иҗтимагый әхлак нормасын бозуда гаепләнеп, штрафка тарттырылган.*

Гарәп газеталарыннан

А, Шәрыкның зарлы бу көйләре!
Һәрбер чаттан агыла кайнар моң,—
Үкенече, хәсрәт-әрнүләре
Тынгылыгын җуйган җаннарның.

Гел күз яшьле генә шушы җырлар,
Айлы кичле, татлы газаплы.
Кая барма, көчле транзисторлар
Сөю сагышларын кабатлый.

Сылу җарияләр кочкан мәлне
Уйлап бакты микән пәйгамбәр:
Оҗмах ләззәтенә өметләнеп,
Кардәшләре газап чигәләр.

Нефть иле, чуар башкалалар
Бөркү төндә иңгән төшмени!
Урам тулы ирләр һәм балалар,
Ә хатын-кыз монда юкмыни?

Шәригатьнең биге гүзәл затны
Сизгер саклый чит-ят караштан.
Әйтерсең лә «хак мөселман халкы»н
«Алла үзе сабыр яраткан!»

Әйдә, Коръән, әхлагыңны макта...
Тик күрәмсең: урам чатында,
Ютәл даруыдай, һәр аулакта
Сөю ләззәтләре сатыла.

Бу әхлакның тимер кысалары
Шытырдатып кыскач каныңны,
Кинозалда, үбешүгә багып,
Йөзләп бугаз чиный: «Их, шуны!..»

Мәскәү метросыннан бер манзара
Китсә икән шулчак күренеп:
Наян бер кыз чия ашап бара
Һәм сөйгәнен үбә үрелеп...

Татып карадың да: «Мә, эч!» — дидең.
Дәшми генә эчтем мин кызыгып:
Үләннәрдән койган шәрабыңда —
Киң даланың әче ялгызлыгы...
Бугазымны өтә бу сихри ут,
Кирәк түгел хәзер артык сүз дә.
Ә син чарасыздан пышылдыйсың:
«Бергә булу язмагандыр безгә!»

Гамлет яшендәге үҗәт кеше,
Мин карышам: «Юк, сөйләмә, ялган!
Бар Офелия дә суга батмый,
Миңа сине яратырга язган!»

Яшь зиһенең чуалып ук бетә,
Сүзләремә каршы дәлил эзләп.
Стенадан шулчак Шекспир үзе
Күзен кыса сиңа көлемсерәп.

## Сабантуйда

Кызларның күзендә очкыннар бии:
Алар күңелен яшь көрәшчеләр били.

Ә хатыннар, күз төшереп мәйданга,
Елмаялар бары батыр калганга.

Әбиләрнең күз карашы ник гамьле? —
Яшермичә җәллиләр җиңелгәнне.

●

Өеннән аяк атламас,
Берекккән мәрмәрмени!
Тынгысыз язмыш эзләргә
Аңа дөнья тармыни...

Бераү һаман юллар гизәр,
Ару-талуны белмәс,
Тәнендә куәт бар чакта
Сәфәрдән кайтып кермәс!

Мәңгелек бәхәс: кем хаклы?
Бу яшәүдә ни мәгънә?
Ә Җир туктамый — ул әнә
Әйләнә дә әйләнә...

●

Бер зур талчыгуны
Мең кечкенә талчыгуга бүлсәң,

Бер зур теләкне
Мең кечкенә теләккә чәчсәң,

Бер зур кешене
Мең кечкенәгә таркатсаң,

Ни өчен
Җиңелчә генә арган,
Берни дә диярлек теләми торган
Бәләкәй кешеләргә
Яшәве ансат икәне аңлашылыр.

●

Электән калган һөнәр бу:
Тотып йөзем тармагын
Эзлиләр комлы далада
Су асты елгаларын.

Шагыйрьләр дә әнә шулай,
Җаннары белән барлап,
Тәмле су табып бирәләр
Сусаган юлчыларга.

Үзләре үк көйрәп үлә
Сусыз булса тапкан җир...
Мохтаҗбыз тик чынга гына,—
Ялгыша күрмә, шагыйрь!

**Флера НИЗАМОВА** тәрҗемәләре.

**Зиннур Мансуров**

# КЫЛДАН НЕЧКӘ, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН

ПОЭМА

**«1907, декабрь, 12 /25 /.
Ленин фин крестьяннары озатуында диңгез култыгы бозы буйлап Лилль Меле утравыннан Нагу (Науво) атавына үтеп чыга. Шушы араны үткәндә Ленин аздан гына һәлак булмый: боз ватыла башлый, һәм ул ниндидер могҗиза белән генә котылып кала».**

Владимир Ильич Ленин. Биографик хроника.

## I

...Бара иде, ди, боз буйлап,
киләчәген уйлап,
китте, ди, таеп,
төште, ди, авып...

Нигә әле хәтеремә килде бүген
бала чакта отып алган такмаза?!
Ничек инде уйланмыйсың — аждаһадай
йоклап яткан диңгез өсләп атла да.

Атлантида һәлакәтен хәтерләтер
хәвеф торса адым саен сагалап?!
Кешелекне тетрәтерлек фаҗиганың
олылыгын булмый хәтта чамалап.

«Боз сиземли хатыннарның көмәнен дә,
юлга энә алырга да базмыйсың...»
Ә ул, әнә, халыкларны кочтырган да
бурлак төсле сөйри Рәсәй язмышын.

Төпкә киткән миллионер «Титаник»ның
йөге генә төялмәгән бит анда!..
Яшьни-яшьни тармакланып чатнар боздан
үтә ала икән шундый титан да.

Ә боз кырыс — куштаннарча, туфрак булып
ятам, диmi, синең аяк астында.
Заманында егып салган (яхшы фалмы?)
даһи Пушкин хәзрәтинең атын да.

Кайсы якка атласаң да хәвеф көтә,
бозга бердер уңлык белән суллык та.
Күзне бәйләп җибәргәндәй таптанасың
күзләвекләр өстендәге сулыкта.

Мондый юлда йөрәк белән капшый-капшый
барганда да ялгышырга бик көйле,
бер адымны алга атлап, ә чынлыкта
ике адым артка киткән шикелле.

Йөрәк тибә: «Артык саклык — куркаклык», дип,
ә су гаярь җаннарны да күп йоткан.
Дуамал фин крестьянымы ике уйлый?! —
кәгеп алгач, диңгезең дә тубыктан.

Шәраб-утка чумган боздай төшеп киту —
бату гына түгел тирән уй-моңга.
Ә су кызы кызмачарак башлыларны
бик яратып ала, имеш, куенга.

Суда батмый, утта янмый. Суда батмый...
Кеше заты башкача да сыналган.
Батмаганны — яндырганнар, ә батканны...
Истә тора шушындый бер чын ялган.

* * *

Үзең фәкать бер уй белән
кыл өстеннән атлап бар;
шундый чакта күз алдына
килсен әле саклаблар.

Шулай хәтер яңартуның
бардыр берәр хикмәте.
...Саклабларда бату-батмау
сыналган, ди, бик каты.

Илләрендә бозыклыклар,
сихер арта башлагач,
карчыкларның кул-аягын
бәйләп суга ташлагач,
калкавычны күзәткәндәй,
карап торган бар кеше:
йә, кайсысы төпкә китәр,
боздай батмас кайсысы?..

Коткарганнар — алтын төсле
су төбенә киткәнен;
батмаганын — яндырганнар,
аңлап сихер икәнен...

Артык йөктән котылырга —
кирәк булган җан кыру.
Ә шулай да уйландыра
батмаганны яндыру.

...Үзең фәкать бер уй белән
кыл өстеннән атлап бар;

шундый чакта күз алдына
килсен әле атлантлар.

Аларда да күп булгандыр
сихерчедәй ят җаннар.
Ә үзләре нигә шулай
яна-яна батканнар?

Атлантларның аяк-кулын
явызлыкмы бәйләгән?
Әйләнеп таш муенсага,
батырганмы әллә дан?

Шатлык белән кайгы яше
сыймаганмы чик-ярга?
(«Батмый торган авианосец»
мөмкин төпкә китәргә.)

Кыл өстеннән атлаганда
ясаганмы зур хата?

Нинди көчләр баш бармакны
аска бөгеп күрсәтә?..

• • •

Бара иде, ди, боз буйлап,
киләчәген уйлап,
китте, ди, таеп...

Җылым төсле чуалышкан уй-гамьнәрен
сөйри иде барысы да бер эздән,
йөрәк итен шартлау җиле кисеп үтте,—
төнне ертып аттылар күк обрездан.

Һәм чайкалды бөтен дөнья! Аяк асты
теткәләнде, чатыр-чотыр ярылып;
әллә инде сигезаяк калкып чыкты —
(боз астында тоелганмы тар булып?!)

Атлантида... Ул да шулай СОС бирергә
өлгермичә төпкә китеп баргандыр.
(«Сусанинчы» агайларның чәкүшкәсе
хәер, йөзеп чыгар иде ярга бер.)

Баштанаяк яшенле уй яшьнәп үтте:
«Туры килә ахмакларча үләргә!..»
Архимедтай ачыш ясап булмый монда —
мәгънәсезлек — ә җан белән түләргә.

...Үшнә җәе. Көнгә җиде коенулар...
Әллә хәтер күреп ала төшләр дә?!
Көнгә җиде... Ә биредә бер коену
мөмкин икән бик кыйммәткә төшәргә.

Ә аяклар әле яхшы хәтерлидер
төпкә кадәр ката торган Шушаны.
Бозга кайчак артыгырак таяныла —
җирне тою ышанычы кушамы?!

Таянычсыз боз гынамы? Көрәшчене
хәтта әле хәтәррәк тә ега җир.
Чакырулы ачы йөрәк авазы да
шундый хәвеф янаганда чыгадыр:

«Революция куркыныч астында!..»

Көтмәгәндә, тайгак боздай, йомшак кына
җирең китсә баскан аяк астыннан!..
Андый хәвеф ерак йөрми. Атламыйсың
Невскийның тротуары ташыннан.

Таянычсыз боз гынамы? Гыйсмәт бабай [1]
әзерләгән сынауларның күп төрен.
Тукталмыйча гел үтәргә — кылдан нечкә,
ә кылычтан үткен сират күперен.

## 2

Мәкер бозы гомер буе әзәрлекле:
еккан, кыскан, кискән, изгән, батырган...
Гладиатор мәйданыдай канга сусап,
кешеләрне көрәшергә чакырган.

Икеләтә хәвефлерәк — бәрелешү
йоклап яткан аждаһаның өстендә.
Көч буләргә туры килә боз мәкерен
дошманыңа каршы борыр өчен дә.

Алыш өчен аяк астын ныгытканда
күкрәгеңнән күпме хәләл көч кими.
...Чуд бозлары ничә канны коктейльдәй
кушып эчкән — калынаер өченме?

Җиңүләрдән баш әйләнеп исерсәң дә,
бик таянма — боз ул һәрчак ап-аек.
Күл өстендә күзләвекләр, канлы күздәй,
корбанына карап тора акаеп.

Тевтон башы боз-көзгегә карап каткан,
кылыч белән кырынасы иткәндәй;
ә сөңгесе терәү булып басып тора,
иттән туеп, су төбенә киткән дә.

Йөрәк-учак урыннарын яшергәндәй,
күл өстенә шәфәкъ суы җәелә...
Асыл ирләр сатлыкҗандай ышанычсыз
бозга ничек таянырга җай белә.

Үзләренә буйсындыра белә алар
аяклары астындагы капкынны.
Ә Чуд суы янартаудай актарыла —
кабул итә алмый ахры ят канны.

---

[1] Татар халык табышмагына — балтасыз-нисез, ягъни боздан күпер ясаучыга ишара.
Автор искәрмәләре.

Боз ул шундый: сарык төсле укмашканнар —
бер-берсенең муенына таш монда.
Туңлыктагы мамонтлардай, күпме башлар
туңып кала зәңгәр юрган астында.

Таянылган җирдән язып, дошманыңның
ныклыгына башың бәреп ват кына,—
барып төштең, димәк, тарих төпкеленең
үзең өчен билгеләнгән катына.

* * *

Мәкер бозы гомер буе ээәрлекли:
еккан, кыскан, кискән, изгән, батырган...
Сабан туе мәйданыдай ымсындырып,
кешеләрне бәрелешкә чакырган.

Кылдан нечкә, ә кылычтан үткен сират —
түләүле юл (һәркем өчен хакы бер).
Бөек Әтил бозында да сугышканнар —
сәяхәтче Әл-Гарнатый хаклыдыр.

Кабан белән Казансу да хәтерлидер
«традицион» канлы йодрык сугышын.
Орышканнар, боз өстендә бәргәләнгән
балык төсле еш-еш алып сулыш-тын.

Сайлаганнар нигә йодрык дуэленә
көзнең көзге калынлыгы боз өстен?
Хәер, әйдә, кыр кәҗәсе гадәтенчә
кара упкын авызында сөзешсен.

Карлы бозга кан агызу һәм түшкәне
атып бәрү көрт-суыткыч эченә —
йодрык белән куйдан тире салдыручы
итче өчен гадәти бер эш кенә.

«Боз сугышы»н аерата комарланып
көткән алар — тореодор шикелле.
Һәм толчукчы татарлар да, кибет тоткан
урыслар да кул уйнаткан бик җилле.

Яссы герләр әзерләнгән, тәнне язып,
тешләр санау әмәленә күчәргә
һәм берочтан күн бияләй хуҗасының
(мөмкин булса) кансызлыгын үлчәргә..

— Хак гыйнаять әйләр ирсен!..[1]

Бөтен базар дәррәү куба! Кабан бозын
буләләрме әллә тере су өчен?!
Тамашачы ике яклап тезелешә,
карагандаи гладиатор суешын.

Кесәләрдән («кын»нарыннан) яшьнәп чыга —
йодрыкларга легальләшкән хөррият!

---

[1] Алла ярдәм итсен!..

Бармаклардан — канлы төен — нәрсәләрне
онытмаска кирәклеген бер өйрәт.

— Әһле ислам! Иманнарын укытыек!
— Борынына кызыл таракан җибәр!
— Иреннәре кычыткандыр — кучтәначтән авыз итсен...

— Покажи, где раки зимуют!
— Танау астына ут элдер!
— Башы эшли башламасмы ләгыйньнең...
— Кәҗә маен чыгар!
— Знай наших!..

***

...Китте, ди, таеп,
төште, ди, авып.
Ыштан төбе ярылды, ди,
кыярлары коелды, ди...

«Бозда цирк...»

Йодрык түгел, билләһидер, яшен ташы
селәгәйле бияләе эчендә!..
Ә тегесе, чия төшен төкергәндәй,
төкреп атты утыз ике тешен дә.

Кышын бала чыгаручы чукырларның
кар өстенә тәгәрәгән күкәе —
тын-кан белән бозны уеп кергән борын —
тору түгел, селкенергә юк җае.

Көндәш йодрык көянтәдә чайкалучы
каз түшкәсе чаклы бардыр — кул таза!..
Бирешмәскә туры килә, уңындагы
бармакларың дүртәү генә булса да.

Кабан бозы — канлы күзге. Дөньялыкны
дөрес итеп чагылдыра кай ягы?..
...Мәчет ае катып калган, ятимлектә
ябышкандай бөек Апуш аягы.

Илаһи йодрык...

Бөек бозлык мамонтларны таптагандай,
телне дә ул бозга салып таптармы?
Бәкеләрдән бәреп чыга кайтавазлар:
— Кыйнамагыз, кыйнамагыз татарны!

Ике яклап тезелгәннәр. Ә бер читтә
граф Толстой (?) — төшкән бугай балдан соң.
Очы-очка бәйләнәме? Күңеленнән
кыйнауларны бер-берсенә ялгасын.

Ике лачын сугышканда, ябалакка
йон булыр, ди, ябалакка йон булыр...
Чыраена бәләк кадәр йодрык төшсә,
авыз һәм күз, имеш шундук йомылыр.

Сабый чакта ләйсән-яшьле күзне сөрткән
йодрыкларны монда кемнәр өстертә?

«Көчленеке замана», дип, кулны бору
алымнарын файдаланып эш йөртә
кемнәр?

Секундантлар, беләсездер, аңлатыгыз!
(Усаллыкның башы һаман Тазданмы?)
Беркайчан да кабул итә алмый тарих,
канга манып, йодрык белән язганны.

Бозда — орыш... Көчләрне ачыклаумы,
яшәр өчен хокук яулап алумы?
Мондый бөек сайланышта ярдәм итми
анархистик илаһ йодрык алымы.

Мәнсез төен (бала башы зурлыгында)
шуны гына төшенәдер: «Сал берне!..»
«Дежур» Дантес кыяфәтле йодрыкларның
очсыз данын боз күтәрә алырмы?

* * *

Ит базары. Йөрәк китерделәр —
мамонт йөрәгедәй катканы...
Әллә нигә бик тә авыр итеп
тартып килде йөкче ат аны.

Йодрык-йодрык йөрәк — кисәкләрдә
унбишләбе бергә бозланган.
Аз-маз сибеп, туңын кайтарырга
итче үзе белән тоз алган.

Йөрәкләрне китеп алыр өчен
ярдәм итми мондый көч кенә;
күтәрде дә бәрде идәндәге
ике потлы герләр өстенә.

Һәм йөрәкләр, вулкан катмарыдай,
төрле якка китте чәчелеп.
...Чират башында бер әби тора,
керфегенә тамчы яшь элеп.

Салкынлыктан гына яшьләнгәндер
(күз алмасын сыккан соңгача).
Боз сөңгесе төсле тезелешкән
кешеләрне никтер моң баса...

Прилавканы шундый айсберг
ничек җимермидер — карачы!..
Менә кайчан якыная икән
йөрәк белән йөрәк арасы.

Күперләрнең кары арчылырмы
халык йөрәгенә тоз салгач?
Аралары, әйе, якыная
йодрык-йодрык булып бозлангач...

Тыңласыннар алар берсен-берсе,—
салкын акыл, бүтән юл кайда?

Йөрәкләрдән әле бозлык чоры
үтеп бетмәгән бит болай да.

Әгәр йөрәкләрне салкын сугыш
шулай бозландырып катырса,
бушанырга кеше табалмыйча,
илдән-илгә кара хат йөрсә,
һәм кешелек чыкса чыгырыннан,
тотынырга булмас салам да;
Кызыл китап битләренә төреп,
сатып ятса Әҗәл талонга
йөрәгеңне,— әле өстәп кенә
бирәр динозавр тешенә...

Тынычланмыйк: бу, дип, гадәттәге
куркынычлы яман төш кенә.

* * *

Кабан бозы — канлы көзге... Мәкер кора
карагруһчы җантимерләр штабы:
«Бирәр татар рабочиен үтертергә,
үтерүче... урыс булсын чтобы!..»

Беркатлыга гаҗәбрәктер: ничек инде
бер-береңә шундый гөрзи ор юкка?!
Күпләр аңлый — җанын кемнәр ауламакчы,
ышыкланып марионетик йодрыкка.

Бүген берсе йодрык ашый, ә иртәгә
ашатканы үзе йодрык ашаса...
Йөрәкләрне яулап-биләп алу юлы
үтәмени шушы йонлач таш аша?!

«Биштән үргән» мәнсез йодрык... Ә бит үзен
бердәмлеккә һәйкәл итеп буладыр!
Чынбарлыкта куздән очкын чәчәргә дә,
оннан камыр изәргә дә ул әзер.

Учка нидер йомган төсле, карында ук
йодрыклана кыз бала да, ир җан да.
Һаман шулай йомарланган хәлдә булса —
көрешүче, мә, дип, бишне биргәндә?!

(Әти мәрхүм йодрык белән капшап белгән
атның кайчан колын алып кайтасын.)
«Рот-фронт!» дип йомарланып бармаклардан
ничек әле селәгәйле кан тамсын?!

...Үтерелгән парламентер әләмедәй,
түшәлә кар... Әллә ява конфетти?!
Йодрык ашап торганнары туядырмы,
ә ашаткан наемникка көн җитми.

«Калинка»га биючене зурлаган күк,
чәчәк таҗы яумый Кабан бозына;
теткәләнгән байрак кебек, җәеләдер
җәрәхәттән тамган канлы тоз гына.

«Кызыл күзләр» белән тулы зәңгәр келәм —
кинәт тартып екмасыннар — карап бас!..
...Көн кадагы... Йодрык шуңа сугалмыймы?..

Боздан сынап бага сыман Карабаш[1]...

Боз өстендә учак ягып җылынырга
омтылулар тәмамлана ни белән?
Таянылган уртак җирең китеп барса,
була алмый җиңгән белән җиңелгән...

3

Казан циркы. Рауза атлы татар кызы,
кертеп төрле кыяфәткә буй-сынын,
хәтәр сират күперсдәй кыл өстендә,
гыйбрәт итеп, уйный үлем уенын.

Шундый уен... Ике яктан Яхшы-Яман
тартып торкан неп-нечкә кыл өстендә!..
Корридамы? Әйе, шуны хәтерләтеп,
бәрелешә капма-каршы көч монда.

Кулда комач җилфердәвен җене сөймәс
ерткыч булып уйный шул ук кешеләр.
(Ә кстати, үгез, имеш, дальтоник, ди —
аералган ике генә төсе бар.)

Шашкан үгез тиреҫендә... Канга сусау
күзгә чыга — сөймәсәң дә кан төсен.
Комарлыктан онытып та җибәргәли
фаҗигале кыл өстеннән атлыйсын.

Әле бер хәл сугыш-патша копилкасы —
«дуңгыз»ларның Чуд төбенә китүе.
Ә кешелек кылыч буйлап атлаганда
көтеп тора хәвефлерәк ит туе.

Аяк асты ай-яй хәтәр: тетрәп тора,
упкын өсләп сузылгандыр кыл елан.
Фәрештәләр канатына килеп төшми
мондый үлем уенында егылган.

Ә хәзергә бәла башы түбәсендә
каршы көчләр бәрелешә йөзгә-йөз.
Ике як та тарта кылны, «Без йә сез»нең
кайтавазы ишетелә: «Өзмәгез!..»

Нәрсә булыр өермәдә ауган агач
бәгыредәй үзәк тамыр өзелсә?!
Йомшак, нәфис, нәзакәтле зат өстенә
кыя таудай ябырылып боз килсә...

Албастылы карурмандай өскә ава,
куркынычлы кара төндәй ишелә!..

---

[1] Гитлерчылар тарафыннан бозда катырып үтерелгән генерал-лейтенант Д. М. Карбышев күздә тотыла. Геройның истәлекләрендә әйтелгәнчә, аның бабалары татар булган һәм «Карабаш» кушаматы йөрткән.

Шашкан үгез! Мондый котсыз кыяфәттә
аңа бөтен афәтләр дә иш килә.

Комач аша кадар да ул, Җирнең үзен
мөгезенә эләр төсле бер тында.
Сөяккәчә батырылган канлы уклар
камыш сыман чайкалыша сыртында.

Алты хәнҗәр... Җирнең алты кыйтгасыннан
алты нәфрәт угы булып очканмы?
Шашкын канның исертүе... Ә хәзергә
җилкендерә әнә шундый көч аны.

Кыска-кыска алты сөңге... Серафимның
өтәләнгән тәгәл алты канаты...
Очынса да тигезлекне саклый алмый —
җан да гөжләп чыга бара кан арты.

Ике мөгез арасына халыклардан
Әҗәл угы алачагын сизенә.
Шулай да ул бозга баскан бозау сыман
егылырга исәпләми тиз генә.

Ә көндәше кыл өстеннән җырлап-биеп
якынлаша: «Син басмасаң, мин басам!..»
Көбә күлмәк капламаган тән алдында
сихерләнеп тукталмый да ичмасам.

Чикмәсә дә, тартышкандай, чүгеп куя —
мондыйларны матурлык та куркыта.
Җәһәннәмнең аръягында көндәш түгел,
уйнак тәнле ымсындыргыч хур көтә!..

Ачык күкрәк... Ә бит аны сәнәктән дә
хәвефлерәк ике үткен япь көтә.
Шулай да ул кыл өстеннән җырлап-биеп
якынлаша: «Ба-ас, кызым, Әпипә!..»

* * *

...Сабан туе. Колга-сират,
чайкаладыр оч ягы...
Ә биредә егылганны
көтми егет кочагы.

Ыштан төбе ярылды, ди,
кыярлары коелды...
Увертюра әллә нинди
матәмчәрәк көй булды.

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Кыярлары коелды, ди,
бала-чага җыйды, ди...
Ни ул кыяр? Монда башны
югалтырлык па-де-де.

Боздан чыксаң, алдан чык син,
судан чыксаң, арттан чык.
Кыл өстеннән балансирсыз
үтмәк була, мактанчык...

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Бер аягын атлаганчы,
икенчесен эт ашый.
Үгез түгел, ә мөгезле
коңгыздыр ул, билләһи!..

Тез буынын тикшергәндәй,
астан күзли, ах, йолкыш!..
(Һаваланма: аягыннан
эләгер, ди, асыл кош.)

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Бер үгездән ике тире
тунамыйлар, шулаймы?
Аркан саклый... Әгәр афәт
элмәк итсә шул бауны?!

Әгъвалаучы юха кыздай,
кызыктырып алдаса?
Ә монысы инде бозга
утыртудан да аша.

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Юха кыздай йотар өчен
тора төсле уй корып...
Искәрмәстән икәвен дә
бушлык алса суырып?!

...Бибкәй матур биеп килә —
суы ничек түгелми!
Сынын бигрәк хәтәр чайкый —
Сөембикә түгелме?!

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Дәрьяларны матурлыкмы,
матурлыкмы кичтерә?
Аның әле үзен дә бит
күтәрергә көч кирәк.

Юк, матурлык очыналмый
башта уйнар җил белән.
Ухват төсле эләктереп
алса мөгез билеңнән!..

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз.

Ә каршыда, күзен сирпеп,
тыпырдамый Хәйбулла...

Бишектә дә егылудан
саклый торган бау була.

Җирдән түбән төшмәссең, дип,
юатмыйлар биредә.
Язмыш — уртак: шул ук кылга
бәйләнгәндер Җире дә.

Басыгыз, басыгыз,
әйләнмәсә башыгыз...

• • •

...Харакири пычагына җырлап-биеп
якынлаша: «Син басмасаң, мин басам!..»
Ә тегесе гаҗизанә тән алдында
сихерләнеп тукталмый да ичмасам.

Кансызлана барган саен, котырынкы
йөрәгенә вакытлыча көч иңә.
Янар күзләр каш астыннан сөзеп карый,
карагандай мөгезенең очына.

Ә мөгездә вакыт сыры арта бара —
үткенләүме, үтмәсләүме — кем белә?!
Шунсы ачык: корбан сорап торган очы
үз башына табарак та бөгелә.

Ярый әле астыртынга әйләналмый,
дуамаллык гомер җебен киссә дә.
Сөзәчәген яшермичә әйтеп сала,
йодрык төсле качып тормый кесәдә.

Ничек инде күкрәк ачып, җырлап-биеп,
куркынычлы кыл өстеннән бар шуңа?!
Ике кулга ике мөгез шәраб тотып,
көйли-көйли килмиләрдер каршыңа...

«Рәхмәт юлы» түгел сират — фәрештәләр
менеп-төшеп йөри торган юл ише...
Түләүле юл — узар өчен каның белән,
ә егылсаң, башың белән түлисе!

Кыл өстеннән тәгәрәтеп барган чакта
йөрәкне дә югалтырга бик көйле.
Катып калсаң башсыз җиңү алиһәсе —
канатлы кыз Нике сыны шикелле?!

Канатлары яндырылган Сөембикә
фаҗигасе әллә тагын сыный бер?
Кылыч-сират. Аста — яра. Тирәнлеге
хәтта башка, хәтта башка сыймыйдыр!..

Үзәк тамыр... Паганини кылларының
өзелсәме иң-иң соңгы төп кылы?!

Риваять тә калмаячак — егылганны
тотып калыр нинди хәтер төпкеле?

Өзелсәме? Бөтенесен юклык йотар —
алмасын да, алмадагы кортын да.
...Ә Җир шары мөгезләрдә тора, имеш,
үгез исә йөзә балык сыртында...

4

...Бара иде, ди, боз буйлап,
киләчәген уйлап,
китте, ди, таеп,
төште, ди, авып...

Очрашканда дустың башка карый, диләр,
ә дошманың күзен алмас аяктан.
...Бозда Апуш табаннары, канлы-канлы
айбалталар белән бергә Ай каткан...

Зәңгәр якут... Йөрәк-учак урыннары...
Яна-яна уеп кергән шәм-чыраг...
Алдашучан канлы көзге... «Кайсы юллар,
нинди упкын тарта безне җан сорап?!.»

Кагылулы-сугылулы корабыңны
мамонтларны изгән бозлар он итсә?!

«Гошер» шундый: башы белән түли кеше
кылыч буйлап атлаганын онытса.

Астыртын боз гомер буе эзәрлекли,
алга куеп сынауларның күп төрен.
Тукталмыйча гел үтәргә — кылдан нечкә,
ә кылычтан үткен сират күперен.

* * *

...Кырык бишнең унберенче февраль таңы...
Әйләнде дә куйды Пасмар [1] сиратка.
Ни ул бозны астан терәү атлант сыман
күкнең үзен күтәрерлек ир-атка!..

Тагын сират. Аргы якта оҗмах түгел,
оҗмахтан да кадерлерәк Җиңүдер!
Җиңү өчен нәрсә тора ватандарга
терәү булып боз астына иңү бер.

Каршысына тагын көзге ыргыттылар
Җиңүгә бер, тик бер адым калганда...
Чит җир бозы бигрәк үчле. Күпер булып
ята ала хәтта трофей калкан да.

Ә боз?!

---

[1] Элекке Көнчыгыш Пруссиядәге елга.

«Тормыш юлы» мәхшәрендә Икмәк үзе
батканда да калкып чыга — боз батмый...

Пасмар суы артып китте, килеп кергәч
Фатих Кәрим — пегас-атлы взводный.

Ай, дуслар,
нурлар алыйк,
юллар салыйк,
гөлләр кадыйк маякка,
гөлләр кадыйк маякка!..

Карасана, бөтен ярга гаскәр кеби
тезелешкән саф-саф татар зелпесе!
— Изрәү җирне шулар белән ныгыталар...
— Шулай арта,— диде шагыйрь,— ил көче.

Бозламыкка кереп китте — Ахилл батыр
атлап керде үлемсезлек суына.
Өшетерлек утлы суда җылытала
Туган илең турындагы уй гына!..

Кереп китте, гөнаһлы җир керен сөттә
юмак булган языклыдай ашыгып.
Язга таба!.. Боз-сөңгеле кырку таллар
ике якка тайпылышты яшь сыгып.

Кылыч йөзе... Йөрәк итен җиңүгәчә
тагын күпме телгәлисе бар әле.
«Илгә генә кайтар, сират, ә җәннәттә
яза алмас хәтта миндәй яралы...

Кыл өстеннән халкым алга үтсен өчен
терәү булам — иңгә өрлек куй гына!..»

...Соңгы күпер... Пегас-атлы Фатих Кәрим
кереп бара үлемсезлек суына.

Ай, дуслар,
нурлар алыйк,
юллар салыйк,
гөлләр кадыйк маякка,
гөлләр кадыйк маякка!..

* * *

Әти сөйли, әти, авылдашлар
атаганча, Мансур Мөҗибе:
—...Кырык өчтә бугай, «тел»гә киттек,
үтә салкын кара көз иде...

...Борын төрттек кенә — башкисәрләр
пәйда булды төнге хуторда.
Чарасызлык!.. Әһә, төш-кит эчкә,
кое чиләгенә утыр да...

Тирән түгел үзе, әмма, каһәр,
сынып төште сиртмә колгасы.

...Заманында шундый чокырларга
тәгәрәгән, диләр, фил башы...

Штабтагы шау-шу гына тынсын,
чыгып булыр әле — көч бар ич.
Тик бәкесе — аяк баскан бозы
убылырга тора, сволочь!..

* * *

Тагын да боз... Мәңге шулай буталырмы
кешелекнең аяклары астында?
Адәм башын идермәкче язмыш төсле,
таләп итә: «Анда басма, бас монда!..»

Тартылулы бикфорд бавы булып яткан —
буйдан-буйга аяк аслап ут йөргән.
...Бөек бозлык... Кара язмыш колы итеп,
мамонтларның бугазына утырган...

Хәтта шундый гигантларны буйсындырган:
«Башың алып, артка таба чап-йөгер!»
Зәгыйфь төшне табып чагар Парис угы —
мәкер бозы һәрчак астан капшыйдыр.

Табаныннан кереп еккан зәхмәт төсле,
адәмнәрнең башын әллә аз кырган?!
Язмышларны ярларыннан чыгарган да
дәрьяларны юлларыннан яздырган...

Мил-ли-он-лап еллар элек Әтил суы,
уңнан килеп, койган, диләр,... Чулманга.
һәркайсысы, дәрәҗәсен белеп кенә,
үзәненнән агып яткан шул җайга.

Бөек бозлык өскә ауган!.. Яәҗүҗ-мәәҗүҗ...
(Кыяматнең чыны менә ул кайда!..)
...Олырагы кушылдыкка әверелгән —
дөньялыкта була икән шулай да...

...Кагылулы-сугылулы корабыңны
мамонтларны изгән бозлар он итсә?!
«Гошер» шундый: башы белән түли кеше
кылыч буйлап атлаганын онытса.

*Тарих юлы*
*Невский проспектындагы тротуар түгел:*
*ул буеннан-буена*
*йә тузанлы, йә пычрак кырлар аша,*
*йә сазлыклар, йә карурманнар аша бара.*
*Кем тузанга батудан*
*һәм итекләрен пычратудан курка,*
*шул кеше иҗтимагый эшкә тотынмасын!..* [1]

---

[1] Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин революцион демократ Н. Г. Чернышевскийның әлеге сүзләрен аеруча яратып кабатлаган.

Юл газабы — гүр газабы... Кемгә җиңел?
Табылырмы бирәү генә булса да?
Тәмле ашап алга барган алма корты?!
Ул бит шулай әҗәленә юл саба!..

«Рәхмәт юлы» түгел сират — фәрештәләр
менеп-төшеп йөри торган юл ише...
Түләүле юл — узар өчен каның белән,
ә егылсаң, башың белән түлисе!

Ә кешелек кыл өстеннән атлаганда,
тәрәккыйның хакы төшә күпмегә!..
Сират һаман корбан сорый... Аяк асты
тетрәгәндә тынычлану юк мигә.

Миләр тетри... Утта көйгән гаҗиз табан
юлыкмасмы фаҗигале бер укка?
Дилеммалар баштан чыксын: алда — бер юл —
хәвеф кылын ярып булмый кырыкка!

Боз өстендә учак ягып җылынырга
омтылулар тәмамлана ни белән?
Таянылган уртак җирең китеп барса,
була алмый җиңгән белән җиңелгән.

«Һомо сапиенс» — Кеше-гакыл иясе!

Саклый ала Кеше үзен, аклый алса
ыруглыктан килә торган асылын!

...Аяк атлый сират өсләп, табан тоя
Невскийның ышанычлы таш юлын.

Меле — Нагу... Өчләп чакрым... «Тормыш юлы» —
төгәл утыз... Җиңүләргә юл башы...
Тәрәккыят! Алда көткән хәвефләрнең
билгелеме ничә чакрым буласы?

Тукталмыйча гел үтәргә — кылдан нечкә,
ә кылычтан үткен сират күперен,
сиратларның күп-үп төрен...

...Бара иде, ди, боз буйлап,
КИЛӘЧӘГЕН уйлап...

1984—1985

# Мәхмүт Хөсәен

## Җиңүче каһарманга

СОНЕТ

Иңдә тарттың йөген сугышның,
Язмышың ил белән бәйләнде.
Батырлыклар тулы тормышың
Дастаннарга, җырга әйләнде.

Дөмектереп фашист шакалын
Җиңү таңын син ул аттырдың.
Туып-үскән Идел-йорт данын,
Ил абруен син ул арттырдың.

Авыр яралардан аусаң да,
Әҗәл белми синдәй батырлар.
Утта янып көлгә калсаң да,
Һәйкәл куя сиңа гасырлар.

Җиңү алып килгән каһарман —
Мәңгелек ут булып янар җан.

## Далам таңнары

Кем соң белми ана җаны төсле
Иркен, якты Җаек каласын?!
Шунда калган балачагым эзе,
Тәпи баскан яшел паласым.
Тууыма, ак биләүгә билап,
Ак тирмәгә алып кайтканнар.
Сау-сәламәт үсүемне теләп,
Алсуланып таңнар атканнар.
Синең, кояш, уттай кызу нурың
Күзләремнән үбеп уяткан.
Әнкәй мине — уймак кадәр улын,
Үчти-үчти иткән, уйнаткан.
Җәйләүләрнең җылы җилкәйләре
Чәч бөдрәмне сыйпап искәннәр.
Җайдак бул дип, казах җиңгәйләре
Уенчык тай бүләк иткәннәр.
Үсә төшкәч, чын атларга менеп,
Күнектем мин җилләр куарга.
«Туган тел»не сөйләп, җырлап, биеп,
Концерт куйдым көткән куйларга.
Милли моңны, Тукай шигырьләрен
Әбекәем миңа өйрәтте.
Арта барган яңа шөгыльләрем
Эш сөючән итте йөрәкне.
Камчы асып уздым озын юлны,
Камчы шартлау — көтү кануны.
Юлдаш булды миңа, моңдаш булды
Думбра белән әткәм гармуны.
Яшен сукты кинәт аяз көнне:
Думбра тынды...
Гармун дәшмәде...
Илгә басып кергән иблис тиңе
Утлы афәт булып яшьнәде!..
Әти белән бергә киттем яуга,
Ил ирекен утта якладым.
Хәер-догам итеп йөрттем янда
Әниемнең язган хатларын.
Ядрә белән дошман җирен сөрдем,
Сынатмады яуда тупларым...
Малай килеш иргә әверелдем
Кичкән чакта тәмуг утларын...
Җиңү белән котлап кырларымны,
Тибрәнделәр думбра кыллары!
Телгә килде тальян:
Җыр агылды —
Яуда ауган әткәм моңнары...

Солдат әткәемнең изге моңы
Минем күзләремдә яктыра!..
Булсам да мин күптән Идел улы,
Алларымда туган як тора.

Чәчәк күмгән тау-тау барханнарны,
Ком чүлендә күлләр тирбәлә...
Төштә күрәм яшел киң даламны,
Омтыла җан газиз җирләргә!..

## Яшьлегемне саклыйм йөрәктә

Яшьлек, яшьлек!
Син — тау гөлләренең
Таҗларына кунган таң чыгы.
Бик кадерләп саклый күңел синең
Ләйсән булып сеңгән тамчыңны.

Яшьлек, яшьлек!
Җиләсең җил кебек,
Чишмәләрдәй җырлап чабасың.
Дәртле утың дөрли йөрәгемдә,
Сафлыгыңны саклый карашым.

Яшьлек, яшьлек!
Тере яшендәй син,
Син — яшькелтем болын гомере.
Ниләр генә бирмәс идем хәзер,
Яшьлегемнең кайтса бер көне!

# Роберт Рәкыйпов

Минем Ватан кайдан башланамы? —
Каеннардан, дустым, каеннардан.
Газапланма санап, алар сансыз —
Барысы да әнә яфрак ярган.

Минем Ватан кайдан башланамы? —
Кәрниздәге кошлар оясыннан.
Кошлар алар бик күп — җырлар белән
Күңелләргә генә сыяр сыман.

Минем Ватан кайдан башланамы? —
Арышлардан, дустым, арышлардан.
Башак саен бәхет. Шушы җирдә
Кояш белән Кеше кавышканнар.

Минем Ватан кайдан башланамы? —
«Әллүки»ле газиз әнкәйләрдән.
Чукоткадан Балтиккача булган
Әткәйләргә куйган һәйкәлләрдән...

## Төньяк океан

Төньяк океанның өч диңгезе,
Поляр параллельләр кискән җирләр.
Безгә монда бакыр таңнар ата,
Октябрьда буран куа җилләр.

Сүнеп бара озын төньяк көне,
Күзгә томаннарда Вайгач яры.
Салкын тауның гранит күкрәгендә
Юешләнә эрбет агачлары.

Чыңлый дулкын сары күбекләрдә,
Кораб бортын кага шашып-шашып.
Чын салкыннар әле бераз алда,
Иллюминаторлар чүт-чүт ачык.

Тынып кына Җидегән йолдыз эри
Шомартылган кубка җизләрендә,
Мачтадагы вымпел өзгәләнә
Октябрьнең биләм җилләрендә...

Тонык фонарь пеләш башын чайкый,
Шыгырдыйлар нык тартылган баулар.
Борчылмагыз анда, сөйгән кызлар,
Барыбыз да саулар әле, саулар...

# Нур Әхмәдиев

## Кышкы учак

Кышкы урманнарда учак ягыйм,
Диеп күпме, күпме хыялландым.
Шул учакның, үзем якканчы ук,
Ялкын утларында күпме яндым.

Кышкы учак нигә кирәк булды? —
Әсир итте кышның аклыклары.
Кирәк түгел тормыш ваклыклары,
Җитә миңа булган шатлыклары.

Кышкы урманнарда учак ягам,
Диеп хыялландым, ягалмадым:
Бәхетемнең очкын чыгарырлык
Чакматашын әллә табалмадым?

Чакматашы бүген кулларымда,
Урман да бар, инде карлары юк.
Парлар да күп — сине таный торган,
Сине аңлый торган ярлары юк.

Кышкы урманнарда учак ягам,
Диеп күпме, күпме хыялланам.
Учак ягу, бәлки, кирәк түгел? —
Болай да бит янам, дөрләп янам.

## Фасыллар

Мин язларга керсәм,
Сиздермичә
Күзләр карый офык артыннан.
Яшьлегем дә минем яз шикелле —
Кай арадыр сырлар тартылган.

Язлардан соң беләм җәй киләсен,
Алышынасын аның көз белән.
Мин язларга кабат кайткан чакта,
Нидер сынган, нидер өзелгән.

Алмашына елның фасыллары,
Бездән сорап тормый алмаша:
Хыянәтсез карап торган күзләр
Чегән хатынысдай алдаша.

Гомеремнең бу мизгеле җәйдер,
Ә күзләре, беләм, ерактыр,
Әле язмыш мине йөз мәртәбә
Елатыр да тагын юатыр...

# Хәниф Хөснуллин

## Алтынчы автобус бара

Алтынчы автобус бара,
Бара иске шәһәрдән.
Башка җирдәге урамнар
Яшь йортлардан яшәргән.
Юл читендә күлләвекләр —
Җәйнең яңгырлы көне.
Сак кына бара автобус —
Бәхет төягән кебек...
Ян-яктагы тәрәзләргә
Яңгыр борчагы куна.
Ике кыз бала елмаеп,
Куанып бара шуңа.
Яңгыр бөртекләрен учлап
Берсе тотмакчы була.

Авызын ачып, иптәше
Барып йотмакчы була.
Аларның уйнавын күреп,
Яңгыр шатлана кебек,
Болыты белән тәрәзгә
Килеп каплана кебек.
Сукрана өлкән кешеләр:
— Туктармы икән яңгыр?
Ике кыз бала ялвара:
— И, яңгыр, тагын там бер.
Алтынчы автобус бара,
Юлчылар көен көйләп.
Тукталышта төшеп калам,
Ике кызга — озак яңгыр,
Зурларга — аяз теләп.

## Балачак хатирәсе

Тау астында агып ята әкрен генә,
Юеш комы, вак ташлары, төсе якын.
Ярларына ята-ята эчкән суы
Еллар аша саркып тора — шундый салкын.

Барасың да, кайтасың да җәйләр җитсә,
Ул чакларның юанычы: урман, җиләк...
Ә чишмәнең моңын һаман көйли күңел,
Тәмен генә булмый аның һич тә сөйләп,

Көтү юлы үтә иде чишмә аша,
Коштай җилеп, күпме уздык юртакларда.
Омтылганбыз, ашкынганбыз икән шулай
Туган илнең олы уен уртакларга.

Янды учак. Учак, гүя, алтын тавык,
Кемнәр аңа утын-агач әрәм, дисен...
Ә астында йомыркалар сыман ятып
Пешә иде көтүчеләр бәрәңгесе.

Үтә вакыт. Ә мин һаман әйтәм аңа:
— Китми тор син хәтеремнән, зинһар, китмә,
Җиләкләрең бүләк иткән җәйге урман,
Тояк тавышы,
Төнге учак,
Салкын чишмә.

## Гарифҗан Мөхәммәтшин

### Офыкларым

Ашыгам, омтылам алга,
Максатым шушы гына —
Җитим әле тизрәк барып
Алдагы офыгыма.
Анысына җитсәм, алда
Ачылыр яңалары,
Бездә күпме серләр бар, дип
Ашкындырыр алары.
Офыклардан офыкларга
Ашкына күңлем минем...
Ачылмаган офыкларны —
Гомерлек кәгъбәм, димен.

❁

Каерылып-канап сынса да
Иңнәрендә канатлар,
Кошлар омтыла югары:
— Югарыдан карап кал
Туган җиргә!— дия кебек
Соңгы сулышларында...

Батырлар йөрәге сыман
Йөрәге кошларның да.

## Сафуан Муллагалиев

### Ничек дөнья суынсын

...Инде күкләр күкрәмәс тә,
Яңгырлар яумас, димә.
Мәңгелек юлында кайнар
Кеше йөрәге тибә...
Җылыта салкын көннәрне,
Утлар капса — сүрелтә...
Табигать — ана җаны күк,
Үзе сулар сибеп тә
Үстерә күңел талларын,
Күкрәтә сер күкләрен...
Уйлый төнлә, уйлый көн дә
Иртәгесен, үткәнен...
Белеп тибә кайнар йөрәк,
Мәңгелеккә тоташып.
Яңгыр яумаса, имәнне
Үстерә сулар ташып...—
Үстерә тормыш имәнен,
Күл итә иңкүләрен.
Бәхет — кайнар йөрәк белән
Дөньяга килүләрең...
...Үсә кеше, акыл белән
Тыңлап галәм сулышын.
Мәңгелек юлында кайнар
Йөрәкле кеше булганда
Ничек дөнья суынсын?!

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Уральск (Җаек) шәһәрендә Орджоникидзе һәм Некрасов урамнары чатындагы Епифанов кибете урнашкан йорт. Тукай биргә клиндер алырга йөргән.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ДАГСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Күп гасырлы кешелек тарихы дөньяга бик күп акыл иялəре биргəн. Аларның шəхеслəре һəм иҗат нəтиҗəлəре гасырлар һəм дөнья киңлеклəре аша үтеп, килəчəк буыннарның да акылларын һəм йөрəклəрен дулкынландыралар. Үзенең күпкырлы иҗаты белəн үлемсезлек яулаган хөрлек һəм көрəш шагыйре, кешелеклелек җырчысы, татар халкының бөек улы Габдулла Тукай — шуларның берсе.

Үз халкының борынгы шигърият чыганакларыннан көч алган, Европа һəм бигрəк тə рус демократик культурасының алдынгы алымнарын үзендə берлəштергəн Габдулла Тукай иҗаты тугандаш татар халкы əдəбияты тарихында гына түгел, башка көнчыгыш халыклары əдəбиятлары тарихында да мəңге җуелмаслык эз калдырды. Дөнья халыклары культурасын Пушкин, Толстой, Шолохов, Шекспир, Шиллер, Гете, Драйзер, Тагор һ. б.ның əдəби мирасыннан башка күз алдына китереп булмаган кебек, милли əдəбиятларны да Тукайның иҗади даһилыгыннан башка күз алдына китерү һич мөмкин түгел. Аның иҗаты күпмиллəтле Дагстан əдəбиятлары тарихында да сизелерлек эз калдырды. Таулар иле əдəбиятларының унысына да — кайберсенə турыдан-туры шагыйрьнең үз телендə чыккан əсəрлəре аша, кайберсенə арадаш халыклар əдəбиятлары аша — Тукай иҗаты уңай йогынты ясаган дисəк, һич тə арттыру булмас. Моны əдəби чыганаклардан да ачык күрергə мөмкин.

Гасыр башында лак халкының бөек мəгърифəтчесе, күренекле җəмəгать эшлеклесе, революционер, публицист Сəид Габиев (1882—1963) Столыпин реакциясенең авыр шартларында Петербургта нəшер иткəн «Дагстан таңы» (1912—1913) һəм «Мөселман газетасы» (1913—1914) битлəрендə Г. Тукай иҗатына багышланган материаллар урнаштырган, үзенең бер шигырен аңа багышлаган. Əлеге хезмəтлəрдə С. Габиевның халык шагыйре иҗатына тирəн ихтирамы, гасырлар дəвамында Дагстан һəм Татарстан халыклары культураларына нигез салучылар сузган дуслык җеплəрен ныгытырга омтылу сизелə. С. Габиевның Г. Тукай иҗатын гына түгел, ə бəлки шагыйрьнең үзен дə белгəн булуы ихтимал. Билгеле булганча, Габиев «Дагстан таңы» газетасын чыгара башлаган елда (1912) Тукай Петербургка килə. «Башкаланың алдынгы милли интеллигенциясе,— дип яза Г. Халит,— кадерле кунакка игътибар һəм ярдəм күрсəтергə омтылды. Прогрессив яшьлəр арасында Мулланур Вахитов та булуы ихтимал»[1]. Билгеле булганча, шул ук елларда Габиев һəм Вахитов арасында дуслык мөнəсəбəтлəре урнаша.

Петербургтан кайтканнан соң бер ел да үтми, Тукай вафат була. Габиев бөек татар шагыйренең вакытсыз үлемен авыр кичерə. «Шагыйрь Г. Тукай истəлегенə» некрологында ул тирəн кайгысын белдерə, Россия халыклары культурасына Тукайның гаять зур йогынтысын билгелəп үтə. «Əле тынып, əле тагын да көчлерəк яңгырый барып,— дип яза Габиев,— алар (Тукай əсəрлəре — С. А.) Башкортстанда, бөтен Идел буе татарлары арасында киң таралдылар, Кырымга, казакъ далаларына, Төркстанга да барып җиттелəр. Аның моңнарын ишеттелəр, һəм инде ул моңнарда Россиянең мөселман халкына якты көннəр якынлашуы сизелде». С. Габиевның Тукай шəхесенə, аның шигъриятенə мөнəсəбəте ул бастырып чыгарган газеталар битлəрендə, Тукай иҗатын сөючелəр җибəргəн телеграммаларда да чагылыш тапты. Ə бер телеграмма шигъри формада бирелгəн:

«И мөкаддəс, моңлы сазым!
Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнəмен,
Айрылабыз ахрысы!

Әйе, саз кыллары өзелде, əмма аның моңнары килəчəк буыннар йөрəклəрендə дə озак яңгыраячагына ышанычыбыз бик зур».

Бу очракта С. Габиевка Тукайның татар телендə язган əсəрлəрен укып аңларга тел аермасы уңайсызлыклар тудырмадымы икəн дигəн сорау туарга мөмкин. Билгеле булганча, аның əсəрлəре гасыр башында əле рус телендə киң таралмаган. Əмма комык телен белгəн Габиевка бу хəл əллə ни кыенлык тудыра алмаган. Төньяк Кавказ халыклары өчен комык теле XX гасырның 20 елларына кадəр үзара аңлашу теле булган. Тукай теленə якын булган бу тел Дагстан публицистына беренчелəрдəн булып бөек Тукай, аның үлемсезлеге турында фикер əйтергə мөмкинлек бирə.

Тукай иҗатын һəм, гомумəн, татар культурасын комык халкы элек-электəн бик

---

[1] Тукай һəм аның замандашлары. Казан, 1966, 174 б.

яраткан. Хәзерге заман комык әдәбиятына нигез салучы Нухай, Зәйналабид Батырмозаев, Әлим-Паша Салаватов, Баһаветдин Астимеров, Әбусуфьян Акаев, Манай Алибәков һәм Дагстан халык шагыйрьләре Аткай Аҗаматов, Әнвәр Аҗиев, Габделваһап Сөләймановларның күп әсәрләре Тукай шигърияте рухы белән сугарылган. «Әдәбият белән таныша башлауга татар әдәбиятының Төньяк Кавказ һәм Дагстан халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда нык алга киткән һәм киңрәк таралган булуын күрдем. Безгә, башлап язучыларга, Габдулла Тукай шигърияте өеруча якын иде. Без аның әсәрләрендә үз халкыбызга, аның шигъри культурасына хас булган идеяләр һәм фикер сөреше, сурәтләү чаралары күрдек, Тукай шигырьләренең һәр юлы минем өчен шигърият мәктәбе булды»,— ди комык әдәбияты аксакалы Аткай.

һәр комык гаиләсе бөек татар шагыйре иҗаты белән азмы-күпме таныш булган. Бу — комык һәм татар культура эшлекләләренең үзара аралашуы нәтиҗәсе. Тукай белән бер чорда иҗат иткән яңа комык әдәбиятына нигез салучылар аның шигырьләрен шәхесен белү белән генә чикләнмичә, шагыйрьдән җәмгыятьнең хатын-кыз язмышы, халык мәгарифе, культура үсеше кебек иң мөһим мәсьәләләрен яктыртырга өйрәнгәннәр. Әнә шундыйлардан Нухай Батырморзаев (1864—1919) — Г. Тукай шигъриятенең үзенә тәэсирен сизгән беренче комык.

Шагыйрь, педагог һәм публицист Н. Батырморзаев борынгы дагстан авылы Аксайда туган. Авыл элек-электән Каспий алды тигезлегенең сәүдә-экономик үзәге булган. Моннан Әстерханга, аннан Идел буена, Үзәк Россиягә сәүдә кәрваннары юл тоткан. Аксай ул чорда Төньяк Кавказның культура үзәге буларак та танылган. Анда мәктәпләр, мәдрәсәләр, китапханәләр булган. Аксайда татар халкының укымышлы вәкилләре Таҗетдин Ялчыгол, Исхак әфәнде һ. б. мәктәпләрдә укытканнар. Н. Батырморзаевның балачагы шушы укымышлы кешеләр арасында узган. Алар ярдәмендә ул төрки, гарәп, соңрак рус теле грамматикаларын үзләштергән, аңарда үз әдәбиятына, тугандаш халыклар әдәбиятларына ихлас ихтирам туган. Ниһаять, ул мәдрәсәдә укыта башлый, шәкертләренә тормыш өчен мөһим белемнәр бирә. Әмма дини карагруһчыларга аның тәрбия һәм укыту ысуллары ошамый. Батырморзаев мәдрәсәдә укытуны ташларга мәҗбүр була. Буш вакытларында ул әдәбият белән кызыксына, үзе яза башлый. Авыр тормыш аны эш эзләп Әстерхан, Царицын, Нижний Новгород, Оренбург якларына барып чыгарга мәҗбүр итә. Киләчәктә талантлы проза һәм шигъри әсәрләр язачак автор өчен Шәрык халыкларының культура үзәге булган Казанга килү гаять әһәмиятле була. Үз тормышының Казан чорын Батырморзаев документаль төгәллек белән «һарун һәм Зөбәйдә, яки бәхетсез Җанбика» әсәрендә сурәтли. Әсәрнең төп герое һарун (автор үзе турында яза) XX йөз башының җәйге бер көнендә икенче класслы пассажир поездында Гайнетдин исемле укымышлы бер татар (Исхак әфәнде күздә тотыла — С. А.) белән Казанга килеп төшә. Казанда юлдашлар Мәскәү урамындагы «Болгар» кунакханәсендә урнашалар. Ул заманда әлеге кунакханәнең кечкенә генә тар бер бүлмәсендә Габдулла Тукай яшәгән. «Бу вакытта Тукай инде танылган шагыйрь һәм журналист... Монда (Казанда — С. А.) Тукай алдынгы татар интеллигенциясе белән аралаша»,— дип яза профессор М. Гайнуллин. Батырморзаев Казанга килүгә Тукайның иҗатын күзәтеп барган һәм, бәлки аның үзе белән дә танышкандыр, дигән фикергә килергә була. Повестьтан күренгәнчә, юлдашы — «укымышлы Казан татары» Гайнетдин аңа эшкә урнашырга ярдәм итә. Гайнетдин әдәби даирәләр белән якыннан таныш булган, матбугат органнары редакцияләрен яхшы белгән. Казанга килгәннең икенче көнендә Гайнетдин һарунга «Синең Казанда танышларың юктыр. Мин сине эшкә урнаштырам»,— ди. Алар фаэтонга утырып Кәримовлар басмаханәсенә китәләр.

Кәримовлар типографиясендә эшләгәндә һарун мәкаләләр яза, аларны либераль «Казан мөхбире» газетасында бастыра, хезмәт сөючәнлеге, актив публицистик эшчәнлеге белән ихтирам казана. Инде «аның исемен укымышлы даирәләрдә дә беләләр иде»,— дип яза автор. һарун Харитонов типографиясе белән дә элемтәдә булган. Н. Батырморзаев Казанда эшләгән елларда әлеге басмаханәләрдә (атап әйткәндә Харитонов типографиясендә) Г. Тукай әсәрләре дә басыла. Бөек шагыйрь әсәрләрен халыкка җиткерүдә дагстанлы Нухай Батырморзаев хезмәте дә бар дисәк, ялгыш булмас дип уйлыйм. Бу элемтәләр, татар шагыйренең әсәрләрен яхшы белү аның үз иҗатына да уңай тәэсир ясаган.

Дагстан халыклары әдәбиятларына башка халык әдәбиятларының тәэсире хакында фикер йөртеп, филология фәннәре докторы Г. Гамзатов болай яза: «Г. Тукай, М.-Ф. Ахундов, К. Хетагуров, Дм. Гулиа һәм рус булмаган башка халык вәкилләре тәҗрибәсе тагын да гыйбрәтлерәк. Аларның эзләнүләрендә һәм табышларында милли әдәбиятларның яңа чоры контурлары һәм чалымнары сизелә, башка әдәбиятлардан үзләштерелгән принципларның үз халкың традицияләре һәм үзенчәлекләре рухында эшкәртелгәндә генә уңай нәтиҗә бирүе күренә. Н. Батырморзаевның «Кавказ һәм бөтен Россиядәге хәл» поэмасына «Бәхетсез Габийбәт» (1910), «Давыт белән Ләйлә» (1912), «һарун белән Зөбәйдә, яки бәхетсез Җанбика» повестьларына һәм Г. Тукайның

«Государственная Думага», «Соры кортларга», «Мужик йокысы», «Китмибез!» һ. б. әсәрләренә чагыштырма анализ ясаганда, Тукай шигърриятенең дагстан әдәбияты тарихына, аерым алганда Н. Батырморзаев иҗатына уңай йогынтысы турындагы фикер ачык раслана.

Халык мәгарифе, хатын-кызларны азат итү, культура үсеше, җәмгыятькә каршы тәртипләрне тәнкыйтьләү кебек чорның мөһим мәсьәләләрен күтәреп чыкканда һәм аларга җавап эзләгәндә, Н. Батырморзаев Тукайның эстетик принципларын күздә тота. Г. Тукай үзенең әсәрләрендә хатын-кызның хокуксыз тормышы турында ачынып сөйли, аның язмышын үзгәртү өчен көрәшкә чакыра. Батырморзаев та үзенең хатын-кыз геройлары үрнәгендә наданлыкның, караңгылыкның кая алып баруын күрсәтә. Үзе яратмаган Арсланга кияүгә бирелгән Габийбәт 31 яшендә аздан гына акылдан шашмый кала, ә яшь чагында мыскылланган Җанбикә үз-үзенә кул сала. Н. Батырморзаев Г. Тукай иҗатын югары бәяләгән, аның әсәрләрен Пушкин, Гоголь, Толстой, Горький әсәрләренә тиңләгән, аларны халыкка, әдәбиятка тугры хезмәт үрнәге дип атаган. «Язучыларга берничә сүз» исемле мәкаләсендә Батырморзаев бөек татар шагыйре әсәрләренең халык арасында ничек хөрмәт ителүе турында яза. «Ул (Тукай — С. А.) бик иртә үлде,— дип яза Батырморзаев. Әмма казан татарлары аның әсәрләрен җыеп бастырып чыгардылар. Ул әсәрләрне мәктәпләрдә өйрәнәләр. Тукай үлгәннән соң урамнарга, авылларга аның исеме бирелде. Аның исеменнән мәктәпләр салынды.» Дагстан мәгърифәтчесе хаклы рәвештә «Тукай — милләтнең горурлыгы һәм яклаучысы»,— дип язды. Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлы Н. Батырморзаевның улы — ялкынлы революционер, шагыйрь, публицист, Дагстандагы гражданнар сугышы герое Зәйналабид өчен дә халыкка хезмәт итү үрнәге булды. Дагстан драматургиясе классигы, шагыйрь, педагог А.-П. Салаватов та (1901-1942) дусты З. Батырморзаев ярдәмендә Тукай әсәрләре белән яшьтән үк таныша. Тукай шигърияте йогынтысында үзенең беренче иҗат адымнарын атлаган шагыйрь соңрак аның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. Тукайның А.-П. Салаватов комык теленә тәрҗемә иткән «Ат, арба, чана» шигыре дагстан әдәбиятын хезмәт темасы белән баетуга үз өлешен кертә.

Татар әдәбияты классигының, аның каләмдәшләренең иҗат мирасы нугай әдәбияты үсешенә дә зур йогынты ясады. Нугай телендәге беренче әдәбият дәреслекләренең өчтән бер өлешен Г. Ибраһимов, Г. Ильяси, Х. Туфан, Г. Гали, Х. Садрый, Н. Баян, К. Нәҗми һ. б. әсәрләренең тәрҗемәләре тәшкил итә. Шунда ук Тукай иҗаты йогынтысында язылган шигырьләр дә бар. Мисал өчен хәзерге нугай әдәбиятына нигез салучы Муса Корманалиев (1894—1970) әсәрләрен күрсәтергә мөмкин.

Корманалиевның нугай халык иҗаты белән сугарылган үзенчәлекле таланты татар һәм башка халык әдәбиятларының алдынгы юнәлешләренә таянып үсә. Революция алды елларында Корманалиев Әстерханда, Казанда яшәгән, татар телендә бастырылган газета һәм журналларны, китапларны даими укып барган. Тукайның реалистик шигърриятенә сокланган Корманалиев татар әдәбияты ярдәмендә дөньяны сәнгатьчә күреп белүен баета.

Тукайның М. Корманалиев иҗатына тәэсирен «Тувган тел» («Туган тел»), «Бишек жыр» («Бишек җыры») кебек шигырьләрендә күрергә мөмкин. Шигырь исемнәре дә Тукайныкы кебек. Эчтәлекләрендә, сурәтләү чараларында да якынлык зур. Әмма бу охшашлык нугай шагыйре әсәрләренең оригинальлегенә шик тудырмый, ә бәлки ике халык шагыйрьләренең иҗади бәйләнешен күрсәтә. Тукайның «Туган авыл» һәм Корманалиевның «Тувган элим» («Туган илем») шигырьләрендә дә шундый аваздашлык, якынлык сизелә.

Г. Тукайның иҗат мирасын Дагстан халыкларына җиткерү, шуның белән милли әдәбиятларны бөек шагыйрьнең тирән эчтәлекле әсәрләре белән баетуда аның шигырьләренең һәм үлемсез иҗатына багышланган мәкаләләрнең тәрҗемәләре зур роль уйнады. «Дуслык» альманахының 1966 һәм 1976 еллардагы язгы саннарында безне кызыксындырган темага багышланган байтак материал күрәбез. Алар арасында «Шагыйрь турында сүз», «Халыкка багышланган талант», «Габдулла Тукай» дип аталган мәкаләләр бар. Шагыйрьнең авар, даргин, комык, лак, лезгин телләренә тәрҗемә ителгән әсәрләре бастырылган, кара костюм һәм түбәтәйдән төшкән фоторәсемнәре бирелгән.

Тукайның тормышына, иҗат эшчәнлегенә багышланган мәкаләләрдә авыр ятим балачагы, яшьлек еллары, гаять зур хезмәт сөючәнлеге, гражданлык батырлыгы, белеменең киңлеге, дөньяга шигъри карашының масштаблыгы турында югарыда әйтелгән барлык телләрдә сөйләнә. Мәкаләләрнең авторлары — республикада һәм илебездә танылган шагыйрьләр, язучылар. Дагстанның халык язучысы Муса Магомедов, Дагстанның халык шагыйрьләре — Әнвәр Аҗиев, Сөләйман Рабаданов, С. Стальский премиясе лауреатлары Бәдәви Рамазанов, Мәҗит Гаджиев кебек Дагстанның танлыган культура эшлеклеләре тәрҗемәләре республикабыз милли әдәбиятларын бөек татар шагыйренең искиткеч әсәрләре белән баетырга, шуның нәтиҗәсендә үз традицияләрен үстерергә мөмкинлек бирде.

«Тукайның шигърият сукмагын яңа иҗади чор ялкыны яктыртты,— дип яза Ә. Әҗи-

ев.— Тукай хәзерге көндә дә азат ителгән халыклар җырчысы. Тукай — безнең замандашыбыз»[1]. Үз фикерләрен раслау өчен комык шагыйре Г. Тукайның «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Туган тел», «Государственная думага», «Егет илә кыз», «Казан» шигырьләренең үз телена тәрҗемәсен китерә. Оригиналда шигърият, моңны саклап калуга ирешә:

> Гъей жан азыкъ, гъей арив тил, атам-анамны тили!
> Ана тилим, сен саялы дюньяда кеп зат билдим...

Бөек шагыйрьнең 90 еллыгына багышлап «Ленин елу» («Ленин юлы», комык), «Ленина байрахъ» («Ленин байрагы», даргин), «Баъараб байрахъ» («Кызыл байрак», авар), «Коммунист» (лезгин) газеталарының 1976 ел 24-26 апрель саннарында бастырылган мәкаләләр Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә лаеклы өлеш кертте дисәк, тыйнаксызлык булмас дип уйлыйм. «Патриот-шагыйрь», «Үз халкының җырчысы», «Татарстанның халык шагыйре» кебек мәкаләләрдә Тукайның тормыш һәм иҗат юлы, шигъриятенең идея-тематик үзенчәлекләре яктыртыла. Яңа буын укучыларны рухи баета һәм тәрбияли барып, Тукай шигърияте шул ук вакытта хәзерге заман дагстан шагыйрьләре һәм язучылары өчен акыллы һәм таләпчән остаз булып тора. Әмма эш Дагстан язучыларының Тукай иҗатына турыдан-туры мөрәҗәгатендә генә түгел. Алар яңа тормыш тудырган башка темаларга язалар. Шулай да татар әдәбияты классигы мирасы тормышчан, идеяле һәм аңлаешлы булуы белән дагстан шагыйрьләре өчен иҗатта дөрес юнәлеш табу, чын шигъриятнең югары үрнәге булып тора. «Татарларның таң белән дус Тукае» — Ә. Аҗиевның ихлас күңелдән әйтелгән бу сүзләрендә бөек Тукайның шигъри даһилыгына сүнмәс мәхәббәт чагыла.

...1976 елның язы иде. 20 май көнне иртәдән үк яңгыр сибәләде. Шуңа да карамастан, Кырлайга халык агылды. Татарлар, казахлар һәм урта азиялеләр, башкортлар, марилар һәм кавказлылар — илебезнең бөтен почмакларыннан алар Тукайның туган якларында яңа салынган ике катлы бинада бөек шагыйрьнең музее ачылу тантанасына җыелдылар. Кырлайда, крестьян Сәгъди абзый гаиләсендә шагыйрьнең балачагы узган. Аның университетлары шушыннан башланган. Шагыйрьнең туган туфрагына баш иярга теләүчеләр агымы кичкә кадәр туктамады. Шушы вакытта ерак Дагстанда, аның башкаласы Махачкалада Рәсүл Гамзатов Тукай иҗат мирасының Дагстан халыклары әдәбияты тарихында тоткан урыны турында уйланган, үзенең бу уйларын «Ут — шагыйрь» исемле мәкаләсенә салган: «Тукай үз халкы талантының бөеклегенә таныклык булып тора, минем аңа мәхәббәтем нәселдән килә... Аның исеме ерак Татарстаннан диңгезләр, елгалар аша үтеп килә. һәр йортта, сакляда ул үзенә сыену тапты».

Танылган шагыйребезнең бөек татар әдибе турындагы бу сүзләре — Дагстан әдәбиятларының тугандаш гаиләсендә Тукай шигърияте тоткан урынга тагын бер югары бәя.

**Солтанморат АКБИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты,
Дагстан АССР, Каспийск шәһәре

---

[1] А. Аджиев. Абдулла Токъай. «Дослукъ». 1966, № 2, 81-82 бб.

*Моңарчы без Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестена кереш рәвешендә юмористик планда язылган автобиографиясен генә белә идек. («Минем тәрҗемәи хәлем»). Татарстан АССРның Үзәк Дәүләт архивында аның үз кулы белән русча язылган яңа автобиографиясе табылды (88 ф. 1 тасв., 2225 эш). Әдипнең 3 номерлы Казан ирләр гимназиясе директорына адресланган гаризасыннан күренгәнчә, бу автобиографияне ул өлгергәнлек аттестатына имтихан тоту максаты белән 1911 елның мартында язган.*

*Шул ук папкадан мәгълүм булганча, имтихан 2 майда башланган һәм, июнварына кадәр дәвам итеп, 32 экстерннан-егеттән алтысы гына тапшырып чыккан. Төшеп калганнар арасында, имтиханга кергән ике татар егете белән берлектә, Ф. Әмирхан да бар.*

*Укучыга тәкъдим ителә торган автобиография әдипнең тормыш юлын төгәлрәк һәм тулырак аңлауда зур әһәмияткә ия. Моңарчы, мәсәлән, архивта саклана торган таныклыгына нигезләнеп, без Ф. Әмирхан Яңа бистәдәге рус классын тәмамлаган дип уйлый идек. Күренә ки, алай булмаган. Булачак әдипнең, мәдрәсәне ташлап, Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов һәм Г. Коләхметов укып чыккан Учительская школага күчәргә омтылганлыгы — аеруча кызыклы һәм кыйммәтле факт.*

Ибраһим НУРУЛЛИН.

# Минем тормыш юлым

Мин 1886 елның 1 нче январе көнне Казан шәһәрендә татар мулласы гаиләсендә туганмын. Атам, бабам, бабамның атасы дин әһелләре булганлыктан, минем дә шул юлдан китүемне теләп, кече яшьтән үк чын мөселман итеп тәрбияләргә тырышканнар. Бу тәрбия тулысынча «Домострой» кагыйдәләрен искә төшерә. Тәрбияләнүченең сәләтләре һәм теләге монда бөтенләй искә алынмый.

Үз-үземне белә башлавым биш яшьләр тирәсенә туры килә.Балачакта булган кайбер эпизодлар бөтен ваклыклары белән хәзергә кадәр хәтеремдә саклана. Ләкин шулар арасында рәхәтлек белән искә алырдае бер генә дә юк: бөтен балачагым ниндидер бөркү атмосферада тар һәм кысан мохитта узган. Бала вакытта мин бик дини идем. Ләкин ул динилектә бер матур сыйфат та юк: анда алланы ярату түгел, бәлки аның каһәреннән курку гына бар иде.

Алты яшемдә мине мәктәпкә бирделәр. Анда мин шактый уңышларга ирештем. Ике елдан мине мәдрәсәгә (ун-унике сыйныфлы дини мәктәпкә) күчерделәр. Мәдрәсәдә укучыларның күпчелеге пансионер була иде. Мин исә баштагы ике елда йөреп укыдым һәм сәләтле, яхшы укучылардан саналдым. Шул вакытларда ук атам-анам мине малайлар белән уйнаудан тыя башладылар. Алар миңа һәрвакыт, мулла буласы кешегә үзенең булачак мәхәллә кешеләре белән уйнау килешми, дип тукып торалар иде. Яшьтәшләрем белән уйнаудан баш тарту никадәр авыр булса да, бер ни эшләр хәл юк:

— Яхшылык белән тыңла, тыңламыйсың икән, камчы бертуганың түгел.

Аннары мөселманлык рухын тәмам сеңдерү өчен мине үзем укыган мәдрәсәнең пансионына бирделәр. Андагы тәрбия белән өйдәге арасында аерма юк дип әйтерлек. Булса да, шул гына: монда катылык үзенең апогеена җиткән.

Өч гасыр дәвам иткән традицияләр буенча мәдрәсә программасына гарәп теле, Коръән тәфсире, хәдис, ягъни Мөхәммәтнең әйткән сүзләре, мөселман хокук фәне, логика һәм Аристотель фәлсәфәсеннән кайбер нәрсәләр керә.

«Гыйлемем» арткан саен, миндә үземне өстен хис итү көчәя бара иде. Минем карашымда кешеләр ике төркемгә бүленәләр: «галимнәр — алары санап үтелгән фәннәрне үзләштергән кешеләр, һәм наданнар — алары ул фәннәрне белмәүчеләр. Барлык мөселман руханиларын мин беренче төркемгә кертәм. Ә калган кешеләрне, шул исәптән европалыларны,— икенче төркемгә.

Бер заман рус теле белән танышу вакыты килеп җитте: закон буенча мулла рус телен белергә тиеш булганга һәм әтинең миннән тизрәк муллалыкка имтихан тапшыртасы килгәнгә, бер татар учителеннән өч ай буе рус теле өйрәндем. Укырга-язарга җиңел өйрәнсәм дә, рус теле миңа җиңел бирелмәде. Рус сүзләрен мин шулкадәр бозып әйтәм, тыңлавы көлке. Рус теленең кайбер авазлары минем әйтүемдә, бер-берсеннән аерылмыйча, бертөсле булып чыга иде. Шулай итеп рус теле миңа авыр һәм кызыксыз тел шикелле тоела башлады.

Унбиш яшемә кадәр мин мәдрәсәдә тыныч кына яшәдем, тырышып укыдым, могътәбәр мулла булырга хыялландым. Ләкин минем болай үз-үземнән канәгать булып тыныч күңел белән яшәвем язмышка ошамады. Ничектер шулай мин төрек һәм гарәп телләрендәге дөньяви китапларга тап булдым. Аларны укыгач күңелемдә ниндидер икеләнү, ризасызлык хасил булды. Күпчелеге русчадан тәрҗемә ителгән мондый китапларны мин әзерлегем җитмәү сәбәпле бик үк аңлап та җитми идем. Ләкин алардагы яңа һәм кыю сүзләр миндә бик үк анык булмаган эзләнү, уйлануның барлыкка килүе өчен җитә калды...

Атамның дөньяви белемгә карашын белгәнгә күрә, мин дини булмаган бер уку йортына керү турында уйларга да куркам, шул ук вакытта мәдрәсә биргән белән генә кала да алмыйм. Зур кыенлык белән тагын өч ай русча уку өчен аның (әтисенең — И. Н.) рөхсәтен алуга ирештем. Бу өч ай минем өчен шактый файдалы булды: русчаны азрак аңлый һәм сөйләшә башладым. Нык тырышканда, бу яшьтә дә рус теленең авырлыкларын җиңәргә мөмкин дигән ышаныч туды. Шуннан соң мин ата-анама мәдрәсәдә бүтән укымыйм, Учительская школага керәм дип белдердем. Минем мондый көтелмәгән «тупаслыгым» аларны хәйранга калдырды. Анам истерикага бирелеп җылый башлады, атам, әгәр мин бу карарымны тормышка ашырсам, өйдән куып чыгарачагын һәм үзенең улы санамаячагын каты итеп әйтте. Нихәл итмәк кирәк, бу хәлдән чыга белү осталыгы да, кыюлык та, килерем дә юк, һәм мин тагын ике ел мәдрәсәдә калдым. Ләкин бу ике елда инде мин анда укытыла торган фәннәр белән бик аз шөгыльләндем.

Мәдрәсәне тәмамлагач, атам мине мулла итәргә теләде. Мин риза булмадым, һәм ул миңа ишек күрсәтте. Коточкыч хәлләр туды. Мин чыгып киткәч, атам белән анам авырый башлаганнар, ә үзем, шашкан кешедәй, таяныр нокта тапмый, анда сугылам, монда сугылам. Әмма алар да, мин дә башкача булдыра алмый идек: һәрберебез үзенчә хаклы.

Әнә шул шартларда мин үзбаш яши башладым. Эшкә күнекмәгәнлек, рус телен белмәү, атам-анам белән арам өзелгәнлекне хис итү — болар барысы да мине гаять читен хәлгә куйды: нервалар какшады, сәламәтлек начарланды, мин холыксыз, авыру, бөтен дөньяга ачулы бер кешегә әверелдем. Әнә шулар һәм акчасызлык миңа рус теле белән кирәгенчә шөгыльләнергә мөмкинлек бирмәделәр.

Бер елдан соң мине Мәскәүгә татар журналы редакциясенә[1] эшкә чакырдылар. Анда, руслар белән аралашып, ярыйсы гына русча сөйләшә башладым, яхшы гына хезмәт хакы килә, һәм миндә өлгергәнлек аттестаты алу хыялы куәтләнде, укырга керештем.

Берничә айдан мин өйдән хат алдым. Анда атам-анам сәламәтлекләренең какшавын язганнар, минем белән килешергә теләүләрен белдергәннәр. Һәм мин өйгә кайттым. Андагы хәлләрне күреп шаккаттым: шушы кыска вакыт эчендә атамның чәче агарган, анам карчыкка әйләнгән, йөзләрендә сырхау, хәсрәт билгесе. Аларга карап йөрәк сыкрый...

Мин үз гаиләмдә яши башладым һәм укуымны дәвам иттем. Ләкин язмышка минем тыныч яшәвем тагын ошамады. 1907 елның көзендә дәвалауга бирелми торган каты авыруга дучар булдым: ике аягым да параличланып, бөтенләй йөри алмас булдым. Хәзер дә шул хәлдәмен.

Инде буш вакыт күбәйде, мин яңадан күптәнге хыялыма — өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшыру уена кайттым. Ике ел буе, бер дә өзелмичә, гимназия курсы фәннәрен өйрәндем. Хәзер инде үземне әзер дип саныйм һәм имтиханга керергә карар иттем.

**Фатих ӘМИРХАНОВ.**

---

[1] 1907 елның гыйнвареннан апреленә кадәр балалар өчен Мәскәүдә чыгарылган «Тәрбиятел-әтфаль» журналы.

# ХАКЫЙКАТЬКӘ ЮЛ ЯРГАНДА

Күренекле язучы, публицист һәм актив җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның дөньяга карашы формалашуда беренче чиратта аның гаилә мохитенең, ә соңрак исә ул белем алган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең бәрәкәтле йогынтысы була. Әмирхановлар, ерак бабалары Фатихтан башлап, татарлар өчен ул чорда мөмкин булган тәпле белем алганнар, гыйлем эстәүне заманының иң абруйлы саналган Урта Азия мәдрәсәләрендә тәмам иткәннәр. Дини-схоластик характердагы кирәксез белем йөге белән берраттән, мәдрәсә тәмам итүчеләр аннан мәгълүм бер дәрәҗәдә кыйммәтле нәрсәләр дә алып чыкканнар. Урта гасырлар Көнчыгышының бай культурасыннан шактый хәбәрдар кешеләр чыккан бу мәдрәсәләрдән. Фатихның бабасы — Хөсәен Әмирхан Фирдәүсинең «Шаһнамә»се кебек күренекле әсәрләр белән дә яхшы таныш була, тарихи эзләнүләр белән шөгыльләнә. Ф. Әмирханның атасы күбрәк дини эчтәлекле әсәрләр язучы буларак мәгълүм. Ләкин атасына бәйле бер факт игътибарны җәлеп итә: ул Ш. Мәрҗани идеяләренең тарафдары була һәм Фатих күңеленә башта шушы мәгърифәтче галим шәхесе белән, аннары ул язган хезмәтләр белән кызыксыну орлыклары салып калдыра. Шушы нәрсәнең Ф. Әмирханның дөньяга карашлары формалашуда зур әһәмияте була. Гаиләдәге иҗади атмосфера, атасының һәм бабасының эрудициясе дә тәэсир иткән, әлбәттә.

Ата-аналары, мәдрәсә тәмамлагач, Фатих, чит илгә китеп, белемен тирәнәйтер, анда гарәп, төрек һәм берәр Европа телен бик шәпләп өйрәнер, һәртөрле гыйлем туплап кайтыр, аннары вакыты җиткәч, бер бик могтәбәр дин галиме булып китәр дип хыялланганнар[1].

Фатих тумыштан зиһенле, укуга тырыш бала булганга күрә бик урынлы хыяллар була бу. 1894 елда аны заманның күренекле уку йорты саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бирәләр. Фатих тиз арада иң зирәк шәкертләр рәтендә йөри башлый.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку чоры Ф. Әмирханның инанган демократ булып формалашуында тирән эз калдыра. Гомумән, бу уку йортыннан электән дә халкыбыз тарихында сизелерлек эз калдырган алдынгы карашлы эшлеклеләр башка мәдрәсәләр белән чагыштырганда күбрәк чыккан.

Мәгълүм булганча, XX гасыр башында шәкертләр хәрәкәтенең беренче яралгылары күренә. Шәкертләрнең, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, уяна башлавы, аларда иҗтимагый активлык сизелә башлау төрле юнәлештәге татар җәмәгать эшлеклеләренең карашын шул тарафка төбәргә мәҗбүр итә. Шәкертләр янында эсерларның пропагандистлары, либераль-буржуаз идеология вәкилләре булгалый.

Әмма либераль - буржуаз идеологлар да, эсерлар да укучы татар яшьләренең төп массасын үз артларыннан ияртә алмыйлар. Ф. Әмирханның һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең башка шәкертләренең карашлары формалашуга социал-демократлар — Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, Г. Коләхметов, большевик студент С. Гассар гаять зур йогынты ясый. Ф. Әмирханда социаль-политик карашлар формалашуда соңгысының роле аеруча зур була.

Социал-демократларның шәкертләргә йогынтысы эсерлар һәм либералларныкына караганда көчлерәк булуы, шәкертләрнең аларга, аерым алганда, Х. Ямашевка шәхси симпатиясе булу нәтиҗәседер. Ямашев үзе дә элек «Мөхәммәдия»дә укый. Алай гына да түгел, Ф. Әмирхан һәм аның иптәшләре Х. Ямашев башлап җибәргән эшне — «Тәрәккый» газетасын чыгаруны дәвам итәләр. Ни генә булмасын, Ямашев шәкертләрдән актив группа туплый ала, алар арасында Ф. Әмирхан да була. Шушы группада үзе дә катнашкан, Фатихның дусты һәм көрәштәше Вафа Бәхтияров социал-демократлар һәм алдынгы карашлы шәкертләрнең беренче уртак эше «Иттифакъ» газетасы булды, дип яза[2]. Газета зур булмаган формат белән дүрт биттә чыга. Барлыгы алты сан чыгарыла. 1903 елның көзендә шул ук состав инде «Җөмһүрият» дигән яшерен газета чыгара башлый. Аның беренче саны Х. Ямашевның атасы өендә, тагын икесе эсер Хөсәен Әбүзәров фатирында басыла. Газета өчен материаллар яшерен большевистик газеталардан, брошюралар һәм прокламацияләрдән алына һәм тәрҗемә ителә.

Беренче рус революциясе алдыннан Ф. Әмирханның һәм большевиклар белән бәйләнештә торган башка шәкертләрнең төп бурычы Г. Сәйфетдинов җитәкчелегендә революцион брошюраларны, прокламацияләрне татар теленә тәрҗемә итү һәм аларны

---

[1] Ф. Әмирхан турында истәлекләр. — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивы (Алга таба — ТӘТИ архивы). 16 ф., 1 тасв., 42 эш, 2 б.

[2] Бәхтияров В. Хөсәен Ямашев һәм аның турында кайбер истәлекләр. — ТӘТИ архивы. 42 ф., 1 тасв., 1 эш, 4 б.

гектографта бастырудан гыйбарәт була. Бу мәгълүматлар Г. Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән монографиясендә язганнар белән дә раслана. Бу эш еш кына Әмирханнар мунчасында, ә җәйге якта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе подвалында башкарыла. Ибраһим Аитов исә С. Гассар, Ф. Әмирхан, Солтан Рахманкулов һәм Исмәгыйль Аитовларның Евангелистическая урамындагы квартираларында да (хәзерге Татарстан урамы, 42) прокламация басуларын әйтә[2].

Листовкалар басу һәм таратудан тыш, Фатих Әмирхан иптәшләре белән бүтән төрле эшләрдә дә катнаша. В. Бәхтияров, кулга алулар һәм полиция облавалары чорында шәкертләр Г. Сәйфетдинов һәм Х. Ямашев белән бергә РСДРПның Казан комитетының актив членнарын яшерергә ярдәм итүләре турында да яза. Еш кына Ф. Әмирханнарның мунчасына яшерә торган булалар[3]. Аларның амбар, баз, печәнлекләре шулай ук комитетның революцион материаллар басу өчен кирәкле техник әсбапларны яшерү өчен дә файдаланыла[4]. Моннан тыш, жандармнар һәм полиция агентлары кулына эләгүдән куркып, Х. Ямашев һәм Ф. Әмирханнарның өйләрендә кайчакта Казан комитетының күчмә китапханәсен дә тоталар. Күргән кешеләрнең әйтүенчә, ул урта зурлыктагы кәрзиннән гыйбарәт булып, анда революцион эчтәлекле төрле әсәрләр: К. Маркснең «Капитал»ы, Г. В. Плехановның хезмәтләре, «Искра» газетасы саннары, үзәктән алган брошюралар, прокламацияләр һ.б. була. Китапханәне куркынычсыз җиргә күчереп йөртү өчен җаваплылык С. Гассарга йөкләнгән була. -

Алдынгы карашлы шәкертләр кулына шундый китаплар керү, шулай ук Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, С. Гассар белән бергәләп революцион эш алып бару аларның идея үсешенә, ә алар аша бөтен шәкертләр хәрәкәтенә йогынты ясаган гаять мөһим фактор була.

Моннан тыш, С. Гассар Россиядәге югары уку йортларына керү хокукы бирә торган аттестат алу өчен имтихан тотарга хәзерләнгән шәкертләргә рус теле дәресләре бирә. Ф. Әмирхан да аннан дәрес ала. Эш телне өйрәнү белән генә чикләнми. Гассар үзенең укучыларына иҗтимагый-политик белем нигезләрен дә бирә. Ф. Әмирхан сыйныфлар, сыйнфый көрәш, теге яки бу сыйныфның интересларын чагылдырган политик партияләр булуы турындагы башлангыч мәгълүматларны беренче чиратта нәкъ менә аңардан ала. Р. Алуши (Ибраһимов) Әмирхан Гассарның бик көчле йогынтысын тойды, дип яза[5]. Ә И. Бикколов, нәкъ менә Гассар аркасында «Мөхәммәдия» шәкертләре 1905 елгы революция чорында социал-демократлар ориентациясендә булдылар, дип саный һәм Фатихның иҗтимагый-политик офыгы киңәю ул Гассардан дәрес ала башлагач булды, дип өсти («Кызыл Татарстан», 1926, 12 март).

Башында Ф. Әмирхан торган шәкертләр төркеме Гассардан һәм Ямашевтан алган белемнәрен үз даирәләрендә генә йомып калдырмыйча, башка шәкертләргә дә тапшыралар. Бу эш 1904 елның декабрь урталарында тәмам оешып беткән һәм 1905 елда яшерен «Әльислах» комитетына әверелгән әдәби түгәрәк утырышларында башкарыла. Түгәрәкнең башка әгъзалары Фатих Әмирханнан һәм аның иптәшләреннән төрле-төрле партияләр булуын беләләр. Шулай ук ул революцион җыр текстлары аяып килеп, аларны шәкертләр арасында тарата. «Фатих Әмирхан,— дип яза М. Укмасый,— безне түгәрәктә «Марсельеза», «Матәм маршы» һәм башка революцион җырлар белән таныштырып, без боларны барысын да язып алып һәм аларның русчасын, шулай ук татарчага тәрҗемә ителгәннәрен һәркайсыбыз җырлап йөри башладык»[6].

Тагын бер кызыклы мәгълүмат бар. 1904 елда Ф. Әмирхан өлкән сыйныф шәкерте буларак, түбәндәге сыйныфларга география дәресләре бирә. Д. Моратов үзенең истәлекләрендә Ф. Әмирханның Христофор Колумбның Американы ачуы турында гаять мавыктыргыч итеп сөйләве турында яза. Шул ук дәресләрдә ул төрле илләрдә дәүләт белән идарә итүнең нинди формалары булуы турында да әйтеп үтә, бигрәк тә төп формалар — монархия, конституцион монархия һәм республиканы аерып күрсәтә, өстенлекне исә соңгысына бирә[7].

Ф. Әмирханның инде 1904 елда ук мондый иҗтимагый-политик мәсьәләләрне анык белүендә аның социал-демократлар белән бәйләнеше һәм, әлбәттә, Гассар дәресләре дә мөһим роль уйный.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр. 7 т. Казан, 1984, 308—309 бб.

[2] Аитов И. Ә хәтердә әле һаман да бүгенге кебек. — «Совет әдәбияты», 1961,1 сан, 112 б.

[3] ТӘТИ архивы, 42 ф., 1тасв., 1 эш, 19 б.

[4] Шунда ук, 19 б.

[5] Алуши Р. Ф. Әмирхан турында истәлекләр. — ТӘТИ архивы, 16 ф., 2 тасв., 43 эш, 5 б.

[6] ТӘТИ архивы, 16 ф., 2 тасв., 46 эш, 6 б.

[7] Шунда ук, 6 б.

Әмирханның социал-демократлар белән нык бәйләнеше, алар белән бергә яшерен революцион эштә катнашуы, шәкертләр хәрәкәтенә җитәкчелек итүе аның дөньяга карашы формалашуы өчен гаять зур әһәмияткә ия була. Нәкъ менә революция алдындагы һәм революция елларын күздә тотып, Ф. Әмирхан: «... ул еллар минем иске караш вә иске ышануларым җимерелгән... еллар»[1] — дип яза. Ризван Алушига 1906 елның 9 декабрендә Мәскәүдән язган хатында ул нык ышанып үзен социалист дип саный[2].

Димәк, укуын дини мәдрәсә шәкерте булып башлаган, үзенең карьерасын дини җирлектә дәвам иттерергә тиешле Ф. Әмирхан 1906 елда үзенең социалист булуына инде чын-чынлап инанган була. Аның үз-үзенә биргән бәясе чынлыкка ни дәрәҗәдә туры килүенә игътибар итмәгән хәлдә дә, иҗтимагый-политик яктан нык үсүе күз алдында.

Ф. Әмирханның иҗтимагый-сәяси проблемаларга багышланган хезмәтләрен, тәрҗемәләрен анализламыйча әдипнең дөньяга карашы формалашуга бирелгән бәя берьяклы булыр иде. Тикшерелә торган чорга аның мондый хезмәтләре шактый була инде. Башында Ф. Әмирхан торган шәкертләр түгәрәге, алдарак искә алынган «Әл-Мәгариф», «Тәрәккый», шулай ук «Кустәргеч», «Телчән», «Манзарател галәм» h. б. кульязма газеталар, гектографта басылган «Әльислах» газетасын чыгара. Аларда Әмирхан язган күп кенә материаллар урнаштырыла. Моннан тыш, шәкертләргә мөрәҗәгать итеп язылган күп кенә листовкалар да аныкы була. Кызганычка каршы, бу гаять күп төрле материал я юкка чыккан, яисә әлегә табылмаган.

Ф. Әмирханның идея ягыннан формалашу чорына караган ике мәгълүм эшенә — «71 елгы Париж коммунасы» дигән марксистик брошюраның тәрҗемәсенә (1906 елда «Әлгасрел-җәдид» журналының 6 һәм 8 саннарында басыла) һәм үзе сәркатип ягъни секретарь булып эшләгән «Тәрбиятел-әтфаль» журналында басылган мәкаләләр циклына кыскача булса да тукталып үтү кирәк.

«Париж коммунасы»н тәрҗемә иткәндә Ф. Әмирхан поляк авторы Марек Конкольның рус телендә чыккан басмасыннан файдалана[3]. 1906 елда Петербургта чыккан рус варианты — «71 елгы Коммуна. Париж эшчеләренең 1871 елгы восстаниесенең кыскача тарихы» дигән исем белән чыккан 32 битлек бәләкәй генә китап. Анда Париж Коммунасы барлыкка килүенең социаль-экономик һәм политик сәбәпләре, аның тарихы һәм төп тарихи сабаклары кыскача бәян ителә. Брошюра көчле хис-дәрт белән язылган, ул революциягә чакыру кебек укыла.

Берничә факт аеруча кызыксыну уята. Беренчедән, брошюра 1906 елда басыла (ае билгеле түгел), ә инде шул ук елның июнь-август айларында аның татарчага тәрҗемәсе чыга. Шушы хәл үзе генә дә Ф. Әмирханның китап продукциясен күзәтеп баруы турында сөйли. Моннан тыш, әчтәлеген татар укучысына җиткерергә теләп, нәкъ менә шушы брошюрага игътибар иткән икән, димәк брошюра аның үзенең фикер сөрешенә туры килә, һәм ул аңа көчле тәэсир ясаган. Р. И. Нәфиков билгеләп үткәнчә, редакциядән тормаган сәбәпләр буенча брошюраның татарча тәрҗемәсе тулы күләмдә басылмаган[4]. Тулы текст гектография ысулы белән яшерен басылган булуы мөмкин дип фараз кылырга урын кала. Ф. Әмирханның әлеге брошюраны Х. Ямашев тәкъдиме белән тәрҗемә иткән булуы да мөмкин.

Ф. Әмирхан файдаланган Петербург басмасы тышлыгының соңгы битендә сатуда булган китаплар исемлеге бирелгән. Алар арасында Ф. Энгельсның «Франция һәм Германиядә крестьяннар мәсьәләсе», Маркс һәм Энгельсның «Иҗтимагый сыйныфлар һәм коммунизм», Лассальнең «Хатын-кызлар һәм социализм» дигән әсәрләре, «Бөек француз революциясе» дигән китап h. б. бар. Соңыннан тышлыкта күрсәтелгән китапларның күбесе Ф. Әмирханның шәхси китапханәсендә дә була.

«71 елгы Париж Коммунасы» брошюрасы 17 параграфтан тора». «Әлгасрел-җәдид»тә түбәндәгечә исемләнгән беренче җиде параграф басыла: «Франция эшчеләренең XIX гасыр уртасына кадәр күтәрелүләре», «Кечек Наполеон падишаһлыгы вакытында Франция», «Сугышка — сугыш», «II нче империянең шартлавы», «Җөмһүрият тарафдарлары байлар (буржуазия) ничек ватанны мәхфүзә[5] иткәннәр», «Париж халкына вә җөмһүриятkә каршы». Әчтәлеге буенча аеруча кызыклы булган шуннан соңгы параграфларны (моны аларның исемнәреннән дә чамаларга була: «Яшәсен Коммуна!» «Пролетариат диктатурасы», «Коммунаның хаталары», «Коммунаның үч алучылары»), күрәсең, цензура үткәрмәгәндер.

---

[1] «Аң», 1914, 18 сан, 332 б.

[2] «Казан утлары», 1966, 1 сан, 106 б.

[3] Конколь М. Коммуна 71 года. П., 1906.

[4] Нәфиков Р. И. Фатих Әмирхан — публицист һәм җәмәгать эшлеклесе. — «Казан утлары», 1976, 8 сан, 145 б.

[5] Мәхфүзә — саклану

Текстта «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» — дигән лозунг бар. Р. И. Нәфиков моны мәшһүр лозунгның татар теленә беренче тәрҗемәсе булуын билгеләп үтә. Тарихи параллельләр, Франциядә Коммуна вакыйгалары чорына кадәр һәм шул вакытны булганны чагыштырулар аеруча игътибарга лаек, алар укучыларга (шул исәптән, тәрҗемәчегә, ягъни Ф. Әмирханга да) тарихи вакыйгалар турында белергә дә, үзебездә, Россиядә булган хәлләрне яхшырак аңларга да ярдәм итәләр. Бу җәһәттән, французныкы яки теләсә кайсы башка милләтнеке булсын — буржуаз ура-патриотизм фаш ителгән урыннар аеруча кызыксыну тудыра[1].

Ф. Әмирханның тәрҗемә итә торган текстка иҗади якын килүе, материалның эчтәлеген тирән аңлавы һәм киң катлам татар укучысына аңлаешлы итәргә омтылуы аның социаль-политик терминнарны тәрҗемәдә ничек бирүеннән үк күренеп тора. «Буржуазное общество», «пролетариат», «демократическая республика» кебек төшенчәләрне ул калька аша гына да, мәгънә буенча гына да тәрҗемә итми, политик белеме чамалы булган гади халык та төшенерлек итеп аңлатып бирә. «Буржуаз җәмгыять» термины алдына ул Конкольдә булмаган «байлар» сүзен өсти. «Пролетариат» сүзеннән соң моның җитештерү средстволары булмаган, үз эш көчен сатарга мәҗбүр кешеләр икәнен өстәп әйтә. «Правительство эксплуататоров»ны ул «аларны (эшчеләрне — А. Х.) залим итә торган вә талап торучылар хөкүмәте» дип тәрҗемә итә. Бу хәл Әмирханның халыкны политик яктан агартырга омтылуын гына түгел, ә бәлки С. Гассар һәм Х. Ямашевларның дәресләре эзсез үтмәвен, аның инде 1906 елда ук төп иҗтимагый-политик терминнар белән иркен эш итүен дә күрсәтә.

Брошюраның «Әлгасрел-җәдид»тә басылган өлешенә, ягъни, баштагы җиде параграфына таянып, Р. И. Нәфиков мондый нәтиҗә ясый: «Әгәр аны гомум тарихның мәгълүм бер өлешен татар телендә фәнни нигездә аңлаткан, татарларны Франция тарихы, фәнни социализмның кайбер положениеләре белән таныштырган беренче хезмәт дисәк, бер дә ялгышмабыз кебек»[2]. Бу әсәрдә пролетариат диктатурасының зарурлыгы кебек иң мөһим положениеләр укучыга гаять җанлы, күңелгә үтеп керерлек итеп җиткерелгән, анда Коммунага гимн җырлана.

Бу брошюрадан алган тәэсир Әмирханның бөтен гомеренә җиткән. Китапханәсендә Париж Коммунасы тарихына караган китаплар, Б. Баксның татарчага тәрҗемә ителгән «Париж Коммунасы» китабы, Коммунаның «Канлы атнасы» күренешләрен сыйфатлаган актлар һәм документлар җыентыгы, К. Маркcның «Франциядә гражданнар сугышы»[3] һ. б. булу әнә шул хакта сөйли.

Нәтиҗә ясап, беренче рус революциясе еллары Ф. Әмирханның бөтен киләчәк иҗтимагый-политик эшчәнлегенә генераль репетиция була, дип әйтергә мөмкин. Бу чорда ул инде үзен ныклы карашлары, аныкланган симпатияләре һәм максатлары булган тәмам формалашып беткән шәхес — демократик үзгәртеп коруларның, гадел социаль строй урнаштыруның ялкынлы тарафдары, татар җәмгыяте тормышындагы барлык феодаль-патриархаль искелек калдыкларының аяусыз дошманы итеп күрсәтә.

**Айваз ХИСАМОВ.**

---

1 «Әлгасрел-җәдид», 1906, 8 сан, 423 б.

2 «Казан утлары», 1976, 8 сан, 146 б.

3 ТӘТИ архивы, 16 ф., 1 тасв., 45 эш.

# УРТАК УЙЛАР

Фатих Әмирхан гомере буе рус әдәбиятына зур игътибар бирде. Мәдрәсәдә уку чорында ук башланган бу мәхәббәт аны 1906 елда Петербургка алып килә. Биредә Әмирхан лекцияләр тыңлый, тарих һәм әдәбият буенча белемен арттыра, русчадан татарчага тәрҗемә белән шөгыльләнә башлый. Әдәби тәнкыйтче һәм публицист буларак аның иҗатын күздән кичергәндә дә әдипнең рус классикларына еш мөрәҗәгать итүен, аларның бай тәҗрибәсен файдаланырга чакыруын күрәсең.

Әдәбиятыбыз аксакалы Афзал ага Шамовның истәлекләренә караганда Фатих Әмирханның яшьләргә теләге шундыйрак булган: «Дөньяда зур әдәбиятлар, зур язучылар бар. Рус әдәбиятын мин шундый зур әдәбиятларның берсе итеп саныйм... Безнең яшь язучыларыбыз, үз әдәбиятыбызны ныклап, бик тырышып өйрәнү белән бергә, шул җәүһәрләрне дә белергә, өйрәнергә, алардан үрнәк алырга тиеш дип табам мин... Дөньяда Пушкин иҗаты бар, Толстой, Тургенев, Чехов һәм Максим Горький иҗаты бар. Алар бөек язучылар, бөек реалистлар...» («Казан утлары», 1966, 1 сан).

Фатих Әмирханның үз иҗаты да рус реалистик әдәбиятының бай тәҗрибәсен уңышлы үзләштерүгә мисал була ала. Без бу язмабызда бер үк чор тудырган иҗтимагый тенденцияләрнең ике әдәбиятта ни рәвешле чагылыш табуын күздән кичермәкче булабыз. Ягъни, рус һәм татар әдәбиятларының күренекле әдипләре А. П. Чехов һәм Ф. Әмирхан иҗатларында бу тенденцияләр ничек чагыла?

Горький бик дөрес язып калдырганча, Чехов яңа төр драма сәнгате тудырды, әдәбият һәм театр тарихына бөек демократ һәм гуманист, кыю новатор булып кереп калды. 1896 елда язылган «Акчарлак» әсәре аны аеруча җитди һәм үзенчәлекле драматург итеп танытты.

Чеховка кадәр яшәгән драматургиядә шундый язылмаган гадәт бар иде: әсәрдә нинди дә булса бер гадәттән тыш вакыйга килеп чыгарга тиеш һәм шуннан соң инде персонажлар бер-берсе белән конфликтка керергә тиешләр. Мондый очракта, билгеле, һәр бәхетсезлекнең, күңелсезлекнең конкрет гаеплесе, сәбәпчесе күренеп, аңлашылып тора. Ә менә Чеховның соңгы пьесаларында алай түгел. Анда күренеп торган көрәш яисә интрига юк. Автор фикерләрен турыдан-туры белдерүче уңай герой да күренми. Геройлар арасында конфликт туа калса, ул да чишелми, ә бары тик кемнеңдер йөрәген генә җәрәхәтли. Персонажлар күбрәк үзләренең гадәти тормышлары белән яшиләр, сөйләшәләр һәм еш бәхәсләшәләр. Шулай итеп, А. П. Чехов бер үзәк герой һәм хәлиткеч бер вакыйга принцибыннан катгый рәвештә баш тарта. Ул әсәр барышында әле бу, әле теге персонажны яктыртып ала, һәм ул персонаж, үзенә никадәр урын һәм әһәмият бирелүгә карамастан, төп фигура булып күренә.

Ф. Әмирханның 1915 елда язылган «Тигезсезләр» драмасы шулай ук буржуаз җәмгыятьнең кешелексез асылын фаш итүгә юнәлдерелгән. Бусы, әлбәттә, һәрбер гуманистик әдәбиятка хас уртак тенденция. Ә менә конкрет караганда татар әдибе үз пьесасын бөтенләй башкача төзи. «Тигезсезләр» өч кисәктән тора. Беренче пәрдәне нигездә озакка сузылган төенләнеш дияргә була һәм ул традицион ысулда иҗат ителгән. Пьеса абый кеше белән сеңелнең үзләренең туганы Рокыя турында сөйләшүеннән башланып китә. Аннары инде яшьлек һәм дәрт ташып торган Рокыя үзе килеп керә. Гәрчә әсәрнең алдагырак күренешләрендә аңа турыдан-туры кагылмаган өлешләр булса да, Рокыя, барыбер, барысын бергә җыеп торучы ниндидер бер үзәк нокта сыман яши.

Пьесаның башыннан ук диярлек музыка яңгырый, Рокыя дәртләнә-дәртләнә пианино уйный. Шулай итеп музыка әсәрнең бөтен барышына ямь биреп кенә калмый, ә катнашучы геройларның эчке дөньясын ачу чарасы да булып тора. Рокыя мисалында исә дәртле музыка гадәти һәм күнегелгән тормыштан күтәрелергә теләү сыман кабул ителә. Беренче пәрдә ахырында Рокыяның: «Мин рәссам булырга телим!»— дигән сүзләре тәэссоратны тагын да көчәйтеп җибәрә.

«Тигезсезләр»нең икенче пәрдәсе бүтәннәреннән нык кына аерылып тора. Биредә инде вакыйга җәй көнендә, дачада бара. Табигатьнең яшәргән, җанланган чагы. Кешеләрне дә шундый ук халәт биләгән. Әмма юк дигәндә дә борчулы авазлар ишетелгәләп китә. Чөнки Рокыяның рәссам булу хыялының тормышка ашмаячагы беленә башлаган. Ләкин ул үзе әле һаман ашкына, фикереннән кире кайтырга теләми. Икенче бер герой аңа карап бер дә юкка гына: «Рокыя, сиңа ефәк канатлар бик тә килешер иде!»— дими.

Бу пәрдәдә сизелгән борчулы авазлар өченче пәрдәдә үзләренең иң зур киеренкелегенә ирешәләр. Табигатьтә дә инде җәй үткән. Көн дә кичкә авышкан. Геройлар да берәм-берәм ачылып, акланмаган өметләре, чынга ашмаган мәхәббәтләре хакына сөйләшәләр.

Шулай итеп, Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»ендә күренеп торган бер зур вакыйга юк. Анда да геройлар үзләренең күңелләре ташып, булып киткән минутларда гына ачылалар һәм шуның белән билгеле бер әһәмият алалар. Ә тулаем тормыш өчен алар барысы да бертигез. Үзара караганда исә алар — тигезсезләр.

А. П. Чеховның «Акчарлак»ында гомер юлы башында торучы яшь кыз Нина курсәтелә. Ләкин аның баштагы хыялы әле зур данга ирешүдән генә гыйбарәт. Тик тормышның байтак четерекле якларын күргәннән соң гына, Нина чын мәгънәсендә халыкка һәм сәхнәгә хезмәт итү юлына баса.

«Тигезсезләр»дә дә һәм шулай ук «Акчарлак»та да мәхәббәт темасы шактый киң яңгыраш ала. Әмма, шулай булса да, ул барыбер әсәрләрнең төп хәрәкәтләндерүче көче түгел. Ул бары тик геройларның аерылгысыз өлеше генә. Бу сызык әсәрдәге төп күренешләргә бик үк бәйләнмичә генә, үзенә аерым гына бара кебек. Чөнки герой һәм героиняларның тормыш коруларында да, бала-чага булдыруларында да әлеге олы хиснең катнашы юк диярлек.

Аның каравы, «Акчарлак»та мәхәббәт темасы белән әдәбият-сәнгать темасы шактый тыгыз үрелгән. А. П. Чехов геройлары җәй чыккан саен яңа чор әдәбиятына һәм сәнгатенә карата үз фикерләре белән бик теләп уртаклашалар. Автор үзе дә бу мәсьәләгә зур игътибар бирә.

Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»ендә, билгеле, әдәбият-сәнгать проблемалары алай ук киң яктыртылмый. Чөнки әле бу вакыт әдипнең үзен дә, прогрессив карашлы бөтен интеллигентларны да икенчерәк уйлар — халык язмышы, аның киләчәге нинди булу борчый. Әсәрдә әлеге фикерләр язучы Сөләйман образы тирәсенә тупланыбрак бирелә. Икенче бер интеллигент Габдулладан аермалы буларак, ул халкына, аның көченә һәм киләчәгенә ышана. Сөләйман халыкның алга баруына интеллигентларның ничек, ни рәвешле ярдәм итә алулары хакында уйлана. Чын интеллигент нинди булырга тиешлеген күзаллый. Гасыр башындагы иҗтимагый тенденцияләрне нечкә тойган Ф. Әмирхан үзенең бу образы белән бик тә әһәмиятле фикерләр әйтә.

«Акчарлак»та геройларның әдәбиятка ике төрле карашлары шактый киң яктыртыла. Яшь драматург Треплев башта тормыштан аерылган иҗат белән мавыга, әр-яңа формалар уйлап чыгарырга ашкына. Аның антиподы Тригорин исә сыналган рәвештәге һәм җиренә җиткереп эшләнгән иҗат ягында. Пьеса ахырында Нина сәнгатьнең чын юлын таба, Треплев та яшьлек мавыгуларын онытып бара. Ул инде хәзер: «Мин һаман ныграк шундый фикергә ышана барам — кеше чын иҗат вакытында бернинди форма турында да уйлап тормый, ул бары тик күңелендә, җанында ташыганны, кайнаганны кәгазьгә генә түгә!» — ди.

«Тигезсезләр»дә дә пьеса ахырына геройлар байтак үзгәреш кичерәләр. Практик омтылышлы кешеләр үз теләкләренә ирешә: Гомәр кибет ача, сеңлесе Сәлимә аның ярдәмчесе булып эшли башлый. Рухи омтылышлырак Рокыя исә гимназия тәмамлый. Ул һаман да иркә-ягымлы кыз, һаман «тел бистәсе». Ләкин хәзер инде анда да киләчәк турында уйлану бар. Рокыя инде хәзер кешеләр хакында җитдирәк итеп фикер йөртә, үзеннән дә күбрәк таләп итә. Бередә, менә шушы образда, Ф. Әмирханның хатын-кыз идеалы да байтак дәрәҗәдә чагылыш таба.

Шулай итеп, егерменче гасыр башының яңа чынбарлыгын чагылдыруда ике зур әдәбиятның ике зур әдибе һәркайсы үзенчә эш итә, сәнгатьнең төрле ысулларын, юлларын файдалана. Әмма иҗтимагый үсешнең яңа тенденцияләре — уртак уйлар — аларның иҗатларын бер-берсенә шактый якынайта да.

Ике олы әдипнең әсәрендә дә сәнгать чараларының киң диапозонын күрәсең: анда тирән моңсулык та, җитди уйлану да, яшьлек дәрте дә һәм юмор да бар. Әмма шунысын басым ясап әйтергә кирәк — боларның һәммәсе ахыр чиктә кеше шәхесен изә торган тормыш шартларын күрсәтү өчен, шул чынлыкны төрле яклап ачу өчен хезмәт итә.


Тарихка бөек гуманист булып кереп калган һәр ике әдип үз әсәрләрендә кешенең бәхетле тормышына бару юлын эзлиләр. Алар яшәү шартларын яхшырту, аны кешелекле итү чараларын табарга телиләр. «Кеше чын-чыннан кеше булып яшәсен өчен, аның бөтен матур сыйфатлары ачылсын өчен тормыш үзе нинди булырга тиеш?» — бу язмада каралган һәр ике әсәрнең иң калку куелган проблемасы әнә шул.

Ф. Әмирхан үз иҗатында яңа үрләр яулый барып, элекке драматургия тәҗрибәсен ныклап үзләштергәннән соң, яңа чор тенденцияләрен уңышлы чагылдыру нәтиҗәсендә беренче психологик драма иҗат итте. Аның бу мөһим адымы киләчәктә татар драматургиясенең киң сулыш алып социаль, психологик тирәнлектә үсеп китүен хәзерләште. һәм инде, әлбәттә, хәзер барыбыз да күреп торабыз: әдип үзенең хыялында күрергә теләгән шартлар да барлыкка килде — илебездә кеше шәхесе һәр яктан матур үссен өчен бөтен шартлар булдырылды.

Эльмира ГОБӘЙДУЛЛИНА

# ФАТИХ ӘМИРХАН ЯДКАРЕ

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның 100 еллык юбилее якынлашкан көннәрдә әдип биографиясенә һәм иҗатына кагылышлы яңадан-яңа материаллар табыла һәм фәнни әйләнешкә кертелә. Хәлбуки, әдипнең үз кулы белән язылган кайбер хат һәм открыткалар әле аерым кулларда, шәхси архивларда саклаулар. Алар Ф. Әмирханны әдип һәм шәхес буларак тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итәләр. Шуны истә тотып, мин дә әтиемнең бертуган апасы Зәйнәп Әмирханованың кәгазьләре арасында сакланган бер истәлекне укучыларга тәкъдим итмәкче булам. Ф. Әмирханның туганнан туган сеңелесе (әтиләре бертуган) Зәйнәп Нәҗип кызы Әмирханова (1893—1977) открытка язылган чорда әтисе гаиләсендә Чистайда яши һәм шундагы кызлар гимназиясендә укый, ә 1914 елда Казанга килеп хосусый гимназиянең соңгы, 8 нче классына керә. Бу вакытларда Зәйнәп абыйсы белән якыннан аралаша. Ф. Әмирханның да Чистайга берничә мәртәбә килүе мәгълүм. Зәйнәп апаның сүзләренә караганда, алар хатны да еш алышканнар. Зәйнәп Фатих Әмирханның бик яраткан сеңелләреннән берсе булган. Әдип сеңелесе белән әдәбият, тарих, культура мәсьәләләре турында сөйләшкән, аңа үзенең яңа язылган әсәрләрен укыган. Шук табигатьле, җор сүзле әдип сеңелесенә хат язганда да аны ЕВБ (ЕЕ Высокоблагородие) дип шаярта торган булган.



Гимназияне тәмамлаганнан соң (1915) Зәйнәп Әмирханова балалар укыта, 1918—1919 елларда ул — мәшһүр төрек революционер-интернационалисты Мостафа Сөбхи җитәкчелегендә чыккан «Яңа дөнья» газетасының хезмәткәре. Соңрак Зәйнәп Бакуга китеп, анда бер-бер артлы педагогия һәм медицина институтлары тәмамлый, илле еллап укытучы һәм врач булып эшли. Түбәндә китерелә торган открытка тексты Ф. Әмирханның сеңелесенә карата булган җылы туганлык хисләрен чагылдыра. Открытка үзе исә Ф. Әмирхан портреты рәвешендә эшләнгән һәм анда портретның «Гасыр» нәшрияты милке икәнлеге күрсәтелгән. Портрет өстенә «Әхмәтгәрәй Хәсәни әфәндегә. Фатих Әмирхан 19 $\frac{26}{VII}$ 12» дип язылган. Ә. Хәсәни (1883—1934) журналист, нашир, «Аң» журналының редакторы һәм Ф. Әмирханның дусты булган. Открытканың икенче ягына түбәндәге сүзләр язылган: «Зәйнәп, менә, сеңелкәем, бу сиңа минем сурәтем. Агаңны кайсы вакытларда сагынып куйсаң, шуңа карарсың. Карарсың да,— әбәү, мәхәббәтсез, нинди Шерлок Холмска охшап төшкән бит!— дип куярсың. Быел ник Казанга килмәдең? Җүләр кызый! Иренмәсәң, хат яз.

Сагынып: Фатих Әмирхан. 19 $\frac{10}{IX}$ 12».

**Равил ӘМИРХАНОВ**,
тарих фәннәре кандидаты.

# БЕР СЮЖЕТНЫҢ СЕРЕ

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның бай һәм күпкырлы әдәби мирасында серләр байтак. Аларның берсе язучының «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясенә бәйле. Бу хикәя 1912 елда языла һәм шул ук елның ахырында «Аң» журналында басылып чыга. Хикәянең исеме астына «сюжеты икенче әсәрдән алынды», дип язылган.

Әлегә кадәр сюжетның кайсы әсәрдән алынганлыгы мәгълүм түгел иде. Бу хакта Ф. Әмирхан үзе әзерләгән басмаларда да, язучының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында саклана торган архивында да (16 нчы фонд) бернинди мәгълүмат юк. Фатих Әмирхан әсәрләренең 1941 елда чыккан бер томлыгында, 1957 елда дөнья күргән ике томлыгында да, шуннан соңгы басмаларында да әлеге мәсьәлә читләтеп үтелә.

Бу юллар авторы, Ф. Әмирханның игътибарын азмы-күпме җәлеп иткән язучыларның әдәби әсәрләрен берәмтекләп күздән кичергәннән соң, бер әсәргә килеп юлыкты. Ф. Әмирханга «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясен язу өчен нәкъ менә шушы әсәрнең сюжеты азык биргән дип һич икеләнми әйтергә мөмкин. Бу — А. П. Чехов иҗатының башлангыч чорында язган «Винт» хикәясе.

А. П. Чехов хикәясенең сюжетына нигез итеп карта уенында артык һәвәсләнеп, комарга бирелеп азыну вакыйгасы алынган. Чехов әсәренең баш герое Андрей Степанович Пересолин — зур чиновник, губерна идарәсе башлыгы. Шыксыз бер көзге төнне, ул театрдан өенә кайтып бара. Каретага кырын төшкән килеш ул, әгәр театрларда әхлаклы пьесалар уйналса, алардан никадәр файда булыр иде, дип акыллы уйларда тирбәлеп кайта. Хикәянең проблематикасы — каһарманның әхлакка, үз бурычына сүздәге һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәте — әнә шулай беренче юллардан ук төсмерләнә башлый.

Губерна идарәсе турыннан үткәндә Пересолинның инде йокы иңә башлаган күзләре дежур бүлмә тәрәзәсендә ут яктысы шәйләп ала. Андрей Степановичның шуннан соңгы фикер-ниятләре менә мондый: «Дүрт аңгыра бәрән утыралар шунда, һаман бетермәгәннәр икән! Мин аларга төнлә дә тынгы бирмим икән, дип уйлар тагын кеше. Куып таратыйм әле үзләрен...»

Бу җөмләләрдә Пересолинның, үзенә буйсынган кешеләр турында кайгыртудан битәр, кеше сүзеннән өркүе күренә. «Ул-бу була күрмәсен»,— куркаклыкның шушы классик формуласына ябышып яшәү Чеховның бу героена да килешеп тора.

Идарәгә кергәч, Пересолин беркадәр вакыт дежур бүлмәнең ярым ачык ишеге артында тукталып кала. Ул бүлмә эчендә күргән чиновниклар һич тә отчет белән түгел, ә бәлки бик тә начар, бик тә әхлаксыз шөгыль — эш урынында карта уйнау белән мәшгульләр ләбаса! Чиновникларның абажурлардан төшкән яшел ут яктысында күгәреп күренгән киеренке, катып калган йөзләре аңа бик нык тәэсир итә.

Шулай да, әгәр чиновниклар гади винт уены гына уйнап утырсалар, мөгаен, башлыклары аларга җәза бирми калмас иде. Ләкин Андрей Степанович Пересолинда тыелгысыз бер кызыксыну уяна. Карта сугучыларның әледән-әле кычкыргалап куйган сүзләре үята бу кызыксынуны. Шул сүзләргә карап, менә нинди нәтиҗәгә килә Пересолин: «Бу винт түгел, гомумән, карта уены икән әле. Бу ниндидер колак ишетмәгән, хикмәтле һәм серле уен...» Уйнаучылар телендәге карта уены терминнары әледән-әле чиновникларның һәм аларның хатыннарының фамилияләре белән чиратлаша. Пересолин һәм хәтта... Пересолиха да игътибардан читтә калмый.

Эшнең асылын ятьрәк беләсе килеп, Пересолин бүлмәгә килеп керә. Аны күргә чиновниклар өнсез кала. Әмма, игътибар иткәнебезчә, ишек артында торганда Пересолинда шушы гайре табигый уен белән кызыксыну вәсвәсәсе уянган инде. Ул чиновникларның винт уенына үзләреннән «яңалык» кертүләрен сорашып белә. Карталарга алар, нинди урын биләүләрен карап, чиновникларның һәм аларның җәмәгатьләренең фоторәсемнәрен ябыштырып чыкканнар икән. «Яңалык» үзләренә ошап киткән ахрысы: уен кызган, вакытның бик соң икәнен дә сизүче юк.

Үзенең треф тузы, ә җәмәгатенең треф дамасы дәрәҗәсендә булуын белү Пересолинның күңеленә хуш килә. «Һы! Кызык бу... Ягез әле, уйныйк! Карап карыйм әле...»— дип, бая гына әхлак, бурыч турында лаф орган, хәзер исә уенга тәмам нәфсесе кузгалган Андрей Степанович кулына карта ала.

Фатих Әмирханның «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясенең сюжетына да нигез итеп карта уены белән вәсвәсәгә төшерү ситуациясе алынган. Хәер, хәзрәтнең башка «йомшак» яклары да бар икән.

Гайнетдин хәзрәтнең Казанга килеше. Бер очтан, «атасының үтенече буенча», элекке шәкертен үгетләп китмәкче дә булган. Андрей Степанович Пересолин кебек, хәзрәт тә үзен бик әдәпле, әхлак сагында җаны фида кеше дип саный. Әмма аның Закир атлы элекке шәкерте хәзрәтнең һәр сүзен мөкиббән китеп тыңларга охшамаган. Алай гынамы әле, Закир үзенең остазын мыскыллы рәвештә «сәламләү маршы» сызгырып каршылый.

Хәзрәт уенча, Закир үзен бик әдәпсез, аныңча әйтсәк, «кабәхәт» тота. Ул өстенә урыс киеме кигән, остазының җилкәсеннән каккалап ала, тәмәке пыскыта.

Васвасә салу механизмы, кайбер детальләр өстәп, А. П. Чеховның «Винт» хикәясендәге тәртиптә корылган. Ф. Әмирхан хикәясендә дә карта, мәҗбүри булмаса да, мәгъкуль атрибут. Иң әүвәл Закир килеп кергән хәзрәткә тәмәке тәкъдим итә: «Я әле, тәкъсир, чәй булганчы, бер төтен чигеп җибәрик әле!» Гайнетдин хәзрәт баш тарта, әмма Закир да мәкерле, ул тәкъсирнең тәмәкене тел астына салырга яратканын белә һәм шундыйны китертә. Бу эшләрдән хәзрәтнең тәмам сабыры җуела.

Аннары, Чехов хикәясендәге рәвешле, өстәлгә карта чыгарыла. Кулына карталар тоткан Закир, шат елмаеп, хәзрәткә мөрәҗәгать итә: «Син нинди уеннар уйный беләсең, тәкъсир? Преферансны яхшы белми торгансың инде?» Бу сүзләрдән тәмам шашынып калган хәзрәт, китәргә дип, җилләнеп урыныннан кузгала, ләкин шәкерте остазының әхлагы кай яклардан чатнаганын күптән белә булса кирәк. Закир, кәефле көлемсерәп, хәзрәтнең күзләренә карый һәм, аның тынычланырга ашыкмаганын күргәч, күрше бүлмәгә дәшә: «Карагыз әле, Мәрьям туташ, менә дамелла чәй эчми китмәкче була». Ул бүлмәдән яңгыравыклы, саф, гаять матур тавышның: «Бер дә ярамый, хәзрәт! Бер дә ярамый! Менә хәзер сезгә чәй әзерлим»,— дигәне ишетелә.

Бу тавыш нәсе бер матур кыз буласын хәзрәтнең колаклары сизмиме соң? Аның күңеле алгысап куя, ачуы басылып, нервлары тынычланып китә, бөтен назланып, вәкарь саклап тормаска була. Чәйдән соң, хәзрәт, Закир, Мәрьям — өчәүләп инде карта уйнап утыралар. Күргәнебезчә, дамелланы юлдан яздыру әйберсе карталар гына түгел. Монда өстәмә стимул пәйда була: бүлмәгә мәхәббәтле яшь туташ керү дәрте азган хәзрәтне тыелган, үзе әйтмешли, «мәһни» эшкә этәрә. Шушы күренештән алдарак хикәядә Закирның дамелла хатыннарын һәм кызларын искә алып сөйләве бар иде. Шәкертнең остазына «икенче юлы яшь хатыныгызны һәм кызыгыз Хәмдияне алып килегез, танцы кичәсе оештырырбыз», дип әйтүе бер дә юкка булмаган икән.

Язык эшкә күндерү күренешен композицион хәл итүдә, Чеховның «Винт» хикәясендәге кебек үк, ярым ачык калган ишек мөһим роль уйный. Пересолин шикелле хәзрәт тә язык эшкә ерактан торып ымсына. Чехов герое бусагадан атлап керүгә уенга кушылып китә. Әмирхан хикәясендә бусаганы Мәрьям туташ атлый, ә хәзрәт исә әхлаксыз шөгыльгә керешергә тиеш. Хикәядә нәкъ шулай була да.

Бу ике әсәрнең финалы тагын да охшашрак. «Винт» хикәясенең ахыры бик мәзәк тәмамлана. Чиновник Недоехов белән бер парда уйнап оттырган Пересолин агарынган, йокы баскан, чәче-башы тузган хәлдә тегенең төймәсен боргычлый-боргычлый сөйли: «Аңла, син шуны аңла, кулымда мин үзем икәнне белә торып Шепелевтан йөри алмый идем... Хәзер мин сиңа исбатлыйм. Әфәнделәр, утырыгыз. Тагын бер робер уйнап карыйк!»

Чиновниклар, шул исәптән, Пересолин да хезмәтләрен онытканнар, гүяки ул бөтенләй булмаган да. Алар, иртән килеп кергән каравылчыны чыгарып җибәреп, уенны дәвам итәләр.

Әмирхан хикәясенең А. П. Чехов хикәясенеке кебек үк мәзәк финалында Закир, хәзрәт һәм Мәрьям өчәүләп карта сугалар. «Винт»тагы кебек үк, уйнаучылар уенның соңгы йөрешләренә аңлатма биреп баралар. Андрей Степанович Пересолин шикелле Гайнетдин хәзрәт тә оттыра. Мәрьям туташ дурак калган дамелланың ун тапкыр борынына чиерткәндә Закир санап тора. һәм үзе сөйләнә: «...катырак, Мәрьям туташ, үгетлим дип йөрмәсен икенче юлы!..» Ә хәзрәт көлә генә: «һи, һи, һи, ахмак, сафсата, андый нәфис бармак белән чиерткәннән борын шешәме соң!» Мондый уенның хәзрәткә хуш килүе көн кебек, һәм мөгаен «Винт»тагы Пересолин кебек ул да уенны дәвам иттерергә теләр.

Шулай итеп, А. П. Чеховның «Винт» һәм Фатих Әмирханның «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясенең вакыйгалар системасын, геройларының психологик халәтен чагыштырып анализлау шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: аларның охшашлыгы очраклы хәл була алмый. Киңрәк тарихи-әдәби контекстта алынган фактлар да моны раслый.

Әмирханның рус әдәбияты белән кызыксынуы, рус язучыларыннан өйрәнүе мәгълүм. Бер мәкаләсендә («Гоголь бәйрәме»—1909) татар классигы болай дип яза: «...рус әдәбияты безнең яңа әдәбиятыбызга күп тәэсир итә генә түгел, бәлки күп ярдәм дә итәдер». М. Укмаси истәлекләренә караганда, Фатих Әмирхан яраткан язучылар арасында А. П. Чехов та була.

«Винт» хикәясенә килгәндә исә, А. П. Чеховның иҗат мирасында аның ныклы урыны бар. Хикәя беренче мәртәбә 1884 елда «Осколки» журналында басылып чыга. Күпмедер үзгәртелеп, ул «Чуар хикәяләр» (1886) җыентыгына, соңрак автор тарафыннан шушы җыентыкның һәр унөч басмасына һәм сайланма әсәрләренең икенче томына кертелә. Әмирхан бу китапларны укымый калмаган, әлбәттә. Беренчедән, күрүебезчә, «Винт» күп мәртәбәләр басылган. Икенчедән, хикәянең идея һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан шөбһәсез өстенлекләре бар, форма җыйнаклыгы һәм тәнкыйтьләү юнәлеше дә Әмирхан күңеленә хуш килсә кирәк.

Әммә Фатих Әмирхан әлеге хикәяне сүзгә-сүз кабатламый, бәлки шундагыга охшаш ситуациядән файдаланып, оригиналь әсәр иҗат итә. Әсәрдә хикәяләү чын милли җирлеккә корылган. Автор XX йөз башы татар җәмәгатьчелеге өчен үтә характерлы образлар — кадим карашлы һәм эчтән бозык Гайнетдин хәзрәт, өлгергәнлек аттестатына имтихан тотарга әзерләнеп йөрүче чая егет Закир, көләч һәм мәгълүм дәрәҗәдә хөр кыланышлы Мәрьям туташ образларын тудыра. Хикәянең сатирик угы милли тормыш прогрессының

явыз дошманына — иске карашлы руханиларга юнәлдерелгән. Хәзрәт белән аның элекке шәкерте арасындагы конфликт шул чордагы татар җәмәгатьчелегенең рухи дөньясына хас социаль-этик каршылыкларның хосусан чагылышы гына ул.

Әмирхан хикәясенең поэтикасы нигезендә дә иҗади башлангыч ята. Чехов хикәясе белән чагыштырганда ул ассоциатив сюжет бәйләнешләренә баерак. «Винт» хикәясендә вакыйгаларга нигезләнү өстенлек ала. Ә «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясендә исә вакыйгалар дәвамында әледән-әле тормыштагы реаль процессларны киңрәк колачларга ярдәм итә торган төрле сүзләр кыстырыла.

Гайнетдин хәзрәтнең «Бохарада белем эстәп кайткан һәм Закир укыган мәдрәсәдә мөдәррислек иткән» мулла икәнлеге башта ук әйтеп куела. Закир үзе турында «мин хәзер инде хәлфә вакыттагы кабахәтлекләремнең бик күбесен ташладым», ди. Гайнетдин хәзрәт үзенең нигә килгәнен әйтмәкче булып кат-кат талпынып карый. Закир Гайнетдин хәзрәтне Мәрьям туташ белән «Каргалының иң зур мөдәррисләреннән» дип таныштыра. Һәм шунда ук хәзрәтнең яшь хатыны белән кызы Хәмдия турында сөйләп китә.

Җыеп әйткәндә, Ф. Әмирхан бөтенләй яңа сюжетлы, Чеховныкы белән чагыштырганда катлаулырак поэтикалы әсәр иҗат иткән. (Монда «Винт» хикәясенең рус язучысының беренче чор иҗатына каравын онытмаска кирәк). Ә сюжет яңалыгында жанр үзгәрешләре дә, художество методының яңарышы да гәүдәләнеш тапкан. «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясе новелла жанрына хас кайбер сыйфатларга ия: интригасы шактый динамикалы, көлкеле ситуация, көтелмәгән комик чишелеш. Нигездә бу — конкрет детальләргә бай реалистик әсәр.

Шулай итеп, мәгълүм бер дәрәҗәдә А. П. Чеховның «Винт» хикәясе белән аваздаш булган һәм аның бәрәкәтле йогынтысында язылган «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясендә Ф. Әмирхан бик тә оригиналь, үзенчәлекле, һәрвакыт сәнгати ачышларга омтылып яшәүче, үзенең элгәрләре тәҗрибәсен иҗади файдаланучы автор буларак калка.

Фатих Әмирхан иҗатының шушы ягын, аерым алганда — Чеховның әдиплек тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итүен татар галимнәре билгеләп үткәннәр иде инде. Әмма тулы бер проблема —«А. П. Чехов һәм татар әдәбияты» проблемасы тикшеренүчеләр күзеннән читтә кала әле. Шушы проблеманы өйрәнеп чыгу XX йөз башындагы яңа татар әдәбияты ничек формалашуны ачыкларга ярдәм итәр иде.

**Рәхимҗан ГАИСИН.**

# ШИГЪРИ МАТЕРИКЛАР КОЛУМБЫ

Атаклы рус совет шагыйре Велимир Хлебниковның тууына 100 ел тулды. Владимир Маяковский аны үз заманында яңа шигъри материклар ачучы Колумб дип атаган иде.

1905 елгы рус революциясеннән соңгы реакция чорын кичереп, Россиядәге яңа демократик күтәрелеш дулкыннарында мәйданга чыккан бер төркем иҗади яшьләр — «Җәмәгатьчелек зәвыгының яңагына сугу» («Пощечина общественному вкусу») дигән әдәби манифест авторлары арасында В. Маяковский белән берлектә В. Хлебников та була. Яшьләргә хас кискенлек белән бөтен искене — шул исәптән Пушкиннарны да!— селереп түгәргә өндәгән, үзләрен яңа заманның яңа даһилары дип игълан иткән футуристлар була болар.

Велимир (Виктор) Владимирович Хлебников 1885 елның 9 ноябрендә Астрахань якларындагы бер авылда (Энциклопедияләрдә Тундутово яки Малые Дербеты авылы күрсәтелә. «Советская Россия» газетасы күптән түгел (25 август, 1985 ел, № 195) калмык далаларындагы Малодербет улусы дип язып чыкты.) натуралист галим-педагог гаиләсендә дөньяга килә. 1903 елдан Велимир — Казан университеты студенты. Ул башта математика, аннары табигать белеме бүлекләрендә укый. 1908 елда Петербург университетының тарих-филология факультетына күчә (тәмамлап чыкмаган). Әдәби иҗат белән студентлык елларында шөгыльләнә башлый. Уолт Уитмен шигырьләре йогынтысында ритмик проза белән язылган «Зверинец» исемле әсәре 1910 елда дөнья күрә.

«Велимир Хлебников ачкан шигъри материкларга без килеп тулдык»,— дип язган В. Маяковский. Әйе, В. Хлебников шигырьдә армас-талмас тәҗрибәләр ясаучы, тынгысыз эзләнүче-экспериментатор була. Аның эзләнүләре үзеннән соңгы буын совет поэзиясе вәкилләре өчен гаять тә әһәмиятле, гаять тә зарури иде. Шул ук В. Маяковский В. Хлебниковның биографиясен чын шагыйрьләр өчен өлге-үрнәк итеп куя.

Велимир Хлебниковның шигырьдәге осталыгына ис китәрлек. Аның башы көне-төне шигырь эшкәртә, ул һәр күзәнәге, бөтен тормышы белән шигырьдә яши. Дусларына ул еш кына берәр шигырь укып китә дә, ярты сүздә бүленеп: «Алга таба шулай бара инде, үзегез дәвам итәрсез»,— ди торган була. Аның һәр ике яктан да бер төрле укылышлы (палиндром) итеп язылган шактый озын поэмасы бар. Аның «люб» тамырыннан ясалган сүзләрдән генә торган алты битлек әсәрен, типографиядә «л» хәрефләре җитмәгәнлектән, бастырып чыгара алмаганнар. Велимир Хлебников тынгысыз сәяхәтче булган. Ул бер урында гына яши алмаган. Аның кайда, нинди максат белән чыгып киткәнен берәү дә әйтә алмаган. Үз шигырьләрен үзе җыеп бастырып йөрмәгән. Үз гомерендә үз кулы белән бер юл шигырен дә матбугатка тәкъдим итмәгән. Моны аның дуслары эшли торган була. Бервакыт В. Маяковский бик зур кыенлыклар белән В. Хлебниковның зур күләмле җыентыгын бастырып чыгарырга әзерләгән, булачак китапның гонорары хисабына аванс итеп Хлебниковка шактый күп (1150 сум) акча биргән. Иртәгә нәшрияттә договорга кул куясы дигән көнне Маяковский Хлебниковны чемодан күтәргән хәлендә урамда очрата. «Сез кая болай?»— дип сорый Маяковский. «Көньякка, яз бит!»— дип авызын ера Хлебников. Вагон түбәсенә кунаклап китеп тә бара... Юл йөргәндә язган шигырьләрен Велимир мендәр сүрүе эченә тутыра, үзе шуның өстендә йоклап йөри, тик барыбер соңыннан мендәрен югалта торган була. Шигырьләре дә шулай югала тора.

Велимир Хлебников шигырьләрен башка телләргә тәрҗемә итеп булмый диярлек. Бары тик соңгы еллар иҗатыннан кайбер әсәрләрен генә, анда да гаять кыенлык белән тәрҗемә итәргә мөмкиндер. Чынлап та «Леса лысы. Леса обезлосили. Леса обезлисили» кебек юлларны «Урманнар пеләш. Урманнар пошиларсыз. Урманнар төлкеләрсез» дип тәрҗемә кылып кына буламы? Хлебниковча бит биредә сүз гел бер тамырдан гына тора: «лес» (урман) «лыс»ка (пеләшкә) әйләнгән, ә инде «лось» (поши) белән «лис» (төлке) шул «лес» (урман) эчендә яшәүче җанварлар.

Менә В. Хлебниковның атаклы шигыре — «Заклятие смехом». Без аны студент чакларда тәрҗемә итәргә тырышып бик чиләнә идек.

О, рассмейтесь, смехачи!
О, засмейтесь, смехачи!
Что смеются смехами, что смеянствуют смеяльно.
О, засмейтесь усмеяльно!
О, рассмешищ надсмеяльных — смех усмейных смехачей!
О, иссмейся рассмеяльно, смех надсмейных смеячей!
Смейево, смейево,
Усмей, осмей, смешки, смешики,
Смеюнчики, смеюнчики.
О, рассмейтесь, смехачи!
О, засмейтесь, смехачи!

Бәлки хәзерге яшь шагыйрьләребез тәрҗемә итеп карарлар бу шигырьне?

В. Хлебников — Г. Тукай замандашы. Ул Казанда Тукай белән бер чорда яшәгән, Тукай заманында ук яза башлаган. Тукай йолдызы сүнгәндә, Хлебников йолдызы әле кабынып кына килгән чак булган. В. Хлебниковның «Вила и леший» исемле поэмасы бар. 1912 елда аерым китап булып та чыккан ул. Китаптагы рәсем-литографияне күргәч, Тукайның «Шүрәлесе» белән аваздашлык-охшашлыкны абайлап, таң каласың. «Бәлки, Хлебников Тукайны укыгандыр?— дигән уй кузгала күңелдә.

Велимир Хлебников күп язган, язганнарын җыя бармаган. Шулай да аның әсәрләре заманында (1928—33) биш томлык булып басылып чыкканнар. Хәзер дә басыла торалар. Әле күптән түгел генә Калмык китап нәшрияты аның «Ладомир» дигән шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Мәскәү нәшриятлары да төрле китапларын чыгарачак.

Шигъри материклар Колумбы Велимир Хлебниковның шифалы йогынтысы бер рус совет поэзиясендә генә түгел (В. Маяковский, Н. Асеев, Б. Пастернак, Л. Мартынов, Е. Евтушенко, А. Вознесенский һ. б.), ул күп милләтле совет поэзиясендә дә ачык чагыла. Башка милләтләргә барып тормастан, үзебезнең һ. Такташ, Х. Туфан, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ә. Фәйзи кебек күренекле шагыйрьләребезне телгә алып үтү дә җитә. Алар үзләренең беренче чор иҗатларында футуристик йогынтыны нык кичерделәр. Рус футуристлары «җәмәгатьчелекнең яңагына сугып», манифест күтәреп чыксалар, һади Такташ та «татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиешле» дип язып чыкты. Болар — яңа әдәбият — совет әдәбияты туу чорындагы үсү-эзләнү «авыруы» иде. Һ. Такташның егерменче елларда Мәскәүгә барып Маяковский, Хлебников һәм башка шагыйрьләрне махсус тыңлап кайтуы турында да мәгълүматлар бар.

Безнең хәзерге урта буын шагыйрьләребез Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гатауллин иҗатларында да без «шигъри Колумблык»ны күрәбез. Эзләнү, яңа сүз әйтү, шигъри традицияләргә яңа «кан өстәү»— бу һәр чордагы яшь шагыйрьләрнең өстенә төшкән газаплы да, җаваплы да миссия, котылгысыз бурыч.

В. Маяковский Велимир Хлебниковны «үзебезнең шигъри укытучыбыз итеп, шигъри көрәшебезнең иң әйбәт, иң намуслы рыцаре итеп санадык һәм санарбыз» дигән. Бу сүзләргә күп милләтле бик күп санлы шагыйрьләр кул куяр иде, минемчә.

Марс ШАБАЕВ.

Ринат Мөхәммәдиев

# ЧАҢНЫ КЕМ ДИП КАГАЛАР...

ХЕМИНГУЭЙ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Декабрьнең егермесе. 1984 ел. Иртәнге сәгать 10. Куба. Гаванадан көнчыгышка таба 13 чакрым ераклыкта урнашкан Сан-Франсиско-де Пауло поселогы. Дөнья әдәбиятының иң зур классикларыннан берсе Эрнест Хемингуэй озак еллар дәвамында яшәгән һәм иҗат иткән «Вихия» утары. Кояшлы аяз көн. 28 градус җылы. Дүрт катлы манараның югарыгы ачык тәрәзәсе каршында бер ялгызым басып торам. Баш очымда, әйләнә-тирәдәге ал, кызыл, шәмәхә чәчәкләрдән аңкыган хушбуйга исереп, бал кортлары безелдәшеп оча. Мине озата менгән кубалы танышым Мануэльне алар инде әллә кайчан меңъяшәр изге агач — сейба күләгәсенә куалап төшергән.

Дөньяның дүрт тарафына караган дүрт тәрәзәле җыйнак кына бүлмә. Урта бер җирендә гадәти язу өстәле, өстәл өстендә берничә бит кәгазь һәм карандаш-ручкалар. Өстәл янында урындык, бер читтә санаулы гына китаплар урнашкан нәни этажерка. Стенада язучының портреты һәм янәшәдә — аның үз кулы белән Африкада атып алынган леопард башы. Бүлмәдә булган җиһаз шуның белән тәмам. Бер карашка ул шыр ялангач сыман, буп-буш — өстәл артындагы урындыкның бушлыгыннан, әлбәттә. Әмма шунда ук, бу тын якты бүлмәдә бөеклек эзләре дә төсмерләнә кебек. Биредә дөнья әдәбиятының иң мәшһүр әсәрләреннән берсе «Карт һәм диңгез» повестеның иҗат ителүен тою гына да ни тора. Монда Хемингуэй «Чаңны кем дип кагалар» романын тәмамлый, «Елга аръягында, агачлар күләгәсендә», «Океандагы утраулар» кебек атаклы романнарын иҗат итә, дистәләгән хикәя, очерк һәм публицистик әсәрләр яза. Шуны белә торып, ничек тыныч кына, битараф кына карап торасың ди... Монда егерменче гасырның байтак дәһшәтле вакыйгаларын сыйдыра алган рух, дөньяда барган көрәшне үз йөрәге һәм бәгыре аша үткәрә, кичерә килгән зур шәхес әле дә яши, исәндер төсле тоела.

Мәшһүр әдипнең стенага эленгән сурәтенә кинәт җан кергән сыман булды. Күзләре миңа төбәлгән, менә-менә өстәл артына килеп утырыр да каршындагы ак кәгазьгә үрелер, тәмамлап өлгермәгән романының яңа сәхифәләрен язарга керешер. Ирексездән, тәрәзәнең читенәрәк елыштым. Юкса, әдипнең бөек серләрен сыйдырган өстәле каршында болай басып тору килешмәс. Һәм шунда гаҗәеп манзарага юлыктым: Хемингуэй карашы, үзенең үлемсез әсәрләрен тудырганда, менә кай тарафка юнәлгән булган икән. Хемингуэй Кубаны, океанны һәм дөньяны менә каян күзәткән!..

Вихия... Утарның исеме үк бу урынның географик үзенчәлеге турында сөйли. Вихия — испанчадан күзәтү каланчасы, күзәтү урыны дип тәрҗемә ителә. Диңгез тигезлегеннән 120 метрга күтәрелеп торган, бөтен әйләнә-тирәдә иң югары нокта булган бу урын испан колонизаторлары тарафыннан хәрби-күзәтү пункты буларак файдаланылган. Ә Хемингуэй өчен, калкулыкның иң югарыгы ноктасында дөньяның иң гүзәл агачларына күмелеп утырган бер катлы мәһабәт йорт биеклеге генә аз тоелган. Чиста зәңгәр күккә якынрак булсын дип, океан киңлекләре күренеп торсын дип, Вихия финкасы белән янәшәдәге әлеге башняны әдип үзе кордыра. Дөрес, әлеге корылманы төзү ихтыяҗының башка сәбәпләре дә булган. Әйтик, ул аны берөзлексез

үзенә агылып торган эшкуар-кунаклардан качу нияте белән дә төзи. Башняның беренче катында этләр тота, ә икенчесендә иллегә якын мәче аерый. Иң югары катка тар гына тимер баскычтан күтәреләә дә баскычны бөтенләй җыеп куя торган була. Исеме дөньяга танылган әдип белән очрашу, әңгәмә кылу, янәшә фотога төшү максаты белән Европа илләреннән һәм АКШтан агылып торган «эш кешеләре»ннән ул үзен әнә шулай изоляцияләргә мәҗбүр була. Эт һәм мәчеләр яшәгән башня очында шундый зур язучы, бөтен дөньяга танылган Нобель премиясе лауреаты утырыр дип берәүнең дә башына килмәгән, әлбәттә. Ә Хемингуэй һәр сәгать һәм минутының кадерен белеп эшләгән, дөньяда барган вакыйгаларның кыл уртасында яшәгән.

Шушы тәрәзә каршына килеп, янәшәдә генә үсеп утырган король пальмаларыннан, күпне күргән манго агачларыннан, күкрәк киереп койма өстенә менеп баскан җете чуар әтәчләрне хәтерләтүче эре чәчәкләргә төренеп утырган бугенвилиялардан югарырак торып күзәткән ул дөньяны. Оҗмах бакчасын хәтерләткән җайлы-уңайлы финкасыннан качып утыруның тагы бер хикмәте шунда булса кирәк, монда аның карашына киртә булырлык һични күренми. Тәрәзә төбендәге куак-гөлләр, ел әйләнәсендә чәчәктә утырган фламбояннарның хуш ис аңкытып торган шифалы күләгәсе белән генә канәгатьләнергә теләмәү тарткандыр аны монда... Әнә, каршыда гына балыкчылар поселогы башланып китә, арырак әфлисун һәм авызга китерсәң эреп торган папая плантацияләре җәйрәп ята. Ә инде тагы да арырак — аксыл зәңгәр күкнең яшькелт зәңгәр океан белән кавышкан җирендә — Кохимар поселогы. Кохимарда Латин Америкасында исеме таралган балыкчылар яшәгән. Кохимарда, кармак сабы тота алырлык һәр малайдан ак сакаллы картларгача, Хемингуэйның икмәк бүлешеп көн күргән дуслары гомер кичергән, һәм шул ук балыкчылар поселогы Кохимарда мәшһүр «Карт һәм диңгез» повестеның прототиплары торган. Кохимарда һәр урам сөзәк калкулык өстеннән туры океанга төшә, һәр тәрәзә океанга төбәлгән, һәр кешенең язмышы башыннан ахырынача океан белән бәйләнгән. Әле кичә генә яр буенда йөргәндә үз күзәтүләрем нәтиҗәсендә ышандым мин моңа. Һәм ни хикмәттер, очраган һәр малай миңа «Карт һәм балыкчы»да тасвирланган Манолин исемле угланны хәтерләтте, ә картлары исә төшенә арысланнар кереп йөдәткән җиңелмәс рухлы Сантьягоның нәкъ үзе диярсең.

Чигәмә уй китереп сукты: әгәр менә хәзер, XX гасырның ахырына дистә ярым ел вакыт калып барган көннәрдә, шушы урында мин түгел, Хемингуэй үзе басып торса, аны нинди тойгылар биләр иде икән?.. Мәшһүр әдип булып фикер йөртү мөмкин түгел. Шулай да бер нәрсәгә икеләнмәскә була: дөньяда барган вакыйгалар өчен сызланыр иде ул. Һәм шушы киеренкелеккә әнә анда, Флорида култыгы артында ук башланып киткән үз ватаны — АКШның төп гаепче булуын аеруча авыр кичерер иде. Башкача булу мөмкин түгел, чөнки әле Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланып кына килгән көннәрдә «Азат дөнья хәзинәләре»дип исемләнгән антологиягә кереш сүз язганда, халыкларга һәм беренче чиратта америкалыларга ул болай мөрәҗәгать иткән иде: «Инде сугыш тәмамланды, үлгәннәрне терелтеп булмас. Безнең алга, һәр кеше алдына тагы да җаваплырак бурыч килеп басты — тынычлыкның нинди зур югалтулар белән яуланганын аңлау. Имин елларда кешелекнең иң зур бурычы — үзара тату, аңлашып яшәүдә». Ә икенче бер хезмәтендә исә ул ватандашларын турыдан-туры кисәтергә кирәк саный: «Бу сугышта җиңәргә кирәк, әмма нәрсә хакына сугышканны онытмыйча җиңәргә. Без әлегә фашизмга каршы, аны юкка чыгару өчен көрәшәбез, әмма фашизм идеяләре һәм идеалларына шуып төшүдән үзебезгә сак булырга кирәк». Бөек әдипнең көрәшчелегенә һәм политик сизгерлегенә сокланырга гына кала. Хәер, XX гасырның беренче яртысында Европада булып узган барлык сугышларда да турыдан-туры катнашкан, берничә тапкыр яраланган фикер иясенең мондый шиге булу табигый да. Америка империализмының дөньяда барган канкойгыч сугышларга иң элек табыш чыганагы итеп каравын,үзенең кемлеген күрсәтү мәйданы һәм шовинистик идеяләрен җәелдерү максатыннан гына чыгып килүен үз күзләре белән күреп кичергән шәхес ич ул.

Әйе, фашистлар Германиясенең җиңелүен бөтен прогрессив кешелек белән бергә тантана иткән көннәрдә үк Э. Хемингуэй киләчәккә карап, киләчәкне кайгыртып фикер йөрткән. «Язучы,— дип яза ул «Хушыгыз,кораллар» романының яңа редакциясенә сүз башында,— җирдә берөзлексез дәвам итеп торган, канкойгыч һәм пычрак җинаять булган сугышка мөнәсәбәттә

һичкайчан битараф була алмый». Аны, барыннан да элек, Кушма Штатларның хәрби көч белән шапырынуы, котырынып яңа төр кораллар эшләп чыгарырга керешүе һәм америка обывателен Советлар Союзына каршы ачыктан-ачык көрәшкә хәзерләве уйланырга мәҗбүр итә. Шуңа да сугыштан соң ук язылган «Елга аръягында, агачлар күләгәсендә» романында ул зур куркыныч янаган әлеге идеологиягә кискен каршы чыга. АКШ армиясе полковнигы Кантуэллның кичерешләре гыйбрәтле. Әле кичә генә фашизмга каршы көрәшкән хәрбине бүген инде синең төп дошманың фашистлар түгел, руслар дип ышандырырга телиләр. Ә Икенче фронтта чирканчык алган Кантуэллның килешәсе килми моның белән. Руслар — синең төп дошманың, диючеләргә ул принципиаль төстә җавап бирергә мәҗбүр була. «Ә миңа шәхсән алар бик ошыйлар, мин алардан да кешелекле һәм игелеклерәк халыкны белмим»,— ди Хемингуэйның дөнья күргән герое. Һәм шул уңайдан сукранып та ала: «Безнең белән хәзер җыен чүп-чар идарә итә, сыра кружкасы төбендә сыланып калган күбек сыманнар».

Кантуэллның сүзләрендә без турыдан-туры Хемингуэйның сугыштан соңгы АКШ администрациясенә булган мөнәсәбәтен сиземлибез. Чөнки, геройлары кебек ук, әдип үзе дә бөтен гомерен җирдә сугыш һәм кан коюлар түгел, имин һәм матур тормыш тантана итсен өчен көрәшкә багышлый. Дөнья әдәбиятында сугышның кешегә китергән афәт һәм бәхетсезлекләрен югары сәнгатьле образлар аша тасвирлап бирүдә Хемингуэй иҗатының мәртәбәле һәм үзгә урын тотуы һич кенә дә очраклы түгел.

Уйларыма чумып шулай берьялгызым онытылып торганда, тар тимер баскыч буйлап берәүнең ашыгып-кабаланып яныма менеп килүен күрдем. Менеп җитәр-җитмәс үк кулын сузды ул һәм үзе артыннан түбәнгә әйдәде. Гөлләр һәм мальва куакларына су сиптереп йөрүче дворникның, минем бер ноктага текәлеп тик басып торуымнан шикләнеп, «бер-бер хәл булганчы» дип ярдәмгә йөгереп менүе икән. Тәрҗемәче белән алар бер-ике сүз әйтешеп алгач, өчәү бергә елмаешып куйдык.

— Ул Хемингуэй исән чакта ук монда эшләгән,— диде тәрҗемәче, чәче һәм сакалларына урыны-урыны белән чал төшкән базык гәүдәле иратка күрсәтеп.

— О-о-о,— дип куйдым, ирексездән,— димәк, бөек әдипне күреп белгәнсез?

Ул үзалдына мөлаем гына елмаеп куйды.

— Бер мин генә түгел, монда һәркем яхшы хәтерли аны. Атакайның җан дуслары бик күп монда.

— Ә сез дуслар идегезме соң?

Сорау сәер тәэсир иттеме,— ул башын чайкап алды һәм уйчанланып калды.

— Шулай булмаса, мин гомерем буе аның гөлләренә су сиптереп йөрер идеммени. Атакайның үлүенә беребез дә ышанып җитми әле. Менә ничә ел инде, көн дә үзе кайтып төшәр һәм пир ясар кебек... Шуңа дип хәстәрлим бакчаны...— һәм ул парк буйлап бераз сүзсез баргач, сорауны хәтерләп, өстәп куйды: — Нәрсәгәдер кәефе кырылганда, яисә мисс Мэри белән үпкәләшсә, гел минем янга килеп чыга иде. Сердәше саный иде ул мине...

Түшенә кара алъяпкыч япкан бу пөхтә кеше мине кызыксындырганнан кызыксындыра барды. Тышкы кыяфәте һәм йөзе белән ул Хемингуэйның үзен хәтерләтә төсле тоелды.

— Ә сез үзегез дә Хемингуэйга охшагансыз,— дип әйтеп ташладым, артык уйлап тормастан.

— О, юк,— дип башын чайкап, җанланып ук китте яңа танышыбыз.— Атакай сезнең кебек, юк, күпкә биегрәк, ике метрга җитәр-җитмәс әзмәвер гәүдәле изге кеше иде. Әнә, сейба агачы кебек,— дип өй читендә үсеп утырган киң ябалдашлы, юан һәм мәһабәт агачка ишарәләде.— Кызганыч менә, сейбаны саклый алмадык, корый башлаган. Югыйсә, әле 200 елдан артык түгел иде аңа. Атакай орышыр инде...

Гаепле кеше сыман башын түбән иеп әйтте соңгы сүзләрен. Аның кичерешен аңлау кыен түгел иде. Чөнки Хемингуэйның әлеге йөзьяшәр агачка булган мөнәсәбәтен, хәтта аңарга табынганлыгын мин инде Юрий Папаровның «Хемингуэй на Кубе» дигән хезмәтеннән укып белә идем. Һәм ул еш кына «Язган әсәрләрең әнә шул изге сейба сыман гомерле булса икән...» дип әйтергә яраткан.

— Башка һич нәрсәдән түгел, Атакайны юксынудан корый ул,— дип өстәп куйды бакча караучы.

Бөек әдипне якыннан белеп, аның серләрен бүлешеп яшәгән кеше белән янәшә атлавымны тоеп, тизрәк, кабаланып диярлек, сораштырасым килә. Әмма нидән башларга да белми газапланам.

— Сез аның сердәше булгансыз... Берәрсен чишмисезме?..

— Сер сөйләнми,— дип кистереп куйды ул, башка сүзгә урын калдырмыйча.

— Бәлки Хемингуэй турында сез белгәннәрне башка беркем дә белми торгандыр... Инде вакыт узгач, аларны сөйләргә дә мөмкиндер,кешеләр бөек әдип турында барысын да белергә тиеш ич,— дип, аңлатырга маташам үземчә.

— Сер сөйләнми,— дип кабатлады ул, тагы да корырак итеп.— Мине юмалаучылар күп булды. Сез беренче түгел. Ни генә вәгъдә итмиләр. Атакайның, ышанып, миңа гына сөйләгәннәрен ничек чишәргә мөмкин... Бу хакта сорамагыз!

— Сез чын ир кеше, чын дусты икән әдипнең,— дип әйтми булдыра алмадым. Соклануымның чиге юк иде.

Тәрҗемәче ачыклык кертте: Хемингуэйның океан артындагы биографлары күп юмалаган бакчачыны, алтынга коендыруны вәгъдә итеп юмалаганнар... Җавап — шул ук булган. Дөньякүләм танылган әдипнең дүрт-биш метр биеклеккә җиткән бамбук куелыгына кереп, үзенең бакчачысына сөйләгән серләре әле дә булса чишелми, саклана бирә.

— Сез Советлар иленнән булса кирәк, димәк, яхшы кеше... Кем булып эшлисез соң? — дип сорап куйды ул, үпкәләмәгез инде, башкача булдыра алмыйм, дигәндәй, йомшарып китеп.

— Әйе, Советлар иленнән, Казан дигән шәһәрне беләсезме?.. Татарстаннан,— дим. Үзем күреп торам, тәрҗемәче дә, яңа танышыбыз да бигүк белешле түгел икән минем туган республикам турында.— Әдәбиятчы мин, тәнкыйтьче,— дип өстәп куям, артык сузмый гына.

«Тәнкыйтьче» сүзенең мәгънәсен һәм кемнең шулай аталуын ачыклап булса кирәк, алар испанча үзара аңлашып алдылар һәм гел көтмәгәндә, бакчачы җанланып китте.

— Атакайның бар курыкканы тәнкыйть һәм тәнкыйтьчеләр иде,— дип елмайды ул.— Миңа да күп тапкырлар зарланганы булды алардан. Яңа чыккан әсәренә нинди дә булса тискәре бәя булганны ишетсәк, без аның күзенә чалынмаскарак тырыша яисә бөтенләй усадьбадан чыгып кача идек.

Янә дәррәү көлешеп алдык, һәммәбезгә кызык булып китте. Буржуаз матбугатка хезмәт итүче тәнкыйть, әйе, Хемингуэйның әчкерсез һәм тиз яраланучан күңеле белән байтак уйнаган. Зур художник һәм фикер иясенең иң танылган әсәрләренә кадәр юкка чыгарып язылган хезмәтләр дә аз булмаган үз вакытында. Хикмәт бары шунда: Хемингуэй буржуаз пропаганда һәм матбугат таләпләренә беркайчан да җайлашып яшәмәгән...

Үзалдыма уйланып барам. Ә янәшәмдә атлаучы танышларымның карашы миңа төбәлгән икән.

— Әйе, тәнкыйтьне яраткан язучы әле дә сирәк,— дип әйтми булдыра алмадым.— Ә ул елларда исә Хемингуэйны бөтенләй хаксызга мыскыл итәргә омтылганнар, мораль яктан үтерергә теләгәннәр...

Бакчачы бермә-бер җанланып китте. Бер яктан бамбук агачлары, икенче яктан хөрмә пальмаларына уралып үскән ефәк сыман лианалар каплаган борылмалы аллеядан барабыз. Нидер хәтерләвен белгертеп, ул кинәт алгарак узды да каршыбызга чыкты.

— «Елга аръягында, агачлар күләгәсендә» романы дөнья күргәч, аеруча котырынып алды буржуаз тәнкыйть. Ничек кенә рәнҗетмәделәр аны. Атакай авыруга сабышты, кан басымы куркыныч чиккә җитте. Шул көннәрдә игелекле бер тәнкыйтьче коткарып калды аны һәлакәттән...

Әлбәттә, бакчачы ул тәнкыйтьченең кем икәнен һәм аның ниләр язганлыгын хәтерләми иде. Ул кадәресен мин Казанга кайткач, китапханәләрдә актарынганда ачыкладым: чынлап та барысы да шулай булган икән. Хемингуэйның докторы Эррера истәлеге шул хакта аермачык сөйли:

— Мин аның кан басымын үлчәдем — 150 гә 90, ә бер тәүлек элек кенә хәле соң дәрәҗәдә куркыныч иде. Феноменаль күренеш! Бер төн эчендә

булган хәл! Өч мәртәбә үлчәдем. Һичнинди ялгышлыксыз. Ә ул чакта медицинада мондый хикмәт ясарга сәләтле дару юк иде, бүген дә юк дип беләм. Бу кискен уңай күренешнең сәбәбе — бары тик гадәти бер тәнкыйть мәкаләсе. Джон О'Хара исемле тәнкыйтьче Эрнестны «чемпионнарның да чемпионы һәм Шекспирдан кала иң зур художник» дип атаган иде. Эрнест ул көннәрдә кушуч белән тәмле конфет тотып йөргән бер сабыйны хәтерләтә иде...

Әйе, бу уйландыра торган факт. Талант ни дәрәҗәдә зуррак булган саен, ул шулкадәр игътибарга һәм җылы сүзгә мохтаҗ. Ә без, тәнкыйтьчеләр, бу хакта вакыт-вакыт оныткалап тормыйбызмы икән?!.

Бакчачы белән без уртак тел таптык. Ул аллеялар һәм тар сукмаклар буйлап йөргәндә, бөек язучы турында, аның хикмәтле гадәтләре, киң күңеллелеге һәм кешелеклеге турында өзлексез сөйләде. Һәр сукмак, һәр агач һәм һәр корылма дөнья әдәбияты классигы Э. Хемингуэй турында истәлекләр һәм сер саклый икән «Вихия»дә. Төрле хуш ис бөркеп торучы мәһабәт агачларга төренеп утырган фин йорты белән дә үз кеше итеп, якыннан таныштырды бакчачы танышыбыз. Монда Хемингуэй укыган китаплар, аның әсәрләре, йорт-җир җиһазлары, кием-салымы — һәммәсе саклана. 47 нче үлчәмле «гигант» аягына киеп йөргән ау итекләре, аркасына асып, континентларны гизгән мылтыклары, каләм-ручкалары — һәммәсе бер реликвия сыман саклана. Ә рәхәт бер салкынлык биреп торган биек стеналарда Хемингуэй атып алган җәнлекләрнең башлары эленеп тора. Африка, Латин Америкасы илләрендә үткән сафариларның (сәфәрләрнең) җуелмас истәлекләре булып саклана алар монда, курку белмәс танылган ау остасын балаларча куанырга һәм кызганудан күз яшьләрен агызырга мәҗбүр иткән табигать могҗизалары...

Мин яңадан Хемингуэй йөрергә яраткан маршрут буенча утар ишегалдын ялгызым урап чыктым. Аны шушы аллея һәм сукмаклар буйлап тын гына үз уйларына чумып йөрергә яраткан диләр. Язылган һәм языласы әсәрләреннән тыш, нинди дөньяви уйлар биләде икән бөек әдипне?!. Еш кына ул менә шушы урында тукталып, озак кына басып тора торган була. Нигә нәкъ менә шушы урында, ә кайдадыр, киңрәк панорама ачылган, яисә хуш исле чәчәкләр мулрак үскән төштә түгел? Тора торгач, үземә күрә моның хикмәтен дә ачыкладым кебек. Үзәк аллея белән тар сукмак кисешкән бу урында гаҗәеп бер контраст җәлеп итте мине. Сукмакның бер ягында яфрак һәм ботакчыкларның нәфислеге белән, күзне иркәләгән чиста-якты яшеллеге белән сокландырган лавр агачлары тезелеп киткән. Ә каршы якта чәнечкеле тимер чыбыктан тарттырылган стена сыман кактус агачлары тырпаеп тора. Буынтык-буынтык булып үскән кактус су өстендә йөзеп йөргән дәһшәтле минага охшаш, ә кечкенәрәк буыннары, «лимонка» гранатасын хәтерләтеп, күңелгә шом салып тора. Мондый кактусларны юл читендә һәм тропик урманнарда күреп узганда, аларның матурлыгына соклана идем, югыйсә. Ә менә лавр яфракларына каршы торып баскан чәнечкеле стена мине сискәндереп куйды. Бу капма-каршы янәшәлек җир йөзендә үзе күргән һәм кичергән контрастларны әдип күңелендә яңарткан булса кирәк. Лавр ботакчыкларының кәкрәеп-бөкрәеп булса да кактус энәләреннән читкә әтәрелүен күрмәү, тоймау мөмкин түгел монда. Ирексездән, Хемингуэй тормышының аерым сәхифәләрен барларга керештем...

19 яше тулыр-тулмас көе ул, ялган пропагандага бирелеп, үз теләге белән Беренче бөтендөнья сугышына килеп керә. Италия солдатлары белән бер сафка басып, австриялеләргә каршы көрәшә һәм каты яралана. Империалистик сугышның чын йөзен күрү аны тетрәнергә мәҗбүр итә һәм айнытып җибәрә, дөньяда барган вакыйгаларга карата күзен ача. Империалистик сугышны ул соңрак «соң дәрәҗәдә начар оештырылган суеш-үтереш мәйданы» дип атый. Әлеге сугыштан алган тәэсирләр әдипнең иң җитди әсәрләреннән берсе «Хушыгыз, кораллар»га нигез булып ята. Һәм аны канкойгыч сугышларны үтергеч фаш итүче зур художник итеп тәрбияли.

Тагы берничә елдан, төгәлрәге 1922 елда, Хемингуэй Канада газетасы корреспонденты сыйфатында Греция белән Төркия сугышына барып чыга. Бернинди гаепсезгә йөзәрләгән, меңәрләгән яшьләрнең, сабыйларның үтерелүен, түбәнлекләргә төшерелүен үз күзләре белән күреп кичерә. «Якын Көнчыгыштан мин чәрдәкләнгән йөрәк белән кайтып төштем һәм, елан сыман салкынга әверелеп, язарга сүз бирдем. Язучы булырга, кешеләргә дөреслекне сөйләргә карар кылдым...» — дип белдерә әдип шул көннәрдә.

1933 елда Германиядә властька фашистлар килгәч, ул зур тетрәнү кичерә һәм 1935 елда «Булачак сугыш турында язмалар» дигән мәкалә белән чыга. Анда ул Европада куркыныч чума авыруының көчәя баруын искәртә (фашизмны шулай атый) һәм Германия белән Италия тагы ике-өч елдан яңа бөтендөнья сугышы башлап җибәрәчәк дип кисәтә. Көнбатыштагы «демократия» илләренең «большевиклар куркынычы» хакында сафсата белән шөгыльләнеп, үз-үзләренә кабер казуларын күрсәтә. Әдипнең дөньяда барган политик вакыйгаларны үтәдән күрү осталыгы һәм көрәшчелегенә сокланырга гына кала. Шул елларда иҗат ителгән иң көчле хикәяләреннән берсе «Килиманджаро карлары»нда аның кешелек язмышы өчен борчылулары аеруча ачык чагылыш таба.

1936 елда Испаниядә гражданнар сугышы башланып китә. Генерал Франконы яклап, Германия һәм Италия фашистлары испан халкына каршы корал күтәрә. Испания республикасын яклап, төрле илләрдән үз теләге белән антифашистлар килә. Әлбәттә, әлеге хәлиткеч көннәрдә Э. Хемингуэй да читтә кала алмый, «фашизмга Испаниядә юл бирсәң, ул тиз арада бөтен дөньяны басып алырга мөмкин» дип саный ул. Фашистларга каршы көрәштә интернациональ бригадаларның батырлыгы аны яңа иҗади биеклекләргә рухландыра. Ут боҗрасында калган Мадридта ул «Бишенче колонна» дигән пьеса язып тәмамлый һәм шул әсәрендә калган бөтен гомерен фашизмга каршы көрәшкә багышларга үз-үзенә сүз бирә. Һәм кире әйләнеп кайткач, Америка язучыларының II конгрессында барлык намуслы каләм ияләрен фашизмга каршы көрәшкә чакырып чыга. «Фашизм — бандитлар уйлап чыгарган ялган ул»,— дип кабатлый Хемингуэй. Испаниядәге халык-азатлык сугышына багышланган «Чаңны кем дип кагалар» романының төп герое үләр алдыннан «дөнья — матур урын, аның хакына сугышсаң да була», дип, очраклы рәвештә генә васыять әйтеп калдырмый.

Хемингуэй Испаниядәге интернациональ бригадалар сафында Советлар Союзы гражданнарын күреп, аларның батырлыгына сокланып өлгерә. Шул көннәрдә ул И. Эренбург белән танышып, дустанә әңгәмәләр кора, дөнья халыкларының фашизмга каршы көрәштә берләшергә тиешлеген яклап сөйли. Һәм шул ук вакытта ул тагы да зуррак һәм куркынычрак сугышның кичектергесез рәвештә якынаюын тоеп яши, фашизмны фаш итүче әсәрләре белән халыкларны кисәтергә ашыга. Бер үк вакытта сугышны фаш итүче иң яхшы әсәрләрдән антология төзү белән дә шөгыльләнә.

Һәм тагы бер гыйбрәтле факт: Германия һәм аның союзниклары Советлар Союзына каршы сугыш башлап җибәргәч, АКШның реакцион даирәләре моңарга куанып туймыйлар, аларның үзара сугышып хәлсезләнүен көтеп торырга керешәләр. Ә бу вакытта Ерак Көнчыгыш илләре буйлап сәяхәттә булган Э. Хемингуэйны әлеге хәбәр тетрәнергә мәҗбүр итә. Сугышның бишенче көнендә, 1941 елның 27 июнендә Мәскәүгә, Сталинга телеграмма җибәрә ул. «Советлар Союзының фашистлар агрессиясен кире кагачагына 100 проценты белән ышанам һәм теләктәшлек белдерәм. Совет халкы үзенең батырлыгы белән фашистлар коллыгына дучар булырга теләмәгән барлык халыкларны да яклап сугыша»,— дигән юллар бүла ул телеграммада. Бу очракта да олы әдипнең совет халкы өстенә төшкән сынауның дөньякүләм тарихи әһәмиятен ни дәрәҗәдә төгәл аңлавын һәм аңарга ныклы ышаныч белдерүенә сокланмый мөмкин түгел.

Ә тагы бер елдан ул матбугатта түбәндәге кыю мөрәҗәгать белән чыга: «...Азатлык сөюче һәр кеше, Кызыл Армия каршында беркайчан да түләп бетерә алмаслык бурычлы булып кала... Гитлерны тар-мар итүгә өлеше кергән һәр ил Кызыл Армиянең геройлыгыннан үрнәк алырга, аңарга охшарга тырышырга тиеш». Бу сүзләрнең 1942 елда Америка гражданины тарафыннан АКШ матбугатында басылуын аерым игътибарга алу кирәк. Һәм ул соңрак, К. Симоновка язган хатларның берсендә: «Бу сугыш дәвамында мин берәзлексез Советлар Союзы армиясе сафына басып сугышасым килде. Сезнең ничек сугышканлыгыгызны күреп таң калырга хыялландым...» — дип, үзенең эчкерсез омтылышлары белән уртаклаша.

Озак кына көттереп, АКШ үзенең сугышка керүен игълан иткәч тә Хемингуэй үзен фронтка хәрби корреспондент итеп җибәрүләрен үтенеп гариза яза. Әмма аның үтенече кире кагыла. Шулай да әдип фашизмга каршы көрәшү омтылышыннан кире кайтмый, ул үзенең балык тоту өчен яраклаштырылган «Пилар» катерында гитлерчыларның Куба ярларыннан

ерак түгел йөзгән су асты көймәләрен эзәрлекли башлый. Тәүлекләр һәм атналар буе ул, төрле куенлыклар белән хисаплашмыйча, үлем куркынычы астында океанда йөзә. Нәтиҗәдә, Хемингуэй биргән координатларга нигезләнеп, АКШ авиациясе фашистларның берничә хәрби су асты көймәсен бомбага тота һәм батыра. Соңыннан бу тәҗрибә әдипнең «Океандагы утраулар» романында киң чагылыш таба.

Э. Хемингуэй сугышның үзендә дә катнашырга өлгерә. 1944 елда союзниклар армиясе белән ул Нормандиягә килеп төшә һәм, Англия бомбардировщикларына утырып, Германияне бомбага тотуда катнаша. Француз партизаннарыннан отряд туплап, разведка эше җәелдерә һәм Парижны азат итешә. Танылган язучы соңрак Германия чигендәге канкойгыч сугышларда да катнаша. Кыскасы, Хемингуэй каләм көче белән генә түгел, корал тотып та фашизмны юк итүгә үз өлешен кертә. Тынгысыз җаны аңар бер генә минутка да зур вакыйгалардан читтә торып калырга ирек бирми.

Кубага әйләнеп кайткач та ул «Мин кешеләрне фашизмнан куркырга мәҗбүр итәрлек рәвештә язарга тиешмен», дип, үз алдында торган максатның ачык һәм конкрет булуын белдерә. Игътибар итик, ул җиңүче сыйфатында АКШка кайтып тантана итүдән, батырлыгы өчен бирелгән орден-медальләрен күкрәгенә тагып йөрүдән тайчына. Чөнки ватандашларының канга сусап, дөньяда хөкемдар булырга омтылуын тою аны сагаерга мәҗбүр итә. Кубада яшәвенең сәбәбе белән кызыксынучыларга ул элеккечә үк кистереп җавап кайтара: «Анда (АКШта.— Р. М.) минем тыным бетә, сулышым тарая. Җилләндерелмәгән кысан бүлмәдә яшисем килми. Сулыш алу гына түгел, фикер йөртү кыен...»

...Лавр яфраклары белән кактус чәнечкеләре әле дә янәшә үсә. Тар гына сукмакның бер ягында — хуш ис сирпеп торган якты яшеллек, ә икенче ягында океан өстендә йөзеп йөргән дәһшәтле миналардай кактус ботаклары тырпаеп утыра. Шушы урында тукталып, озак кына уйга чумып торган әдипне аңлау мөмкин кебек. Зәңгәр күк астында сугыш һәм тынычлык дигән ике төшенчә әле дә янәшә тора.

Э. Хемингуэй үзенең легендар шәхесе белән кызыксыну һәм соклану арта барган, роман һәм повестьларының популярлыгы күзгә күренеп үскән көннәрдә дә зур борчуларда яшәвен дәвам иттергән. Әдәби иҗатта һәм мәхәббәттә булган уңышлар белән генә канәгать булып кала алмый әдип. Юл йөрүдән туя белмәгән сәяхәтче, кыюлык һәм батырлык җәһәтеннән тиңдәшсез саналган аучы, бөтен Латин Америкасына мәгълүм балыкчы дигән даны да күңел тынычлыгы китерми аңарга. Тәнендә 250 дән артык җәрәхәт һәм җөй йөрткән, үз гомерендә ике авиакатастрофа, берничә автомобиль һәлакәте һәм байтак сугыш яраларын кичерергә мәҗбүр булган баһадир гәүдәле олы әдип дөньядагы вакыйгаларның киеренкелеге кимемичә, арткаңнан арта баруны күреп борчыла. Һәм шушы киеренкелеккә үз ватандашлары төп сәбәпче була баруын тою аны аеруча тынгысызлый килә.

Әлеге тынгысызлык Хемингуэйны дөнья мәшәкатьләре һәм ыгы-зыгы белән кайнап яшәгән Гаванага әледән-әле алып килә. Дөньяда барган вакыйгаларның асылына төшенүгә омтылыш яшькелт-зәңгәр киңлеге белән, гигант балыклары, дельфин һәм альбатрослары белән өзлексез ашкындырып торган океанны да берара онытып торырга мәҗбүр итә.

Менә колониаль Гаванаaның Овиспо һәм Меркадере урамнары чаты. Монда «Амбос Мундос» отеле урнашкан (сүзгә-сүз тәрҗемә итсәң, «Ике дөнья» дигәнне аңлата бу исем). Хемингуэй 1928 елда Кубага беренче килүендә үк шушы отельнең дүртенче катындагы 511 нче номерына урнаша. Икенче разрядлы шушы кунакханәдә ул «Африканың яшел калкулыклары» әсәренең аерым бүлекләрен, «Иябулырга һәм булмаска» романын һәм киләчәктә язылачак «Чаңны кем дип кагалар» романының беренче сәхифәләрен иҗат итә. Гаванада куна калырга туры килгәндә, Хемингуэй соңгы елларда да һәрчак шушы отельдәге әлеге бүлмәне сайлый торган була. Тәрәзәсе Гавана капитолиумына, мәһабәт король пальмалары үскән иркен паркка һәм М. Горький исемендәге совет китаплары кибетенә карап торган шушы бүлмәдә әдип үзенең туган иленнән һәм Европадан килгән политик эшлеклеләр, язучы һәм галимнәр белән төннәр буе фикер алышкан, бәхәсләшергә яраткан. Ә кичләрен ялгызы гына урамның каршы ягындагы «Эль Флоридита» ресторан-барына йөргән.

«Эль Флоридита»га Хемингуэй, кагыйдә буларак, бары тик ялгыз йөр-

гән. Моның сәбәбе нидә? Шул кызыксыну мине дә монда ялгызым килергә мәҗбүр итте.

Монда кайсыдыр бер почмакта бөек язучы әле дә утырадыр төсле. Ипле генә як-якка карангалап алучы күзләр аны эзлиләрдер кебек. Гаврананың күпләгән кабаре, клуб һәм ресторан-барларыннан аерылып торган бер рух яши монда. Ул үзенчәлекне моңсу тынлык яисә талгынлык дип бәяләргә мөмкин. Кубалылар ял иткән урын җыр, музыка һәм тукталуны белмәгән дәртле биюләрдән башка булмый. Хакыйкатьтә монда да шулай. Шул ук вакытта ипле бер талгынлык та үзен сиздереп тора. Күрәмсең, зал шулай эшләнгән: бер өстәл артындагы авазлар икенче өстәлгә барып җитми, каядыр биеккә, диңгез сурәтләре белән бизәлгән түшәмгә күтәрелеп юкка чыга.

Хемингуэй бу өстәлләрнең кайсысы артында утырырга яратты икән? Күңелем сизеп тора, аның монда да үз урыны булырга тиеш. Чөнки Кубада Э. Хемингуэй белән бәйле ничәмә-ничә урында инде әдипнең һәр очракта даимилеген, тотрыклылыгын, бирелгәнлеген раслаган мисалларга игътибар юнәлтеп өлгергәннәр иде. Җавапсыз калырга теләмичә кыбырсый башлады сорау. Ул урын кайда да булса уртадарак, яисә әнә дәһшәтле диңгез картинасы эленгән якты мәйданчыктадыр... Ул да түгел, ярымкараңгылык эчендә изрәгән барның ишек катындагы почмагында тонык кына янып торган утка күзем төште. «Мине эзлисеңме — мин монда», дигәндәй, аннан Хемингуэйның бронза бюсты карап тора иде. 1955 елда Куба скульпторы Фернандо Боада эшләгән аны. Шунысы кызык, бу — язучы үзе исән чакта аның натурадан эшләнгән бердәнбер скульптурасы икән. Һәм ул монда әдип үзе исән чакта ук, ягъни 1958 елда урнаштырылган. Шул рәвешле. Хемингуэй «Эль Флоридита» да еш кына үз бюсты белән янәшә утырырга мәҗбүр булган. Чөнки бюст аның даими урындыгы белән янәшә үк урнаштырылган булган. Шулай да, кубалыларның сөйләвенә караганда, бюсты урнаштырылгач, ул монда килүен сирәгәйткән. Һәм килгән очракта инде берне түгел, ике дайкири коктейле сората торган булган. «Берсе — үземә, ә икенчесе, әнә, аңарга»,— дип ым каккан үз бюстына. Үзе белән әңгәмә корырга, яисә интервью алырга, бәхәсләшергә дип тинтерәтүчеләргә дә: «Әнә, аның белән сөйләш. Ул шундук сине аңлар. Сез уртак тел табарсыз...» — ди торган булган.

Бюст белән янәшәдәге урын менә инде егерме елдан артык буш тора, аны кызыл бәрхет «киртә» белән аерып куйганнар. Бу — әдип урыны. Әмма ул буш түгел, анда аның рухы, олы җаны әле дә булса яши кебек. Янәшәдәге икенче бер буш урынга барып сөялүем булды, шундук хәйран калдым: моннан киң һәм иркен ресторан-бардагы һәммә почмак уч төбендәгедәй күренеп тора икән. Хәтта барменның, өстәл артында кырыкмаса-кырык шешәләрдән тамыза-тамыза, нинди осталык белән коктейль ясавын да күзәтергә мөмкин. Димәк, тар почмакка ук терәлеп торган урын әдип тарафыннан очраклы рәвештә генә сайланмаган. Иң элек, монда теләсә кем килеп борчырлык урын түгел. Икенчедән, ул, шушы тын почмакка утырып, ресторан-барның һәр ике залын уч төбендәгедәй күзәтә алган. Түрдәге якты залда, кубалыларның сөйләвенә караганда, ул елларда дөньяның төрле почмакларыннан килгән «акча капчыклары» һәм эшкуарлар мыж килеп торган. Ә ишек катындагы бар әйләнәсендә исә кәеф-сафа корып йөргән яшьләр өстенлек иткән булса кирәк... Хемингуэйның биографиясен өйрәнүчеләр язганча, монда ул 1941—1942 елларда аеруча ешлаган. «Пилар» катерында тәүлекләр, атналар буена хәрби задание белән йөреп, талчыгып, «Вихия» усадьбасына кайтуга ук ул, машинасына утырып, «Эль Флоридита»га чыгып чаба торган була. Һәм сәгатьләр буена, ә еш кына таңга кадәр, һичкемгә сүз катмыйча, кашларын җыерып, залдагы ыгы-зыгыны күзәтеп утыра. Бөтен иҗаты сугышка һәм фашизмга ачы нәфрәт белән өртелгән олы әдипнең күңелендә шатлык һәм елмаюларга урын табылмау табигый, әлбәттә. Дөнья картасына төшкән кара шәүлә барлык прогрессив кешелекне тетрәндергән, борчып сыкранырга мәҗбүр иткән көннәр була ич...

Шундый уйлар белән мин баш очымда торган бронза бюстка янә текәлдем. Анда — Э. Хемингуэй. Ул әле дә тирән борчуга чумган хәлдә утыруын белә. Маңгаендагы тирән җыерчыклар, сынаулы караш, чытыла төшкән йөз әдип рухының тирәнлеген, ул янып яшәгән проблемаларның җитдилеген тагы бер мәртәбә ассызыклап тора.

Әлбәттә, Кубада яшәү дәверендә Хемингуэйның иркен сулыш алган, шатлыктан канатланып йөргән көннәре дә була. Мисал өчен Кубада рево-

люция җиңгән көннәрне алыйк. «Мин Кастро җитәкләгән революцияне яклыйм, чөнки ул халык массаларының омтылышын чагылдыра...» — дип, интервью бирә ул америка журналистларына әле Батистаның канлы режимы бәреп төшерелгәнгә кадәр үк. Революция җиңгән көнне үк ул үзенең машинасын, складта сакланган мылтыкларын һәм берничә әрҗә патронын революционерларга бирә. Хәтта үзенең торак урынын да, стратегик күзәтү урыны икәнлеген истә тотып, файдаланырга тәкъдим итә. 1959 елның 4 ноябрендә Хемингуэй, революцион хөкүмәтнең яңа флагын үбеп, «Үзебезнең һәммә кыенлыкларыбыз уртак булсын», дип, Куба халкына тугрылыкта ант бирә.

Хәер, бу тугрылык, азатлык утравына һәм аның киң күңелле халкына булган чиксез мәхәббәт һәм ихтирам-хисе әдипнең бөтен иҗаты һәм тормыш юлына хас үзенчәлек. Әйтик, «Карт һәм диңгез» әсәре өчен үзенә Нобель премиясе бирелү хәбәре килгәч тә беренче интервьюсында ук ул: Бу бүләкне мин Кубага бирелгән дип кабул итәм... Кубада яшәп тә бу әсәрне начар язу мөмкин түгел иде...» дип басым ясап әйтә. Һәм сүзләрен «Мин үземне кубалы дип хис итәм», дип тәмамлый.

Соңрак Хемингуэй, әлеге повестьның туу тарихына тукталып, язып чыга: «Диңгез үзенең берөзлексез үзгәреп торган төс һәм төсмерләре белән, өзлексез хәрәкәте, кырыс законнары һәм көче белән повестьны үзе язды... Мин бары тик океанны тыңладым, барын да ул кушканча, ул боерганча эшләдем... Миңа Кубада эшләве рәхәт». Дөньякүләм танылган язучы үзенә, иҗат серләре турында сөйләвен үтенеп, өзлексез мөрәҗәгать итеп торган буржуаз матбугат вәкилләренә әнә шул рәвешле җавап биреп тора. Иҗатына Кубаның экияти табигате, эчкерсез һәм бер үк вакытта каһарманлык сыйфатларына ия кешеләренең чиксез зур йогынтысын яшерми. Хәтта үзенә бирелгән югары бүләк — Нобель премиясе медален дә ул мәңгелеккә кубалыларга бүләк итә.

Әлбәттә, Куба халкы да үз чиратында бурычлы булып калмый. Хемингуэй исеме азатлык утравында революция эше өчен башларын салган милли геройларныкы сыман ук мәңгеләштерелгән һәм һәрдаим олылап искә алына. Хемингуэй исеме белән бәйле урыннар дәүләт тарафыннан зур кайгыртучанлык белән саклана. Моңарга күпләгән мисаллар да китерергә мөмкин булыр иде, әлбәттә. Нибарысы бер кечкенә фактны искә алуны кирәк саныйм: мәгълүм булганча, Хемингуэйның эчкерсез аралашкан дуслары — Кохимар балыкчылары була. Һәм Кохимарда өлкән яшьтәге һәр кеше үзен әле дә Хемингуэйның якын дусты саный һәм әдип белән булган әңгәмәләрен, истәлекле вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләргә әзер тора. Кохимар балыкчылары белән соңгы тапкыр аерылышканда, Хемингуэй күз яшьләрен яшерә алмый еларга мәҗбүр булган. Ә инде танылган әдипнең трагик төстә дөньядан китүе хәбәре килгәч, Кохимар балыкчылары, аның исемен мәңгеләштерү максатыннан, су астына баткан көймәләрдән мең газап белән җыелган бронзадан Хемингуэйга һәйкәл куйдыралар. Атлантик океанның иксез-чиксез ераклыкларына төбәлеп торган һәйкәл, балыкчыларның әдипкә эчкерсез хөрмәте символы буларак, әле дә яр буенда горур басып тора.

Бронза сын каршында торганда, мин янә, онытылып, үз уйларыма бирелгәнмен. Болай да җиңел булмаган тормышларының кыенлык белән очын-очка ялгап барган гади хезмәт халкы — балыкчыларның дөньякүләм танылган әдипкә, гасырыбызның иң зур художникларыннан берсенә ихлас мәхәббәте билгесе ич бу һәйкәл. Халык ихтирамы очраклы булмый. Әдип булудан да бигрәк, Хемингуэйның кешелек сыйфатларына һәйкәл бу, чөнки аны салу инициативасы белән йөргән балыкчылар арасында байтагының укый-яза белмәгәнлеге мәгълүм. Сокландыргыч дәрәҗәдә гыйбрәтле факт! Бөеклекне күңел күзе белән тоя һәм күрә алган Кохимар балыкчылары алдында баш иясем килде минем.

Су өстендә, балык тәңкәләредәй елык-елык килеп, кояш нурлары җемелдәшеп уйный. Яр буенда судан чыгып торган коралл рифлар өстендә яланаяклы чем-кара малайлар балык чирттерә, аларның баш очында, канатларын җәеп, озын томшыклы альбатрослар очып йөри, яшькелт-зәңгәр океанда җилкәнле көймәләр чайкала. Ярдан читтәрәк пар дельфин уйнаклый. Ятьмәсендәге тишекләрне ямау белән мәшгуль булган карт балыкчы, башын күтәреп, авызындагы юан сигараны суыра-суыра, каш өстенә кулын куеп, шул дельфиннарга сокланып тора...

Хемингуэй яраткан кешеләр, Хемингуэй яратып туймаган гүзәл табигать, Хемингуэй үз җанынннан да болайрак күргән, әмма аның серләренә төшенеп, аңлап бетерә алмаган иксез-чиксез дөнья. «...Мин күп нәрсәне аңлый алмыйм,— дип уйлады ул үзалдына.— Ләкин шунысы әйбәт, кояшны, айны һәм йолдызларны үтерергә безнең буй җитми. Диңгездән ризык тартып алуыбыз һәм үз туганнарыбызны үтерүебез дә җитеп ашкан...» Тормышчанлыгы һәм фәлсәфи тирәнлеге, колачы беләя вакыт ягыннан булсын, пространство ягыннан булсын чикләрне белмәгән мәшһүр әсәр «Карт һәм диңгез» повестеннан Сантьяго әнә шулай фикер йөртә. Үзенең гомере кыл өстендә торганда да гади бер балыкчы дөньяны — кояшны, айны, йолдызларны кайгырта, аларның кеше ихтыярыннан югарырак торуына куанып туймый. Әлбәттә, балыкчы картның бу куанычы әдипнеке белән уртак. Бөтен гомерен һәм иҗатын кешедә кешелеклелек сыйфатларын олылауга, җирдәге иминлекне саклауга, фашизмга каршы көрәшкә багышланган әдип кояш һәм йолдызларның, димәк, тормышның мәңгелегенә ихластан ышана...

Әгәр бүген исән булып, АКШ президентының «Йолдызлар сугышы» турындагы хыял белән саташканын ишетсә, Хемингуэй нәрсә дияр иде икән?! Мөгаен, Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач та үз ватандашларын көч белән, корал белән шаяра-шаяра фашизм идеологиясенә тәгәрәүдән кисәткәнлеген хәтерләр иде. Ләкин сер бирмәс, төшенкелеккә юл куймас иде. Тагы бер тапкыр һәм үз-үзенә тирән ышаныч белән «...кеше юк булу һәм җиңелү өчен яратылмаган. Кешене үтерергә була, әмма җиңү мөмкин түгел!» — дип, кистереп җавап кайтарыр иде. Кулләренә кан сауган, куллары җәрәхәтләнеп, бөтен тәне канга буялган Сантьяго карт та үз-үзен кызганудан түгел, кешеләрне, җирне, дөньяны яратудан «Йолдызлар — сеңелләрем минем...» дип дәшә ич галәмгә.

Дөнья тыныч түгел. Дөньяда тормышны һәм кешене саклап калу өчен зур көрәш бара. Ерак тарафлардан чаң авазы ишетелә...

Чаңны кем дип кагалар?..

*Сан Франциско-де-Пауло — Гавана — Казан.*



**Н. Ф. Вәлиев,**
КПССның Сарман райкомы беренче секретаре.

# ҖЫРЛЫ ЯК

Көмеш сулы Минзәлә елгасы буена урнашкан Сарман районы бүгенге көндә 15 колхозны, 4 совхозны берләштерә. Районда 72 авыл һәм Җәлил эшчеләр поселогы бар, аларда 40 мең кеше яши.

Нурлы як, җырлы як диләр бу якларны. Аның зәңгәр таулары Бөгелмә калкулыгын башлап җибәрәләр, Урал тауларының еракларга сузылган итәге безгә килеп җитә.

Тарихи чыганакларга караганда, мондагы авыллар нигездә XVII һәм XVIII гасырларда барлыкка килгәннәр. Район үзәге булган Сарман авылы, мәсәлән, Россия Фәннәр академиясенең беренче член-корреспонденты П. И. Рычков төзегән карталарга 1737 елда теркәлгән. Халыкта сакланган шәҗәрәләргә караганда, авылга нигез салучы Сарман бабай Пугачев явы вакытында исән булган әле. Риваятьләр аның «халык патшасы Питр Фидрич»ка үзенең кара бәкәлле ак атын бүләк итүе турында сөйлиләр.

Сарман ягы авыллары Пугачев хәрәкәтенә ярдәм кушылганнар, патша гаскәрләренә һөҗүм итүдә дан алган Тимерхан Мостафин кебек кыюларга күрше өязләрдә дә сокланып караганнар. Җәмәлҗән тавы, Каравыл тавы, Калатау кебек исемнәр дә — шул чорның онытылмас ядкарьләре. Казан — Уфа, Уфа — Минзәлә юллары өстендә утырган бу яклар аркылы элек-электән сәүдәгәрләр узган. Гарәбстан, Иран ягыннан зур ярминкәләргә узучылар инеш башларына махсус тукталганнар, тирәннән типкән көмеш сулы бер чишмәне алар «Минзел» дип (гарәпчә «тукталыш» дигән сүз) атаганнар. Бу чишмәдән юл алган елга соңыннан Минзәлә дип йөртелә башлаган.

Сарман яклары Софья Перовская, Николай Кибальчич кебек народникларның якты истәлеген зур хөрмәт белән саклый. Архив материаллары раслаганча, алар бирегә — Иске Кәшер волостена караган Мазуревский имениесендә яшәгәннәр һәм үзләре ясаган снарядларны да шунда сынап караганнар.

Үлгән як, бөлгән як дип йөрткәннәр ул заманнарда безнең якларны. Рангазар авылы кешеләре:

— Безнең авылга сыер елында нигез салганнар, шуңа безнең сыер урынына савалар,— дип зарлана торган булганнар.

— Безнең авыл елкы елында барлыкка килгән, шуңа безне ат урынына эшләтәләр,— дип сөйләгәннәр Чураш авылыныкылар.

— Ә безнең авыл эт елында оешкан, шуңа күрә безне эт типкесендә йөртәләр,— дип үзләрен тынычландырырга тырышканнар Күтәмәле кешеләре.

Әйе, бөлгенлектә, хәерчелектә яшәгән халык. Стахеев, Мусин, Шнегас, Пальчиков, Гани бай кебек боярлар һәм алпавытлар изгән, талаган крестьяннарны. Карындык тәрәзәле карсак өйләргә, җир идәнле землянкаларга ачлык-ялангачлык юлдаш булган. Ваба, тиф беркайчан да китеп тормаган. Туган балаларның өчтән бере бер яшькә дә җитмичә үлә барган. Яртысы биш яшькә җиткәнче дөнья куйган.

Яхшыбай авылы кешеләре шундый бер вакыйганы сөйлиләр: гасыр башында авыл бае Минзәлә ярминкәсеннән унлы лампа алып кайткан. «Оҗмах нурын» күрергә дип тирә-як авылларыннан да халык агылган. Чыра яндырып көн күргән кеше өчен, әлбәттә, унлы лампа яктысы могҗиза булып тоелган.

Ул чакта кешеләрнең күбесе русча укый-яза белмәгән. Әйтик 1900 елларда Сарманга губерна үзәгеннән «чинлы кеше» килгәч, аның белән иркенләп сөйләшерлек русча белүче табылмаган.

Караңгы торгынлыкта яшәгән Сарман ягына Бөек Октябрь бәхет китерде. Бил турайтып башын күтәргән халык җирнең төп хуҗасына әйләнде. Шул бәхет өчен утка-

суга керде, фашистларга каршы көрәште. Октябрь казанышларын саклап калу өчен сарманлылар үзләрен аямадылар. Шул изге юлда корбан булган якташларыбызны без һәрвакыт тирән горурлану белән җылы итеп искә алабыз. Совет властеның дошманнары тарафыннан үтерелгән Анак авылының беренче коммунисты Әхәт Иштирәков, Кәүҗияк авылының комсомолы Хаҗи Ишморатов, Азалак авыл Советы секретаре Гыйлфан Хәйретдинов, Ләшәү-Тамак авылы активисты Биктимер Сафин, Рангазар авылында беренче колхозны оештыручы Латыйп Рәхмәтуллин, Петровка спирт заводы директоры Сәгыйдулла Хәбибуллин исемнәре районыбыз тарихына мәңгегә язылганнар. Сарман җиреннән күпләгән азинчылар, чапаевчылар үсеп чыккан.

Бөек Ватан сугышы башлангач, районыбызның егет һәм кызлары немец илбасарларына каршы күтәрелгән. 9722 кеше сугыш кырына киткән, 6327 кеше яу кырында, бүгенге матур тормышыбыз хакына, башын салган. Александровка авылы егете Александр Казаков Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булды. Иске Кәшер авылыннан Зиннәт Хәсәнов Муса Җәлилнең иң хәтәр поручениеләрен үтәүче көрәштәше буларак бөтен илебезгә мәгълүм.

Бу мәкаләдә Сарман туфрагы тудырган язучылар һәм шагыйрьләрнең исемнәрен дә атау кирәктер дип уйлыйм. Алар — Вәдүт Мифтахов, Сөббух Рафиков, Аяз Гыйләҗев, Рәфкать Кәрами, Диләрә Зөбәерова, Мәдинә Маликова, Клара Булатова, Хәниф Хәйруллин, Әзһәр Габиди һәм башкалар. РСФСРның халык артисты Илһам Шакиров, композиторлар Мәсгут Латыйпов һәм Ифрат Хисамов, рәссам Татарстанның халык художнигы Мәснәви Хәйретдиновлар да безнең өчен үз һәм якын.

Юлтимер авылы егете нефтьче Әнәс Абдуллин СССР Дәүләт премиясе лауреаты булды. Саный китсәк, күп безнең районның мактанычлары. Шуны гына да әйтү җитә, бүген районыбызда 50 дән артык Ленин ордены кавалеры, республиканың атказанган терлекчеләре, механизаторлары, нефтьчеләре, укытучылары яши.

Билгеле булганча, Сарман районы ВЦИК карары нигезендә, Татарстандагы 46 районның берсе буларак 1930 елның 10 августында төзелә. Әлбәттә, ул чактагы район белән хәзергесе арасында аерма бик зур. Сарман авылы үзе дә танымаслык булып үзгәрде. Асфальт юллар аны төләсә кайсы шәһәр белән тоташтыра. Бүген Сарман аэропортыннан республикабыз башкаласына кырык биш минутта барып җитәсең. Бүген Сарманга «зәңгәр ягулык» — газ кертелде, нефтьне дә Сарман үзе чыгара. Хәзер бөтен район төзелеш мәйданын хәтерләтә дисәм, хата булмас. Сарман белән Җәлилдә генә түгел, барлык колхозларда да төзү эшләре кызу темп ала. Һәр колхозда һәм совхозда типовой культура йортлары, мәктәп биналары салынды. Медицина, сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү учреждениеләре челтәре киңәя. Ел саен техника паркы ишәя, тракторлар, комбайннар саны арта.

Районыбызның сөрүлек җирләре 100 мең гектардан да артып китә. Шуның 72 мең гектары иген кырлары. Шул ук вакытта без шикәр чөгендере дә игәбез.

Республикабызның көньяк-көнчыгышына урнашкан Сарман районы эшчәннәре киләчәккә матур планнар белән яшиләр. Алар партиябезнең XXVII съездына хезмәт бүләкләре әзерлиләр, районыбыз йөзен үзгәртү, аны тагын да матуррак итү өчен көчләрен аямыйлар.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Кояш Тимбикова

# УТ КИРӘК, УТ!

Алар тирән йокыга талганнар иде инде. Ишек дөбердәткән шомлы тавышка барысы да берьюлы уянды. Рәисә, сикереп торып, электр төймәсенә басты. Төймәнең «шылт, шылт» иткән тавышы берничә тапкыр кабатланса да, өйгә яктылык сирпелмәде. Ишекне тагын дөбердәтә башладылар.

— Кара инде,— дип сукранды хуҗа хатын. Абына-сөртенә ишек ягына китте.— Кем ул, кара төндә ни калган? Ник алай сабырсызланасың?

— Рәисә апа, ач әле! Расих бу, Расих Исмәгыйлев. Дамир да кирәк, үзең дә. Ут юк, ут өзелгән.

Шырпы эзләделәр — юк, кесә фонаре булырга тиеш иде, анысын да табарлык түгел. Барысы да электрга көйләнгән йортта андый нәрсәләрне кадерләп саклаудан алар бизеп беткәннәр иде инде...

Кеше гомере буе утка тартылган. Утның серләрен ачкач кына ул чын мәгънәсендә кешечә яши башлаган. Кешегә ут бүләк иткән Прометей турында бер дә юкка гына буыннан-буынга риваятьләр сөйләмиләр. Максим Горький да мәшһүр Данконың йөрәген тикмәгә генә ут итеп балкытмаган. Утка ия кеше генә көчле була ала. Ут ул — әллә нинди көч-куәтләр чыганагы. Көч дигәнең исә безгә өзлексез кирәк.

Кешелекнең әллә ни ерак тарихына кагылмыйча, үз илебезнең үткәнен генә күздән кичерсәк тә, энергиягә бай бүгенге көннәребезнең кадере тагын да артып китә. Әле кайчан гына чыра яктысында кич утырганнар. Салкын кышлар озакка сузылса, идәннәрен мичкә ягып, өй җылыткан вакытлар булган. Авыр эшләрнең барысын да кеше үз көче белән генә ерып чыга алган.

Октябрь безне яктылыкка алып чыкты, дибез икән, бу сүзләр, социалистик революциянең кешелеккә нурлы яңа юл ярып күрсәтүен генә белдереп калмый. Бу сүзләрне туры мәгънәсендә дә кулланырга һәм әлеге төшенчәне аңлатып бирергә була. Бары тик Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына безнең илдә кешеләргә яктылык, җылылык, көч бирердәй чаралар күренә. Илне электрлаштыру турында даһи Ленин үзе башлап кайгыртучанлык күрсәтә. Аның тәэсире Татарстанга да бик тиз килеп ирешә: беренче бишьеллыкларда ук ТЭЦлар салына. Зәй ГРЭСыбыз, Түбән Кама ГЭСыбыз бар безнең. Ниләр генә эшләтмибез без электрдан?! Санап чыгуы да — зур мәшәкать кебек. Шуларны кулдан башкарырга калсаң, утын ягып җылытырга, шырпы сызып яктыртырга тотынсаң, ай-һай, искә тиз төшә алар. 1978 елның декабрен генә хәтерлик: безнең якларда бик сирәк була торган суыклар башлангач, Зәй ГРЭСында кыска гына вакытка эш тукталып калды. Тыштагы җайланмалар түбән температура тәэсирендә кысылганнар, энергия озатып торучы приборларның тәртибе бозылган һәм бер мизгел эчендә станция энергия бирүдән туктаган иде. Ничә предприятиегә, ничәмә-ничә колхоз-совхозга зыян килүен хәзер искә төшерүе дә авыр. Моңарчы җылылыкны да, яктылыкны да, завод-фабрикаларны хәрәкәткә китерүче көчнең дә кайдан алынуына игътибар бирми йөрүчеләр: «Аһ!» иттеләр. Гыйбрәт өчен ГРЭС системасына тоташтырылган бер генә совхоз хуҗалыгының бер генә тармагын телгә алып үтик.

Чистай районындагы «Роман» совхозындагы комплекс, электрсыз калган шушы хәвефле бер төнне уздырганчы, ике мең баш дуңгыз баласы һәлак булды. Вакыт-вакыт без электр көченең кадерен генә белеп бетермибез, аның булмау ихтималын хәтердән чыгарып ук торабыз. Ә ул, һич көтмәгәндә, үзенең ачуын сиздергәләп куя, аңардан башка яшәү кыенлыгын искәртә сыман. Шунлыктан кеше дә мая туплабрак яшәү ягын карый. Татарстандагы электр челтәре мисалында бу әзерлек бигрәк тә ачык күренә. Без инде шактый еллардан бирле электр энергиясе белән тулысынча тәэмин ителеп, аны гомумсоюз системасына да бирү мөмкинлегенә ирештек. Шулай да...

Энергия чыганаклары дөнья күләм саегып барганда, ягъни җирдәге ташкүмер, нефть, урман кебек кешегә ут бирердәй байлыклар санаулыга кала башлаганда галимнәр иң отышлысы атом электр станцияләре салу икәнлеген расладылар. Заман яңалыгына Татарстан да игътибар итте һәм, Түбән Кама ГЭСының барлык турбиналары әле сафка басып та өлгермәстән, без Кама елгасы буенда ук атом электр станциясе салырга тотындык. Кешеләребез яктылыктан, җылылыктан, көч бирү чыганагыннан бер вакытта да мәхрүм булмасын өчен шулай кирәк иде.

Кама ярында, борынгы Кама Аланы авылына яшь прометейлар, яңа заман данколары җыела башлады: тәҗрибәле төзүчеләр Рәис Сәлахов, Рифкат Кәтиев, Надежда Макаева, Дамир Сабиров, Альберт Хәбиров, Камил Әхмәдиев, Василий Филиппов, Гиздулла Җиһаншин, Илфат Вәлиуллин... Иң өлгерләре, иң ышанычлылары гына да йөзләп аларның. Кама Аланында хәзер өч меңләп кеше бар. Аларның беренче адымнары ук гыйбрәтле, тирән мәгънәле булып чыкты. Кылган һәр эшләре: «Кешеләргә ут кирәк, без монда шуңа җыелдык!»— дип эрактан ук хәбәр сала кебек. Тизлекләренә күз иярми. Нибары өч еллап вакыт үтте — тын гына уйсулыкта яңа шәһәрнең карашларны иркәләрдәй күркәм силуэты калыкты. Шәһәр өчен җаваплы 12-төзү-монтаж идарәсе җитәкчесе Рәис Сәлахов гел яңача эшләүне алга сөрә. Башта авыл янына уннарча яшелле-зәңгәрле торак вагоннар китереп тезгәннәр иде. Эш кабинетлары да, ашханә дә, яшәү урыны да — барысы да вагоннарда иде. Анда гына сыешмаганнары борынгы авыл кешеләре янына өйдәш булып урнаштылар. Хәзер берсенең дә эзе юк. Вагоннарны да, иске йортларны да сыдырып алып бетергәннәр, кешеләре нәкъ шул урыннарга салынган тугызар, бишәр катлы ташпулатларга күчкәннәр.

Инде атом электр станциясенең беренче реакторы куелырга тиешле мәйданның үзен ук кымтырыкларга тотынганнар. Җирне умыралар, ун-унбиш скрепер берьюлы эшли, гаҗәп көчле экскаваторлар «БелАЗ», «КрАЗ», «КамАЗ»ларга кирәкмәгән балчыкны төяп тора, Тегеләре оча гына. Җирнең өстәге 5—6 метрлы катламы сыдырыла. Төзелеш коллективларының партия комитеты секретаре Рифкат Кәтиев:

— Реакторны урнаштырганда бу мәйданны әле тагын берничә метр тирәнлеккә казып төшерәчәкбез,— дип гади генә аңлата. — Якында гына зур бетон заводы эшләп торачак. Реакторның стеналарын ныгытканда яхшы сыйфатлы бик күп бетон кирәк булачак, аны ерактан ташып өлгертү мөмкин түгел...

Атом көчен буйсындырырга җыелган егетләр, ул егетләргә багышлап яңа шәһәр салырга җыелган ут чаткысыдай җитез төзүчеләр үзләре дә ашыгучан, кабаланучан булырга тиеш кебек. Искене җимереп, әр-яңаны, ата-баба күрмәгәнне торгызганда, ыгы-зыгыларсыз гына ничек мөмкин? Тик театрга барырга әзерләнгән кеше кебек пөхтә киенгән Рифкат Кәтиев белән Рәис Сәлаховның үз-үзләрен тотышларында да, сөйләшү алымнарында да һичнинди каударлану сизелми. Алардагы сабырлык, уйлап кына, җай гына эшләү прорабларга, участок начальникларына, мастерларга, бригадирларда һәм гомумән барлык төзүчеләргә хас сыйфат булып таралган. Башны ташка бәрердәй хәвефле хәлләр дә, аларның сабырлыгын сынарга теләгәндәй, аяк астыннан чыккандай туып кына тора, югыйсә. Төн уртасында Дамир Сабировның ишеген ник кагалар дисез? Вакытлыча тоташтырылган электр җайланмалары сафтан чыккан. Ут юк. Бу хакта иң әүвәл Рәискә хәбәр иттеләр. Ул сабыр гына:

— Дамирга йөгерегез!— диде.

— Ул бит электрик түгел, йортлар бизәү участогында начальник. — Идарә җитәкчесе Дамирны башка берәү белән бутый, дип уйладылар. — Электриклар теге йортта.

— Вазифалар бүлешеп торыр чак түгел. Дамирның осталыгы бар,— диде Сәлахов.— Ул барында электрикларың бер якта торсын. Аларны да чакырырбыз, иң әүвәл Дамир кирәк, ансыз барып чыкмас.

Рәис Сәлаховның сабырлыгы әллә нинди тирән серләргә нигезләнмәгән, сәбәбе ап-ачык: ул үз кешеләрен яхшы белә, бөтен хикмәт шунда. Кемгә нинди чакта ышанып таянырга мөмкин, кем көчле, кем юлдан тайпылып куючан — аның күз алдына бары рәт-рәт тезелгән. Шунлыктан кирәк чакларында, ары сугылып, бире бәрелеп, чара эзләп маташулар юк, иң дөрес һәм бердәнбер юлны, кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклекне, хафаланып тормыйча, тиз хәл итә.

Берсендә Дамир Сабиров участогы бизәп, эшен тәмамлап чыккан әр-яңа йортның торбаларыннан су агарга тотынды. Юри көтеп торган диярсең, бу хәтәр хәл дә төнлә булды. Күрәсең, өйләрдә судан файдалану тукталгач, басым артып киткәндер. Бусында Дамирның хатынына, җылылык челтәре өчен җавап бирүче оешмада эшләүче Рәисә Сабировага да эш чыкты. Су басымына чыдый алмаган торба завод брагы икән. Шуны ачыкладылар. Рәисә карамагындагы складтан аны алыштырырдай башка торба таптылар. Дамир бөтен эшне башлап йөрде. Рәис исә мондый очраклы күңелсезлекләр кабатланмасын өчен кискен чара күрү кирәклеген уйлады. Заводларның кайчак төзелешкә түбән сыйфатлы материал озаткалавы бүгенге хәл генә түгел. Еллар буе килеп тора. Бетон әйберләр

заводы кагыйдәгә сыймый торган авырлыктагы плитәләр коеп үзәккә үтә, еш кына материаллар соңга кала, сантехниклар торбалардан, краннардан, боргычлардан зарланалар... Заводта җай гына ясала торган детальләрне төзелештә тәртәгә кертә-кертә күпме вакыт үтә. Ярамаслыгы күзгә күренеп торса да, бәлки чыдар әле, бәлки, үтәр әле, дисең. Ярамый икән шул, әнә, кайчак аварияләр дә чыгып куя.

Рәис Сәлахов, уйларына юл таба алмый башласа, Рифкать Кәтиев белән киңәшергә ярата. Бу ике җитәкче әлеге зур эштә берсен-берсе тулыландырып торалар. Рәис төзү осталыгына хезмәт аша, барын да үз куллары белән эшләп карап өйрәнгән. Ул төзелештәге теләсә нинди һөнәр иясен, кирәк икән, ике дә уйламыйча, үзе алмаштыра һәм аның бурычын шәп итеп башкарып чыга. Рифкать теория ягыннан килгән көчле. Ютазы урта мәктәбен тәмамлагач, Рифкат Мәскәүнең төзелеш институтында укыган. Аннары еракка, Казахстан далаларына китеп, җаваплы объектларны салуда катнашкан. Белем, культура, тәҗрибә, дөньяга караш — һәммәсе заманча. Өстәвенә, Рәис шикелле үк, гаиләсен дә бөтен иттереп өлгергән. Хатыны Элмира Кәтиева — АЭС дирекциясендә экономист, кызы Диләә өченче класста укый, Азат бакчага йөри.

Рәис белән Рифкатнең яшьтәшләр булуы да бер-берсен сүзсез аңларга, мөгаен, ярдәм итәдер.

— Рәис Сәлахович, яңа мәктәп турында киңәшәсе бар иде,— дип шалтырата Рифкат. Җәйге яңгырларда эш мөшкелләнгәч, мәктәпнең уку чорына өлгерү-өлгермәве куркыныч астында калды. — Нишләрбез икән?

— Килеп чык монда!— Рәиснең сабыр тавышы ук борчуларны басып куя. — Мин уйладым. Мәктәп өлгерергә тиеш. Инде бераз алданрак тапшырырга уйласак, берничә әмә оештырырбыз. Укучыларны да тартырга була. Өйрәнә торсыннар! Кил, планлаштырыйк!

Моңарчы Кама Аланының мәктәбе сигезьеллык кына иде. Вакытында шунысы да бик җитте. Төзүчеләр килгәндә, авылда нибары ун-унбиш укучы бар иде, яңа мәктәп бинасы салынгач, кырык-илле булдылар. 1984—85 уку елын 280 бала тәмамлады. Инде бөтен шарты килгән урта мәктәп өлгертү турында сүз бара. 1985—86 уку елын 500 бала көтеп тора. Моңарчы күрше Ширәмәт мәктәбенә йөреп укыган тугызынчы, унынчы класслар да яңа шәһәрнең үз урта мәктәбен көтеп алдылар. Спорт белән мавыкканнарга төрле түгәрәкләр оештырыла, мәктәптәге бассейнда уздырылачак ярышларга да әллә ни күп вакыт калмаган.

Яңа мәктәпнең 1500 укучыга исәпләп салынуы сәер тоела:

— Ничек? Ун-унбиш укучылы мәктәп ике-өч ел эчендә шулай зураеп өлгердеме?

Бик җитди сүзне дә тыенкы гына елмаеп сөйләүчән Рәис Сәлахов бу юлы шактый ачылып китә:

— Нәрсәсе гаҗәп аның?— ди. — Әнә, әле яше кырыкка да җитмәгән Дамир Сабиров өендә генә дә дүрт бала. Өчесе мәктәпкә йөри, бәләкәй Русланы — бакчага. Киңәштек, киңәштек тә шундыйрак гаиләләргә йөз тотып салдык инде мәктәпне.

Атом электр станцияләре, гадәттә берничә ел буе салыналар. Бу очракта аның барлык алты реакторы да энергия бирә башлаган вакыт күздә тотыла. Станциянең беренче реакторын 1989 елларда сыный башлауларны искә төшерсәк, атом көченнән файдалану көннәрен әллә ни күп көтәргә дә калмый. Һәр минут — исәптә. Беренче карашка, мең төрле тармакка җәелеп киткән төзелеш көн саен, сәгать саен төп максатка якыная бара. Барлык төзүчеләргә билгеле булганча, максат бер генә — ут! Кешеләргә ут-көч кирәк! Кешенең тормышы, яшәү рәвеше тагын да яхшырак булсын өчен кирәк ул. Мәктәбе дә, мунчасы да, бер-бер артлы сафка кереп барган ашханәләр дә — барысы да атомны гади хезмәттә файдаланучы кеше бәхете өчен төзелә.

Ашханә димәктән, атом электр станциясенә әзерләнә торган мәйданнан ерак та түгел бетон заводы белән рәттән тагын бер зур ашханәгә нигез салалар. Бетон заводын салучыларны бригадир Камил Әхмәдиев җитәкли. Кама Аланына беренчеләрдән килгән ул. Туган якта яңа төзелеш кузгалганын ишеткәч, Норильскидан кайткан. Анда ул бакыр-никель заводы салган булган. Шунда ук техникум тәмамлаган. Кама буена исә бөтенләйгә, төпләнеп яшәргә кайткан. Егетнең өйләнүен генә көтеп торганнар — квартира биргәннәр үзенә. Гөлүсәсе торак йортлар салуда иң уңган буяучы-сылаучы булып танылган.

Бу төзелешне үз итеп, гомерлеккә шунда төпләнеп яшәргә килүчеләр хәзер күзгә күренеп арта, андыйлар яңа шәһәрнең үзәгенә-төшенә тупланалар.

— Артур, нигә кәефсез син? Нәрсә булды?— Партком секретаре энергетикларны туендырыр өчен салына башлаган ашханә төзелешендәге егетләр янында иде.— Әйтеп җибәр, бәлки ярдәм итәрмен.

— Юк, Рифкат Кәшипович, зарланырлык бер нәрсә дә юк. Менә көнне генә суытып җибәрде, кулыгыздан килсә, җылылык өстәгез бераз!— Бригадир Артур Уразаевның монтажчы егетләре көлеп җибәрделәр. — Эштә барысы да нормально!

— Укуың ничек? Өегездә ниләр бар?

Партком секретаре коммунист Артур Уразаев кебек төзүчеләрнең хәл-әхвәлен

өзлексез сораштырып тора. Читтән торып Куйбышевта төзелеш институтында укый Артур. Яшь кенә булса да күпне күргән. Бригадасындагы егетләр белән мөгамәләсе әйбәт. Төзелештә берәр яңа алым башлыйм дисәң, яки четерекле хәлгә тап булсаң, нәкъ менә шушы Артур кебекләргә килеп сүз кушасың. Ил күләмендә коллектив подряд ысулы хуплангач та Рифкат Кәтиев шушы бригадага килде. Мондый яңалыкка няреп киту өчен, бригаданың шактый мөстәкыйль булуы шарт. Шуны истә тотып, Рифкат:

— Егетләр, сез бригадагызга берәр ташчы да аласызмы әллә?— дип, читтәнрәк сүз башлады.

— Мин үзем ташчы,— Артур көлде. — Монда — безнең һәрберебез берничә һөнәр белә, разрядларыбыз бар.

— Алайса, бер-ике балта остасы бирик без сезгә.

— Анысы да бар, Рифкат Кәшипович, ни телисез? Яңа ысулга күчермәкче буласызмы?

— Син аңа минем теләк итеп карама, Артур! Үзеңә дә кызык булырга тиеш. Менә шушы ашханәне баштанаяк үзегез генә салып чыксагыз, сиңа институтыңны тәмамларлык диплом эше әзер диген сүз. Уйла тагын бер мәртәбә. Әгәр сезгә материал биреп торучы завод белән дә, аны ташучы шоферлар белән дә килешә алсагыз, тоташ подряд ысулы ясыйбыз. Мин сезгә устав китабын калдырам. Кагыйдәләрен өйрәнегез. Аннары килешү төзисез. Ашханә — сездән, хак түләү — дирекциядән.

Егетләрнең кызыксынуы йөзләренә чыга. Тәгәл бәясе,— вакыты-фәләне — барысы да алдан ук ачыкланса, эшләве дә мавыктыргычрак ич аның! Ул чагында ел саен төзелеш материалының 2 процентын янга калдыру диган икенче максатка ирешү дә җиңелләшә. Барысы да бер юнәлештә тырышса, һәммә кеше яхшырак булсын дип теләсә...

Атом электр станциясен төзүчеләр арасында, әлбәттә, очраклы кешеләр, үз мәнфәгатен олы бурычлардан өстенрәк куючылар яки яшәү максатын әлегә аңлап бетермәүчеләр дә юк түгел. Тик андыйлар белән дә бик сак эш итәләр. Кешедән дә кадерле көчнең юклыгын һәрчак истә тоталар.

Җитәкче булуның кыйммәтле сыйфаты да шунда — ул, кирәк чакта, яңа каланың яңа кешесе өчен барган көрәштә бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала белә. Туганов фамилияле берәү тәртип бозган, эшкә соңга калган. Коммунистлар шул мәсьәләне карарга махсус җыелдылар. Тегенең җавабы да әзер икән:

— Мин бит мастерга әйткән идем,— дип котылмакчы.

— Бер кешене кырыкка бүләргә торган вакытта, берниндн мастерның да эштән җибәреп торырга хакы юк. — Моңарчы юаш кына күренгән Рәис Сәлаховның күзендә очкыннар бии. — Һәр җирдә әйтелгән: төзелешкә чыкмый калырга кирәк булса, бары тик шушы кабинетта гына рөхсәт алырга була, мин генә хәл итәм, бары мин генә. Шулай булгач, җаваплылыкны мастерга сылтавың дөрес түгел, Туганов.

— Гафу итегез!

— Итмибез. Каты шелтә белдерергә тәкъдим кертәм. — Идарә начальнигының тавышы кырыслана бара. — Без моңарчы Тугановның барлык үтенечләрен канәгатьләндердек. Кулында үзе теләгән эш, әле генә квартира алды. Сөенеп хезмәт итәсе урынга, дилбегәне бушатып куйган. Һәм, беләүемчә, бу беренчесе генә дә түгел.

Киңәшмәгә җыелганнар бер-берсенә карашалар. Туганов турында башкасын белмиләр иде. Шикле уйларны Тугановның:

— Әйе шул,— дигән сүзе бүлде. — Соңгысы булыр. Мин теге чакта сезнең тыныч кына әйткән киңәшләрегезне истән чыгарганмын, Рәис Сәлахович. Бу юлы, чынлап әйтәм, соңгысы булыр. Менә күрерсез. Бу сүземне дә тотмасам, йөземә төкерерсез...

АЭС салырга килгәннәрнең омтылышлары изге икән, Кама Аланында аны тормышка ашыру өчен барысына да әзер кешеләр күп. Теләгең генә булсын. Хәтта һичнинди һөнәрсезләрне дә кире какмыйлар, төзелеш өчен кирәкле һөнәргә өйрәтүче уку комбинаты да ачылган. Рәхим ит, укы, өйрән! Аның мөдире Арсентий Кудряшов әйтүенчә, 1985 елда гына да уку пунктыннан 900 кеше яңа һөнәр алып яки разрядларын күтәреп чыкканнар. Кешеләр тагын да рәхәтрәк яшәсен өчен башланган бу төзелештә башкача була да алмый.

Кеше гомере буе ут эзләгән, аны үзенә юлдаш, ярдәмче итәргә, аның белән уртак тел табарга омтылган. Аны бер сүндерсәң, бер югалтсаң, тиз генә табармын димә. Күпләр хәтерли: сугыш китергән авыр елларда шырпы азайды, авыл кешеләре, аны исраф итмәс өчен, чиратлашып, төн буе учак яндыралар иде. Иртә торасың да, мич үрләтер өчен, соскыч тотып, күршеңә киләсең: «Ут бир әле, зинһар!» Икенче көнне сиңа киләләр: «Ут бир әле!».

Шулай итеп, ут безне дуслыкның кадерен белергә, ныграк берләшергә дә өйрәткән икән. Уйлый китсәң, утка безнең үткәнебез дә, киләчәгебез дә турыдан-туры тоташкан. Төзелеш белән танышкач, күңелдә шундый бер тойгы уяна. Бәхетле киләчәк өмет иткән һәр кешенең карашы, әйтерсең лә, монда төбәлгән, гүя алар төзүче егетләргә: ут кирәк, ут! дип, ашыктырып, көч биреп торалар сыман. Татарстан АЭСын салучы егетләр бу җаваплылыкны үз җилкәләрендә тоеп эшлиләр.

# ТРАДИЦИЯЛӘР ЯҢАРГАНДА

Рәссамнарның Палангадагы иҗат йортында мин Гүзәл Вәлиева-Сөләймановaның «Совет Татарстанының монументаль-декоратив сәнгате» исемле китабына юлыктым һәм аны зур канәгатьләнү белән «бер тында» укып чыктым. Алдан ук шуны әйтим, яшь татар галименең әлеге хезмәте миндә, әзербәйҗан халкының күп гасырлык монументаль-декоратив һәм сынлы сәнгатьләре тарихын шактый еллар буе өйрәнүче буларак, тирән кызыксыну уятты. Татарстан китап нәшрияты, хезмәтне рус телендә чыгарып, башка республика белгечләренә дә галимнең эзләнүләре белән танышырга мөмкинлек тудырган.

Өч бүлектән торган әлеге китап татар халкының монументаль-декоратив сәнгатен тулаем колачлый һәм гасырлар буе тупланган бай мирас белән дә таныштыра. Күпләгән фактик материалны төрле яклап өйрәнү нәтиҗәсендә, милли монументаль-декоратив сәнгать үсеше этаплары тарихи эзлеклелектә ачыла. Әйтик, беренче бүлектә Болгар дәүләтенең VIII—X гасырлардагы культурасына бәйле борынгы ядкарьләрдән алып XIX һәм XX гасыр башына караган халык иҗаты әсәрләрен колачлаучы мирасның төрле катламнары тикшерелә. Милли төзелеш сәнгате белән монументаль-декоратив сәнгать тарихы китапта бербөтен процесс буларак күзәтелә. Урта гасыр татар сәнгате буенча күренекле белгеч Ф. Вәлиев хезмәтләренә, шулай ук башка тарихчы-галимнәр, археологлар һәм этнографларның эзләнүләренә таянып, үзе тикшерә торган материалны автор сәнгать белеме мәсьәләләре белән бәйләп өйрәнә. Халык художество традицияләренең башлангычын ул Болгар дәүләте сәнгатендә таба, милли стиль үзәнчәлекләрен сәнгатьчә орнаментация җирлегендә ачып бирә. Милли бизәк төшерү сәнгатенә исә үсемлек мотивларын «уйнату» мөмкинлеге, шарык орнаменты шикелле катгый, кануннарга сыешмау һ. б. шундый үзәнчәлекләр хас. Болгар корылмаларындагы бизәкләр үзенчәлеген автор төп архитектур-конструктив формаларны калку итеп күрсәтүдә мөһим роль уйнаучы архитектур декорга җыйнак-тыгыз композиция хас булуында күрә.

Идел буе болгарларының декоратив сәнгате принциплары, Г. Вәлиева-Сөләйманова документаль-декоратив сәнгать җирлегендә ышандырырлык итеп раслаганча, татар сәнгатенең яңа төрләрен формалаштыруда, тотрыклы иҗат традицияләре барлыкка китерүдә нигез булып хезмәт итәләр. Монументаль-декоратив сәнгатьнең ташта, гипста уеп ясала торган төрләре (шул исәптән коелмалар һәм штамповкалар) һ. б. үрнәкләр Казан ханлыгы чоры архитектурасында, бигрәк тә орнаментациядә, архитектур-декоратив (фронтон уемнары һ. б.), төсле (полихромия) композицияләрдә — XVI гасырдан соңгы халык төзелеш сәнгатендә киң үстерелеш таба.

Китапта XVIII гасыр уртасыннан соң төзелгән шәһәр архитектурасы декоры үзенчәлекләренә дә игътибар юнәлдерелә. Билгеле булганча, әлеге чорга караган декорга шул замандагы рус архитектурасына хас стильләр — классицизм, барокко һәм соңрак эклектика (Мәрҗани, Апанай, Әҗем мәчетләре һ. б.) йогынтысы сизелә. Һәм, автор әйткәнчә, XIX гасыр ахырына биналарның гомуми архитектур йөзе һәм аларның декорлары милли үзенчәлекләрен сизелерлек дәрәҗәдә югалталар. Шул ук вакытта бу гасыр башында милли профессиональ сәнгать туу өчен мөмкинлекләр ачыла. Хезмәтнең алдагы бүлекләрендә нәкъ менә шушы чор яктыртыла.

Татарстан монументаль-декоратив сәнгатенең 1917 елдан алып 50 нче елларга кадәрге үсешен анализлаганда, автор тарафыннан моңарчы билгеле булмаган яңа материал — республикадагы монументаль пропаганданың ленинчыл планын тормышка ашыру чараларына бәйле архив документлары, шәһәр йөзен чагылдырган фоторәсемнәр китерелә. Әлеге бүлектә Казан рәссамнарының (В. Богатырев, Ф. Гаврилов, К. Чеботарев, Ф. Таһиров һ. б.) яңа революцион тематиканы үзләштерү, архитектурада мөстәкыйль сурәтләү стиле булдыру юнәлешендәге иҗади эзләнүләре күзаллана, монументаль-декоратив сәнгать формаларының беренче үсеш тенденциясен билгеләүдә революцион графиканың мөһим роль уйнавы ассызыклап әйтелә. Яшь галимнең егерменче еллар монументаль сәнгатен өйрәнү буенча әһәмиятле эш башкаруы совет сәнгате тарихын өйрәнүче танылган белгеч В. Толстойның «Совет монументаль сәнгатенә нигез салганда» исемле китабында уңай яктан билгеләп үтелә. Сәнгатьчә яңа чишелешләр эзләүне, чыннан да, яңа милли формалар та-

бу юнәлешендәге башлангычлар белән бәйләп карарга кирәк. Мәсәлән, А. Платунова «агитка»ларында татар орнаментлары, гарәп хәрефләре һәм башка традицион формаларның декоратив үзенчәлекләрен куллану, скульптор В. Богатыревның революционер М. Вахитовны гәүдәләндергән эшендә милли архитектура формаларын файдалану дөрес һәм табигый юл буларак аңлатыла. Китапның әлеге бүлегендә, архитекторлар И. Гайнетдинов, Р. Мортазин, И. Вәлиев һ. б.ларның эшләренә нигезләнеп, 1930—1950 еллар милли архитектурада декоры стилистикасына җентекле анализ ясала, аерым алганда, рәссам Ч. Әхмәровның стена бизәкләре цикллары, беренче татар скульпторы С. Ахунның монументаль-декоратив әсәрләренә тукталып үтелә. Ул чордагы җәмәгатьчелек биналарын декоратив бизәүдә өлешчә үткән гасырлар сәнгатеннән әзер элементларны күчереп куе хас, һәм әлеге күренештә Г. Вәлиева-Сөләйманова хаклы рәвештә чикләнгәнлек күрә, традицияләрне киңрәк мәгънәдә аңларга чакыра.

«Совет Татарстанының монументаль-декоратив сәнгате» китабының өченче бүлеге 60—70 еллар халык художество традицияләре үсешенә багышлана, һәм шулай ук анда бүгенге заманның үзенчәлекле гомуми проблемасы — сәнгатьләр синтезы мәсьәләләренә дә игътибар юнәлтелә. Әлеге бүлектә алты төркемгә аерылган материал да бирелә: стена бизәге, мозаика, гипсны һәм агачны уеп-сырлау, художестволы металл, тукылган панно (гобелен). Төп стилистик юнәлешләрне, үсеш тенденцияләрен гомумиләштереп, автор бер яктан, хәзерге заман сәнгатенең халык традицияләре белән уртак билгеләрен ача, икенче яктан, аларны аерым бер әсәр структурасында файдалану алымнарын күрсәтә һәм шулай итеп билгеле бер сәнгать төре җирлегендә сурәтләү чаралары эволюциясен күзәтүгә ирешә. Традицион сурәтләү чаралары аерым бер художник-монументалист иҗаты җирлегендә ничек үзләштерелә? Галим әлеге сорауга конкрет мисалларга таянып җавап бирә һәм, шул рәвешле, укучыга җирле сәнгать үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итә. Ул татар халык орнаментын, традицион төзелеш композицияләрен куллану алымнарын күздән кичерә, интерьер үрнәкләренең эмоциональлеген арттырырга, бертөрлелектән качарга ярдәм итүче образлардагы фольклор белән бәйләнешнең (фольклор темаларын, сюжетларын һәм символикасын куллануның) әһәмиятен күрсәтә.

Шуны аерым билгеләп үтәсе килә: китапта күтәрелгән проблематика бик актуаль. Чыннан да, монументаль-декоратив сәнгать өлкәсендә эшләүче осталарыбызның иҗат принциплары, аларның архитекторлар һәм проектчылар белән хезмәттәшлеге зур игътибарга лаек. Бу җәһәттән китапта автор концепциясе дөрес булып күзаллана, һәм ул фәнни яктан ышандырырлык итеп нигезләнгән.

Китапның аерым җитешсезлекләре нигездә текст өстәмәләрендә күренә. Җәмәгатьчелек бинналары интерьерлары үзенчәлекләре киңрәк ачылса, авыл корылмалары интерьерына мөнәсәбәттә параллельләр күбрәк үткәрелсә, тәҗрибәсезрәк рәссамнарның әсәрләре таләпчәнрәк бәяләнсә һәм шул ук вакытта танылган осталар иҗатының кыйммәтле сыйфатлары калкурак ачылса, хезмәтнең максатка ирешүчәнлеге һәм әһәмияте тагын да югарырак булыр иде шикелле.

Соңгы сүз итеп әйткәндә, Г. Вәлиева-Сөләйманованың әлеге китабында Татарстан сәнгатенең милли үзенчәлек нигезләре тулы ачылган. Профессиональ рәвештә анализланган материал күпмилләтле совет сәнгать белеменә кыйммәтле өлеш булып керерлек кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәт художник-монументалист, бизәүче һәм архитекторларга да ышанычлы таяныч булыр.

**Мурсал НАДЖАФОВ,**
Әзербайҗанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре докторы, профессор.
Баку шәһәре.

# ТЫНГЫСЫЗ РУХЛЫ КИТАП

Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинның яңа китабы дөнья күрде. Ул «Талантлар юлы»[1] дип атала. Бу китапның автор өчен исталекле һәм әһәмиятле ягы — аның чирек гасыр дәвам иткән тәнкыйть эшчәнлеген гомумиләштереп, үзенә күрә бер йомгак ясап, түгәрәкләп куюында. Китапның эчтәлеге дә шушы максатка җайлашкан: ул авторның төрле елларда күптөрле мәсьәләләр уңае белән һәм төрле темаларга язган унҗиде мәкаләсен эченә ала.

Тәнкыйтьче — ул шулай ук иҗат кешесе. Бер дә юкка гына әдәби тәнкыйтьне матур әдәбиятның табигый бер тармагы дип санамыйлар. Тәнкыйтьченең әдәби процесста башкарган гаять тә җитди вазифасы аның эшчәнлеген дә барлап карауны.

[1] Фәрваз Миңнуллин. Талантлар юлы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.

үсеш юлына күз салуны сорый. Шуңа күрә дә табигый рәвештә аерым бер проблемага багышланган китаплар белән бергә тәнкыйтьченең иҗатын гомумиләштереп күз алдына бастыра торган җыентыклар басыла тора.

Китаптагы мәкаләләрне укып чыккач, Фәрваз Миңнуллинның үзе сайлаган авыр өлкәдә — әдәби тәнкыйть өлкәсендә озак еллар дәвамында ихлас күңелдән бирелеп хезмәт итүен, төпле белемгә, ачык карашка, төгәл зәвыкка, мөстәкыйль принципиаль фикергә ия булуын, тәнкыйтьче буларак профессиональ осталыгы үсүен ачык күрәсең.

Ф. Миңнуллинның тәнкыйть мәкаләләре алтмышынчы елларда күренә башлады. Аның әдәби тәнкыйтьтәге беренче адымы ук Г. Нигъмәти исеме белән бәйле: 1960 елны ул тәнкыйтьче-галимнең нәшриятта басылып чыккан сайланма әсәрләренә рецензия яза. «Әдәбиятыбызның күренекле галиме» исемле әлеге мәкаләсендә үк яшь авторның үзе яза торган материалын ныклап өйрәнүе, Г. Нигъмәтинең хәзерге укучыларга аз таныш булган бай иҗатын киңлеге белән иңләп алырга омтылуы, иҗатын 20—30 елларның эстетик фикер атмосферасы белән тыгыз бәйләнештә каравы, тәнкыйтьченең уңышларын күрсәтә алу, йомшак якларын исә шул чорның эстетик фикер дәрәҗәсе белән аңлатуы, гомумән, аны олы талант иясе итеп каравы ачык күренде.

Яшь тәнкыйтьченең бу күзәтүләре әле дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар. Ф. Миңнуллин тәнкыйтьченең үсешен дә күрә, йомшаклыкларыннан арына баруын күзәтеп, аны дәлилле итеп аңлата.

Тәнкыйть һәм әдәби тәнкыйть тарихы өлкәсендәге беренче адымнарыннан соң, Ф. Миңнуллин игътибарын хәрәкәттәге әдәби процесска юнәлтә, бигрәк тә проза тармагы аның күңеленә ныграк хуш килә. Моңа аның аспирантурада укуы, өйрәнү объекты итеп татар совет повестен алуы нык йогынты ясый. Әдәби процессның үзендә актив катнашу, әдәбият дөньясының үзәгендә кайнау (Ф. Миңнуллин күп еллар дәвамында «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеген җитәкләде, Татарстан Язучылар союзы председателенең урынбасары булып эшләде) тәнкыйтьченең заман тойгысын тагын да үткенәйтә, әдәбиятның өлгергән мәсьәләләрен күреп алырга һәм аларга җәмәгатьчелекнең игътибарын тупларга ярдәм итә. Тәнкыйтьченең активлыгы мәсьәләсе генә җәмгатьчелекне бераз сәерсендереп куя: белеме дә бар, фикере дә бар, яза да белә, әмма нигәдер мәкаләләре сирәгрәк күренә. Ф. Миңнуллинның характеры шундый: үзен тәнкыйтьче буларак күрсәтергә дә, кайберәүләр кебек кыбырсып алгы планга чыгарга да, күп язуы белән шаккатырырга да омтылмый. Ул кабаланмыйча гына яши, фикерен җитди уйланганнан соң, бернichә кат үлчәгәннән соң, мәсьәләнең төбенә төшкәннән соң гына әйтергә ярата. Шуңа да аның бәяләре төпле, нигезле булып яңгырый.

Җыентыкның әһәмияте тәнкыйтьченең күп еллык эшчәнлеген гомумиләштерү белән генә чикләнми. Ул — хәзерге әдәби процессның байтак әһәмиятле мәсьәләләрен күтәрүе, әдәбияттагы затсызлыкка, урталыкка каршы көрәшеп, язучыларның һәм укучыларның эстетик фикерләренә актив йогынты ясарга омтылуы белән дә игътибарга лаек.

Матбугатта еш кына: «Тәнкыйтьче язучы өченме, укучы өченме иҗат итә?» — диган схоластик бәхәсләр кузгалып куя. Тәнкыйтьнең язучыны күздә тотып язылганы да, укучыга адресланганнары да була. Бу — мәгълүм нәрсә. Шул ук вакытта тәнкыйтьченең язучыны һәм укучыны бердәй күздә тотып иҗат иткән мәкаләләре дә языла. Хәзерге әдәби процессның үсеш тенденцияләрен ачыкларга, иҗат кешесенең яки әдәби әсәрнең катлаулы серләрен ачарга багышланган мәкаләләрне мин шундый типтагы хезмәтләргә кертеп карыйм.

«Талантлар юлы» җыентыгында укучыга язучы яки тәнкыйтьче турында информация бирүне, язучының иҗатын юбилей уңаеннан бәяләп узуны, аның аерым әсәрләрен аңлатуны, аерым китапларын укучыга тәкъдим итүне күздә тотып язылганнары да бар. Андый пландагы мәкаләләрнең, рецензияләрнең кирәклеген инкарь итмәстән, мин бу юлы тәнкыйтьченең икенче типтагы — язучының һәм укучының эстетик фикренә йогынты ясау рухында, хәзерге әдәби процессны тикшерү, язучы турында уйлану юнәлешендә иҗат ителгәннәренә игътибар юнәлтмәкче булам. Төрле елларда иҗат ителгән мәкаләләрне бер тирәгә тәнкыйтьченең әдәбиятка әнә шундый актив мөнәсәбәте, әдәбият язмышы турында борчылып уйланулары туплый, аларны язучы өчен дә, укучы өчен дә бердәй кызыклы итә.

Тәнкыйтьчене әдәби тормышның нindирәк мәсьәләләре борчый соң? Күп алар. Үзе дә әдәби процессның үзәгендә кайнаганга оештыручы вазифасын практик яктан башкарып килгәнгә, Фәрваз Миңнуллин игътибарын әдәбият үсешенең бик тә җитди, өлгергән, актуаль һәм әһәмиятле мәсьәләләренә юнәлтә. Аларның барысын бергә җыйнап, гомумләштереп: «Заман темасы һәм аны язучының югары сыйфатлы итеп сурәтләве» дип атарга мөмкин булыр иде. «Әдәбият һәм үгет-нәсихәт» (1970) исемле мәкаләсендә, мәсәлән, ул җитмешенче елларда балалар өчен язылган йөзгә якын хикәя белән танышып чыга һәм аларны анализлап, «бүгенге балалар прозасының йөзен урта кул хикәяләр билгели», — диган фикергә килә. Шуңа күрә ул игътибарын, мактаудан биг-

рәк, кимчелекле якларга, балалар әдәбияты алдында торган бурычларга юнәлтә, үзен борчыган фикерләре белән уртаклаша. Тәнкыйтьчене балалар прозасын зәвыксыз әсәрләр, арзанлы акыл сатуга корылган, кызыксыз язылган, дулкынландырмый торган хикәяләрнең басып китүе, алар арасында И. Газиның «Ак сирень», «Сиртмә койрык» кебек затлы хикәяләре сирәк очравы борчый. Авторның ясаган нәтиҗәсе хәзер дә уйландыра: «Балалар өчен язылган хикәяләргә куела торган төп шарт шундый: алар укылырлык, мавыктырырлык булсыннар!.." Бала булып кыланy гына җитми. Бездә исә нәниләр тормышыннан нигездә олылар өчен генә кызык тоелырдай якларны сайлап язылган әсәрләр күбәеп бара. Хикәяләрдә чын бала образлары белән аз-рак очрашабыз. Алардан бигрәк, бала булып кыланучы, ләкин балаларның гадәтхолыкларын, психологиясен өстән-өстән генә белгән авторлар үзләре өстенлек итә» (47 б.).

Прозага кагылышлы бер өлкә дә автор игътибарыннан читтә калмый. Кайберләрен ул киңрәк итеп ала, алар турында төплерәк тикшеренүләр алып бара. Әйтик, повесть жанрындагы үзгәрешләрне ул аеруча тәфсилле күзәтә. Кайберләренә исә андый ук җентекләп тукталмаса да, мәсьәләне мөгезеннән тотып күтәрә: язучыларның да, укучыларның да игътибарларын әнә шул мәсьәләләргә юнәлтә. Бер мәкаләсе турыдан-туры «Романга ни булды» дип атала. Татар әдәбиятында роман жанры чыннан да тигез үсми, сугыштан соңгы чорда бер күтәрелеп ала да, алтмышынчы елларның ахырларына, җитмешенче елларга таба тыныбрак кала. Сан ягы зарланырлык түгел икән — күп язалар романны. Әмма сыйфат ягы, аның камиллеге күп калыша, мавыгып укырлык романнар иҗат ителми.

Ф. Миңнуллин бөтенесен дә кара буяуга буямый. Ул Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» кебек сәнгатьчә затлы итеп эшләнгәннәрен дә күрсәтеп уза. Хәзерге иҗат ителгән романнарда тормышчан һәм ышандырырлык итеп сурәтләнгән аерым күренешләрнең, образларның булуын да әйтә. Әмма зуррак таләпләр куя автор. Бу мәсьәләне бөтен әдәбият үсеше күләмендә алып карый. Ә шулай караганда күп романнар кечерәеп, вакланып кала. «Пешүе җитмәгән аш» белән чагыштыра тәнкыйтьче андый әсәрләрне. Төрлесендә төрле кимчелек: берсе романдагы барлык геройларны һәм вакыйгаларны бергә тупларлык төп идеяне ачыклап бетермәгән: икенчесе көнкүреш материалын «дыңгычлап» тутырган, өченчесенә дәрт һәм кайнарлык җитми, дүртенчесенең укучыга әйтер сүзе юк, бишенчесен укып булмый — авыр тел белән язылган.

Тәнкыйтьче роман өлкәсендәге авыру күренешләрне ачык күрсәтеп кенә калмый, аларны ничек дәвалау, ул кимчелекләрдән ничек котылу турында да фикер йөртә. Автор дөрес язганча, сүз әсәрләрнең сыйфаты турында барса да, бу әдәби технология мәсьәләсе генә түгел. Ул әдип карашының киңлеге һәм тирәнлеге, үзенә хас концепциянең булуы, масштаблы итеп фикерли алуы белән бәйле. Тәнкыйтьче үткәндәге бай тәҗрибәне ныклабрак үзләштерү, күп милләтле совет әдәбиятының казанышларын өйрәнү һәм файдалану турында сүз алып бара.

Ф. Миңнуллинны роман һәм повесть кебек күләмле жанрлар гына түгел, хикәя кебек кечә формалы жанрларның торышы да кызыксындыра. «Хикәя һәм хикәячеләр» (1983) мәкаләсе нәкъ әнә шундый тынгысыз борчылу рухы белән сугарылган тәнкыйть мәкаләләренең үрнәге була ала. Автор хикәя жанрының үсешен күзәтеп, илленче елларның урталарыннан хикәя «туфрагы ашланмаган гөл кебек сүрелә һәм саргая, шиңә башлый», «бер урында таптана, бер югарылыкта кала бирә» дигән фикергә килә. Хикәяләр аз түгел икән, әйбәт хикәяләр аз! Автор сирәк булса да тәҗрибәле әдипләр тарафыннан уңышлы хикәяләр язылуын да, Ф. Яруллин, Ф. Шәфигуллиннарның юмористик-сатирик хикәя төрләрен җанландыруларын да, М. Галиев, Ә. Гаффар, Н. Гыйматдинова, К. Кәримов кебек яшьләрнең хикәягә тартылуларын, уңышлы гына әсәрләре белән күренүләрен дә уңай тенденция буларак билгеләп үтә. Шул ук вакытта ул хикәяне бер урында таптануга китергән кимчелекле якларны ачуга да игътибарын киметми. Әдәбиятның сугышчан һәм оператив, шул ук вакытта кыен һәм авыр жанры саналган хикәянең хәзер сугышчанлыгын киметүен, әдәби яктан төссезләнүен тәнкыйтьче конкрет мисалларда күрсәтә: «Безнең хикәячеләр матбугатка язарга уйлаган, язарга җыенган әсәрләренең киңайтелгән проспектын, планын гына бастырып чыгаралар. Аерым хикәячеләргә язучы буларак өлгергәнлек, фикер тирәнлеге, чын мәгънәсендә гражданин булу җитми. Алар вак мәсьәләләрдән зур фәлсәфә чыгарырга азапланалар, я булмаса зур мәсьәләләрне ваклап, кечерәйтеп ташлыйлар...», «...безнең хикәяләрдә охшаш эпизодлар, кабатланган ситуацияләр очрый»... (54 б.) Мондый конкрет анализ, жанр торгынлыгының сәбәпләрен төрле яктан ачу, әлбәттә, хикәянең үсүенә уңай тәэсир ясаячак.

Фәрваз Миңнуллин хәзерге татар романы яки хикәясе турында күзәтү ясыймы, татар совет прозасының илле еллык тарихи үсеш юлын гомумиләштерәме, М. Әмир, Ә. Еники, Х. Туфан, Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев, Ә. Баянов, М. Маликова, М. Рафиков, Р. Мостафин кебек әдипләрнең иҗат портретын күз алдына бастырамы — ул үзенең һәм укучыларның игъ-

тибарын әдәбият өчен бик тә әһәмиятле мәсьәләгә — талант төшенчәсенә юнәлтә. Җыентыкның исеме дә «Талантлар юлы» дип очраклы рәвештә генә сайланмаган. Тәнкыйтьче фикеренчә, әдәбиятны талантлар тудыра. Шуңа да ул язучы иҗатын тикшерүгә, аның үзенчәлекләрен ачуга, язучы турында фикер әйтүгә җитдилек һәм җаваплылык белән якын килә, әдипнең әсәрләрен саклык һәм илтифат белән тикшерә, тәнкыйть фикерен язучының күңелен рәнҗетмичә әйтергә омтыла.

Талант төшенчәсен Ф. Миңнуллин әдәбиятның техникасын үзләштерүгә яки әдәби осталыкка кагылышлы тар юнәлештә генә карамый. Ул аны шәхескә табигый тумыштан бирелгән сәләт рәвешендә, әмма халык байлыгы итеп күз алдына китерә. Бу кыйммәтле хасиятне тәнкыйтьче иҗат кешесенең иле, халкы, заманы алдындагы җаваплылыгын тоюы белән тыгыз бәйләнештә карый. Шушы фикергә нигезләнеп, ул, мәсәлән, тырышлык белән генә балалар язучысы булып булмый, аның өчен балалар язучысы булып туарга кирәк дигән фикерне хуплый.

Хикәя турындагы мәкаләсе дә сүзне талантка китереп бәйләү белән тәмамлана: «Инде килеп, безгә тагын бер хакыйкатьне аңларга вакыт: хикәя — әдәбиятның иң кыен, иң авыр жанры. Хикәя жанрына әдәбиятыбызның иң талантлы көчләре алынсын иде. Шул чагында гына әйбәт хикәяләр артачак, шунда гына хикәя жанры чын-чынлап алга китәчәк» (62 б.).

Талантның төп көчен ул иҗат кешесенең кешене, тормышны ни рәвешле ярата алуында күрә. Бер мәкаләсенең исеме үк «Ярату» дип атала. Биредә ул матур әдәбиятның тәрбияви йогынтысы һәм тәэсир көче беренче чиратта, язучының тормышка, кешеләргә булган мөнәсәбәте белән билгеләнүе турында да сүз алып бара. «Татар әдәбияты тарихыннан китерелгән күп мисалларга нигезләнеп, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, һ. Такташ, М. Җәлил, С. Хәким әсәрләренә таянып, әдәбиятның нигезендә кешене ярату хисе ятуын аңлата. «Күренекле талант ияләре»,— дип фикер йөртә тәнкыйтьче,— әсәр язуның тегe яки бу алымнарын, әдәби техниканы гына үзләштермәгәннәр, гади хезмәт кешесенә, кеше хисләренә хөрмәт, мәхәббәт белән карарга да өйрәнгәннәр. Аны тагы да үстергәннәр — туган илгә мәхәббәт хисе белән баетканнар» (74 б.). Бик тә гыйбрәтле сүзләр Хәсән Туфанга багышланган. «Җыр йөрәктә туа» мәкаләсендә ул халыкны, илне, кешеләрне ярату хисенең ни рәвешле шагыйрьне югары күтәрүен, талантны билгеләүче олы хасият булып әверелүен тикшерә. Ул сүзне шагыйрьнең «Кер чайкыйлар кызлар» исемле шигыреннән башлый да, кешене ярату фикерен аның бөтен иҗаты киңлегендә карый. «Елларны яхшыртасы килү, җирне агартырга теләү — Туфан поэзиясенең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла барган төп мотив...— дип яза тәнкыйтьче.— Шигырьләрендә ил язмышы да, үз язмышы да. Алар бик тә охшашлар. Туфан поэзиясе — ифрат дәрәҗәдә ихлас поэзия. Шигырь язу — аның һөнәре генә түгел, яшәү һәм көрәш рәвеше дә, табигый халәте дә (129 б.). Шушы ук фикерен — язучы кешене ихлас яратырга тиеш,— дигән карашын Фәрваз Миңнуллин Рафаэль Төхфәтуллинның хикәяләрен һәм повестьларын җентекләп тикшергән. «Ир язмышы — ил язмышы» мәкаләсендә дә, Әмирхан Еникинең прозаик әсәрләрен үзәккә куйган «Намус эше» мәкаләсендә дә, Әхсән Баянов повестьларын тикшерүгә багышланган «Шагыйрьнең прозасы» мәкаләсендә дә ныклап уткәрә, тормышка һәм әдәбиятка бәйле күп мәсьәләләрне шушы яссылыкта карый.

Тәнкыйтьченең осталыгы язучыдагы әлеге изге хисне — тормышны, кешеләрне матуррак итү белән януны әдәби анализда калку итеп, алгы планга чыгарып күрсәтүендә генә дә түгел. Фәрваз Миңнуллин талант дәрәҗәсен билгеләүче бу хасиятнең һәр язучыда үзенчәлекле рәвештә ачылуына да игътибарын юнәлтә һәм әдипләрнең сурәтле фикерләүләрендәге аермалыкларны оста итеп анализлап күрсәтә. Тәнкыйтьче М. Әмир, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев кебек әдипләрнең үзләренә хас талант стихияләрен аеруча дәлилле һәм конкрет итеп күрсәтүгә ирешкән.

Озак вакытлар дәвамында тәнкыйтьтә Әхсән Баяновның прозасы бәхәсләр кузгатып, төрле фикерләр уятып килде. Ф. Миңнуллин «Шагыйрьнең прозасы» (1983) мәкаләсендә беренче буларак шагыйрьнең прозасына тәпле анализ ясады, аның талант үзенчәлекләрен ачыклап, язучыны сәнгатьче катлаулылыгында ачып бирде. Шуның белән ул Ә. Баянов иҗатын бәяләүдә һәртөрле аңлашылмаучылыкка чик куйды.

Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинның «Талантлар юлы» җыентыгындагы аерым бәяләр, фикерләр белән килешмәскә дә, бәхәсләшергә дә мөмкиндер. Тезис рәвешендә генә әйтелеп калган, дәлилләүне сорый торган фикерләр дә очрый торгандыр. Әмма шунысы бәхәссез, бу җыентык язучыны да, укучыны да ваемсыз калдырмый. Бүгенге тормыш һәм әдәбият турында уйландыра, хәзерге татар әдәбиятын, аның үсеш тенденцияләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә, язучыларның уңышлары өчен сөендерә, кимчелекләре өчен көендерә. «Талантлар юлы»— уйлы, хисле, тынгысыз рухлы китап. Ул тәнкыйтьнең хәзерге әдәби процесста актив катнашып, эстетик фикерләүгә сизелерлек йогынты ясарга омтылуы турында сөйли.

**Нил ЮЗИЕВ.**

## Дамир Гыйсметдинов

# ОЯТ ТҮГЕЛМЕ?



Автобаза директоры Хәмзин галстугын бушатты да дулкынланган тавыш белән:

— Иптәшләр, көн тәртибендә әлеге дә баягы слесарь Сабиржанов мәсьәләсе,— диде.— Кабат айныткычка эләккән, мертәт!

Озын өстәл артында утырган механик Гайфетдин һәм профком председателе Имамгали бердәм баш чайкадылар.

— Бүгенге утырышта, ниһаять, ул җүнсезнең үзен күреп сөйләшә алабыз. Рәхмәт Имамгалигә.— Директор өстәл артында утырган алагаем борынлы берәүгә ымлап күрсәтте.— Тәки эзләп тапкан бит. Алай гына да түгел — җитәкләп алып килгән. Маладис!.. Керегез, Сабиржанов.

Ишектә битләре шешенгән кара чәчле бер адәм күренде.

— Тә-әк,— диде Хәмзин керүчене баштанаяк үлчәп,— утырыгыз. Елдам егет икәнсез, Сабиржанов. Алты ай эчендә алты тапкыр айныткычта булырга өлгергәнсез...

— Әйе,— дип баш какты слесарь.

— Сезгә бер дә оят түгелме?

— Оят...— диде Сабиржанов тирән сулап.— Тәмәке тартырга ярыймы?

Директор кесәсендәге сигарет кабын изгәләп:

— Ничек, иптәшләр, рөхсәт итәбезме?— дип сорады.

— Тартсын, тартсын, рөхсәт!— дип шаулашты кабинеттагылар.

Сабиржанов артлы урындыкка иркенләбрәк утырып, «Астра» көйрәтеп җибәрде.

— Я, башлагыз,— дип каударланды директор.

— Нәрсәне?— дип гаҗәпләнгән булды Сабиржанов.

— Нәрсәне, нәрсәне? Сөйләгез. Ничек бу хәлгә барып җиттегез?

— Ә-ә,— дип көрсенде Сабиржанов, өстәлдәге графиннан күзен алмыйча.— Су эчәргә ярыймы, иптәшләр? Авыз кипкән. Тел аңкауга ябышкан.

Хәмзин графинны Сабиржановка таба этәрде. Слесарь иплап кенә бер стакан суны әйләндереп салды. Йөзе хәмер эчкәндәге сыман сытылып китте. Җиңел сулап куйды.

— Рәхмәт, иптәшләр...

— Я, я,— дип янә түземсезләнде директор.— Менә иптәшләр алдында әйтеп бирегез әле. Ничек мондый хәлгә төштегез?

— Ә-ә,— дип тирән сулады Сабиржанов.— Мин бит ни... егетләр, гафу... иптәшләр. Сүзгә мачтырлык юк бит, каһәр! Кичерегез инде, мөмкин булса... Ничек бу хәлгә төштемме? Мин аны ни... Менә болай күрсәтеп бирәләм.— Сабиржанов сорап-нитеп тормыйча, графиннан тагын бер стаканны аударды.— Менә шулай, иптәш директор, күтәрәсең дә саласың. Калганы милиция пыртакулында язылган.

Директор, графинны үзенә таба тартып куеп:

— Карагыз әле, Сабиржанов, монда сәхнә түгел, кәмит ясамасагыз да ярый!— дип кырт кисте.— Су эчеп тә исерәсез, панимаеш.

Сабиржанов акланырга дип авызын гына ачкан иде, аны механик Гайфетдин бүлдерде.

— Син, агай-эне, туктап тор әле,— диде ул графинга үрелеп.— Авыз кипкән. Мөмкинме, иптәш директор?

Директор җәһәт кенә стаканны тотырып куйды.
Механик кырлы савытны түнтәргәч, дусларча елмаеп:
— Болай үзе әйбәт кеше ул Сабирҗанов,— диде.— Эчте исә — әүлия. Эчмәгән чакта гына көйсезрәк кылана. Минемчә, аңа салган килеш урам буенча маҗара эзләп йөрмәскә генә кирәк. Шым гына җәмәгате янына кайтырга да китәргә. Аңладыңмы, хәчтерүш?
— Әһе,— дип баш какты Сабирҗанов.—Р-рәхмәт яхшы сүзеңә...
Профком председателе дә бу олы тәрбия дәресендә катнашмый булдыра алмады.
— Иптәшләр,— диде ул.— Мин дә бер ике сүз әйтим әле.
Директор графинны Имамгалигә таба этәрде. Стаканны әйләндереп салгач, профсоюз башлыгы җиңел генә тезеп китте:
— Сабирҗановны күп еллар беләм. Кулыннан эш килә. Башы түгәрәк. Эчсә — җен кебек эшли. Җырлап кына яшәрлек егет ул үзе...
Шулчак сәер кызарынып-бүртенеп утырган Сабирҗанов:

— Имам абый, син үзең
Кашыңдин кара күзең...—

дип сузып җибәрде.
Гаҗәпләнгән Хәмзин карандашы белән өстәлгә каккалап:
— Я-я!— дип тәртипкә чакырды.— Сез кайда утырганыгызны онытып җибәрмәгез!.. Иптәшләр, нинди тәкъдимнәр бар?
— Графиндагыны салып бетерергә...— дип мыгырданды Сабирҗанов.
— Житте, җитте. Сез барыгыз, кайтып китегез!— дип боерды директор.
Слесарь алпан-тилпән атлап бүлмәдән чыгып китте. Хәмзин өстәл артында утыручыларга сораулы караш ташлады. Берсе дә сүз дәшәргә ашыкмагач, графиннан үзенә су салды. Стаканны авызына якын китерде дә кире өстәлгә куйды һәм ачуланып:
— Кайсыгызның графинга хәмер салырга башына килде?— дип кычкырды.
Имамгали кызарып китте.
— «Сабирҗановны теләсә ничек алып кил»,— дигәч, мин ниткән идем,— диде ул моңсу гына.— Андый җүнсезне болай гына китереп булмый бит... «Килсәң — бер литр куям. Өстәлдәге графинда булыр»,— дигән идем, йөгереп килгән инә...
— Анысына башың житкән,— дип көлемсерәде директор.— Ә менә закуска турында уйламагансың, панимаеш.
— Бар бит, бар!— дип Имамгали куеныннан зур гына бер кыяр тартып чыгарды.— Анысын да юнәткән идем, өстәлгә куярга гына оныткანмын...
— Маладис, Имамгали! Башың түгәрәк икән!— диде директор һәм графинга үрелде.

# ТОРМЫШ ЮЛЫ

Иртән торуга, кесә төбендә сукыр бер тиен дә тапмагач, Шәмәрдәнов яшәүнең мәгънәсе турында тирән фәлсәфи уйларга чумды.
— Гомер уза, Шәмәрдән дус,— дип мөрәҗәгать итте ул үз-үзенә.— Яшең, мин сиңайтим, кырыкка җитте, тик менә нәсел-нәсәбеңә бу дөньяда ни нәмәрсә калдырасың? Хет язып карасаң икән берәр хатирәме шунда, гыйбрәтле истәлекме. Әйтәләр бит әле, һәр адәмнең тормышы — үзе бер хикәят, дип. Менә каләм сиңа, менә кәгазь. Утыр да яза башла!
Шәмәрдән өстәл янына барып утырды да уйга талды. Башы чатнап авырта иде. Әллә акыл хезмәтеннән, әллә кичәге тамашадан — бер ходай белә.
«Тә-әк, нәрсәдән башлап китәргә соң әле?— дип газапланды ул.— Әйтик, хак тәгалә кушуы буенча дөньяга килдең. Балачак... Хәтереңдәдер, күбәләкләр куып йөрдең... Үсә төшкәч, тагын күбәләкләр. Бар иде бер шундый чаясы... Хәзер дә әле күбәләк сыман гына түгел, кигәвен кебек артыңнан калмый йөдәтә, алиментә кәгазе җибәреп ята. Ә аннары? Кирәк бит, әй, һичнәрсә хәтергә төшми. Гомереӊ буе йөгердең дә чаптың... Йөгерү дигәннән, вакыты җитеп килә икән ләбаса! Йөгерергә инде, йөгерергә!
Шәмәрдән каләмен ыргытып бәрде дә ашыга-кабалана ишеккә юнәлде. Берничә минуттан ул инде сыраханәнең түгәрәк таш өстәле янында иш-кушлары белән гөрләшә иде.

— Р-р-рәхмәт яусын баш түбәгезгә, егетләр, хәлемә кердегез, коткардыгыз. Онытасым юк үлгәндә дә, гүр-ләргә кергәндә дә... Соң исемнәрегез ничек әле сезнең, егет асыллары?

— Син, картлач, һаман шаяртасың,— дип көлде егетләр һәм Шәмәрданнең кружкасына тагын бераз тамыздылар.— Я, әйдә, бездән булсын изгелек! Синең язылачак романың хөрмәтенә!

— Рәхмәт егетләр, ә... ә сез кайдан беләсез?..

— Кичә үзең өзми-куймый сайрадың ич... Я, күтәр, каләм әһле. Әсәреңә безне дә кыстырырга онытма.

— Бармый бит әле дусларым, бар-рмый. Илһам килми,— дип үксеп җибәрде Шәмәрдән.— Төзелешкә китәрмен ахрысы...

Икенче көнне уянганда ул башының ярылырдай булып авыртканын тойды. Күз алдында аллы-гөлле чаткы-йолдызлар уйный иде.

— Житте, тор, Җәлмәнов!— дип дәште аңа кемдер кырыс тавыш белән.

Ул, йодрыгы белән күзләрен уа-уа урыныннан торып утырды. Каршысында, алагаем калын капка тотып, милиционер басып тора иде.

— Шул-лай, тагын башбаштаклык,— диде ул папкадагы кәгазьләрен актарып.— Сыра будкасын этеп кыйшайткансың, тешең белән чәйнәп су шлангасын өзгәнсең, сәүдә эшенә аяк чалгансың. Котлыйм! Синең данлыклы биографияңә, димәк, тагын бер бизәк. Хәер, андый бизәкләрең монда ике романга житешле!— Милиционер папканы япты да, аның авырлыгын чамалагандай, кулларында селкеткәләп алды.

— Гражданин... иптәш милиционер!— дип ыңгырашты Шәмәрдән кулларын алга сузып.— Зинһар бирегез сез миңа ул папканы. Тик бер генә тәүлеккә. Бер генә кичкә! Күчереп кенә алыймчы, анда... анда бит минем бөтен аңлы тормыш юлым теркәлгән!..

## Җәгъфәр Токумаев,

балкар язучысы

## Кем алдакчы?

Хужа Насретдин буфетчы булып эшли икән. Бер көнне иртә белән, сәүдәсен башлап җибәрүгә, аның янына дүрт егет килеп керә.

— Кадерле Хужа,— ди болар,— без бик ашыгабыз, бер шешә коньяк кына биреп җибәр әле. Бүләккә алып барасы иде.

— Сәгать унбергә кадәр спиртлы эчемлекләр сатырга хакым юк,— дип кырт кисә Хужа.

— Ничек инде алай? — дип өзгәләнә егетләр.— Шәфкатьле кеше икәнлегең йөзеңнән үк күренеп тора. Нәкъ бер сәгатьтән самолетыбыз очып китәчәк, зинһар, ярдәм ит инде. Тау белән тау гына очрашмый...

— Самолетыгыз кайчан оча дисез әле? — дип сорый Хужа.

— Бер сәгатьтән!

— Сәфәр чыгасы булгач, ярар инде алайса, кагыйдәне бозарга туры килә.— Хужа астан гына шешәне ала да, кәгазьгә төреп, ялынучыларга суза.— Тик карагыз аны, мине уңайсыз хәлгә калдырмагыз — берәүгә дә күрсәтмәгез.

Егетләр Хужага рәхмәт әйтә-әйтә тиз генә буфеттан чыгып югала. Әмма бер сәгатьтән алар яңадан әйләнеп керәләр һәм гауга куптаралар.

— Син, оятсыз, кыңгыр куллы икән ич, алдагансың. Шешәдә коньяк түгел, гап-гади чәй генә!

— Кем кемне алдагандыр әле? — ди Хужа ачуланып.— Самолетыбыз бер сәгатьтән очып китә, диючеләр сез үзегез түгелме соң? Шуңа карамастан, әле дә булса монда буталасыз. Алдакчы — сез ул!

## Сәнгатьнең көче

1798 елда, император Павел I Казанга килгәч, алпавыт П. П. Есипов патшадан публичный театр ачарга рөхсәт сорый. Театр труппасы алпавытның крепостной артистларыннан төзелә. Тора-бара театрга Казан татарлары да йөри башлый.

Бервакыт Есипов театрында «Мөхәммәт» исемле трагедия куела. Залда татарлар да күп була. Сәхнәдә чалмалы Мөхәммәт күренүгә татарлар арасында ыгы-зыгы куба: «Алла, алла»,— дип кычкырып алар театрдан чыгып чабалар; бер өлеше исә сәхнәдәге актерны үзләрен кяферләр җыелышына йөргәннәре өчен шелтәләргә килгән чын «Мөхәммәт рәсүл аллаһ» дип кабул итә. Һәм тиз генә аяк киемнәрен салып атып, «Алла, алла» дигән сүзләр белән ярлыкауны, гафу итүне сорап йөзтүбән егылалар.

Бу вакыйгадан соң алар бик озак вакытлар театрга йөрмәгәннәр, имеш.

## Күңел күзе

Күренекле татар шагыйре Шәмсетдин Зәки (1821—1865), сукыр булуына карамастан, искиткеч хәтерле, гаҗәеп дәрәҗәдә зиһенле, сөйләүләргә караганда, кайбер күзле кешеләрдән дә тизрәк һәм күбрәк йөри торган кеше була. Шуңа күрә кайберәүләр аның сукырлыгына шикләнеп караганнар.

Ашказар-Балыклы авылы мәдрәсәсендә укыганда ул 20 чакрым ераклыктагы Кара Киртә авылына бер үзе кайтып йөри торган була. Анда шагыйрьнең туганнары яшәгән. Шулай беркөнне Ашказар-Балыклы авылының бер кешесе, Ш. Зәкине сынау нияте белән, ул узачак юл кырыена барып ята. Шагыйрь бу кеше турысына килеп җиткәч:

— Әссәламегаләйкем, Шаһмөхәммәт абзый, монда нишләп ятасың? — дигән.

Шаһмөхәммәт үз нәүбәтендә:

— Сине күрми дип әйтәләр иде, күрәсең икән,— дип җавап биргән.

Шагыйрь:

— Күңел күзе күргәч, заһир (ачык күренеп торучы) күзнең күрмәве зарар бирми,— дип, юлын дәвам иткән.

## Башка чара калмагач

1925 елда беренче татар операсы «Сания»нең музыкасы язылып беткәч, ниһаять, репетицияләр башлана. Рольләр бүленә. Сания партиясе Зөһрә Бәйрашева белән Разия Садыйковага бирелә. Зариф ролен Әхәт Хисамов башкарырга алына. Зыя образын Газиз Әлмөхәммәтов ала. Ә менә Старостага җырчы табылмый. Кире тип булганлыктан, аны беркем дә алырга теләми. Соңыннан әлеге партиягә, башкару осталыгы чамалы булса да, композитор Солтан Габәши үзе алынырга мәҗбүр була.

«Кызыклы хәлләр»не бу санга Җәүдәт Миңнуллин әзерләде.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1985 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


Михаил Сергеевич Горбачев. № 4.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү. № 4.

1985 елның 11 мартында КПСС Үзәк Комитеты Пленумында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш М. С. Горбачев речь. № 4.

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына мөрәҗәгате. № 4.


## ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ.


Татарстан АССР Язучылар союзын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләү турында. № 2.


## КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ.


1985 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында. № 7.


## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА


Баян Н. Хат язсам да. Шигырь. № 5.
Безнең авылдан да сугыш узды. Балалар яза. № 5.
Горшунов Ю. Җиңүгә рухландырган җыр. № 5.
Гыйззәтуллин Н. Халык батырлыгы һәм әдәбият. № 5.
Гыйльманов Җ. Бөтенесе — фронт өчен. № 5.
Давыдов Ә. Кулларыма. Шигырь. № 5.
Кутуй Г. Туган ил. Шигырь. № 5.
Мәҗитова Г. Музалар тын тормады. № 4.
Мөдәррис Ш. Күп булса да. Шигырь. № 5.
Насыйров Т. Үзәк нәшриятлар — Казанда. № 4.
Низамиев М. Сүнмәс балкыш. № 3.
Нури З. Фронт мәзәкләре. № 5.
Рафиков М. Ил кызлары. № 3.
Сабирҗанов Г. Җиңелмәс туганлык. № 5.
Хафизов С. Шагыйрьләр һәйкәле. № 7.
Хуҗин М. Ярамый, ярамый! № 4.
Хәтергә иң тирән уелганнардан. Фронтовик язучылар түгәрәк өстәл янында. № 5.
Яковлев А. Генерал язмалары. № 5.
Әхмәтгалиев М. Прикладка куеп язылган хатлар. № 5.
Җәләлов А. Кызларыбыз — яу батырлары. № 3.
Җәләлов А. Каһарманлык елъязмасы. № 5.
1946—1985: ике фото. № 5.
Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларыбыз. № 5.


## ПРОЗА

### «БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА


Кәримов К. Көзнең соңгы төне. Хикәя. № 1.
Латыйпов К. Яшьлек рәхмәте. Хикәя. № 4.
Фәизов Р. Ике тапкыр ветеран. Хикәя. № 2.
Хуҗин М. Бәхет җире. Хикәя. № 3.
«Батырлык дәвам итә» конкурсы йомгаклары. № 5.
Галиев Ә. Асыл кошым минем. Повесть. № 1.
Дәүли Н. Язмышка юл. Повесть. №№ 8, 9.
Дәүләтказин Г. Югалту. Хикәя. № 8.
Еники Ә. Соңгы китап. Сәхифәләр. №№ 1, 2.
Измайлова Н. Яшьлек шаярулары. Хикәя. № 8.
Ишморатова Р. Рәйханә. Повесть. № 5.
Камалов Х. Безне өйдә көтәләр. Роман. №№ 4, 5, 6.
Кашапов Г. Язмышыңа ышан. Роман. №№ 3, 4.
Мөхәммәдиев Р. Ак кыялар турында хыял. Повесть. № 6.

Несин А. Эт койрыгы. Ватан вазифасы. Хикәяләр. № 8.
Нуруллин В. Ике урам арасы. Повесть. №№ 9, 10.
Низамиев Р. Урман эчләрендә урман. Повесть. № 2.
Паушкин Г. Үткел. Хикәя. № 5.
Рәхимов Җ. Бурыч. Хикәя. № 1.
Салахов И. Иманнар тамыр җәйгәндә. Роман. №№ 11, 12.
Сабиров С. Сыерчыклар ни дип сайрый? Хикәя. № 11.
Төхфәтуллин Р. Кояшлы яклар гөле. Хикәя. № 7.
Фәтхетдинов З. Кем — кемне... Повесть. №№ 10, 11.
Юхма М. Көнгыш — үлемсезлек кошы. Повесть. № 7.

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Гыйматдинова Н. Соңгы очрашу. Хикәя. № 7.
Гыйсметдинов Д. Юмористик хикәяләр. № 7.
Хәсәнов А. Фатиха. Хикәя. № 9.

ОСТАХАНӘ

Хәсәнов Н. Инешемдә — гомер агышы. Хикәя. № 7.
Бәширов Г. Яшьләргә өмет. № 7.

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

Гыйсметдинов Д. Оят түгелме? Тормыш юлы. № 12.

## ДРАМАТУРГИЯ

Гаффар Ә. Сызылып таңнар атканда. Романтик драма. № 8.
Миңнуллин Т. Әниләр һәм бәбиләр. Драматик хикәя. № 6.
Юзеев И. Онытылмас бәет. Драма. № 11.

## ПОЭЗИЯ

Акчурин М. Шигырьләр № 12.
Арсланов Н. Сугышчы төше. Шигырь. № 5.
Арсланов Н. Яшенле төндә. Шигырьләр. № 9.
Афзал Г. Муса Акъегет. Шигырьләр. № 7.
Баянов Ә. Тынлык эше. Шигырьләр. № 6.
Гадел Ә. Моң. Шигырьләр. № 11.
Галиев Ш. Мәкерле миналар. Шигырьләр. № 1.
Гатауллин Р. Мәхәббәткә мәрхәмәт! Шигырьләр. № 3.
Гәрәй Р. Күңелемдә яфрак яралар. Шигырьләр. № 10.
Исхак Ә. Кызыл кошлар. Шигырьләр. № 4.
Латыйп Г. Бик кадерле бит ул Туган туфрак. Шигырьләр. № 11.
Латыйп К. Куллары белән. Шигырь. № 5.
Латыйп К. Уй сәяхәте. Шигырьләр. № 10.
Маликов Ә. Тугрылык. Поэма. № 5.
Мансуров З. Кылдан нечкә, кылычтан үткен. Поэма. № 12.
Миңнуллин Р. Яхшылык. Шигырьләр. № 9.
Муллагалиев С. Ничек дөнья суынсын. Шигырь. № 12.
Мөхәммәтшин Г. Офыкларым. Шигырьләр № 12.
Нури З. Яратам, яратмыйм. Шигырьләр. № 11.
Рафиков М. Шигырьләр. № 4.
Рәкыйпов Р. Минем Ватан. Шигырьләр. № 12.
Рәхим Г. Оча күңелем. Шигырьләр. № 11.
Рәшитов Ә. Тантана. Шигырь. № 5.
Рәшитов Ә. Атлап килә атлар. Шигырьләр. № 8.
Сафин Ф. Таң. Шигырьләр. № 2.
Синугыл Ә. Сәфәр җилләре. Шигырьләр. № 8.
Сөләйманов Б. Тайга аланында. Шигырьләр. № 10.
Фәйзуллин Р. Туган халкым. Шигырьләр. № 9.
Харис Р. Ант суы. Поэма. № 1.
Хикмәт Н. Егерме сигез хикәясе. Поэма. № 5.
Хәким С. Тукайга. Шигырьләр. № 2.
Хәким С. Йолдыз. Шигырь. № 5.
Хәлиуллина Р. Чаң. № 10.
Хөснуллин Х. Алтынчы автобус бара. Шигырьләр № 12.
Хөсәен М. Җиңүче каһарманга. Шигырьләр. № 12.
Яруллин Ф. Сирәгәя бара. Шигырьләр. № 8.
Әгъләмов М. Синең кулда каләм. Шигырьләр. № 6.
Әхмәдиев Н. Кышкы учак. Шигырьләр. № 12.
Әхмәтҗанов Роберт. Сәхипҗамал. Поэма. № 4.
Әхмәтҗанов Рәшит. Томаннарда адашкан кош. Шигырьләр. № 8.
Әюпов Х. Гамәл дәфтәре. Шигырьләр. № 2.

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Булатова К. Әлмәт урамында. Шигырьләр. № 3.
Галиева Ф. Яшәү — бәхет. Шигырьләр. № 3.
Туктарова В. Язгы нурлар. Шигырьләр. № 3.
Фәйзуллина М. Салют биргән. Шигырьләр. № 3.

Шәфикова К. Бишекләр. Шигырьләр. № 3.

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Акмалов Н. Җыр елгасы. Шигырьләр. № 2.
Газизов Р. Безнең яшьлек. Шигырьләр. № 7.
Гайфуллина А. Иске җыр. Шигырьләр. № 3.
Закиров Р. Сагыну хисе турында баллада. Шигырьләр. № 7.
Зәйдуллин Р. Ана. Шигырьләр. № 4.
Леронов Л. Бүгенгедән — килер көнгә. Шигырьләр. № 7.
Моратов Г. Мин дөньяны тыңлыйм. Шигырьләр. № 7.
Мәхмүдов Ә. Сызлаган җан монологы. № 7.
Салихова Д. Җыр. Шигырьләр. № 3.
Садә Г. Кура ярында. Шигырьләр. № 10.
Сәлимов Г. Кафедагы песи. Шигырьләр. № 2.
Фәйзуллин Р. Мәңгелек ут яна мәйданнарда. Шигырьләр. № 7.

ЮМОР-САТИРА

Кизәнов. Ораторга киңәш. Шигырьләр. № 3.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Байбурин Г. Диңгез. Шигырьләр. № 12.
Байзаков Т. Үрлә. Шигырьләр. № 2.
Бүкиев У. Ялгыз аучы. Повесть. № 12.
Каирбәков Г. Бодай бөртеге. Шигырьләр. № 12.
«Калевала». Эпостан өзек. № 7.
Конанбаев А. Ак көмештәй. Шигырь. Мирас... Хикәя. № 7.
Мулдагалиев Җ. Күңел тавышы. Шигырьләр. № 12.
Муртазаев Ш. Чикерткә җыры. Хикәя. № 12.
Мәүленов С. Уйлану. Шигырь. № 12.
Садай В. Томан исе. Хикәя. № 6.
Сениэль М. Фестиваль. Шигырьләр. № 6.
Сулейменов О. Куып тот. Шигырьләр. № 2.
Сәрби Р. Нарат. Шигырьләр. № 6.
Токумаев Җ. Кем алдакчы? Хикәя. № 12.
Ухсай Я. Иванов урманы. Шигырьләр. № 6.
Уяр Х. Котлау хаты. Хикәя. № 6.

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Абдуллин Ф. Ышаныч. Очерк. № 4.
Гыйләҗев А. Шәһәр юллары авылга илтә. № 3.
Зарипов М. Күңелләргә юл ярганда. № 1.
Зарипов М., Подольский А. Алтын орлык. № 10.
Зарипов М. КамАЗ ныклыгы. № 11.
Рәхимов Җ. Ерактагы биләмәләр. № 9.
Шәймиев М. Ш. Икмәк һәм су. № 6.

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Бәйрәмова Ф. Ак төннәр илендә. № 3.
Низамиев Р. Геройлар — тормышның үзендә. № 7.
Хәсәнов А. Кайсы ысул кулайрак? № 7.

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Вәлиев Н. Җырлы як (Сарман). № 12.
Гыйматдинов Г. Тиңнәребез арасында (Норлат-Октябрь). № 6.
Каюмов Д. Без — Тукай якташлары. (Арча). № 11.
Нигъмәтуллин И. Юлларыбыз үргә таба (Саба). № 8.
Стекольщиков В. Кама суы буенда (Чистай). № 7.
Төхбәтуллин С. Без — Ленин якташлары (Чүпрәле). № 9.
Хәйретдинов Х. Гөлбакчада яшибез (Зеленодольск). № 10.

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Абдуллин Р., Харис Р. Кама Аланы. Җыр. № 9.
Кәмалов Б. Төп һөнәрләре — өйрәнү. Очерк. № 10.
Кашапов Г. Язмышыңа ышан. Роман. №№ 3, 4.
Тимбикова К. Ут кирәк, ут! № 12.
Якупов Р. Кама Аланының яңа күренеше. № 11.
Әмирханов М. Гаризалар. Очерк. № 7.

* * *

Галиуллин Т. Уртак елга — катлаулы уйлар. Австрия республикасына сәяхәт. № 3.
Измайлов Р. Көрәш дәвам итә. № 9.
Хисмәтуллин Р. Тамырлар тибеше. № 2.

1985 ЕЛ — ХАЛЫКАРА ЯШЬЛӘР ЕЛЫ

Әшрәфҗанов Х. Фестиваль балкышы. № 7.

## ЮБИЛЕЙЛАР

МАРИЯ АЛЕКСАНДРОВНА УЛЬЯНОВАНЫҢ ТУУЫНА — 150 ЕЛ

Сәйдәшева М. Иң бәхетле ана. № 3.

ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 115 ЕЛ

Миндубаев Ж. Юлбашчы яшәгән гаиләдә. № 4.
Скворцов В. Ленинның беренче шәкерте. № 4.

МУЛЛАНУР ВАХИТОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Беляев Р. Революционер-ленинчы. № 8.
Краева Л. Кыйммәтле ядкарьләр. № 8.
Лайпанов К. Мулланур Вахитовның дусты һәм көрәштәше. № 8.
Мулюков М. Мөселман социалистлар комитетын төзүче. № 7.
Низамов И. Иделдән бер хатирә. № 8.
Нәфиков Р. Ленинның көрәштәше. № 6. Ул безнең арада. № 8.
Хәйретдинов Р. Дәүләт эшлеклесе. № 8.
Чанышев Я. Мәңге исән Мулланур. № 7.
Юхма М. Көнгыш — үлемсезлек кошы. Роман. № 7.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Абдуллин Я., Әмирханов Р. Революцион-демократик идеология һәм XX йөз башында әдәби хәрәкәт. № 10.
Акбиев С. Габдулла Тукай һәм Дагстан халыклары әдәбияты. № 12.
Гобәйдуллина Э. Тукай исемендәге театр. № 10.
Иксанов М. Зуп-зур Тукай булдым. № 4.
Мингалим Р. Сагыну. Шигырь. № 4.
Рәшитов Ә. Тукай клубы. № 6.
Сафиуллина Ф. Шагыйрьнең бер тәрҗемәсе. № 11.
Турдыев Ш. Тукай һәм үзбәк әдәбияты. № 9.
Хаҗиәхмәтов Т. Уральскида Тукай урыннары. №№ 1—4, 6—12.
Әгъзамов Ф. Тукай — публицист. № 1.
Әхмәрова Н. Шагыйрьне без дә күрдек. № 3.

ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Гайсин Р. Бер сюжетның сере. № 12
Гобәйдуллина Э. Уртак уйлар. № 12
Хисамов А. Хакыйкатькә юл ярганда. № 12
Әмирханов Р. Фатих Әмирхан ядкаре № 12.
Әмирханов Ф. Минем тормыш юлым. № 12

ШАКИР МӨХӘММӘДОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Мөхәммәдев Ш. Максат. «Карчыга» журналыннан. № 7.
Әмирханов Р. Давыллы чор җырчысы. № 7.

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Вәзиева Ж. Хезмәт кешесе иде. № 9.
Гыйззәтов К. Әти турында. № 9.
Гыйззәтов Р. Ял вакытында. № 9.

ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Хамматов Ш., Тәхау К. Ике әдип дуслыгы. № 1.
Максуд Х. Яшьлек истәлеге. № 1.

* * *

Есенин С. Шигырьләр (туувына 90 ел тулу уңаеннан). № 10.
Гыйлманов Г. Кояшлы шигърият (Ш. Бабичның туувына 90 ел). № 2.
Гайнуллин М., Вәзиева Ж. Заһидә Бурнашева (туувына 90 ел тулу уңаеннан). № 10.
Миңнуллин Ж. Фидакарьлек (Н. Исәнбәткә 85 яшь). № 3.
Баттал С. Яктырту. Шигырьләр (80 яшь тулу уңаеннан). № 10.
Ихсанова Л. Каләмдәшне сагынганда (А. Әхмәтнең туувына 80 ел). № 3.
Юзиев Н. Әдәбиятка олы мәхәббәт (Г. Халитка 70 яшь). № 6.
Бикчурина Ф. Бәхет китерүче осталык (А. Аббасовка 60 яшь). № 1.
Госманов М. Игелекле хезмәт (Ә. Кәримуллинга 60 яшь). № 8.
Мусин Ф. Олы юлдан (Г. Ахуновка 60 яшь). № 9.
Мәхмүтов Х. Җырга гашыйк галим (И. Надыйровка 60 яшь). № 4.
Насыйбуллин М. Шөбһә. Хикәя. (60 яшь тулу уңаеннан). № 10.
Рафиков М. Бераз гына үзем турында (60 яшь тулу уңаеннан). № 4.
Шәрифуллина Н. Моң тамырсыз булмый (А. Монасыйповка 60 яшь). № 7.
Галимуллин Ф. Такыялар балкышы (М. Маликовага 50 яшь). № 9.
Гурарий С. Халык моңына сарылып (Ф. Әхмәтовка 50 яшь). № 4.
Исхакова-Вамба Р. Үз аһәңе бар. (И. Якуповка 50 яшь). № 10.
Миңнуллин Ф. Ягымлы геройлар (В. Нуруллинга 50 яшь). № 4.
Шабаев М. Шигъри материклар Колумбы (В. Хлебниковның туувына 100 ел). № 12
Яктылыкка, нурга илтә. (Т. Миңнуллинга 50 яшь). № 9.
Җырлап яшәргә! (И. Шакировка 50 яшь). № 2.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. Егермедәгеләр. № 1.
Кукушкин Р. Диңгезче егет моңы. № 3.
Мусин Ф. Детектив турында. № 10.
Хатипов Ф. Үткәннәр аша — киләчәккә. № 11.
Уңай герой — төп юнәлеш. № 8.

ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

Вәлиев Д. Мәңгелеккә өч сәяхәт. № 2.

Мостафин Р. Несин белән очрашулар. № 8.
Нури З. Яшел диңгездәге көяшлы утрау. № 2.
Хәсәнов М. Икмәк — тормыш ул. № 6.
Мөхәммәдиев Р. Чаңны кем дип кагалар... № 12.

##### ИСТӘЛЕКЛӘР. ХАТЛАР

Габдрахман Әпсәләмов хатлары. № 7.
Гатина Х., Гыйләҗетдинова А. Җәлил турында истәлекләр. № 2.
Хәсәнов М. Яшел роза. № 11.

##### БИБЛИОГРАФИЯ

Алишев С. Болгар-татар тарихына яңа китап. № 2.
Бакиров М. Балалар фольклоры. № 3.
Вәлиев Ф., Исхакова С. Себер татарлары турында. № 9.
Гайнетдинов М. Татар хрестоматияләре. № 2.
Госманов М. Татар фольклористикасының яңа казанышы. № 7.
Елькович Л. Гүзәллек ничек туа? № 7.
Миңнуллин Ж. Азатлык җырчысы. № 10.
Мәхмүтов Х. Исемнәр — тарих хәбәрчеләре. № 2.
Наджафов М. Традицияләр яңарганда. № 12.
Саттарова Л. Сынлы сәнгать елъязмасы. № 11.
Скоробогатов В. Каһарманнар елгасы. № 6.
Сәхәпов Ә. Яңу. № 4.
Урманчеев Ф. Зур мирасның җитди өлеше. № 9.
Фәйзуллаева М. Еллар һәм җырлар. № 11.
Фәйзуллин М. Сәнгатькә юл ярганда. № 2.
Юзиев Н. Тынгысыз рухлы китап. № 12.

##### ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Ибраһимов А. Тирән фикерле әсәр. № 1.
Фәттах Н. Татар шигърияте күгендә. № 1.
Уйландыра, тәэсир итә. № 10.

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Гыйләҗев И., Литвин А. Россиядәге 1905—1907 еллар революциясе Казанда. № 2.
Ломидзе Г. Сүнмәс нур. № 2.
Хәким С. Буыннар авазы. № 2.
Хәсәнов М. Шигъриятнең саф, раушан күзгесе. № 2.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я. Күренекле мәгърифәтчебез. № 4
Горшков В. Үлемсез «Шүрәле». № 8
Гыйләҗетдинова А., Гатина Х. Җәлил турында истәлекләр. № 2.
Исмәгыйлов Н. Гасырларны кичкән сюжет. № 9.
Кәримуллин Ә. Татар китаплары кайда саклана? № 7.
Таминдарова Т. Үткән еллар кайтавазы. № 8.
Һилалов И. Беренче ташны салганда № 8.

## СӘНГАТЬ

Хәйруллина З. Җыр да җиңү яулашты. № 7.
Әһлиуллина Ф. Ташны җырлату авырмы? № 3.
Әһлиуллина Ф. Чынлыкка омтылу. № 10.
Әлмиева Н. Җырлап ачыла күңел. № 9.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Н. Лаисов, Р. Рәкыйпов, Н. Хисамов. № 2.
Р. Кожевникова, Л. Шакирҗанова. № 4.
Ә. Мушинский, Э. Шәрифуллина, Н. Әхмәдиев. № 10.

Бер сорауга — бер җавап. №№ 1, 2, 8, 10, 9, 11.
Укучылабрыбыз яза. № 7, 9.
Кызыклы хәлләр. №№ 1, 2, 3, 9, 10, 12.
Культура тормышы көндәлеге. №№ 1—12.

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Горшунов Ю. Исемсез биеклектә. № 3.
Горшунов Ю. Җиңүгә рухландырган җыр. № 5.
Горшунов Ю. Яшь кала. № 12.
Коробцова Л. Тынычлык маршы. № 11.
Николаева Л. Көрәштәшләр. № 8.
Разумейченко В. Җиңүне якынайткан парад. № 1.
Цой В. Җиңү язы таңында. № 4.
Цой В. Хезмәт бәйрәме. № 6.
Цой В. КамАЗ чибәрләре. № 9.
Шаһиева Р. Уралтау эргәсендә. № 7.
Шаһиева Р. Җәлилчеләр. № 2.
Шаһиева Р. Гомер чишмәсе. № 10.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ УКУЫ

31 октябрьдә КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында иҗат интеллигенциясе активы өчен даими эшләүче семинарның яңа уку елындагы беренче занятиесе булды. Аны кереш сүз белән КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова ачты. «Барлык мөмкинлекләрне һәм резервларны — 1985 ел планын һәм социалистик йөкләмәләрне уңышлы үтәүгә, КПССның XXVII съездын лаеклы каршылауга» дигән темага республика культура министры М. М. Таишев, Кинофикация дәүләт комитеты председателе Р. Х. Ногманов, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. С. Мөхәммәдиев, Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин һәм Казан кинохроника студиясе директоры И. Н. Алексеев информацияләр белән чыктылар. Аннары философия фәннәре кандидаты Г. Н. Веневитиков (Мәскәү) «Социалистик яшәү рәвешен тагын да камилләштерүдә сәнгатьнең роле һәм урыны» дигән темага лекция укыды.

## «АЛТЫН БАШАК» ФЕСТИВАЛЕ

Октябрь аенда республикабызда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары катнашында «Алтын башак» дип исемләнгән музыка фестивале булып узды.

Республикабыз игенчеләре өчен уздырыла торган мондый фестивальләр традициягә әйләнә бара һәм аның географиясе дә киңәя.

Фестивальнең беренче очрашуы Питрәч игенчеләре янында булды. Балык Бистәсе, Арча, Лаеш, Зеленодольск районнарында узган фестиваль концертларында РСФСРның халык артисты И. Шакиров, РСФСРның атказанган артисткасы Ә. Авзалова, ТАССРның халык артистлары В. Гыйззәтуллина, Р. Ибраһимова, Г. Ильясов, Ш. Әхмәтҗанов, яшь артистлар И. Биктаһиров, М. Сөнгатуллин, М. Гыйләҗев, Г. һәм М. Мостафиннар, җыр һәм бию ансамбле катнашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫН УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

17 октябрьдә Брежнев шәһәренең «Энергетик» культура сараенда «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булып узды. Конференцияне кереш сүз белән Брежнев язучылар оешмасының җаваплы секретаре драматург Р. Хәмид ачты.

Шәһәрнең күпсанлы әдәбият сөючеләре каршында журналның баш редакторы шагыйрь Р. Харис, поэзия бүлеге редакторы шагыйрь Р. Гатауллин, хатлар бүлеге редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, язучы Г. Кашапов, шагыйрьләр Н. Мадъяров, К. Сибгатуллин, Р. Бәширов, Ф. Баширова, Мәскәүдән килгән шагыйрә һәм тәрҗемәче В. Вәлиева һ. б. чыгыш ясады. Журналның иҗат тормышы, анда басылачак әсәрләр турында төпле сөйләшү, фикер алышу булды.

Саба районы Культура йортында «Казан утлары» журналын укучылар конференциясе булды. Аны КПССның Саба райкомының икенче секретаре З. Г. Шәйхетдинов ачты. Конференциядә чыгыш ясап, район китапханәсе хезмәткәре Р. Хафизова, Саба урта мәктәбе укучысы С. Җиһаншина, «Марс» колхозы савымчысы Д. Билалова, Саба урта мәктәбе укытучысы К. Исмәгыйлева, «1 Май» колхозы китапханәчесе В. Вәлиәхмәтова, Сабада яшәүче шагыйрь Г. Нәбиуллин журнал турында үзләренең фикерләре һәм теләкләре белән уртаклаштылар. Очрашуда катнашучылар Казаннан килгән язучылар Н. Дәүли, М. Мәһдиев, М. Хуҗин, «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре С. Маннапов чыгышларын кызыксынып тыңладылар.

Конференциядә КПССның Саба райкомының беренче секретаре И. Н. Нигъмәтуллин катнашты.

## «КЫЗЫЛ КАУРЫЙЛАР» БӘЙРӘМЕ

Шагыйрә Сажидә Сөләйманова турында хатирәләрне әлмәтлеләр кадерләп саклыйлар. Шәһәрнең бер урамы һәм җирле әдәби берләшмә аның исемен йөртә.

31 октябрьдә Әлмәтнең төзүчеләр Техника йортында С. Сөләйманова иҗатына багышланган «Кызыл каурыйлар» исемле әдәбият-сәнгать бәйрәме үткәрелде. Күркәм традициягә әйләнеп килүче бу бәйрәмдә Әлмәт язучылары Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, К. Булатова, Ә. Гаффар, Э. Мөэминова белән бергә Сарман, Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләреннән, Баулы һәм Җәлил поселокларыннан килгән яшь шагыйрьләр И. Мәрданшин, Т. Шәмсуаров, М. Мостафин, С. Әхмәтҗанов һ. б. лар С. Сөләйманова иҗаты турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен уку-

дылар. Татарстанның халык артисткасы Л. Садыйкова һәм нефть ягы үзешчәннәре башкаруында шагыйрә сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

Бу бәйрәмдә Казаннан язучылар — «Казан утлары» журналының редколлегия члены Н. Фәттах һәм журналның җаваплы секретаре С. Маннапов катнашты һәм чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕҢ МАТУР НӘТИҖӘСЕ

Мәгълүм булганча, моннан берничә ел элек «Казан утлары» журналы белән Татарстан АЭСын төзүчеләр арасында хезмәттәшлек договоры төзелгән иде. Журнал әлеге төзелешкә шефлык итә, аның хезмәтчәннәре белән даими элемтәдә яши. Быел журнал битләрендә Г. Кашаповның «Язмышыңа ышан» дигән романы басылу да шушы хезмәттәшлекнең күркәм бер нәтиҗәсе булды. Татарстан атом электростанциясен төзүчеләргә багышланган бу әсәр укучыларда зур кызыксыну уятты.

26 октябрьдә Тат. АЭС төбәгендә — Кама Аланы поселогында «Язмышыңа ышан» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Чыгыш ясаучы иптәшләр үзләре эшли торган төзелеш турында әсәр язылуны хуплап сөйләделәр, романның уңай һәм кимчелекле якларына тукталдылар. Тормыш һәм әдәбият арасындагы бәйләнеш, уңай герой мәсьәләсе фикер алышуларның үзәген тәшкил итте.

Аннары автор романның язылу тарихын сөйләде, укучыларның сорауларына җавап бирде.

Конференция эшендә Тат. АЭС төзелешенең берләштерелгән парткомы секретаре Р. Кәтиев, СМУ—12 начальнигы Р. Сәлахов, «Казан утлары» журналының проза бүлеге редакторы Р. Низамиев катнашты.

## АЧ. ШИГЪРИЯТ СЕРЛӘРЕННЕ

Татарстан Язучылар союзы һәм Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе тарафыннан оештырылган шигырь кичәләренең быелгы беренчесе шагыйрьләр ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары И. Юзеев һәм Г. Рәхим иҗатына багышланды. Кичә 28 октябрьдә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры бинасында булды.

Кичәдә РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов, РСФСРның атказанган артисты Р. Шәрәфиев, Татарстанның халык артисткасы Р. Ибраһимова, Татарстанның атказанган артисты Р. Сабиров һәм башкалар катнашты.

Кичәдә шагыйрьләр үзләре дә чыгыш ясады.

## ЯЗУЧЫЛАР КЛУБЫНДА

Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубы эшли башлауга 50 ел тулды. Быелгы сезон ачылу шушы датага туры килде.

Клуб тарихы, анда үткәрелгән истәлекле вакыйгалар, очрашулар турында шагыйрь Ә. Рәшитов сөйләде. Әдәбиятыбыз аксакалы Гомәр Бәширов үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Бу кичәгә күп кенә язучы һәм шагыйрьләребез үзләренең яңа әсәрләрен алып килгәннәр иде. Тамашачылар язучы М. Мәһдиев, М. Хуҗин, Ф. Бәйрәмова, шагыйрьләр Г. Зәйнәшева, Р. Харис, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов чыгышларын яратып тыңладылар.

Казанга кунакка килгән чуваш язучысы, М. Вахитов турында язылган китапның авторы М. Юхма тугандаш әдәбиятлар дуслыгы хакында сөйләде, үзенең яңа шигырьләрен укыды.

Кичәнең концерт өлешендә РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Ә. Авзалова, җырчылардан Х. Хәсәнова, И. Биктаһиров һ. б. лар катнашты.

## АЗАТ АББАСОВКА —60 ЯШЬ

22 октябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында СССРның халык артисты Азат Аббасовка 60 яшь, аның иҗат эшчәнлегенә 35 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне ТАССР культура министры М. М. Таишев ачты. ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов юбилярны җылы тәбрикләде һәм аңа Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы тапшырды. Азат Аббасовның тормыш һәм иҗат юлы турында РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе профессор Ш. М. Сарымсаков сөйләде.

Юбилярны республикабызның партия, совет һәм профсоюз оешмалары, хезмәт коллективлары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, А. Аббасовның туган ягы — Алабуга районы вәкилләре, Башкортстаннан килгән кунаклар котлады.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты.

Кичәнең икенче өлешендә А. Аббасов, опера һәм балет театры артистлары катнашында концерт булды.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

29 октябрьдә Казанның Актерлар йортында Татарстанның халык артисткасы, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Сара Садыйкованың иҗат кичәсе булды. Үзләренчә тамашачылар өчен җыр бәйрәменә әйләнгән бу кичәдә композиторның яңа җырлары белән бергә, инде халыкта киң таныл

тапкан җырларын Татарстанның халык артисты У. Әлмиев, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев, җырчы Л. Хәсәнова башкарды.

## ХЕЗМӘТ һӘМ ҖЫР ТУГАНЛЫГЫ

19—23 сентябрьдә Балтач районында РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. И. Глинка исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты композитор Ф. Әхмәтовның иҗат кичәләре, игенчеләр белән очрашулары зур уңыш белән узды.

Әлеге кичәләрдә, очрашуларда композиторның төрле елларда язылган җырлары, яңа әсәрләре яңгырады. Тамашачылар Ф. Әхмәтовның тормышы, иҗаты, татар музыка сәнгатенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турындагы әңгәмәсен зур кызыксыну белән тыңладылар.

Татарстанның атказанган артисты М. Галиев, җырчылар Г. Сафиуллина, Л. Хәсәнова композиторның әсәрләрен һәм халык җырларын башкардылар.

## «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ» КУНАКЛАРЫ

2—3 ноябрь көннәрендә Түбән Камада сәнгать бәйрәме булды. Нефтехимиклар шәһәренә РСФСРның халык художнигы, республиканың Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманче һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ф. Әхмәтова килгәннәр иде.

Шәһәр музеенда күренекле рәссамның күргәзмәсе ачылды.

Кунаклар Техника йортында «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе кичәсендә катнаштылар.

## БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ

7—12 октябрьдә Ленинград шәһәрендә «Җир иминлеге өчен» дигән темага язучыларның Бөтенсоюз конференциясе булып узды. Ул Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган иде. Бу конференциягә 100 дән артык күренекле совет әдибе һәм 35 илдән җыелган 60 чит ил язучысы килгән иде. Конференциядә Татарстаннан шагыйрь Р. Фәйзуллин да катнашты һәм чыгыш ясады. Ул шулай ук Ленинградның Яшьләр культура сараенда узган интернациональ шигырь кичәсендә шигырьләр укыды.

## ЯҢА ИҖАТ БЕРЛӘШМӘСЕ

Минзәлә ягы — әдәбиятыбызга һәм сәнгатебезгә шактый талантлар биргән як. Г. Мөхәммәтшин, Г. Зәйнашева, Г. Сабитов, Р. Гәрәй, М. Шабаев, Ф. Сафин, С. Гәрәева, Р. Солнцев һәм башкалар зур әдәбиятка шушы төбәктән юл алдылар.

Бу төбәктә әле дә яшь талантлар үсеп тора. Аларны бергә туплау һәм үстерү максаты белән, күптән түгел район культура сарае каршында «Сибелә чәчәк» исемле әдәбият-сәнгать берләшмәсе оештырылды. Берләшмәнең беренче утырышы аның шеф-консультанты шагыйрь Рәшит Гәрәйнең иҗат кичәсе рәвешендә уздырылды.

## ГАЛЕРЕЯГА 10 ЯШЬ

Әлмәттәге картиналар галереясына 10 ел тулды. Бу вакыйганың үзенчәлеге шунда: галерея яңа бинага күчте. ТАССРның атказанган культура работнигы Г. А. Стефановский инициативасы белән оештырылган сынлы сәнгать сараенда хәзер 700 дән артык картина бар. Бирәдә Мәскәү, Ленинград, Харьков, Рига, Сочи, Куйбышев, Казан һәм илебезнең башка шәһәрләрендә яшәүче танылган рәссамнарның иҗаты белән танышырга мөмкин.

Яңа бинаның әйбәт җиһазландырылган 4 экспозиция залы, сәхнәсе, лекция залы, фонд саклау урыны, эш бүлмәләре бар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Философия фәнен үстерүдәге һәм фәнни кадрлар хәзерләүдәге хезмәтләре өчен СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, философия фәннәре докторы, профессор Яхъя Габдуллович Абдуллинга, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 30 сентябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# ЯШЬ КАЛА

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рауль Нурмөхәммәтовны без төрле жанрларда эшләүче рәссам буларак беләбез. Шулай да ул пейзаж жанрын яратарак төшә, шушы өлкәдә үзен көчлерәк сизә. Рәссам монда да төрлелеккә омтыла. Төрле чорларны чагылдырган әсәрләр арасында без лирик үрнәкләрне дә, геройк-романтик рухлы, әйтик, «Порт» кебек зур масштаблы пейзажларны да күрәбез. Үзгә бер яңалык сирпелеп торган, гадәти булып тоелучы урам, йорт һәм агачларга бөтенләй башкача карауны гәүдәләндергән әсәрләр дә шактый. Мондый картиналар белән танышканда ничектер йомшак җил исеп куйгандай була, әсәрдә сурәтләнгән кояшлы һәм шаулы дөньяга «керү» теләге уяна.

«Яшь кала» дип исемләнгән картина рәссам иҗатында күренекле урын тота. Яшь кала... Түбән Камага багышланган әлеге пейзажда, әйе, бөтенләе белән яшьлек тантана итә: шәһәр үзе дә яшь, хуҗалары да. Картина төзелә торган йорт биеклегендә торып эшләнгән шикелле. Шаулы урам. Кешеләр һәм машиналарның ачык фигуралары әсәрнең «салкынча» яшькелт-соры колоритына җанлылык биреп торалар. Урамның каршы ягында төзү краннары күренә. Искерәк корылмалар янәшәсендә генә заманча күпкатлы йортлар күтәрелә. Рәссам кышкы салкын көннең «халәтен» төгәл итеп бирүгә ирешкән. Композицион чишелеш масштаблылыкны күрсәтүгә, төзелеш романтикасын ачуга хезмәт иттерелгән. Шәһәр киңлеккә дә, биеклеккә дә үсә. Кечкенә урман читендәге агачлар шәһәрнең аерылгысыз пейзажына әверелә. Ерактан күренеп торучы химкомбинат яшьлек каласының символы буларак кабул ителә.

«Яшь кала»... Картина тикмәгә генә шулай аталмаган. Үзәк итеп алынган образ тирән мәгънәгә ия, һәм ул күңелдә иксез-чиксез ассоциацияләр уята. Мондый яңа калалар илебездә күпләп төзелә. Һәр шәһәрнең үзенә генә хас кабатланмас йөзе бар. Пейзаж остасы Рауль Нурмөхәммәтов Түбән Каманың нәкъ менә шундый билгеләрен тотып ала алган. Масштаблылык, оптимизм, романтика... Рәссамның әлеге әсәре әнә шундый сыйфатларны калку күрсәтүе белән кыйммәтле.


**Юрий ГОРШУНОВ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның өлкән фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле драматург Риза Ишморат.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)